# 2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эшчәнлек нәтиҗәләре турында ХИСАП

Казан 2024

# ЭЧТӘЛЕК

СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ТОТРЫКЛЫЛЫКНЫ ТӘЭМИН ИТҮ ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ........ 3
ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ........ 6
БЮДЖЕТ СӘЯСӘТЕ ........ 9
ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАЛАРЫ ........ 13
ТӨП СОЦИАЛЬ КҮРСӘТКЕЧЛӘР ........ 20
МӘГАРИФ ........ 23
СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ........ 32
ХЕЗМӘТ, МӘШГУЛЬЛЕК ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ ........ 38
ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ ........ 51
ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕ ........ 54
МӘДӘНИЯТ ........ 61
КОММЕРЦИЯЧЕЛ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАРГА ЯРДӘМ ИТҮ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ ........ 70
МӘДӘНИЯТ, СОЦИАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ, СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ҺӘМ МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛГӘН ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ СЫЙФАТЫНА БӘЙСЕЗ БӘЯ БИРҮ ........ 74
ТУРИСТЛЫК ........ 76
ЭКОЛОГИЯ ........ 80
ТӨП ИКЪТИСАДЫЙ КҮРСӘТКЕЧЛӘР ........ 89
СӘНӘГАТЬ ........ 94
АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫ ........ 108
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ ........ 114
ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК ........ 119
ИНВЕСТИЦИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ........ 124
ФӘННЕ ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ ҮСТЕРҮ ........ 135
КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫК ........ 143
ЦИФРЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ ........ 152
ДӘҮЛӘТ БЕЛӘН ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ ИДАРӘ ИТҮ ........ 154
КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ТОРУ ........ 159
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КОМИТЕТЛАРЫННАН ҺӘМ ДЕПУТАТ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕННӘН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА СОРАУЛАР ИСЕМЛЕГЕ БУЕНЧА МӘГЪЛҮМАТ ........ 163

## СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ТОТРЫКЛЫЛЫКНЫ ТӘЭМИН ИТҮ ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ

Чикләүләр һәм санкцияләр белән басым ясау дәвам итүгә дә карамастан, 2023 елда уңай тенденцияләр саклап калынды, республиканың төп макроикътисадый күрсәткечләренең үсешенә ирешелде. Предприятиеләр һәм оешмалар күп кенә кыенлыкларның тискәре йогынтысын киметүгә, инвестиция активлыгын һәм күп кенә җитештерү өлкәләрен саклап калуга, кооперациядә яңа элемтәләрне җайга салу эшен дәвам итүгә, логистика бәйләнешләрен үзгәртеп коруга, товар сату өчен яңа базарлар табуга, чит ил товарларын алмаштыруга ирешә алды.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов рәислегендә Татарстан Республикасының социаль-икътисадый тотрыклылыгын тәэмин итү буенча оператив штаб тарафыннан (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы) (алга таба – Оператив штаб), предприятиеләр белән социаль-икътисадый тотрыклылыкны, соңгыларының ярдәм чараларында катнашуын тәэмин итү буенча эш оештырылды.

Фән һәм мәгариф учреждениеләре, инжиниринг компанияләре белән уртак эш дәвам иттерелә. Предприятиеләр өчен республикадагы һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендәге альтернатив товар сатучыларны ачыклау мәсьәләләре тикшереп өйрәнелә.

Товар сату базарларын киңәйтү һәм эре заказчылар белән хезмәттәшлекне җайга салу максатларында даими рәвештә товар китерүче көннәре, республика предприятиеләре вәкилләре катнашында түгәрәк өстәлләр уздырылды.

Оператив штаб һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы коллегиясе уртак утырышының 2023 елның 21 мартындагы ПР-62 номерлы беркетмәсе нигезендә 2023 елда Социаль-икътисадый тотрыклылыкны һәм Татарстан Республикасы икътисадын үстерүне тәэмин итү буенча чаралар планы («Юл картасы») (алга таба – Чаралар планы) хупланды. Чаралар планы барышы ел әйләнәсендә даими рәвештә Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов уздырган киңәшмәләрдә каралды.

2023 елда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 18 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) үз эшен дәвам итте.

Эш төркеменең 38 утырышы уздырылды, аларда түбәндәге төп мәсьәләләр каралды:

2023 елда Чаралар планының үтәлешенә мониторинг ясау;

предприятиеләрнең чимал, материаллар, компонентлар белән тәэмин ителеше;

предприятиеләрнең федераль һәм республика ярдәм чараларында катнашуы;

социаль әһәмияткә ия булган товарларга бәяләргә мониторинг ясау һәм аларны контрольдә тоту;

дөньякүләм сәүдәне җайга салу һәм Татарстан Республикасы предприятиеләре өчен киләчәктәге мөмкинлекләр;

кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү, шул исәптән Республика маркетинг үзәге эше өлешендә дә, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары экспорты, сәнәгать паркларын, электрон сәүдәне үстерү;

2024-2026 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразларын булдыру;

Татарстан Республикасының система тәшкил итүче оешмаларының финанс-икътисадый хәлен мониторинглау һәм контрольдә тоту;

инвестиция активлыгына, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында инвестиция климаты торышы илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы инвестиция климаты торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 30 декабрендәге 1459 номерлы карары кысаларында да, этәргеч бирү;

илкүләм проектларны гамәлгә ашыру;

2030 елга кадәр төп торак пунктларының һәм алар тирәсендәге территорияләр – авыл агломерациясенең озак вакытка исәпләнгән социаль-икътисадый үсеш планнарын төзү;

республиканың моношәһәрләрендә башлангыч белән чыгучылар тарафыннан инвестиция проектларын башкару өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү һәм (яисә) төзекләндерү буенча чараларны финанслауга ВЭБ.РФ га заявкалар әзерләү;

Татарстан Республикасының алгарышлы үсеш территорияләрен үстерү;

контроль органнарның рәсми сайтларында муниципаль контрольне алып бару, профилактика визитларын уздыру;

муниципаль хезмәтләр күрсәтү срокларын үтәү;

муниципаль дәрәҗәдә җайга салу йогынтысын һәм экспертиза уздыруны бәяләүне уздыру;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең коммерциячел булмаган секторын үстерү.

Эш төркеме утырышларында федераль дәүләт хакимияте органнары һәм оешмалар вәкилләре, шул исәптән Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының икътисадый сәясәт буенча комитеты рәисе М.А. Топилин, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Хезмәт җитештерүчәнлеге, капитал салуларны яклау һәм аларга ярдәм итү департаменты директоры А.В. Молодцов, «Россия экспорт үзәге» АКБО вице-президенты А.В. Солодов, «МСП» корпорациясе» АҖ МСП субъектларының кооперация бәйләнешләрен үстерү дирекциясе җитәкчесе урынбасары Е.А. Козырева, Женева шәһәрендә Россиянең ВТО каршындагы даими вәкиле Д.В. Лякишев, ВТО мәсьәләләре буенча экспертиза үзәге киңәшчесе М.Ю. Медведков һ.б. актив катнашты.

Эш төркеме Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының икътисадый сәясәт буенча комитеты рәисе М.А. Топилин белән бергәләп Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән «ТГК-16» АҖ, «ТАГРАС» холдингы, «Кама» сәүдә йорты» ҖЧҖ, «Татэнерго» АҖ, «ТАИФ-НК» АҖ, НИЦ «Инкомсистем» ЯАҖ республика предприятиеләре тәкъдимнәрен Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Түбәндәге товарларга карата Россия Федерациясе Граждан кодексының, аларның Россия Федерациясе территориясеннән читтә хокукка ия булган (патентка ия булган) затлар тарафыннан, шулай ук алар ризалыгы белән әйләнешкә кертелгән булулары шарты үтәлгәндә, 1252, 1254 статьялары, 1286.1 статьясының 5 пункты, 1301, 1311, 1406.1 статьялары, 1446 статьясының 1 пунктчасы, 1472, 1515 һәм 1537 статьялары нигезләмәләре

кулланылмый торган товарлар (товарлар төркеме) исемлеген раслау турында» 2023 елның 21 июлендәге 2701 номерлы боерыгына кертү мәсьәләләре эшләнде.

Федераль һәм республика ярдәм чаралары (ташламалы кредитлар, займнар һәм субсидияләр) кысаларында система төзүче предприятиеләргә 75,1 млрд сум күләмендә һәм республиканың кече һәм урта бизнес предприятиеләренә 87,3 млрд сумлык ярдәм күрсәтелде.

# ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ

## Илкүләм проектлар

2018 елда Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин тарафыннан Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары билгеләнде (Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы һәм «2030 елга кадәр Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы).

Аларга ирешү инструментлары – илкүләм проектлар. Алар, беренче чиратта, илнең бар халкының яшәү шартларын яхшыртуга һәм уңайлы шартлар булдыруга юнәлтелгән.

2023 елда Татарстан Республикасында 13 илкүләм проектлары максатларына ирешү өчен 50 төбәк проекты чаралары үтәлде. Аларны финанслау күләме 46,0 млрд сум, шул исәптән федераль бюджеттан – 30,9 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан – 15,1 млрд сум тәшкил итте.

Илкүләм проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2023 елда республиканың муниципаль берәмлекләрендә 398 социаль әһәмиятле капиталь төзелеш объекты һәм 189 юл челтәре объекты төзелде һәм төзекләндерелде, шул исәптән:

8 гомуми белем бирү мәктәбе төзелде: Арча муниципаль районында (1 мәктәп), Тукай муниципаль районында (1 мәктәп), Чаллыда (2 мәктәп), Казан шәһәрендә (4 мәктәп), шулай ук «19 номерлы гимназия» МБМУга 300 урынлы өстәмә корпус (Казан шәһәре);

һәрберсе 220 урынга 2 балалар бакчасы (Казан шәһәре);

парклар һәм скверларны кертеп, 54 җәмәгать урыны төзекләндерелде;

2 спорт залы капиталь төзекләндерелде (Чүпрәле һәм Теләче муниципаль районнары) һәм 2 яшьләр үзәге («Вертолет» Казан шәһәре, «Креатив процесслар фабрикасы» Әлмәт шәһәре);

151 сәламәтлек саклау объекты, шул исәптән фельдшерлык-акушерлык пункты (ФАПлар), хастаханәләр, поликлиникалар һәм табиб амбулаторияләре төзелде һәм төзекләндерелде;

28 мәдәният һәм иҗади үсеш объекты төзелде һәм төзекләндерелде, шул исәптән: 22 авыл мәдәният йорты, 4 музей, балалар музыка мәктәбе (Түбән Кама шәһәре), «Зеленодольск музыкаль театры» МБУ (Зеленодольск шәһәре);

республиканың муниципаль районнарында 17 су белән тәэмин итү инженерлык-хуҗалык челтәре, канализация һәм җылылык тәэминаты, биологик чистарту корылмалары, шулай ук су тәэминаты һәм су агызу системалары объектлары төзелде;

11 урам-юл челтәре объектлары төзелде һәм төзекләндерелде: гомуми кулланыштагы автомобиль юллары, торак комплекслары, шулай ук Мәләкәс елгасы аша салынган күпер астыннан әйләнгеч юл һәм Чаллы елгасы күпере аша чыгу юлы (Чаллы шәһәре);

Казан шәһәрендәге Самосырово полигонын рекультивацияләү уздырылды һәм Берсут елгасы кушылдыгы (Мамадыш муниципаль районы) чистартылды;

Түбән Кама сусаклагычы акваториясендәге Озерный чыганагының эшләми торган торбаүткәргечләре сүтелде;

республиканың 10 муниципаль районында гражданнарны тузган торак фондыннан күчерү өчен 109 фатир сатып алынды;

189 юл челтәре объекты норматив хәлгә китерелде (409,0 километрдан артыграк юл төзелде, төзекләндерелде һәм яңартып корылды);

Казан шәһәрендә (Иске Татар бистәсе) һәм Алабуга шәһәрендә туристлык маршрутлары төзелде, фотозоналарны яктырту оештырылды, җәмәгать санитария узеллары төзекләндерелде, бәйрәм чараларын уздыру өчен сәхнәләр һәм мәйданчыклар корылды;

«Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе базасында (Казан шәһәре) Туристлык өлкәсенең кадрлар потенциалын үстерү һәм яңадан һөнәри әзерлек бирү программалары буенча укыту үзәге төзелде.

2024 елда төгәлләү планлаштырылган чараларны үтәү дәвам иттерелде:

2 гомуми белем бирү мәктәбе: Лаеш муниципаль районының Усад авылында 1 501 урынлык мәктәп һәм Казан шәһәренең «Весна» торак комплексында 1 224 урынлык мәктәп (2023–2024 еллар);

Казан шәһәрендә канализацияне биологик чистарту корылмаларын (БОСК) яңартып кору (2021–2024);

Казан шәһәренең биологик чистарту корылмаларының елылы кырларын кулланырга яраклы итеп торгызу (2021–2024);

Саба муниципаль районының Шәмәрдән поселогында нефтьле пычраткычлар белән пычратылган җирләрне файдаланырга яраклы итү (2023–2024 еллар);

Моннан тыш, социаль әһәмияткә ия мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният һәм спорт объектларын цифрлы нигезгә кору һәм аларның матди-техник базасын яхшырту өчен җиһазлар сатып алынды.

Эшкуарларга ярдәм чаралары күрсәтелде, балалы гаиләләргә социаль түләүләр бирелде, яшьләр белән эш алып барылды.

2023 елда илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы барлык 167 күрсәткечнең дә максат итеп куелган дәрәҗәсенә житә алды, планлаштырылган барлык чаралар да үтәлде.

Илкүләм проектларны гамәлгә ашыру барышында түбәндәге күрсәткечләргә ирешелде:

балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге – 100 процент (2023 ел планы – 100 %);

5 яшьтән 18 яшькәчә 80 проценттан артык  балага өстәмә белем бирелә (2023 ел планы – 77,2 %);

62,9 % граждан системалы төстә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнә (2023 ел планы – 58,2 %);

бер үк вакытта күпме кеше сыйдыра алу ягыннан чыгып караганда гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителгәнлеге 71,7 % тәшкил итте (2023 ел планы – 71,7 %);

хезмәт яшеннән узган гражданнарга, диспансерлаштыруны да кертеп, профилактик тикшеренүләр уздыру – 69,2 % (2023 ел планы – 65,3 %);

җәмәгатьчелек фикере буенча халыкның медицина ярдәме күрсәтүдән канәгатьлеге – 59,3 % (2023 ел планы – 55 %);

кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә эшләүчеләр саны, шәхси эшкуарларны да

кертеп – 859,7 мең кеше (2023 ел планы – 718,4 мең кеше);

электрон рәвештә күрсәтелгән массакүләм социаль әһәмияткә ия дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өлеше – 100 % (2023 ел планы – 95 %);

торак төзелеше күләме – елына 3,4 млн кв. м (2023 ел планы – елына 2,83 млн кв. м);

293 җәмәгать урыны төзекләндерелде (2023 ел планы – 293).

2024 елда 49 төбәк проектының чараларын гамәлгә ашыруга 25,8 млрд сум күләмендә лимит билгеләнде, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан – 14,3 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан – 11,5 млрд сум.


Республикада социаль әһәмияткә ия булган учреждениеләрне төзү, төзекләндерү һәм матди-техник базаларын яхшыртуга, шулай ук гаиләләргә һәм бизнеска ярдәм итүгә юнәлтелгән чаралар дәвам иттереләчәк. Моннан тыш, балалар тәрбияләүгә, яшьләр сәясәтенә һәм цифрлаштыру чараларына игътибар биреләчәк.

**БЮДЖЕТ СӘЯСӘТЕ**

*Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре өлешендә.*

2023 елда Татарстан Республикасы бюджетына салым һәм салым булмаган керемнәр 407,2 млрд сум күләмендә җыелды, план күрсәткечләренең 100,8 процентын тәшкил итте, бу исә 2022 ел күрсәткечләреннән 40,6 млрд сумга яисә 11,1 процентка артыграк. Федераль бюджеттан һәм башка чыганаклардан республикага 79,7 млрд сум җәлеп ителде.

**2023 елда Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре структурасы**




Республика бюджетына керемнәрне арттыру өчен даими төстә Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының үз керемнәрен үстерүне тәэмин итү буенча ведомствоара комиссиясе эшли (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 30 апрелендәге 687-р номерлы карары кысаларында), аның эшчәнлеге кысаларында түбәндәгеләр башкарылды:

керемгә салым түләүгә ай саен мониторинг уздырылды, нәтиҗәдә алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда түләүләре кимегән оешмалар ачыкланды. Мондый оешмаларның исемлеге квартал саен аналитик эш белән шөгыльләнүче тармак министрлыгына җиткерелеп торды, алар баланс комиссияләре эшчәнлеге кысаларында салымнар түләүнең кимүе сәбәпләрен һәм барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләүләр буенча бурычы булган оешмалар эшчәнлеген тикшерделәр. Уртак эш йомгаклары буенча тармак министрлыклары тарафыннан үз карамакларындагы оешмаларның җитештерү рентабельлеген арттыру һәм керем алу дәрәҗәсенә чыгу, шулай ук бюджетка түләүләр буенча бурычны киметү буенча тәкъдимнәр эшләнде;

физик затларның керемнәренә салым салу өлешендә яшерен хезмәт хакын легальләштерү, конвертта акча түләүне һәм салым түләүдән читләшүнең башка схемаларын ачыклау эшчәнлеге алып барылды, учреждение хезмәткәрләренә хезмәткә түләүнең федераль законнарда билгеләнгән иң түбән күләменнән азрак

булмаган күләмдә хезмәт хакы түләү контрольдә тотылды, шулай ук әлеге салымны түләүне алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда киметкән салым түләүчеләргә мониторинг уздырылды;

продукция җитештерү һәм сату күләмнәренә, акцизга караган продукцияне төп җитештерүчеләрнең акциз салымын түләүнең план биремнәренә ирешүенә мониторинг уздыру буенча акцизларга караган продукция җитештерүчеләр белән даими эш алып барылды;

салым түләүче физик затларның милеккә салым түләүләре үз вакытында һәм тулысынча башкарылуын тәэмин итү максатларында зур предприятиеләр, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләр белән салымнарны законнарда билгеләнгән срокларда түләү буенча хезмәттәшлек ителде. Шулай ук салым түләүчеләргә салым түләү турында хәбәрнамәләрне җиткерү, кредит оешмалары һәм почта бүлекчәләре тарафыннан түләүләрне өзлексез кабул итү эше оештырылды, шулай ук киң колачлы мәгълүмати эш, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында да, җәелдерелде;

салым булмаган керемнәр өлешендә Татарстан Республикасы бюджетына һәм муниципаль районнар һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларына керә торган керемнәрне анализлау һәм фаразлана торган керемнәрне бәяләү башкарылды, керем базасын арттыру һәм түләүләр буенча бурычларны киметү максатларында салым булмаган керемнәр администраторлары белән уртак эш алып барылды;

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салым бурычларын киметү буенча (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 июлендәге 1493-р номерлы карары белән төзелгән Ведомствоара комиссия (штаб) эше кысаларында). Ай саен муниципаль районнарга һәм шәһәр округларына Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белешмәләреннән чыгып, бурычлары булган салым түләүчеләр турында мәгълүмат юлланды. Муниципаль берәмлекләрнең ведомствоара комиссияләре эшенең йомгаклары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре катнашында видеоконференция режимында уздырылган киңәшмәләрендә каралды. Бурычлары булган затлар белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы икътисадый эшчәнлек төрләре буенча эш уздырылды. Федераль һәм төбәк законнарына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына бурычны киметүгә юнәлтелгән шартлар булдыру өлешендә үзгәрешләр кертү зарурлыгы турында тәкъдимнәр бирелде.

Моннан тыш, бюджетка керемне арттыру максатларында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан республиканың зур күләмдә салым түләүчеләре белән эш уздырылды, шул исәптән түләүләрне анализлау һәм фаразлана торган түләүләрне бәяләү, түләүләр кимүе сәбәпләрен ачыклау, шулай ук бюджетка түләүләрне арттыру өчен чаралар күрү.

Салым сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында керемгә салым һәм оешмалар милкенә салым буенча ташламалар рәвешендә яисә алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары составына кертелүгә дәгъва кылган инвестиция эшчәнлеге субъектларының инвестиция проектларына экспертиза ясалды.

Инвестиция эшчәнлеге субъектларының республиканың берләштерелгән бюджетына инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында тиешле килешүләр гамәлдә булган чор эчендә салымнар һәм җыемнар түләүне ел саен тәэмин итү буенча йөкләмәләрен үтәүләренә мониторинг уздырылды һәм бәя бирелде.

Кабул ителә торган үзгәрешләрнең Татарстан Республикасы икътисадына һәм берләштерелгән бюджетына мөмкин булган йогынтыларга кагылышлы тиз арада идарәчел карарлар кабул итү максатында федераль закон проектлары даими нигездә анализланды.

2023 елда салымнар һәм җыемнар турындагы законнарга үзгәрешләр кертү буенча закон инициативаларына 100дән артык бәяләмә әзерләнде. Алар арасында этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм аның әйләнеше өлкәсендә федераль законнарны камилләштерү буенча закон проектлары да бар.

2024 елда Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешен формалаштыру һәм үтәү кысаларында аның тотрыклылыгын һәм балансланган булуын тәэмин итү максатларында системалы эш дәвам иттереләчәк.

*Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары өлешендә*

Тулаем алганда, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 510,2 млрд сум күләмендә башкарылган, шулардан иң зур күләмдәгеләре:

мәгарифкә – 100,6 млрд сум;

социаль сәясәткә – 58,7 млрд сум;

сәламәтлек саклауга – 50,8 млрд сум;

юл хуҗалыгына – 95,9 млрд сум;

авыл хуҗалыгына – 16,8 млрд сум;

мәдәнияткә –24,4 млрд сум.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы муниципаль берәмлекләр белән берлектә, бюджетны үтәүнең казначылык системасын файдаланып, хезмәт хакын, социаль түләүләрне вакытында түләүне, бюджет учреждениеләре мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүне һәм инвестиция проектларына ярдәм күрсәтүне контрольдә тотты.

Эчке дәүләт финанс контроле кысаларында 309 контроль чара уздырды, аларның йомгаклары буенча бюджет акчасының 134,2 млн сумга нәтиҗәсез файдаланылуы ачыкланды. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү чараларын күрү өчен учреждениеләр җитәкчеләренә кисәтүләр ясалды. Тикшерүләр актлары Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

Һәр квартал саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салым һәм финанслар комитеты утырышларында Татарстан Республикасы бюджетына керемнәр туплау һәм бюджет акчаларын нәтиҗәле куллану мәсьәләләре каралды. 2023 елның июлендә, октябрендә һәм декабрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 2023 елга Татарстан Республикасы бюджетына үзгәрешләр кертү буенча эш башкарылды.

Татарстан Республикасының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителде һәм аңа Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов кул куйды («Татарстан Республикасының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

Татарстан Республикасының тупланган бюджетының чыгым өлешен 2024 елга

социаль-мәдәни өлкә тармаклары буенча формалаштырганда норматив планлаштыру ысулы кулланылды, республиканың учреждениеләрне финанслау нормативларын раслаучы тиешле законнары һәм хокукый актлары кабул ителде.

2023 елда 2024 елга кадәр Татарстан Республикасы дәүләт финансларының кимчелекле якларын бетерү буенча чаралар планы гамәлгә ашырыла, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 31 декабрендәге 1194 номерлы карары нигезендә расланды. Шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 мартындагы 788-р номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының керемнәрен арттыру, чыгымнарын киметү һәм бурыч сәясәтен камилләштерү буенча чаралар планы үтәлә.

*Татарстан Республикасының дәүләт бурычы белән идарә итү өлешендә.*

Ел дәвамында республика дәүләт бурычын йөкләмәләрне үтәү графиклары нигезендә исәпкә алу, рәсмиләштерү, вакытында түләү һәм хезмәт күрсәтү мәсьәләләре белән бәйләнгән чараларның тулы бер комплексы уздырылды. Дәүләт бурычын киметү буенча чаралар планы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 14 гыйнварындагы 10-р номерлы боерыгы) 2023 елга үтәлде. Бу эшне башкарганда республика бюджеты дефицитын финанслау максатында коммерциячел оешмалардан акча алуга куелган чикләүләр бозылмады.

2023 елда «Торак», «Заманча мәктәп», «Мәдәни мохит», «Сәламәтлек саклау өлкәсенең башлангыч буынын яңартып кору», «Төбәк һәм җирле юл челтәре» федераль проектларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасының тиешле өлкәләрдә объектларны төзү һәм капиталь төзекләндерү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслар белән алдан ук тәэмин итү максатларында бюджетның бердәм хисабында калдыкка кушу өчен бюджет кредиты форматында 14 969,1 млн сум тотылды.

Федераль бюджетка яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашырудан алынган салым керемнәре күләмендә Татарстан Республикасының федераль бюджет алдында бюджет кредитлары буенча бурычларының бер өлешен чигерү эше дәвам иттерелде. 2023 елда 7,9 млрд сум күләмендә кредитлар буенча бурычлар чигерелде.

2023 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт бурычының тулаем күләме (дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрне исәпкә алып) 125,7 млрд сум тәшкил итте. Татарстан Республикасы бюджетының бурыч йөкләмәсе дәрәҗәсе (салым һәм салым булмаган керемнәрнең еллык күләменә дәүләт бурычы күләменең нисбәте) 30,9 % процент тәшкил итте.

Россиянең «Аналитика Кредит Рейтинг Агентлыгы» (АКРА) һәм «Эксперт РА» рейтинг агентлыклары Татарстан Республикасының кредит рейтингы Россия Федерациясендә иң югары дәрәҗәсенә җитте дигән бәя бирде.

## ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАЛАРЫ

Татарстан Республикасында 2023 елда 35 дәүләт программасы гамәлгә ашырылды, алар җәмгыять тормышының икътисадый һәм социаль өлкәләренә кагыла.

Татарстан Республикасының 33 дәүләт программасын үтәүгә 472,9 млрд сум тотылды: Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан – 416,9 млрд сум, федераль бюджет акчалары хисабыннан – 56,0 млрд сум.

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» һәм «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» дәүләт программаларын финанслауга Татарстан Республикасы бюджетыннан акча тотылмады.

### Дәүләт программаларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (алга таба – дәүләт программалары) гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрнең факттагы дәрәҗәсе белән аларның максатчан (план) дәрәҗәсен чагыштыру, шулай ук аларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән финанслар күләме белән чынлыкта тотылган акча күләмен чагыштыру юлы белән башкарылды.

2023 елда үтәлгән 35 дәүләт программасыннан:

27се – индикаторларның пландагы дәрәҗәсенә ирешү өлешендә югары дәрәҗәдәге нәтиҗәлелек белән гамәлгә ашырылды – 95 % һәм башкалар;

5се – индикаторларның пландагы дәрәҗәсенә ирешү өлешендә канәгатьләнерлек дәрәҗәдәге нәтиҗәлелек белән – 80ннән 95 процентка кадәр;

1се – индикаторларның пландагы дәрәҗәсенә ирешү өлешендә канәгатьләнерлек булмаган дәрәҗәдәге нәтиҗәлелек белән – 80 проценттан кимрәк;

2сен бәяләү мөмкин түгел.

33 дәүләт программасының 2 167 күрсәткече буенча пландагы дәрәҗәләре тулы күләмдә үтәлде, 20 дәүләт программасының 95 күрсәткече буенча алар арттырып үтәлде, 14 дәүләт программасының 69 күрсәткече буенча аларга ирешелмәде: «Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү», «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен үстерү», «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү», «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү», «Икътисадый үсеш һәм Татарстан Республикасының инновацияле икътисады», «Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү», «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» «Цифрлы Татарстан», «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү», «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау», «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу», «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү», «Татарстан Республикасында архив эшен үстерү», «Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү».

**Дәүләт программаларында билгеләнгән индикаторларның 2023 ел өчен куелган план күрсәткечләренә ирешү турында мәгълүмат**

| Т/с | Дәүләт программасының атамасы | Дәүләт программасының дәүләт заказчысы-координаторы | Аларның үтәлеше турында мәгълүмат дәүләт программаларын гамәлгә ашыру хакындагы хисапларда бирелгән индикаторлар саны | шул исәптән | | | Дәүләт программасының нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | >95 %* | <95 % | >200 % | |
| 1. | Татарстан Республикасында туристлыкны һәм кунакчыллыкны үстерү | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты | 20 | 20 | 0 | 0 | 100,0 |
| 2. | Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 47 | 47 | 0 | 0 | 100,0 |
| 3. | Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 10 | 10 | 0 | 0 | 100,0 |
| 4. | Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 58 | 56 | 0 | 2 | 100,0 |
| 5. | Чит илләрдә яшәүче ватандашларга Татарстан Республикасына ирекле төстә күченүдә ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 6 | 4 | 0 | 2 | 100,0 |
| 6. | Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләр өчен газ салу компрессор станцияләре төзү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 1 | 1 | 0 | 0 | 100,0 |
| 7. | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | 24 | 23 | 0 | 1 | 100,0 |

| Т/с | Дәүләт программасының атамасы | Дәүләт программасының дәүләт заказчысы-координаторы | Аларның үтәлеше турында мәгълүмат дәүләт программаларын гамәлгә ашыру хакындагы хисапларда бирелгән индикаторлар саны | шул исәптән | | | Дәүләт программасының нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | >95 %* | <95 % | >200 % | |
| 8. | Татарстан Республикасы дәүләт милке белән идарә итү | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 26 | 26 | 0 | 0 | 100,0 |
| 9. | Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 25 | 25 | 0 | 0 | 100,0 |
| 10. | Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 96 | 94 | 0 | 2 | 100,0 |
| 11. | Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 46 | 46 | 0 | 0 | 100,0 |
| 12. | Татарстан Республикасында электрга көйләнгән автомобиль транспорты өчен зарядка инфраструктурасын булдыру | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 4 | 3 | 0 | 1 | 100,0 |
| 13. | Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 10 | 8 | 0 | 2 | 100,0 |
| 14. | Әйләнә-тирә мохитне саклау, Татарстан Республикасының табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | 83 | 83 | 0 | 0 | 100,0 |

| Т/с | Дәүләт программасының атамасы | Дәүләт программасының дәүләт заказчысы-координаторы | Аларның үтәлеше турында мәгълүмат дәүләт программаларын гамәлгә ашыру хакындагы хисапларда бирелгән индикаторлар саны | шул исәптән | | | Дәүләт программасының нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | >95 %* | <95 % | >200 % | |
| 15. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 45 | 42 | 0 | 3 | 100,0 |
| 16. | Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 84 | 83 | 0 | 1 | 100,0 |
| 17. | Татарстан Республикасы халкы мәшгульлегенә ярдәм итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 47 | 42 | 0 | 5 | 100,0 |
| 18. | Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 153 | 146 | 0 | 7 | 100,0 |
| 19. | Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 139 | 139 | 0 | 0 | 100,0 |
| 20. | Татарстан Республикасында мәгарифне һәм фәнне үстерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 193 | 185 | 2 | 6 | 98,9 |
| 21. | Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен үстерү | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 123 | 117 | 2 | 4 | 98,8 |
| 22. | Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек | 158 | 149 | 3 | 6 | 98,1 |

| Т/с | Дәүләт программасының атамасы | Дәүләт программасының дәүләт заказчысы-координаторы | Аларның үтәлеше турында мәгълүмат дәүләт программаларын гамәлгә ашыру хакындагы хисапларда бирелгән индикаторлар саны | шул исәптән | | | Дәүләт программасының нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | >95 %* | <95 % | >200 % | |
| | | саклау министрлыгы | | | | | |
| 23. | Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү | Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | 37 | 36 | 1 | 0 | 97,3 |
| 24. | Икътисадый үсеш һәм Татарстан Республикасының инновацияле икътисады | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 202 | 184 | 6 | 12 | 97,0 |
| 25. | Цифрлы Татарстан | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 102 | 97 | 2 | 3 | 97,0 |
| 26. | Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | 30 | 29 | 1 | 0 | 96,7 |
| 27. | Татарстан Республикасында юстицияне үстерү | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 29 | 26 | 1 | 2 | 96,6 |
| 28. | Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | 56 | 53 | 3 | 0 | 94,6 |

| Т/с | Дәүләт программасының атамасы | Дәүләт программасының дәүләт заказчысы-координаторы | Аларның үтәлеше турында мәгълүмат дәүләт программа-ларын гамәлгә ашыру хакындагы хисапларда бирелгән индикаторлар саны | шул исәптән | | | Дәүләт программа-сының нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | >95 %* | <95 % | >200 % | |
| 29. | Татар халкының милли тәңгәллеген саклау | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 124 | 112 | 9 | 3 | 92,7 |
| 30. | Татарстан Респуб-ликасында авыл хуҗа-лыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базар-ларын җайга салу | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 166 | 123 | 14 | 29 | 91,6 |
| 31. | Татарстан Респуб-ликасында яшьләр сәясәтен үстерү | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | 155 | 136 | 18 | 1 | 88,4 |
| 32. | Татарстан Республикасында архив эшен үстерү | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе | 23 | 17 | 3 | 3 | 85,0 |
| 33. | Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 9 | 5 | 4 | 0 | 55,6 |
| 34. | Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге** | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | - | - | - | - | - |
| 35. | Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше*** | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | - | - | - | - | - |
| **БАРЛЫГЫ:** | | | **2 331** | **2 167** | **69** | **95** | **97,0** |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы 7.5.1 пункты нигезендә пландагы һәм

фактагы күрсәткечләр арасында аермалар чикләре билгеләнде: әгәр фактагы күрсәткеч пландагы күрсәткечтән 95 процентны тәшкил итә икән, аңа ирешелгән дип санала.
** «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» дәүләт программасы буенча хисап бирү өчен 2023 ел өчен мәгълүматлар 2024 елның III кварталында Федераль дәүләт статистика хезмәтенең хисабы бастырып чыгарылганнан соң биреләчәк.
*** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 декабрендәге 1429 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» дәүләт программасы расланды. Аның дәүләт заказчысы-координаторы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Түбәндәге дәүләт программалары кысаларында булганлыктан, дәүләт программалары чараларын финанслау сылтама характерында була: «Татарстан Республикасында мәгарифне һәм фәнне үстерү», «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен үстерү», «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау», «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү», «Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә», «Икътисадый үсеш һәм Татарстан Республикасының инновацияле икътисады», «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү», «Татарстан Республикасында электрга көйләнгән автомобиль транспорты өчен зарядка инфраструктурасын булдыру», «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү».

Дәүләт программалары чараларын 2024 елда 376,2 млрд сум планлаштырылган, шул исәптән федераль бюджеттан – 39,3 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан – 336,9 млрд сум.

2023 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе тарафыннан 2022 елның расланган ММ-П6-14588 номерлы карары белән расланган план-графигы нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан республиканың башкарма органнары белән бергәләп 2024 елдан Татарстан Республикасы дәүләт программаларын проектлы идарә системасына күчерү эше башкарылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 елның 30 маендагы 655 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2023 елның 22 декабрендәге 1667 номерлы карарлары расланды.

Федераль үзәк белән эшне синхронлаштыру, дәүләт программаларын гамәлгә ашыру һәм корректировкалауны тизләтү өчен Татарстан Республикасы дәүләт программалары 2024 елдан электрон төргә күчерелде, аларның гамәле цифрлы модульдә алып барыла.


2023 ел дәвамында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан республиканың башкарма хакимият органнары белән бергәләп Россия Федерациясе сенаторлары һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Татарстан Республикасыннан депутатлары җитәкчелегендә эш төркемнәре белән эш уздырылды (эш төркемнәренең 183 утырышы булды). Эш төркемнәре утырышлары кысаларында чараларны уздыруга федераль бюджеттан, Россия Федерациясенең төрле фондларыннан (Сәнәгатьне үстерү фонды, «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясе, ДОМ.РФ Банкы, Россия Федерациясе юл фондлары һ.б.), закон чыгару башлангычларын (ислам партнерлык финанслары, югары технологияләр өлкәсендә технопарклар, җитештерү һәм куллану калдыклары буенча һ.б.) хуплауга, Татарстан Республикасы оешмаларының һәм муниципаль берәмлекләренең заявкаларын хуплауга өстәмә финанслау җәлеп итү мәсьәләләре каралды.

# ТӨП СОЦИАЛЬ КҮРСӘТКЕЧЛӘР

## Тормыш дәрәҗәсе

Республика предприятиеләрендә һәм оешмаларында, кече эшмәкәрлек субъектларын да кертеп, уртача исәпләп чыгарылган хезмәт хакы 2023 елда 61 840,7 сум тәшкил итте һәм 2022 ел белән чагыштырганда 18,8 процентка артты. Товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә куллану бәяләре индексын исәпкә алып хисапланган реаль хезмәт хакы 113,2 % тәшкил итте.

**Татарстан Республикасында айлык уртача хезмәт хакы**




Уртача исәпләп чыгарылган хезмәт хакы күләме буенча Идел буе федераль округы төбәкләре арасында рэнкингта Татарстан 1 нче урында тора.

Республикада югары хезмәт хаклары икътисадый эшчәнлекнең түбәндәге төрләрендә күзәтелде: файдалы казылмалар чыгару – 98,5 мең сум; мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек – 95,2 мең сум; финанс һәм иминиятләштерү эшчәнлеге – 90,7 мең сум; электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һава әйләнешен булдыру – 83,8 мең сум; һөнәри,фәнни һәм техник эшчәнлек – 80,7 мең сум; эшкәртү производстволары – 73,6 мең сум.

Мәгариф өлкәсендә хезмәткәрләрнең уртача айлык хезмәт хакы 48,1 мең сум, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә – 53,9 мең сум, мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачуны оештыру өлкәсендә 62,4 мең сум тәшкил итте.

2023 елда Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы, «2012–2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә кылынган гамәлләрнең илкүләм стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы, «Балаларны, ятимнәрне һәм ата-аналар тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның кайбер чаралары турында» 2012 елның 28 декабрендәге 1 688 номерлы указларын гамәлгә ашыру эше дәвам иттерелде.

2023 ел йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президентының 2019 елның 27 февралендәге Пр-294 номерлы йөкләмәсендә билгеләнгән аерым категория хезмәткәрләргә түләү күрсәткечләре әлеге категория хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү дәрәҗәсе белән төбәктәге уртача алынган хезмәт хакы дәрәҗәсе арасындагы

тигезлекне саклау тулы күләмендә үтәлде. Әлеге категория хезмәткәрләргә эш хакы түләүгә 198,3 млрд сум тотылган, шул исәптән федераль бюджеттан – 2,8 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 140,2 млрд сум, Мәҗбүри медицина иминләштерүе фонды акчалары хисабыннан – 41,7 млрд сум, бюджеттан тыш акчалар хисабыннан – 13,6 млрд сум.

Бюджеттан тыш сектор оешмаларында һәм юридик зат буларак теркәлмичә генә эшләүче шәхси эшкуарлар хезмәтенә түләүнең минималь күләмен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Эшкуарлар берләшмәләренең координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында даими рәвештә айлык хезмәт хакының минималь күләме турында килешүләр (алга таба – Килешү) төзелә.

2023 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 28 декабрендәге Килешү нигезендә минималь хезмәт хакы аена 19 565 сум күләмендә билгеләнде, бу исә 2022 елның III кварталы өчен Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь куллану бюджеты бәяләр күләменең 93 процентын тәшкил итә.

2024 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 27 декабрендәге Килешү нигезендә минималь хезмәт хакы аена 22 020 сум күләмендә билгеләнде, бу исә 2023 елның II кварталы өчен Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь куллану бюджеты бәяләр күләменең 100 процентын тәшкил итә.

Бурычлы предприятиеләр белән эшләү республикада Халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшырту, хезмәт, Татарстан Республикасында чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе, шулай ук Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы республика комиссиясе каршындагы Хезмәткә түләү, керемнәр һәм халыкның тормыш дәрәҗәсе буенча координация советы эшчәнлеге кысаларында муниципаль берәмлекләрдәге территориаль комиссияләр, тармак министрлыклары, контроль күзәтчелек һәм салым органнары, республиканың һөнәри берлекләре һәм эш бирүчеләре берләшмәләре белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барыла.


**Хезмәт базары**

2023 елда Татарстан Республикасында, тулаем алганда, Россия Федерациясендә кебек үк, эшсезлек тарихта моңарчы күрелмәгәнчә түбән булды. 2024 елның 1 гыйнварына халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә исәптә эшсезләр сыйфатында 4,3 мең кеше теркәлгән, бу – эшче көчләр санының 0,21 процентын тәшкил итә.

Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча исәпләнгән халыкның эш белән тәэмин ителгәнлек дәрәҗәсе 2023 елда Татарстан Республикасында 62 процент тәшкил итте.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен, Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте эшчәнлеген камилләштерү кысаларында 2024 елның 1 гыйнварыннан «Россия Федерациясе халкының эш белән тәэмин ителүе турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565 номерлы Россия Федерациясе Законының кайбер нигезләмәләре үз көченә керә, закон тулысынча 2025 елның 1 гыйнварыннан тулысынча үз көченә керә.

**Эшсезлек дәрәҗәсенең динамикасы**




Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы Законда төп яңалыклар арасында түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

эшсезлек буенча пособие билгеләүнең яңа кагыйдәләре. Эшсезлек буенча пособие яңа кагыйдә буенча кулланучылар бәяләре үсеше динамикасын исәпкә алып индексацияләнәчәк. Индексация 2024 елның 1 февраленнән башлап ел саен ясалачак;

хәрби хезмәтне тәмамлаган гражданнар, яшьләр, шулай ук эш бирүчеләр өчен махсус ярдәм чараларын үстерү;

эш белән тәэмин итү хезмәтләренең мәгариф системасы органнары һәм оешмалары белән хезмәттәшлеге;

легаль булмаган эш белән тәэмин итүгә каршы көрәшү;

инвалидларның эш белән тәэмин ителүенә ярдәм буенча махсус чараларны үстерү.

**МӘГАРИФ**

*Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары*

Республикада 1 945 мәктәпкәчә мәгариф оешмасы эшли, аларда мәктәп яшенә җитмәгән 201 632 мең бала тәрбияләнә.

Балалар бакчаларының гомуми саныннан 729 ы татар телендә белем һәм тәрбия бирә, аларга татар милләтеннән булган 28 023 бала йөри.

665 рус-татар балалар бакчасында 1 400 татар төркеме эшли, аларда татар милләтеннән булган 25 301 бала тәрбияләнә.

Моннан тыш, республикада 51 – чуваш , 15 – удмурт, 8 – марий, 1 – мордва телләрендә белем һәм тәрбия бирә торган балалар бакчасы эшли.

Татарстан Республикасында туган телдә тәрбия һәм белем бирү дәрәҗәсе 56,8 % тәшкил итә.

2023 елда 1 000 урынга 4 балалар бакчасы төзелде, шул исәптән:

560 урынга 2 балалар бакчасы (Тукай муниципаль районының Новотроицкое авылында 220 урынга балалар бакчасы, Чаллы шәһәрендә «Яшьлек» торак комплексының 69 мкр. 340 урынга балалар бакчасы) – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карары буенча;

«Демография» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәрендә 440 урынга исәпләнгән 2 балалар бакчасы (Казан шәһәренең 59 кварталында 220 шәр урынга исәпләнгән 2 балалар бакчасы).

Россия Федерациясенең «Мәгарифне үстерү» дәүләт программасын, «2014–2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын, шул исәптән «Демография» илкүләм проектын, Россия Федерациясенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасының «Авыл территорияләренең заманча йөзе» федераль программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә барлык яшь категориясендәге балалар мәктәпкәчә белем бирү мөмкинлеге белән 100 процентка тәэмин ителде.

*Гомуми белем бирү оешмалары*

2023/24 уку елында республикада 1 402 гомуми белем бирү оешмасы эшли:

1 288 гомуми белем бирү мәктәбе (шуларның 425е авылдагы урта мәктәпләр) һәм 25 мәктәп-интернат;

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 23 мәктәп һәм 30 мәктәп-интернат;

2 шифаханә-мәктәп-интернат;

девиант тәртипле балалар өчен 1 мәктәп;

7 кичке гомуми белем бирү мәктәбе;

дәүләтнеке булмаган 24 мәктәп;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы 2 гомуми белем бирү мәктәбе.

Уку елы башында республиканың гомуми белем бирү оешмаларында 501,4 мең кеше (шуларның авылдагы урта мәктәпләрдә – 72 224 бала) белем алды, педагогик кадрларның саны 36 меңнән артып китте, шуларның 32 меңе – укытучылар.

2023 елда 9 974 урынга 12 гомуми белем бирә торган объект төзелде (шул исәптән 300 урынлык инде элек төзелгән мәктәпкә өстәмә 1 корпус):

«Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында 9 329 урынга 8 мәктәп һәм 300 урынлык инде элек төзелгән мәктәпкә өстәмә 1 корпус төзелде (Тукай муниципаль районының Шилнәбаш авылында 100 урынга мәктәп, Казан шәһәренең Сибгат Хәким урамында 1 224 урынга 1 мәктәп, Чаллы шәһәрендә 1 501 урынга 1 мәктәп, Казан шәһәренең «Светлая долина» торак комплексында 1 501 урынга мәктәп, Казан шәһәренең «Салават Күпере» торак комплексында 1 501 урынга мәктәп, Казан шәһәренең Гәрәев урамында 1 501 урынга мәктәп, Арча муниципаль районының Түбән Мәтәскә авылында 500 урынга мәктәп, Чаллының 34 микрорайонында 1 501 урынга мәктәп, Казан шәһәренең Идел буе районында «19 нчы гимназия» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә 300 урынлык өстәмә корпус);

Россия Федерациясенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасының «Авыл территорияләренең заманча йөзе» федераль программасы кысаларында 140 урынга балалар бакчасы булган 320 урынга 2 мәктәп

(Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәрендә 120 урынга балалар бакчасы булган 240 урынга мәктәп, Биектау муниципаль районы Коркачык авылында 20 урынга балалар бакчасы булган 80 урынга мәктәп);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым боерыгы нигезендә Әлки муниципаль районының Түбән Колчура авылында 25 урынга балалар бакачасы булган 25 урынлык мәктәп;

2023/24 уку елында Татарстан Республикасында түбәндәгеләр эшли:

874 рус телендә белем бирелә торган мәктәп, аларда 419 908 бала укый;

татар телендә белем бирелә һәм аерым фәннәр рус телендә өйрәтелә торган 600 ( шуларның 97се – филиаллар) гомуми белем бирү оешмасы, 81 481 укучы, шулардан 57 808 бала туган телдә белем ала;

белем бирүдә этномәдәни компонентлы 129 мәктәп:

белем бирүдә чуваш этномәдәни компоненты кулланылган, чуваш теле өйрәтелә торган 87 гомуми белем бирү оешмасы (19 филиалы белән) (3 608 укучы);

белем бирүдә удмурт этномәдәни компоненты кулланылган, удмурт теле өйрәтелә торган 22 гомуми белем бирү оешмасы (5 филиалы белән) (1 585 укучы);

белем бирүдә мари этномәдәни компоненты кулланылган, мари теле өйрәтелә торган 16 гомуми белем бирү оешмасы (филиалы белән) (949 укучы);

мордва теле өйрәтелә торган 3 гомуми белем бирү оешмасы (филиалы белән) (60 укучы );

яһүд теле өйрәтелә торган 1 гомуми белем бирү оешмасы (740 укучы).

Күпмилләтле якшәмбе мәктәпләренең 110 бүлекчәсендә 25 милләтнең (азәрбайҗан, әрмән, таҗик, үзбәк, немец, грузин, корея, бурят, гарәп, якут, кыргыз, әфган, украин, башкорт һәм башкалар) теле һәм мәдәнияте өйрәнелә. 1 732 бала укытыла.

Сыйныф җитәкчеләренә ай саен бер сыйныфка 550 сум һәм һәрбер укучы өчен 80 сум түләнә. Федераль бюджеттан сыйныф җитәкчеләренә өстәмә рәвештә ай саен 5 000 сум түләү каралган.

2023/24 уку елында 497 210 укучы кайнар ризык белән тәэмин ителде, шулардан 226 272 бала 1–4 сыйныф һәм 270 938 бала 5–11 сыйныф укучылары.

Өстәвенә кече сыйныф укучыларының күпчелеге көненә 2 тапкыр ашатыла (туклану белән тәэмин ителгән әлеге яшьтәге балалар саныннан 68 %), урта һәм өлкән сыйныф укучыларының күпчелеге бер тапкыр туклана (туклану белән тәэмин ителгән 5–11 сыйныф укучыларының 72 %).

1–4 сыйныф укучыларын 2023 елда түләүсез туклану белән тәэмин итүгә 2 526,0 млн сум тотылды, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 515,6 млн сум һәм җирле бюджетлардан – 1 010,4 млн сум.

2023 елда 2,02 млрд сумга 45 объект төзекләндерелде, шул исәптән:

1 424,93 млн сумга 6 муниципаль мәктәп;

148,03 млн сумга 30 дәүләт мәгариф оешмасы, шул исәптән коррекция һәм кадет оешмалары;

422,62 млн сумга 8 балалар бакчасы;

30 млн сумга 1 олимпия үзәге.

Мәктәпләрне төзекләндерү федераль программасы кысаларында – 31 гомуми белем бирү оешмасы биналарында 4,03 млрд сумга төзекләндерү эшләре башкарылды (2,42 млрд сум – федераль бюджеттан субсидия, 1,61 млрд сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары).

Татарстан Республикасының төп эш бирүчеләренең кадрларга ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен төзелгән ресурс үзәкләре биналарын җиһаз, инвентарь алып һәм территорияләрен төзекләндереп, шулай ук Татарстан Республикасының һөнәри мәгариф оешмалары биналарын капиталь төзекләндерү программалары кысаларында 2023 елда 500,00 млн сумга 9 һөнәри гомуми белем бирү оешмасы төзекләндерелде.

Шулай ук капиталь төзекләндерү программалары кысаларында җиһаз, инвентарь алып һәм территорияләрен төзекләндереп һөнәри мәгариф оешмаларының 4 тулай торагын 406,5 млн сумга төзекләндерү башкарылды.

Гомуми белем бирү оешмаларында 1–4 сыйныф укучыларын түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру өчен кирәкле инфраструктураны яхшырту өчен җиһаз алып 143 мәгариф объектында 1,0 млрд сумга ризык пешерү блоклары төзекләндерелде.

2023 елда балаларга өстәмә белем бирү программаларын республиканың 2 580 мәгариф оешмасы башкарды, шуларның 153е – мәгариф системасының балаларга өстәмә белем бирүне оештыру муниципаль оешмалары. Өстәмә белем бирү программалары буенча шөгыльләнгән 5 яшьтән 18 яшькәчә балаларның өлеше 81,2 % тәшкил итә.

Республиканың мәгариф оешмаларында «Гаилә белеме» проекты гамәлгә ашырыла, аның максаты – укучы балаларны гаилә тормышына әзерләү, гаилә коручының шәхесен, традицион гаилә кыйммәтләренә: йортка, гаиләгә, әти-әни булуга, туганлыкка, никахта тугрылыкка һәм мәхәббәткә хөрмәт формалаштыру.

«Гаилә белеме» проекты мәгариф системасына электив, факультатив яисә сыйныф сәгате буларак мәгариф оешмаларының тәрбия эше кысаларында кертелә.

2024 елның 25–26 гыйнварында Түбән Кама муниципаль районында (ул «Гаилә белеме» проектын гамәлгә ашыру буенча республика инновация мәйданчыгы булып тора) «Гаилә: минем өемдә минем урыным» дип аталган укыту-методик семинар узды, ул Гаилә елына багышланган иде. Анда директор урынбасарлары һәм тәрбия буенча директор урынбасарлары, «Гаилә белеме» укытучылары катнашты.

Казан шәһәренең Яңа Савин районы «146 нчы Лицей «Ресурс» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе Татарстанда гаилә белеме буенча педагогларның осталык дәресләре уздыруы ягыннан федераль дәрәҗәдә «Россиянең иң яхшы мәктәбе» дип танылды.

Республикада Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларыннан килгән балалар өчен профильле тел өйрәнү лагерьлары оештырылды. 2023 елда бу лагерьларда 1 580 бала ял итте. Профильле сменалар эшчәнлеге барышында иҗат кичәләре, конкурслар, татар теле дәресләре, татар халкы тарихына багышланган дәресләр, осталык дәресләре, язучылар, республиканың талантлы яшьләре белән очрашулар оештырылды.

*Урта һөнәри белем бирү*

Татарстан Республикасында 100 урта һөнәри белем бирү учреждениесе (8 8 дәүләт һәм 12 дәүләтнеке булмаган) эшли, аларда 78 027 студент белем ала.

Республиканың һөнәри белем бирү системасы Татарстанның кадрларга ихтыяҗын канәгатьләндерүгә эшли. Республикада 47 ресурс үзәге бар.

«Профессионалитет» федераль проектында республиканың 14 оешмасы җиңүче дип табылды:

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ катнашында Алабуга политехника көллияте базасында; «КАМАЗ» ГАҖ катнашында «Чаллы политехника көллияте» ДАПМУ, «Татшина» ҖЧҖ катнашында «Түбән Кама индустрия техникумы» ДАПМУ, «КАМАЗ» ГАҖ катнашында «В.Д. Поташов исемендәге техник көллият» ДАПМУ, «Ростар» КБПБ тарафыннан «Машина төзү» тармагы буенча мәгариф-производство үзәкләре (кластерлар) төзелде;

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «Шешмаойл» АҖ, «ТаграС-Холдинг» ҖЧҖ катнашында «Әлмәт политехника көллияте» ДАПМУ; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «Охтин-ойл» АҖ, «ТаграС-Холдинг» ҖЧҖ катнашында «Лениногорск нефть техникумы» ДАПМУ базасында «Ягулык-энергетика комплексы» тармагы буенча мәгариф-производство үзәкләре (кластеры) булдырылды;

«Шәрык» ҖЧҖ, «Бозкур» ҖЧҖ катнашында «Кукмара аграр көллияте» ДАПМУбазасында; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «Союз Агро» ҖЧҖ катнашында «Азнакай политехника көллияте» ДАПМУ базасында «Авыл хуҗалыгы» тармагы буенча мәгариф-производство үзәкләре (кластеры) булдырылды;

«СИБУР» ҖЧҖ катнашында «Н.В. Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте» ДАПМУ базасында химия тармагы буенча «Химия тармагы» мәгариф-производство үзәкләре (кластеры) булдырылды;

«Чаллы торба заводы» ҖЧҖ, «ТЭМПО» Кама металлургия комбинаты» АҖ, «Чаллы торба заводы «ТЭМ-ПО» АҖ катнашында «Л.Б. Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» ДАПМУ базасында «Металлургия» тармагы буенча мәгариф-производство үзәкләре (кластеры) булдырылды;

«Чаллы технология техникумы» ДАПМУ, «Халыкара сервис көллияте» ДАПМУ; «Г.И. Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» ДАПМУ базасында «Туристлык һәм хезмәт күрсәтү өлкәсе» юнәлешендә урта һөнәри белем бирү буенча мәгариф кластерлары булдырылды.

«Казан технологияләр һәм дизайн көллияте» ДАПМУ базасында «Сәнгать һәм креатив индустрия» юнәлешендә урта һөнәри белем бирү буенча мәгариф

кластерлары булдырылды.

Бүгенге көндә республикада 7 укыту-производство һәм мәгариф кластерлары булдырылды.

*Югары белем бирү*

2023/24 уку елында 46 югары белем бирү мәгариф оешмасы белем бирү эшчәнлеген башкарды, шул исәптән 25 төп (16 дәүләтнеке, 9 дәүләтнеке булмаган (шуларның 3се дини), 21 филиал (13 дәүләтнеке, 8 дәүләтнеке булмаган) югары белем бирү мәгариф оешмасы. Югары белем бирү мәгариф оешмаларында барлыгы 148 110 студент белем ала.

2023/24 уку елы кабул итү кампаниясе йомгакларына караганда, югары белем бирү программалары буенча укуга 45 386 кеше керде, шуларның 70,9 проценты – көндезге укуга.

2023 елда укуны тәмамлап чыгучыларның гомуми саны – 28 656 кеше, шул исәптән көндезге уку буенча – 19 055 кеше, кичке уку буенча – 941 кеше, читтән торып уку буенча – 8 660 кеше.

Республикада 15 якын һәм 111 ерак чит илдән 22 658 чит ил студенты белем ала.

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре студентларына дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2010 елның 21 декабрендәге 835-ПУ номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларының йомгаклау этабында җиңүчеләрдән һәм бүләк алучылардан булган студентлары өчен Татарстан Республикасы Рәисе стипендияләре билгеләнә, аларның исемлеге башкарма хакимиятнең мәгариф өлкәсендәге вәкаләтле федераль органы тарафыннан раслана. Айлык стипендиянең күләме – 7 мең сум. 2023/24 уку елында 414 студентка билгеләнде.

**«Мәгариф» илкүләм проекты.**

2023 елда Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проектының төбәк өлешләре кысаларында түбәндәге чаралар гамәлгә ашырылды:

*«Һәр баланың уңышы» төбәк проекты:*

Чүпрәле муниципаль районының «Дементьев Василий Степанович исемендәге Алешкин-Саплык урта гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең, Теләче муниципаль районының «Теләче урта гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең спорт заллары капиталь төзекләндерелде;

*«Заманча мәктәп» төбәк проекты:*

9 329 урынга 8 мәктәп төзелде һәм ачылды, Казан шәһәренең Идел буе районында «19 нчы гимназия» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә 300 урынлык өстәмә корпусын төзү тәмамланды;

гомуми белем бирү инфраструктурасын яңартып кору кысаларында түбәндәгеләр төзелә башлады: Лаеш муниципаль районының Усад авылында

1 501 урынлык мәктәп һәм Казан шәһәренең «Весна» торак комплексында 1 224 урынлык мәктәп;

республиканың кече шәһәрләрендә һәм авыл җирлекләрендә мәгариф оешмаларында 66 «Үсеш ноктасы» үзәге төзелде;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче лицее» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе базасында «Кванториум» балалар технопаркы ачылды;

5 коррекция мәктәбенең матди-техник базасы яхшыртылды («Актүбәнең сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәп-интернаты» ДБМУ, «Бөгелмәнең сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 10 нчы мәктәп-интернаты» ДБМУ, «Зеленодольскиның сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 2 нче мәктәп-интернаты» ДБМУ, «Зәйнең сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 9 нчы мәктәп-интернаты» ДБМУ, «Болгарның сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәп-интернаты » ДБМУ);

23 укытучыга «Земство укытучысы» программасы кысаларында 1 млн сум түләнде.

*«Цифрлы нигездә белем бирү мохите» төбәк проекты:*

40 мәгариф оешмасында мәгълүмат-коммуникация җиһазлары (компьютер, күпфункцияле җайланмалар, телевизорлар, интерактив комплекслар, видеокамералар) яңартылды;

*«Россия Федерациясе гражданнарында ватанпәрвәрлек тәрбияләү» төбәк проекты:*

«Ватанпәрвәрлек тәрбиясе» федераль проекты кысаларында республиканың 734 мәктәбендә директорның тәрбия һәм балаларның иҗтимагый оешмалары белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе ставкалары кертелде (1 мәгариф оешмасында 0,5 ставка). 1 гыйнвардан киңәшчеләр ставкасы 224 гомуми белем бирү оешмасында кертелде. Шул рәвешчә, мондый ставкалар республиканың 978 мәктәбендә кертелде;

426 мәктәптә Россия Федерациясе дәүләт символлары куелды.

Әлеге максатларда 2023 елда федераль бюджеттан 5,5 млрд сум бүлеп бирелде, 1,5 млрд сумы Татарстан Республикасы бюджетыннан бергәләп финансланды.

**Мәгарифне цифрлы нигезгә күчерү**

Татарстан «Минем мәктәп» федераль дәүләт мәгълүмат системасын һәм «Сферум» мәгълүмат-коммуникация платформасын гамәлгә кертү һәм үзләштерү эшенә актив кушылды. 2023 ел нәтиҗәләре буенча әлеге ресурслардан 272 225 укучы һәм республиканың 36 187 педагогик хезмәткәре актив файдаланды.

2023 елда республиканың мәгариф системасын цифрлы нигездә идарә итүнең яңа моделенә күчү максатларында состав элементы сыйфатында Мәскәү электрон мәктәбе базасында электрон журналлар һәм көндәлекләрнең унификацияләнгән чишелешен кертү юлы белән «Татарстан Республикасы электрон мәгарифе» дәүләт мәгълүмат системасын модернизацияләү гамәлгә ашырылды. Республика мәктәпләре 2024 елның гыйнварыннан яңартылган системада эшли.

2022/23 уку елында «Киләчәк коды» федераль проекты программалары буенча программалаштыруның заманча телен өйрәнү өчен 8 254 укучы, шул исәптән офлайн

форматта белем алу өчен 3 720 укучы, 2023/24 уку елында 13 139 укучы, шул исәптән офлайн форматта белем алу өчен 5 954 укучы укырга керде.

2023 елда 116 укучы «Яндекс.Лицей» мәгариф проекты кысаларында программалаштыруның заманча телләрен өйрәнү буенча ике еллык курсны тәмамлады. Алты уку елы дәвамында Татарстаннан 2 292 мәктәп укучысы укырга керде. Проектны гамәлгә ашыру күрсәткечләре буенча республика Россия төбәкләренең беренче өчлегенә керә.

Ел саен көз көне республика мәгариф оешмаларында Интернет челтәрендә киберкуркынычсызлык дәрәҗәсен арттыруга, ата-аналар белән педагоглар җәмәгатьчелегенең «Интернет» челтәрендә балалар иминлеге проблемаларына игътибарын җәлеп итүгә һәм мәктәп укучыларында цифрлы грамоталылыкны үстерүгә юнәлдерелгән Бердәм иминлек дәресе уздырыла.

2023 елның 18 маенда Kazan Digital Week - 2023 Халыкара форумы эгидасы астында «Мәгарифтә цифрлы технологияләр» дигән темага вебинар уздырылды, анда заманча һәм куркынычсыз цифрлы белем бирү мохитен булдыру һәм үстерү, укучыларның цифрлы компетенцияләрен үстерү, «Киләчәк коды» федераль проектын гамәлгә ашыру үзенчәлекләре, шулай ук Россия уку җиһазлары һәм укыту чаралары индустриясен үстерү векторлары каралды.

Форум көннәрендә мәгарифкә багышланган 9 төрле форматтагы чара (секцияләр, «түгәрәк өстәлләр», мастер-класслар) үткәрелде. Докладлар белән 60тан артык Россия спикеры турыдан-туры да, онлайн форматта да чыгыш ясады.

2023 елның 20 сентябреннән 23 сентябренә кадәр «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәге базасында 30 мәгълүмат технологияләре компетенцияләре буенча DigitalSkills 2023 цифрлы технологияләр өлкәсендә V тармак чемпионаты уздырылды.

2023 елда форумның партнеры – «Мобиль Электрон Белем бирү» компаниясе җитәкчелегендә Татарстанда 8–11 сыйныф укучылары өчен хакатон серияләренә старт бирелде, алар «Киләчәк коды» федераль проекты программалары кысаларында программалаштыру курсларында укыдылар.

2023 елның 20 ноябреннән 5 декабренә кадәр «Мин – укучы» мобиль кушымтасы базасында юл хәрәкәте иминлеге буенча «Мин – укучы» конкурсы уздырылды, анда 10 меңнән артык 7–11 сыйныф укучысы катнашты. Җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

**Төп казанышлар**

Бердәм дәүләт имтиханы йомгаклары буенча 2023 елда йөз балл җыю очраклары – 199, шулардан 9 укучы ике предметтан 200 балл җыйды. Математика, рус теле һәм ирекле сайлап алынган фән буенча БДИ йомгаклары республикада Россиядәге уртача күрсәткечләрдән югарырак.

2022/23 уку елында 251 укучы бөтенроссия мәктәп укчылары олимпиадасының йомгаклау этабында призлы урыннар яулап алды. Олимпиадада катнашу нәтиҗәлелеге ягыннан Татарстан Мәскәү шәһәреннән генә калышып, 2 нче урынны яулады.

Швейцариядә узган Химия буенча 55нче халыкара олимпиадада Казан шәһәренең Вахитов районы «131 нче лицей» укучысы Никита Перов алтын медаль яулады.

IOI-2023 информатика буенча Венгриядә узган халыкара олимпиадада Казан шәһәре Мәскәү районының «2 нче лицей-интернат» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе укучысы Гыймран Абдуллин һәм «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Н.И. Лобачевский исемендәге лицей» гомуми белем бирү мәктәп-интернаты укучысы Валерий Родионов алтын медальләр яуладылар.

«2023 ел тәрбиячесе» бөтенроссия конкурсында Казан шәһәре Киров районының «101 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе Ю.А. Токмакова Россиянең иң яхшы 5 тәрбиячесе арасында мактаулы урын алды.

«Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы-2023» бөтенроссия һөнәри конкурсы кысаларында «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телен үстерүдә иң яхшы тәҗрибә» номинациясендә Казан шәһәре Вахитов районының «41 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә төркеме тәрбиячесе А.Г. Лотфуллина абсолют җиңүче булды.

Казан шәһәре Яңа Савин районының «Татар телендә белем бирелә торган 13 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укытучысы А.И. Шәгәрәева «Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы» конкурсының биш финалчысы арасында мактаулы урын алды.

«Иннополис лицее» ДАМУның математика укытучысы А.А. Костанян «Ел укытучысы» бөтенроссия конкурсының призеры булды һәм Россиянең иң яхшы биш укытучысының берсе булып танылды.

Казан шәһәре Совет районының «108 номерлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең физика укытучысы Р.Р. Хәбиров «Класс темасы!» бөтенроссия конкурс-телешоуының финалисты булды.

2023 елның апрелендә Ижевск шәһәрендә «КЭС-БАСКЕТ» баскетбол лигасы мәктәп чемпионатының Педагоглар һәм остазларның баскетбол буенча бөтенроссия турнирында Татарстан Республикасы педагоглары җыелма командасы 3 урынны алды.

Илкүләм «Абилимпикс» чемпионатында һәм Профессиональ осталык буенча «Профессионаллар» бөтенроссия чемпионат хәрәкәтендә Татарстанның җыелма командасы 2 нче урынны алды.

2023 елның 28 июленнән 7 августына кадәр Новосибирскида пилотсыз авиация буенча 105 дисциплина һәм тематик юнәлеш: спорт, технология, популяр, мәктәп һәм хәрби-тактик юнәлешләр буенча ярышлар узды.

Аларның йомгаклары буенча республика вәкилләре 22 дисциплина буенча 13 алтын, 9 көмеш һәм 7 бронза медаль алдылар.

III Халыкара төзелеш чемпионатында Татарстан җыелма командасы 14 медаль (7 алтын, 3 көмеш, 4 бронза) алды.

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» федераль проекты кысаларында 2013 елдан 2023 елга кадәр балигъ булу яшенә җитеп, балалар йортларыннан һәм әти-әнине алмаштыручы гаиләләрдән киткән 4 728 бала торак белән тәэмин ителде, шул исәптән 2023 елда – 762 бала.

Укытучы һәм остаз елында укытучы һөнәренең абруен күтәрү буенча чаралар уздырылды: «Укытучы булу яхшы!» психолог-педагогик сыйныфлары слеты, яшь укытучыларның һөнәргә керешүе тантанасы,«Авыл укытучылары белән данлыклы» республика авыл укытучылары форумы, А.С. Пушкин исемендәге мәгариф оешмалары вәкилләре халыкара форумы, I Республика Вагыйзов укулары һ.б. Боларда 65 меңнән артык укытучы катнашты.

Мәктәп бетерүчеләр арасыннан аеруча талантлы һәм кызыксынган яшьләрне укытучы эшенә тарту өчен республикада психолог-педагогик юнәлештәге профильле класслар челтәре үсеш алды. Боларда 6,5 мең укучы катнаша.

Аеруча ихтыяҗ булган әзерлек юнәлешләре буенча, беренче чиратта, авыл районнарында, республикада булачак укытучылар әзерләү эшенә стипендия бирү белән ярдәм итү проекты гамәлгә ашырыла. Бу проектта «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе һәм «Чаллы дәүләт педагогика университеты» дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең 745 студенты катнашты.

Шуларның 70 проценты ике теллелек һәм күп теллелек мәгариф даирәсендә эшләү программалары буенча укый.

## СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ

Ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында фаразланган гомер озынлыгы 75,25 ел тәшкил итте. Әлеге күрсәткеч буенча Татарстан Россия Федерациясе субъектлары арасында 14 нче урынны, ә Идел буе федераль округы субъектлары арасында 1 нче урынны били.

| Күрсәткеч | 2023 елның гыйнвар-декабрь айлары өчен күрсәткеч | Татарстан Республикасы тоткан урын | |
|---|---|---|---|
| | | Россия Федерациясендә | Идел буе федераль округында |
| Туу (1 000 кешегә) | 9,1 | 25 | 1 |
| Төрле сәбәпләрдән үлү (1 000 кешегә) | 10,7 | 20[1] | 1[1] |
| Төрле сәбәпләрдән үлү (1 000 кешегә) | 3,1 | 8[1] | 3[1] |

[1]Тоткан урыннар күрсәткечне арта бару тәртибендә бүлеп исәпләнде (беренче урын – иң түбән (иң яхшы) күрсәткеч, соңгысы – иң югары (иң начар)

2023 елда төрле сәбәпләр буенча халыкның үлеме күрсәткечләре динамикасы (2022 ел белән чагыштырып) (халык санынннан 100 мең кешегә исәпләп):

кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлү очраклары 515,6 дән 498,0 очракка кадәр кимегән (3,4 %);

COVID-19 китереп чыгарган коронавирус инфекциясеннән үлү 50,6 дән 3,5 очракка кимегән (93,1 %);

«башка рубрикаларда классификацияләнмәгән, клиник һәм лаборатор тикшеренүләр вакытында ачыкланган симптомнар, билгеләр һәм нормадан тайпылу очраклары» сәбәпле – 70,5 дан 38,0 очракка (46,1 %); шулардан картлыктан 88,0 %.

2023 елда бөер – 115, бавыр – 72,26 – йөрәк күчереп утырту буенча, балаларда сөяк җелеген күчереп утырту буенча – 10 (беренче тапкыр) операция ясалды.

Югары технологияле 7 медицина үзәгендә 7 917 пациентка рентген-эндоваскуляр операция, 13 458 ашыгыч диагностик коронарография, 6 469 ангиография ясалды.

### «Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты

2023 елда Сәламәтлек саклау» илкүләм проектын гамәлгә ашыруга 3 743,2 млн сум бүлеп бирелде, шуларның 2 619,1 млн сумы – федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 124,1 млн сум. «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының төбәк проектлары кысаларында түбәндәге чаралар уздырылды:

*«Татарстан Республикасында башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты:*

халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәте белән тәэмин итү (201 очыш ясалды, 197 пациент эвакуацияләнде);

Татарстан Республикасы гражданнары профилактик тикшерүләр белән тәэмин ителде;

диспансерлаштыру уздырганда 2 625,4 мең кеше тикшерелде;

мобиль комплекслар республиканың 29 районына чыккан (148 торак пункт), 31,9 мең кеше тикшерелгән, шуларның диспансерлаштыруның II этабы барышында – 14,1 мең кеше;

*«Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты:*

129,5 млн сумга 183 берәмлек медицина җиһазы белән 3 кан тамыры үзәге җиһазландырылды («Төбәкара клиника-диагностика үзәге» ДАСУ, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАСУ, «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү хастаханәсе» ТР ДАСУ) һәм «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, «Зелнодольск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, Казан шәһәренең «12 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ базасында базасында 3 башлангыч кан тамыры үзәге;

йөрәк-кан тамырлары авырулары килеп чыгуны һәм диспансерда күзәтүдә торган, сәламәтлегенә аеруча зур куркыныч янаган авыруларда йөрәк-кан тамырлары авыруларының көчәеп китүен булдырмау өчен дарулар сатып алу (26,7 мең пациент тәэмин ителгән).

*«Онкология авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты:*

71,64 млн сумга 8 берәмлек махсуслаштырылган җиһаз алынды, шул исәптән «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен яңадан җиһазлау өчен;

Казан шәһәренең «20 номерлы шәһәр поликлиникасы» ДАСУ, «Буа үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАСУ базасында яман шешләрнең төп төрләре буенча комплекслы һәм тиз диагноз кую өчен онкология ярдәме күрсәтү буенча 3 амбулатория үзәге ачылды;

*«Балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктурасын булдыруны да кертеп, балалар сәламәтлеген саклау өлкәсен үстерү» төбәк проекты:*

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАСУ территориясендә Онкология, гематология һәм хирургия балалар үзәгендә 3 418 пациент дәваланды;

репродуктив сәламәтлекне саклау максатында 15–17 яшьтәге 96 799 балага профилактик медицина тикшерүе уздырылды (100 %);

17 яшькә кадәр 827 233 балага профилактик тикшерүләр уздырыла (100 %);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» ФДБМУ симуляция үзәгендә перинатология, неонатология һәм педиатрия өлкәсендә 231 белгеч өйрәтелде;

бала тудыру вакытында һәм аннан соң 29 692 хатын-кызга медицина ярдәме күрсәтелде (100 % ).

*«Сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проекты:*

яшь белгечләр – табибларга хуҗалык шартларын җайга салу өчен бер тапкыр бирелә торган акча һәм беренче 3 елда өзлексез эшләгән чорында айлык өстәмә түләү рәвешендә социаль ярдәм чараларын финанслауны тәэмин итү. Республиканың сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә алынган 373 яшь белгечкә (табибка) дәүләт ярдәме күрсәтелә, шуларның 170е бер тапкыр бирелә торган 21 534 сум күләмендә компенсация түләве һәм 2 510 сум күләмендә беренче тапкыр айлык

өстәмә түләү алды.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган табиб-белгечләргә, клиника-лабораториядә диагноз куючы табибларга дәүләт ярдәме чараларын финанслауны тәэмин итү. 100,0 млн сумга 125 грант бирелде;

медицина хезмәткәрләре арасында һөнәри осталык һәм профориентация конкурсларын уздыру.

Өстәмә рәвештә «Земство табибы» һәм «Земство фельдшеры» программалары гамәлгә ашырыла. Бер табибка бер тапкыр бирелә торган түләүнең күләме 1 дән 1,5 млн.га кадәр булды, фельдшерларга – 500,0 дән 750,0 мең сумга кадәр. 2023 елда 127 медицина хезмәткәренә компенсация түләве бирелде, шул исәптән 95 табибка һәм 32 урта медицина персоналына.

*«Бердәм дәүләт мәгълүмати сәламәтлек саклау системасы (ЕГИСЗ) нигезендә сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм цифрлы контур булдыру» төбәк проекты:*

«Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклау өлкәсе» дәүләт мәгълүмат системасын яңартып коруны үстерү, сервер җиһазларын китертү, программа тәэминатына гадәттән тыш булмаган хокуклар сатып алу.

*«Медицина хезмәтләре экспортын үстерү» төбәк проекты:*

Татарстан Республикасы территориясендә 158 илдән килгән 112 934 чит ил гражданына медицина ярдәме күрсәтелде. Проектны гамәлгә ашыруда 65 медицина оешмасы катнашты, шуларның 57се – дәүләт милекчелеге рәвешендә, 8е – хосусый милекчелек рәвешендә;

Мәскәүдә узган «Россия сәламәтлек саклау» халыкара фәнни-гамәли форумы кысаларында декабрьдә республиканың 4 медицина оешмасы («Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» ДАСУ, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар клиник хастаханәсе» ДАСУ, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАСУ, Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ) «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының «Медицина хезмәтләре экспортын үстерү» төбәк проекты кысаларында җиңүче дип табылды.

*«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының башлангыч звеносын яңартып кору» төбәк проекты:*

1 979 берәмлек медицина җиһазы, шул исәптән флюорографлар, маммографлар, стационар рентген-аппаратлары, ультра тавыш аппаратлары, автоматик дефибрилляторлар сатып алынды;

башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтә торган медицина оешмаларына, шулай ук авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда һәм кече шәһәрләрдә урнашкан оешмаларга пациентларны медицина оешмаларына, медицина хезмәткәрләрен пациентларның яшәү урынына кадәр илтү, тикшеренүләр өчен биологик материалларны алып килү, кайбер районнарда яшәүчеләргә дарулар китерү өчен 3 автомобиль сатып алынды;

33 сәламәтлек саклау объекты төзелде (31 фельдшер-акушерлык пункты (алга таба – ФАП), 2 поликлиника (Зеленодольск районының Осиново поселогында өлкәннәр һәм балалар өчен 1 күппрофильле поликлиника, Казан шәһәренең Дербышки поселогында 1 балалар поликлиникасы), «Салават күпере» торак

комплексында күппрофильле поликлиника төзелә башлады (2024 елның декабрендә төгәлләү күздә тотыла);

117 медицина оешмасы бинасына һәм аларның аерымланган структур бүлекчәләренә, шул исәптән авыл җирлегендә, эшчеләр поселокларында, шәһәр тибындагы поселокларда һәм халык саны 50 мең кешегә җитмәгән кече шәһәрләрдә дә, капиталь төзекләндерү уздырылды (9 поликлиника (шул исәптән 1 күчмә объект), 5 участок хастаханәсе, 7 табиблык амбулаториясе һәм 96 ФАП);

**«Сәламәтлек саклау» буенча республика программалары һәм проектлары.**

*«2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасының «Сәламәтлекне яхшырту өчен оптималь медицина тернәкләндерүе» федераль проекты төбәк программасы.*

2023 елда 4 медицина оешмасына өстәмә рәвештә 368 заманча тернәкләндерү җиһазлары (153,54 млн сумга) сатып алынды (Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» ДАСУ, Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» ДАСУ, Казан шәһәренең «7 нче шәһәр поликлиникасы» ДАСУ).

*Башлангыч медицина-санитария ярдәмен яңартып кору программасы.* Модульле ФАПлар һәм амбулаторияләр төзү һәм капиталь төзекләндерү программасы 2012 елдан гамәлгә ашырыла. Барлык ФАПлар бердәй модуль проекты буенча төзелә һәм ахырга кадәр әзер хәлдә тапшырыла, бу исә аларның сыйфатын яхшыртырга һәм бәясен арзанайтырга мөмкинлек бирә.

2023 елда 25 объектта 330,0 млн сумга эш башкарылды, шул исәптән:

326,38 млн сумга 23 объект төзелде, шул исәптән 22 ФАП, 1 гомуми практика табибы офисы;

2 объектта 3,62 млн сумга капиталь ремонт ясалды, шул исәптән Нурлат муниципаль районы ФАП һәм Казанда балалар поликлинкасында.

*«Стационарларны төзү һәм капиталь төзекләндерү» республика программасы кысаларында* финанслауга бүлеп бирелгән лимит кысаларында 2023 елда 3 257,07 млн сумга 31 объект төзелде һәм капиталь ремонт ясалды, шулардан:

3 230,75 млн сумга 30 объект төзекләндерелде;

26,32 млн сумга Казанда МРТ җайланмасы өчен корпус төзелде.

2023 елда республика Россия Федерациясенең 6 субъекты составында «Персональ медицина ярдәмчеләре» пилот проектын гамәлгә ашыруда катнашты. Аның максаты – персональ медицина җайланмалары һәм үзәкләштерелгән диагностика сервисларын файдаланып, шикәр чире һәм артериаль гипертензияле гражданнарга ярдәм күрсәтү. Артериаль гипертензия авыруы булган 1 700 пациент һәм 600 шикәр чире булган пациент дистанцион күзәтүдә тотылды.

**Медицина ярдәме күрсәтү сыйфатын яхшырту**

Медицина ярдәме сыйфатын яхшырту юнәлешләренең берсе – медицина оешмаларында ISO 9000, EFQM халыкара сыйфат менеджменты стандартларын куллануга кертү. Бу системаны куллана башлаган медицина оешмалары республиканың барлык медицина оешмаларының гомуми санынннан 51,8 % тәшкил итте. Сертификат алган медицина оешмалары өлеше – 21,1 %

Сәламәтлек саклау учреждениеләре Европа сыйфат менеджменты кысаларында ISO 9001:2015 ирекле сертификатлаштыру, Россия Федерациясе Сәламәтлек өлкәсенә күзәтчелек оешмасының «Медицина эшчәнлегенең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы» ирекле сертификатлаштыру системасы таләпләренә туры килү сертификатын, пациентның һәм персоналның иминлеге системасы халыкара сертификатын (JCI) алды:

республиканың 24 сәламәтлек саклау учреждениесе ISO халыкара сертификатына ия;

7 сәламәтлек саклау учреждениесе Европа сыйфат менеджменты фондының (EFQM) «Танылган камиллек» халыкара сертификатына ия булды;

9 сәламәтлек саклау учреждениесе Россия Федерациясе Сәламәтлек өлкәсенә күзәтчелек оешмасының «Медицина эшчәнлегенең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы» ирекле сертификатлаштыру системасы таләпләренә туры килү сертификатын, пациентның һәм персоналның иминлеге системасы халыкара сертификатын алды;

1 сәламәтлек саклау учреждениесе JCI халыкара иминлек стандартына туры килә – Чаллының «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе»;

1 учреждениенең Cert International (Словакия) халыкара сертификатына ия – «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» ДАСУ.

Хәзерге вакытта 59 медицина оешмасы медицина эшчәнлегенең сыйфаты менеджменты заманча принципларын куллана башлауларын конкурсларда катнашу аша раслалылар. 2023 елда 5 медицина оешмасы «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсы лауреаты, 7 оешма дипломантлары булдылар.

Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме» ДАСУ кардиохирурглары һәм рентгенэндоваскуляр хирурглары (Р.А. Якубов, М.Р. Шәрәфетдинов, Р.З. Садыйков) Россия Федерациясендә беренче тапкыр буларак кеше тәнендәге иң зур кан тамырын ныгыту операциясе ясадылар, моның өчен 3D-принтерда чәрдәкләнгән аортаның төгәл күчермәсе ясалды, стент-графтта махсус технология кулланып аортадан чыккан артерияләрдә кан әйләнешен саклау һәм яшәү өчен иң кирәкле органнарда кан әйләнешен тәэмин итү өчен үтәли тишемнәр ясалды.

2023 елның 9 июнендә «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгенең Илһам Шакиров исемендәге концерт залында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов катнашында 15-нче «Ел табибы – Ак чәчәкләр – 2023» республика конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды.

Тантананың «Ел табибы» төп номинациясендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш анестезиология-реаниматология буенча баш белгече, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең анестезиология-реаниматология, катастрофалар медицинасы кафедрасы мөдире А.Ж. Баялиева җиңүче дип табылды.

«Сәламәтлек саклау өлкәсе легендасы» дип профессор, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең хирургия авырулары кафедрасы мөдире, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең Атказанган табибы Д.М. Красильников танылды.

«Уникаль очрак» номинациясендә Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме» ДАСУ командасы җиңеп чыкты.

«Иң яхшы башлангыч звено табибы» номинациясендә «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ участок педиатры Н.А. Романов җиңеп чыкты.

«Елның иң яхшы медицина хезмәткәре» номинациясендә «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе шәфкать туташы М.С. Шәрәфетдинова җиңде.

## ХЕЗМӘТ, МӘШГУЛЬЛЕКҺӘМ  СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ

**Хезмәт һәм мәшгульлек.**

2023 елда  Татарстан Республикасында 15 тән алып шуннан өлкәнрәк яшьтәге эшчеләр саны 2 069,6 мең кеше тәшкил итте, шулардан 2 029,6  мең кеше икътисад өлкәсендә эшләде һәм 40,0 мең кешенең (яки эшче көчләрнең гомуми санынннан 1,9 %) эше булмады, әмма алар актив төстә эш эзләде (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе нигезендә алар эшсез дип таныла).

2003 елда эшкә урнаштыру хезмәте органнарына 92,1 мең кеше төрле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иткән, шул исәптән 30,6 мең кеше эш эзләүчеләр сыйфатында исәпкә алынган.  Шушы чор эчендә 21,9 мең кешегә эш бирелгән, шуларның 20 меңе – эшсез граждан.

2024 елның  1 гыйнварына халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә  эшсезләр сыйфатында 4,3 мең кеше теркәлде. Теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе республика эшчеләр санының 0,21 процентын  тәшкил итә (2023 елның 1 гыйнварына – 0,37 %).

2023 ел башы белән чагыштырганда эшсезләр составында түбәндәге үзгәрешләр килеп чыкты:

пенсия яшенә җитеп килгән гражданнар өлеше 18,39 проценттан 24,69 процентка, үз теләге белән эштән киткән гражданнар өлеше – 71,48 проценттан 75,62 процентка, авылда яшәүчеләр өлеше – 27,27 проценттан 29,32 процентка, инвалидлар өлеше – 6,06 проценттан 7,92 процентка, яңадан эшкә урнашырга теләүчеләр өлеше – 7,34 проценттан 8,15 процентка, югары һәм урта белемле гражданнар саны  78,18 проценттан 78,27 процентка артты.

Хатын-кызлар өлеше – 68,49 проценттан 68,44 процентка, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче әти-әниләр өлеше 35,24 проценттан  35,07 процентка,  беренче тапкыр эшкә урнашкан гражданнар өлеше – 3,94  проценттан 1,51 процентка, 16−29 яшькәчә яшьләр өлеше –11,66 проценттан 8,48 процентка кимеде.

Республика буенча эшсезлек уртача 4,28 ай дәвам итте. Республика буенча эшсезлек чорының уртача күрсәткеченнән түбәнрәк күрсәткечләр түбәндәге категорияләрдә күзәтелде: «16−29 яшьлек яшьләр» (2,91 ай), «монопрофильле шәһәрләрдә яшәүчеләр» (4,27 ай), «авылда яшәүчеләр» (4,3 ай). «Хатын-кызлар» категориясендә эшсезлек республика буенча уртача күрсәткечтән югарырак – 4,48, «инвалидлар» категориясендә – 4,96 ай.

2024 елның 1 гыйнварына, эш бирүчеләр мәгълүматына караганда, республикада 48,7 мең вакансия исәпләнгән.

Кисүче, слесарь (төрле белгечлектәге), автомобиль йөртүче, территорияләр һәм производство, хезмәт биналарын җыештыручы, инженер (төрле белгечлектәге), монтажчы (төрле белгечлектәге), тәрбияче (кече тәрбияче), кухня эшчесе кебек һөнәрләргә ихтыяҗ зур.

Хезмәт базарында киеренкелек коэффициенты 2024 елда 1 вакансиягә 0,08 кеше тәшкил итте.

**Кадрлар белән эшләү**

Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча эш төркеме утырышлары кысаларында Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү чараларының үтәлүенә оператив мониторинг ясала,

аларны контрольдә тота, тиешле, шул исәптән халыкны эш белән тәэмин итү буенча чаралар күрелә.

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый тотрыклылыгын тәэмин итү буенча оператив штаб (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы белән расланды) тарафыннан социаль-икътисадый тотрыклылыкны саклау һәм икътисадны үстерүне, аларның ярдәм чараларында катнашуын тәэмин итү буенча предприятиеләр белән килештерелгән эш оештырылды.

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Т.А. Голикова рәислегендә Хезмәт базарын торгызу мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме йөкләмәсен үтәү кысаларында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә оборона-сәнәгать предприятиеләрен (алга таба – ОПК) эшче кадрлар белән тәэмин итү буенча системалы чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру эше оештырылды. Татарстан Республикасы ОПК оешмаларында кадрларга ихтыяҗны мониторинглауны атна саен алып бару оештырылды.

ОПК предприятиеләренең кадрларга ихтыяҗын тәэмин итү буенча индивидуаль планнар төзелде, аларга эш белән тәэмин итү үзәгеннән куратор билгеләү, консультация һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү, вакансияләр ярминкәләре, эш бирүче көннәре уздыру, «Һәркем өчен эш урыннары» телеграм-каналында, сайтларда һ.б. ОПК предприятиеләрен презентацияләү керә.

2022 елның сентябреннән «Россиядә эш урыннары» порталында предприятиеләрнең кадрларга ихтыяҗы турында мәгълүматны актуальләштерү өлешендә ОПК предприятиеләре белән эш алып барыла.

Вакансияләрне биләүне оештыру өчен Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсе учреждениеләре ресурслары, һөнәри мәгариф оешмалары студентлары, шулай ук студентларның хезмәт отрядлары файдаланыла. Моннан тыш, сәнәгать предприятиеләренең вакансияләр ярминкәсенең төбәк һәм бөтенроссия этапларында катнашуы тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән ел саен республика икътисадының өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлеге раслана. Әлеге исемлек нигезендә Татарстан Республикасының 7 елга югары һәм урта һөнәри белемле кадрларны әзерләүгә дәүләт заказы һәм киләсе елга эшчеләргә һөнәри әзерлек һәм яңадан әзерлек бирү программалары эшләнә.

Республикада урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә дәүләт заказын формалаштыруга системалы караш икътисад тармаклары ихтыяҗына карап эшкә алуның контроль саннарын билгеләргә мөмкинлек бирә.

Республика предприятиеләренең фаразланган ихтыяҗларын исәпкә алып, ел саен халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, кадрларга заказ биргән предприятиеләр, шулай ук муниципаль берәмлекләр, һөнәри мәгариф оешмалары белән тыгыз бәйләнештә эшчеләргә һөнәри әзерлек һәм яңадан әзерлек бирү программалары буенча кадрлар әзерләү ихтыяҗы формалаштырыла. Шул ук вакытта әзерлекне күләме һәм юнәлешләре мәгариф оешмалары тарафыннан аз вакыт эчендә заказчыларның (предприятиеләр, эш белән тәэмин итү үзәкләре һ.б.) актуаль

ихтыяҗларын исәпкә алып төзәтелергә мөмкин. Шул рәвешчә, 2023/24 уку елына республиканың 15 көллиятендә һәм техникумында 13 һөнәр буенча кадрларга тизләтелгән әзерлек бирү буенча 550 бюджет урыны буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләме расланды.

Студентларны һәм укучы яшьләрне вакытлы, сезонлы һәм даими эш урыннарына урнаштыруны тәэмин итү, аларга Татарстан Республикасының хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган һөнәр үзләштерү мөмкинлеге бирү, эш белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан ел саен студентларны әзерләү территорияләрен, һөнәрләр исемлеген һәм күләмнәрен билгели, шулай ук студентларны һөнәри белем алуга юллауны тәэмин итә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 мартындагы 436-р номерлы боерыгы).

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге Федераль закон нигезендә студентларны эшче һөнәрләр буенча укыту өчен мәгариф оешмаларын сайлап алуны уздыралар һәм алар белән дәүләт контрактлары төзиләр.

2023 елда студент хезмәт отрядларында катнашкан 548 студент Казан, Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск, Бөгелмә, Чаллы шәһәрләрендә эшче һөнәрләргә укыды.

2024 елда Казан, Әлмәт, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрендә студент хезмәт отрядларында катнашкан 700 дән дә ким булмаган студентны эшче һөнәрләр буенча укыту күздә тотыла.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Демография» илкүләм проектының «Эш белән тәэмин итүгә булышлык» федераль проекты кысаларында гражданнарның аерым категорияләрен һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын гамәлгә ашыруга коммерциячел булмаган оешмаларга федераль бюджеттан субсидияләр формасында грантлар бирү турында» 2021 елның 13 мартындагы 369 номерлы карары нигезендә яшәү урыны буенча эшкә урнаштыру үзәкләренә мөрәҗәгать иткән, ала торган һөнәрләре белемнәре буенча (белгечлекләре буенча) яраклы эш булмаган, урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф программалары буенча белем алуларын тәмамлаучы, 35 яшькә җитмәгән яшьләр арасыннан булган гражданнар укытыла.

2023 елда 8 276 кеше укып чыкты, шул исәптән хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган түбәндәге мәгариф программалары буенча 35 яше тулган 137 кеше: «газ саклавычлы эри торган электродлы дугасыман эретеп ябыштыру остасы», «Web-программист: нульдән беренче проектка кадәр», «Робот техникасы башлангычлары», «Банк сәүдәсе технологияләре», «Адаптив физик культура буенча инструктор-методист», «Маркетплейслар: таныту, аналитика и автоматлаштыру», «Төзелеш производстволарын оештыручы», «Косметик-Эстетист», «Пешекче» һ.б.

2024 елда федераль бюджет хисабыннан Татарстан Республикасында аерым категория гражданнарны, шул исәптән 35 яшькәчә яшьләрнең аерым категорияләрен укытуны оештыру дәвам итә.

Укытуны федераль өч оператор башкара: «Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия Халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе, «Томск илкүләм тикшеренү дәүләт университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү

мәгариф учреждениесе, «Һөнәри белем бирүне үстерү институты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе.

Уку курсын узарга теләгән гражданнар «Россиядә эш урыннары» эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә цифрлы нигезгә корылган бердәм платформа аша һөнәри белем яисә өстәмә һөнәри белем алырга теләүләре турында гариза бирәләр, анда алар катнашу категориясен, уку программасын һәм мәгариф оешмасын сайлыйлар.

Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү оешмаларында яшьләр белән эшләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 9 августындагы карары нигезендә расланган «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында башкарыла. Яшьләрне, шул исәптән һөнәри мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү максатында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыруга юнәлтелгән чаралар кысаларында аларны булган, резервка калдырылган эш урыннарына урнаштыруны оештыра.

2023 елда халыкны эшкә урнаштыру үзәкләренә 13,4 мең яшь граждан мөрәҗәгать итте, шуларның 10,1 меңе (мөрәҗәгать итүчеләрнең 75,4 проценты) эшкә урнаштырылды.

«Социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган гражданнарны һәм инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә урта һөнәри яисә югары белеме булган һәм эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны эшкә урнаштыру өчен, ул белеме һәм квалификациясе турында документлар тапшырган көннән бер ел эчендә, эш урыннарын резервлау башкарыла.

2023 елда әлеге категория гражданнар өчен 93 эш урыны резервланды, аларга 22 кеше эшкә урнаштырылды.

Яшьләрне эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү юнәлешләреннән берсе – эшсез гражданнарга, шул исәптән яшьләргә эшкуарлык эшчәнлеге башлау өчен дәүләт хезмәте күрсәтү. Бу юнәлештә 2023 елда 18 – 29 яшьтәге 161 гражданга дәүләт хезмәте күрсәтелде, 18 – 29 яшьтәге 57 граждан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге ярдәме белән эшкуарлык эшчәнлеген теркәде, аларга әлеге дәүләт теркәвен башкарган очракта бер тапкыр 145,1 мең сум күләмендә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтелде.

Республиканың әйдәүче эш бирүчеләре белән бергәләп һөнәри белем бирү учреждение базасында кадрлар әзерләүнең резерв үзәкләре булдыру эше алып барыла, аларда югары технологик заманча ихтыяҗлар белән бәйле рәвештә квалификацияле эшче кадрлар әзерләү билгеләнешендәге иң яхшы укыту-методика, кадрлар һәм матди-техник ресурслар тупланган.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2023 елда аерым категориядәге гражданнарны эш белән тәэмин итүне стимуллаштыру максатларында юридик затларга, коммерциячел булмаган оешмаларны кертеп, шәхси эшкуарларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2021 елның 13 мартындагы 362 номерлы карары нигезендә 2023 елда Татарстан Республикасында 30 яше тулган 1,8 мең яшь граждан эшкә урнаштырылды. Гражданнарның аерым категорияләрен эшкә алуга субсидияләр программасы кысаларында дәүләт ярдәме эш бирүчеләргә эш тәҗрибәсе булмаган

яшь гражданнарны, шул исәптән көллиятләрне һәм югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны эшкә алуга яхшы этәргеч бирде.

Эш бирүчеләр һәм Татарстан Республикасы һөнәри мәгариф оешмалары арасындагы тыгыз бәйләнеш эш урынын алдан билгеләп белем бирү турында килешүләр төзү тәҗрибәсен ел саен киңәйтергә мөмкинлек бирә. 2023 елда мондый килешүләр 1 194 кеше белән төзелгән.

Моннан тыш, 2023 елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри мәгариф оешмаларының беренче курсына кергән 365 кеше мондый килешүне машина төзү комплексы предприятиеләре («КАМАЗ» ГАҖ, «Туполев» ГАҖ филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы) белән төзеде.

Эш урынын алдан билгеләп белем бирү турында килешүләр төзү кысаларында ярдәм чаралары буларак эш бирүче-предприятиеләр тарафыннан студентларның укуы өчен түләнә, стипендия түләнә, практика узу вакытында хезмәт хакы бирелә, укуларын тәмамлаучылар эшкә урнаштырыла.

Мәгариф һәм сәнәгатьне нәтиҗәле берләштерү өчен Татарстан Республикасында предприятиеләрдә югары уку йортларының база кафедралары эшләү кебек уңай тәҗрибә бар, 122 мондый кафедра эшләп килә.

«Мәгариф һәм педагогика фәннәре» белгечлеге һәм юнәлешләре буенча югары белем бирү мәгариф программалары буенча укый торган һәм арадаш аттестацияне уңышлы узган студентлар, шулай ук өстәмә гомуми белем бирү программалары юнәлешләренә туры килгән белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча югары белем бирү программалары буенча укый торган һәм арадаш аттестацияне уңышлы узган студентлар кимендә ике ел укыганнан соң гомуми белем бирү оешмаларында эшләргә хокуклы.

Республиканың мәктәпләрендә һәм балалар бакчаларында 800 дән артык студент эшли (2022/23 еллар уку елында – 445 студент). 2023 елның 1 сентябреннән көллиятләрнең чыгарылыш курслары студентларына шулай ук мәктәпләрдә эшләү рөхсәт ителә.

«Яшь һөнәр ияләре» һәм «Цифрлы нигездә белем бирү» федераль проектлары кысаларында 64 остаханә заманча җиһазландырылды.

Алдынгы һөнәри әзерлек үзәге һәм «ИТ-клуб» балалар өчен цифрлы нигездә белем бирү буенча 3 үзәк ачылды.

«Профессионалитет» федераль проектында республиканың 14 оешмасы җиңүче дип табылды. 7 укыту-производство һәм мәгариф кластеры булдырылды, 2024 елда тагын 7се ачылачак.

Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Премьер министры урынбасары Л.Р. Фазлыева тарафыннан 2023 елда республиканың эш бирүчеләре һәм мәгариф оешмалары вәкилләре белән Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы утырышларында кабул ителгән карарларны үтәү һәм кадрлар әзерләү өлкәсендә уртак эшне камилләштерү буенча киңәшмәләр уздырылды.

Республика предприятиеләрендә чит ил эшчеләрен эшкә җәлеп итү буенча уңай тәҗрибә тупланды. Мәсәлән, «КАМАЗ» ГАҖ 2021 елдан башлап Үзбәкстан гражданнарын эшкә ала. Чит ил эшчеләренә предприятие хезмәт урынында җайлашуда булышлык күрсәтә. Аларны өйрәтү, торак урыннарга урнаштыру (тулай

тораклар), социаль-көнкүреш шартларын бозмауларын күзәтеп тору һәм башка чаралар оештырылды.

2023 елның 18 декабрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Рәисеннән чит ил гражданнарын эшкә алуның нәтиҗәлелеген арттыру буенча Татарстан Республикасы предприятиеләре белән бергә эшләнгән тәкъдимнәр юлланды.

Мөрәҗәгать йомгаклары буенча бүгенге көндә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын оешкан төстә эшкә чакыру эшен үстерү кысаларында чит ил гражданнарының Россия Федерациясендә аерым бер эш бирүчедә оештырылган (максатчан) чакыру буенча эшкә алынуга хокукын раслый торган документның аерым бер формасын гамәлгә кертү механизмы эшләнә.

**Хезмәт миграциясе өлкәсендәге чаралар**

Чит ил гражданнарын эшкә җәлеп итү һәм эшче көч буларак файдалану механизмы миграция сәясәтенең барлык төп нигезләмәләре кебек үк федераль дәрәҗәдә формалаштырыла.

Татарстан Республикасында чит илдән эшче көчләр җәлеп итү һәм аларның хезмәтеннән файдалану «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка закон актлары нигезендә тормышка ашырыла.

Татарстан Республикасында тышкы хезмәт миграциясенә кагылышлы өлештә тормышка ашырыла торган төп юнәлешләрнең нигезен федераль норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына торган блок тәшкил итә. Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан Россия Федерациясенә виза нигезендә килгән чит гражданнарын эшче көч буларак җәлеп итүгә ихтыяҗны билгеләү һәм чит ил гражданнары тарафыннан хезмәт эшчәнлеге алып баруга квота формалаштыру буенча эш Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан чит илдән эшче көчләр җәлеп итүгә ихтыяҗны билгеләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 23 гыйнварындагы 27н номерлы карары нигезендә алып барыла.

2023 елда Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын эшче көч буларак файдалануга расланган квота 45 чит илдән виза нигезендә эшкә килүче 1 054 гражданга исәпләнгән иде. Әлеге квотага эш бирүчеләрдән 47 гариза да кертелде.

2024 елда Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын эшче көч буларак файдалануга расланган квота 22 чит илдән виза нигезендә эшкә килүче 1 480 гражданны эш белән тәэмин итү мөмкинлеге бирәчәк. Әлеге квота эш бирүчеләрдән 41 гаризаны да үз эченә ала. Иң күпсанлы эшче көчләр Кытай Халык Республикасыннан булыр дип көтелә.

«Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар Россия Федерациясенә килгән чит ил гражданнарын виза алуны таләп итмичә, патент нигезендә эшкә җәлеп итә ала.

Татарстан Республикасында ел саен «Татарстан Республикасында хезмәт базарының үзенчәлекләрен чагылдыручы коэффициентны раслау турында» закон

кабул ителә. 2023 елда төбәк коэффициенты 2,08 булды, Татарстан Республикасында патентның бәясе айга 5 666 мең сум тәшкил итте, 2024 елда төбәк коэффициенты – 2,163, патент бәясе айга 6 229 мең сум тәшкил итәчәк.

**Социаль ярдәм**

Ярлылык дәрәҗәсен киметүнең бер ысулы ул – социаль контракт – авыр тормыш хәлендә калган гражданга яшәү шартларын яхшыртуда ярдәм итү максатында граждан һәм социаль яклау органы арасында төзелгән шартнамә. 2023 елда 5,3 мең социаль контракт төзелде, аларның проценты гражданны эш белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

2018 елдан авылларда даими яшәүче 25 яшькәчә хатын-кызларга беренче баласын тапкан өчен (50 мең сум), 29 яшькәчә хатын-кызларга өченче һәм аннан да күбрәк бала тапкан өчен (100 мең сум) кызыксындыру чарасы буларак өстәмә акчалата түләүләргә республика бюджетында чыгымнар каралган. 2018–2023 елларда 12,6 мең кеше әлеге акчалата түләү алды, шул исәптән 2023 елда – 1,7 мең кеше.

Балалы гаиләләргә түбәндәге өстәмә социаль ярдәм чаралары кертелде:

өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, кеше башына уртача кереме яшәү минимумыннан кимрәк булган гаиләләргә балалар бакчасы өчен түләүгә 100 % компенсация. 2023 елда 3,9 мең граждан әлеге ярдәм чарасыннан файдаланды;

кеше башына уртача кереме яшәү минимумыннан кимрәк булган гаиләләрдәге өч яшькә кадәрле балаларга дарулар сатып алуга 10,0 мең сум күләмендә акчалата түләү. 13,4 мең граждан әлеге түләүләрне алды;

кеше башына уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артык булмаган яңа туган сабыйлары булган гаиләләргә бала кирәк-яраклары белән бүләк комплектлар. 3,0 меңнән артык бүләк комплекты бирелде.

2000 елдан 5 һәм аннан күбрәк бала табып, аларга лаеклы тәрбия бирүче (тәрбия биргән) хатын-кызларны югары дәрәҗәдә бәяләү билгесе буларак, дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале гамәлгә куелды. Соңгы 10 елда «Ана даны – Материнская слава» медале 1,5 мең анага бирелде, аларга 50 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк тапшырылды. 6 яисә аннан күбрәк бала тәрбияләп үстергән аналарга – бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләме алтынчы балага һәм аннан соң килә торган һәр балага хисаплап, бүләкләү көненә аларның өч яше тулган булу шарты үтәлгәндә, тиешенчә 10 мең сумга арта. 2023 елда «Ана даны – Материнская слава» медале белән 24 ана бүләкләнде.

2024 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов Указы нигезендә акчалата түләүнең күләме арттырылды (5 бала өчен – 100 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү, 20 мең сум – аннан соң туган һәрбер бала өчен).

Гаиләнең һәм ата-ана хезмәтенең абруен күтәрү максатларында Татарстан Республикасының яңа дәүләт бүләге – «Ата-ана фидакарьлеге» медале гамәлгә куелды, ул 7 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче яисә тәрбияләгән гаиләләргә биреләчәк. Әлеге медаль белән бүләкләнгән ата-ананың (уллыкка яисә кызлыкка алучының) берсенә 100 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк тапшырыла. 2022 елдан 13 гаилә (24 кеше) бүләкләнде.

2024 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов Указы нигезендә акчалата түләүнең күләме 200 мең сумга кадәр арттырылды

2023 елның 1 гыйнварыннан балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең яңа формасы гамәлгә куелды – бала тапкан һәм бала тәрбияләгән өчен Россия Социаль фонды тарафыннан бирелә торган бердәм пособие, аңа түбәндәгеләр керә:

кеше башына уртача кереме 12 219 сумнан артмаган (Татарстан Республикасында кеше башына уртача яшәү минимумы), бала тапкан һәм 17 яшькәчә бала тәрбияләүче гаиләләргә айлык пособие, ул дифференцияләнгән күләмдә исәпләнә: балалар өчен: Татарстан Республикасында балалар өчен яшәү минимумының 50 % (5 926 сум), 75 % (8 889 сум) яисә 100 % (11 852 сум);

йөклелегенең иртә срогында медицина оешмаларына исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие: Татарстан Республикасында эшкә яраклы кешеләр өчен яшәү минимумының 50 % (6 659,5 сум), 75 % (9 989,25 сум) яисә 100 % (13 319 сум).

2023 елда Россия Социаль фонды бюджетыннан әлеге түләүләргә чыгымнар 25,67 млрд сум тәшкил итте, алар 209 275 балага һәм 2 197 йөкле хатын-кызга түләнде.

Әлеге чаралар ярдәмендә соңгы 10 елда күпбалалы гаиләләр саны 24,4 меңнән (2013 елның 1 гыйнварына) 50,2 меңгә җитте (2024 елның 1 гыйнварына).

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү**

2023 елда махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү буенча системалы эш дәвам иттерелде, сәнәгать предприятиеләренең, бизнес-җәмгыятьләренең, волонтерлар хәрәкәтләренең һәм җирле үзидарә органнары арасында хезмәттәшлекнең төгәл схемасы төзелде.

Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү максатыннан 360,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү каралган (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 23 июнендәге ПУ-438 номерлы Указы).

2023 һәм 2024 елларда Россия Федерациясе Кораллы Көчләре белән хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән аеруча категория хәрби хезмәткәрләргә 305 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләнде.

Татарстан Республикасында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү эше оештырыла, түбәндәге бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр билгеләнде:

махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның 18 яшькәчә һәр баласына 20 мең сум күләмендә;

махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына 2,0 млн сум күләмендә.

Татарстан Республикасында махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына ярдәм итүнең түбәндәге чаралары каралган:

яңа туган балалары булган гаиләләрне, кеше башына уртача керемне исәпкә алмыйча, бала кирәк-яраклары өчен бүләк комплектлары белән тәэмин итү;

гаилә әгъзалары булып торучы пенсионерларга һәм 60 һәм 55 яше тулган гражданнарга (тиешенчә хатын-кызларга һәм ир-атларга) санаторий-курорт дәвалануы өчен беренче чиратта юлламалар бирү;

олы яшьтәге гражданнарга, I һәм II төркем инвалидларга өйдә бушлай социаль хезмәтләр күрсәтү;

олылар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда, психик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернат-йортларда, мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә өстенлекле хокук бирелү;

гаилә әгъзалары булып торучы инвалид балаларга мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә өстенлекле хокук бирелү;

тиешле эш табу максатында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләрендә теркәлеп, гариза калдырган гаилә әгъзасын, аңа туры килә торган эш табу мөмкин булмаган очракта, эшсез дип тану вакытын кыметү (тиешле эш эзләүдә булышуны сорап дәүләт хезмәт күрсәтү турында гариза бирелгән көннән соң 3 көннән дә артык булмаган вакытта);

Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча көндезге уку бүлекләрендә укучы студентларга бер тапкыр кайнар ризык белән бушлай туклану мөмкинлеге бирелү;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының 1–11 сыйныф укучыларына көненә ике тапкыр бушлай кайнар ризык белән (иртәнге һәм көндезге аш) туклану мөмкинлеге бирелү;

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче 7 яшьтән алып 17 яшькә кадәрле балалары булган гаиләләргә ялга юлламалар алуга беренчел хокук бирелү;

18 яшькә кадәрле балаларга һәм әтисенә йә әнисенә (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләрендә уздырыла торган чараларга бушлай керү хокукы бирелү.

Түбәндәге өстәмә ярдәм чаралары расланды:

билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре тарафыннан аларның шәхси эш ачуга бизнес-планнарын беренчел чиратта карап тикшерү;

3 һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләргә, әгәр әтисе йә әнисе хәрби хезмәткәр булган очракта, гражданнарның Татарстан Республикасында 5 ел дәвамында даими яшәргә тиешлеге таләбен исәпкә алмыйча, җир кишәрлекләре бирү;

гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан бер йорт исәбеннән йортка газ уздыру һәм өй эченә куела торган газ җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга тотылган чыгымнар исәбеннән, ләкин 100 мең сумнан да артык булмаган күләмдә субсидия бирү;

Россия Федерациясе Президентының 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Указының 2 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән затларның һөнәри белем алуын һәм өстәмә һөнәри белем алуын оештыру;

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган гражданнар 2021 ел салым чорына транспорт салымыннан азат ителә;

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу шарты белән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби

хезмәткә алынган, иреклеләр формированиеләрендә хезмәт итү турында (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ирекле рәвештә ярдәм итү турында) контракт төзегән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына бушлай юридик ярдәм күрсәтү каралган.

Махсус хәрби операциядә барлык катнашучыларның балаларына уку йортларына кергәндә өстенлекле хокук бирелә. 2023 елда махсус хәрби операциядә барлык катнашучылар һәм аларның балалары өчен аерым квота кысаларында югары уку йортларына керүгә махсус хокук билгеләнде.

Шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның балаларына югары уку йортларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында буш урыннар булганда һәм академик бурычлары булмаган очракта, түләүле төркемнәрдән бюджетка күчү хокукы бирелә.

Шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә хезмәт итүче, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарга, махсус хәрби операция барышында ирекле рәвештә хәрби бурыч үтәүче гражданнарга, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе куркынычсызлык федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре һәм аларның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) әлеге категория гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү тәкъдим ителә:

мәктәпкәчә белем бирү программасы нигезендә эшләүче Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмасына баланы чиратсыз урнаштыру хокукы бирелү;

мәктәпкәчә белем бирү программасы нигезендә эшләүче Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмасында баланы тәрбияләгән өчен түләүдән азат ителү;

муниципаль мәгариф оешмаларының 1–11 сыйныф укучыларына көненә ике тапкыр бушлай кайнар ризык белән (иртәнге һәм көндезге аш) туклану мөмкинлеге бирелү;

18 яшькәчә балаларга һәм әтисенә йә әнисенә (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль мәдәният учреждениеләрендә уздырыла торган чараларга бушлай керү хокукы бирелү.

Казан шәһәренең район администрацияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ташламалар бирелүне раслау өчен «Батыр» пластик карталары бирелә, аның аша балалар мәдәният, спорт учреждениеләренә һәм күңел ачу паркларына бушлай керә ала.

**«Демография» илкүләм проекты**

2023 елда «Демография» илкүләм проекты максатларына ирешүгә юнәлдерелгән төбәк проектлары кысаларында түбәндәге чаралар тормышка ашырылды:

*«Балалар туганнан соң гаиләләргә финанс ярдәме күрсәтү» төбәк проекты:*

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация бирелде;

республика территориясендәге авылларда, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга беренче, өченче һәм аннан соңгы балалар туу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде;

өч һәм аннан күбрәк игезәк балалар тәрбияләүче гаиләләргә пособиеләр бирелде;

«Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга, «Ата-ана фидакарьлеге» ордены белән бүләкләнгән ата-аналарга (уллыкка алучыларга) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде;

уртача кереме Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән җан башына туры килә торган яшәү минимумыннан артык булмаган гаиләләрдәге ясалма катнаш туклануда булган һәм хроник авырулары булган 36,1 мең өч яшенә кадәр бала бушлай махсус балалар ризыгы белән тәэмин ителде;

1 991 экстракорпораль орлыкландыру процедурасы уздырылды.

*«Халыкка эшкә урнашуда ярдәм итү» төбәк проекты:*

федераль бюджет хисабыннан 8,3 мең кеше укырга җибәрелде, шул исәптән:

халыкны эш белән тәэмин итү органнарында теркәлгән, эштән азат итү куркынычы алдында калган гражданнар, пенсия алды яшендәге гражданнар һәм 50 яшь һәм аннан да өлкәнрәк булган 3,4 мең эшсез граждан;

баласына 3 яшь тулганчы бала карау буенча отпускта булган, хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм 7 яшьне кертеп, мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбияләүче 4,8 мең хатын-кыз;

35 яшькәчә (35 яшьне кертеп), төрле категория яшьләр арасыннан 137 кеше.

Укыту хезмәт базарында ихтыяҗ булган профессияләр һәм белгечлекләр буенча, шул исәптән эшкә алу турында гарантия белән тәгаен эш бирүче заказы буенча алып барыла. Укытудан соң эшкә урнаша алу дәрәҗәсе 84 процент тәшкил итә.

2023 елда Татарстан хезмәт базарында киеренкелекне киметү буенча өстәмә чаралар уздыруда катнашты, моңа 188,6 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән федераль бюджеттан – 186,7 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1,9 млн сум. Әлеге чаралар:

эшсез калу куркынычы алдында торган 1,7 мең кешегә вакытлыча эш урыны тәкъдим итү нигезендә керемнәр һәм халыкның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен саклап калу;

0,7 мең эшсез граждан өчен иҗтимагый эшләр оештырылды;

эшсез калу куркынычы алдында торган 1,3 мең хезмәткәргә оборона-сәнәгать комплексының 9 предприятиесендә һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирелде;

*«Өлкән буын» төбәк проекты:*

озак вакытка исәпләнгән һәм гаиләдә тәрбияләүне үстерү системасы оештырылган. 2023 елда финанслау күләме 87,3 мең сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджеттан – 70,7 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 16,6 млн сум. Уздырылган чаралар нәтиҗәсендә:

бушлай социаль пакет кысаларында 6,0 мең өлкән яшьтәге гражданга һәм инвалидка озак вакытка исәпләнгән тәрбиягә алу хезмәте, 420 өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) тәрбияче хезмәте күрсәтелде;

көндезге бүлекләрдәге (төркемнәрдәге) когнитив һәм менталь авырулары булган 1,1 мең өлкән яшьтәге кеше һәм инвалид көндезге вакытта эш белән тәэмин ителде;

2,9 мең гаилә әгъзасына гаиләдә тәрбияләү нигезләре өйрәтелде;

авылларда яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк булган 61,7 мең граждан медицина оешмаларына урнаштырылды, шул исәптән 45,3 мең кеше – диспансеризация һәм профилактик медицина тикшеренүләре узды;

33 өлкән яшьтәге граждан (инвалид) «Өлкәннәрне тәрбия алучы гаилә» проекты кысаларында гаиләгә тәрбиягә алынды;

65 яшьтән өлкәнрәк булган затларның пневмококк йогышлы авыруына каршы торучанлыгын арттыру максатларында вакцина эшләнде.

озак вакытка тәрбиягә мохтаҗ гражданнарның шәхси исәбен алып баруны тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасын яңартып кору өчен җиһазлар сатып алынды.

*«Җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту» төбәк проекты:*

йогышлы булмаган авыруларны профилактикалау, халыкка сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру һәм санитария-гигиена таләпләрен үтәү турында мәгълүмат бирү;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә сидектә наркотик матдәләрне ачыклау өчен реагентлар сатып алынды;

лекторлык осталыгы конкурсы уздырылды, басма продукция (белешмәләр) бастырып чыгарылды.

*«2019–2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның ирекле рәвештә Татарстан Республикасына яшәргә күчеп килүенә булышлык итү» дәүләт программасы*

Чит илләрдә яшәүче ватандашларны җәлеп итү ярдәмендә Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм демографик үсешенә булышлык итү максатларында «2019–2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның ирекле рәвештә Татарстан Республикасына яшәргә күчеп килүенә булышлык итү» дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) гамәлдә.

2023 елда программаны финанслау күләме 0,9 млн сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджеттан – 0,54 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан – 0,36 млн сум.

Программада катнашучылар Дәүләт программасында катнашуга дәгъва кылучы ватандашлар кандидатуралары гаризаларын карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан һөнәри һәм квалификация таләпләрен һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең балл системасы нигезендә сайлап алына. Мәгариф, сәламәтлек саклау, авыл хуҗалыгы, спорт, мәгълүмат-коммуникация технологияләре, машина төзелеше тармаклары эшкә урнашу өчен өстенлекле өлкәләр булып тора.

Сайлап алу йомгаклары буенча 185 ватандаш һәм аларның 471 гаилә әгъзасы Комиссиянең уңай бәяләмәсен алды.

Әлеге гражданнар Таҗикстан Республикасы (74 кеше), Төрекмәнстан Республикасы (34 кеше), Үзбәкстан Республикасы (27 кеше) һәм башка илләрдән.

Дәүләт программасында катнашуга кандидатлар Казан, Чаллы, Зеленодольск һәм башка шәһәрләргә күчеп килергә планлаштыра.

Дәүләт программасы программада катнашучыларга һәм аларның эшкә сәләтле яшьтәге балигъ булган гаилә әгъзаларына һөнәри һәм өстәмә һөнәри белем алуда, медицина таныклавы узуга финанс ярдәме күрсәтү, торак алуда беренчел ярдәм итү мөмкинлеге күздә тотыла.

# ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ

Татарстан Республикасы лаеклы рәвештә илебезнең иң яхшы спорт төбәге, ә Казан шәһәре спорт башкаласы дип танылды.

## Спорт инфраструктурасы

Татарстан – Россия Федерациясендә спорт объектлары белән тәэмин ителгән төбәкләр арасында лидерларның берсе. Гражданнарга бер үк вакытта спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирелгән спорт корылмалары белән тәэмин ителеш 2023 ел йомгаклары буенча 71,7 процент тәшкил итте.

Республикада барлыгы 11 820 спорт корылмасы эшли, шулардан 6 396 бер яссылыкта урнашкан спорт корылмасы, 2 083 спорт зал, 46 стадион, 56 ябык боз аренасы, 31 манеж (10 җиңел атлетика буенча, 21 футбол), 293 йөзү бассейны, 91 чаңгы базасы, 1 биатлон комплексы, 2 ишкәк ишү базы, 185 ату буенча спорт төрләре өчен һәм 2 636 башка спорт корылмасы эшли.

2023 елда 139 спорт корылмасы төзелде.

Универсаль спорт мәйданчыклары төзү буенча республика программасы кысаларында 2013 елдан 2023 еллар эчендә 1 153 спорт корылмасы, шул исәптән 40 хоккей тартмасы, 44 блоклы модульле чаңгы базасы һәм 15 каркас-тент капламлы футбол кыры. Әлеге максатларга барлык чорга Татарстан Республикасы бюджетыннан 4 488,3 млн сум акча бүлеп бирелде.

2023 елда 4 универсаль спорт мәйданчыгы (Казан шәһәрендә ике, Чаллы шәһәрендә һәм Саба муниципаль районында берешәр); 4 ябык манежлы каркас-тент капламлы футбол кыры (Азнакай, Актаныш, Апас, Питрәч муниципаль районында) төзелде.

2023 елда капиталь төзекләндерү республика программасы кысаларында 15 спорт объектында 668,5 млн сумга төзекләндерү эшләре башкарылды. 2020 елдан барлыгы 82 спорт объекты капиталь төзекләндерелде.

«Спорт – тормыш нормасы» федераль проекты кысаларында түбәндәге чаралар тормышка ашырылды:

Әгерҗе, Баулы, Кама Тамагы, Лаеш, Минзәлә муниципаль районнарында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» мәйданчыклары өчен җиһазлар китертелде һәм урнаштырылды;

23 спорт мәктәбе өчен (10 республика һәм 13 муниципаль) җиһазлар һәм кирәк-яраклар сатып алынды.

Бизнес-спринт (Мин спортны сайлыйм)» федераль проекты кысаларында 2023 елда түбәндәге чаралар тормышка ашырылды:

Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында модульле спорт залы;

3 «акыллы» спорт мәйданчыгы төзелде (Казан, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә);

дәүләт һәм хосусый партнерлык кысаларында Чаллы һәм Әлмәт шәһәрендә «ФИЗРА» спорт үзәге» физкультура-сәламәтләндерү комплексы» спорт инфраструктура объектлары һәм Казан һәм Зеленодольск шәһәрләрендә аларның камилләштерелгән вариантларын төзү проектын тормышка ашыру;

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның аерым карары буенча 2023 елда Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында мини-футбол һәм волейбол уеннары өчен ябык универсаль спорт залы, Лениногорск шәһәрендә «Нефтяник» боз сарае, Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында «Сабантуй» ат спорты комплексы, Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында Бадминтон үзәге төзелде.

**Физик культура**

«Демография» илкүләм проектының «Спорт – тормыш нормасы» дигән төбәк проекты кысаларында 2030 елга системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр күләмен 75 процентка җиткерү планлаштырыла.

2023 елда системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең (3–79 яшь) өлеше 62,9 процент тәшкил итте (2022 елда – 57,8), бу исә 2,29 млн кеше дигән сүз.

Республикада «TIMERMAN» һәм «Яшел Фитнес» социаль спорт проектлары гамәлгә ашырыла. Әлеге проектлар халыкны системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итүгә юнәлтелгән.

2023 елда «TIMERMAN» спорт проекты кысаларында 10 чара (Казан, Әлмәт, Чаллы, Иннополис шәһәрләрендә; «Свияжск утрау-шәһәрендә») анда Россиянең 81 төбәгеннән 25 мең кеше катнашты. «Казан марафоны» масштаблы ярышында йөгерү белән шөгыльләнүче 12 меңнән артык кеше катнашты.

**Спорт резервын әзерләү**

Татарстанда 162 спорт мәктәбендә, шулардан 27 спорт мәктәбе «олимпия резервы» статусына ия, аларда 79 спорт төре укытыла. Барлыгы спорт мәктәпләрендә 93 751 кеше шөгыльләнә. 3 146 тренер-укытучы тренерлык эшчәнлеге алып бара.

2024 елда спортта югары казанышларга ирешкән өчен 1 065 спортчы айлык стипендия ала, шулай ук спортчылар әзерләгән өчен республиканың 72 тренеры-укытучысына өстәмә түләү билгеләнде.

2023 елда бик күп санда спорт дәрәҗәсе һәм разряд бирелде: 3 Россиянең атказанган спорт мастеры, 11 халыкара класслы Россия спорт мастеры, 274 Россия спорт мастеры һәм 1 504 спорт мастерына кандидат.

**Спорт казанышлары**

Республикада 138 спорт федерациясе эшли, алар 140 спорт төрен үстерү өчен җаваплы.

Ел саен бөтенроссия һәм халыкара ярышларда яулап алынган медальләр санының уңай динамикасы күзәтелә. Татарстан спортчылары тарафыннан бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге ярышларда 965 медаль яулады, шулардан 292 – алтын, 325 – көмеш, 348 – бронза.

Россия җыелма командаларына Татарстаннан 957 спортчы кертелде, шулардан спортның олимпия төрләре буенча – 461 спортчы.

Татарстан спортның 35 база төре буенча җаваплы, шуларга 33 спортның олимпия төре керә, шул исәптән 27 индивидуаль (бадминтон, бокс, велосипед спорты, гольф, байдаркаларда һәм каноэда ишү, ишкәк ишү, дзюдо, җиңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү, суга сикерү, ядрә белән ату, синхрон йөзү, спорт көрәше, спорт гимнастикасы, стендка ату, теннис, триатлон, тхэквондо, авыр атлетика, фехтование,

фигуралы шуу, нәфис гимнастика, ике төрдә чаңгы ярышлары, чаңгы ярышлары, чаңгыда трамплиннан сикерү, сноуборд); 6 уен (су полосы, волейбол, регби, футбол, чирәмдә хоккей, хоккей), 2 паралимпия төре (терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарланган затлар өчен спорт), 1 сурдлимпия төре (сукырлар өчен спорт).

2023 еллар сезонында спорт ареналарында һәм подиумнарында түбәндәге һөнәри клублар уңышлы чыгыш ясады: беренче тапкыр «УНИКС» баскетбол клубы Россия чемпионаты һәм ВТБ бердәм лигасы җиңүчесе булды; «Динамо-Ак Барс» чирәмдә хоккей буенча ир-атлар клубы 21 нче тапкыр Россия чемпионатында җиңү яулады; «Зенит-Казан» ир-атлар волейбол клубы 11 нче тапкыр волейбол буенча Россия чемпионы титулын яулады; «Ак Барс» хоккей клубы Континенталь хоккей лигасы көчен призеры булды; «Рубин» футбол клубы Футбол буенча илкүләм лигасы беренчелегендә җиңүче; «Стрела» регби клубы һәм «Ирбис» футбол клублары Россия Кубогы иясе булды.

**Спорт чаралары**

2023 елда Татарстан территориясендә Махсус Олимпиада Бердәм Уеннары, «Фиджитал лайв» халыкара уены тест чаралары, «Дөнья кубогы» шпагаларда фехтование буенча халыкара ярышлары, спорт гимнастикасы буенча Россия чемпионаты, «Ак Барс Кубогы» каратэ буенча халыкара турнир, «МАТЧ Урам уеннары» IV бөтенроссия урам уеннары, Футбол буенча Россия супер кубогы, йөзү буенча Россия кубогы финалы, «Милләтләр кубогы» чирәмдә хоккей буенча ир-ат һәм хатын-кыз командалары арасында халыкара турнир, тхэквондо буенча ГТФ «Дөнья кубогы» халыкара ярышлары, синхрон йөзү буенча «Федерация Кубогы» халыкара ярышлары, суга сикерү буенча «Россия Федерациясе Кубогы» халыкара ярышлары кебек 50 зур спорт чарасы оештырылды.

## ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕ

Республикада яшьләр сәясәте буенча муниципаль берәмлекләр, югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары, предприятиеләр, яшьләр оешмалары белән киң колачлы эш алып барыла.

### Яшьләрнең ирекле хәрәкәте

Республиканың 180 мең волонтердан һәм 1 247 ирекле хәрәкәте оешмаларыннан торган волонтерлар берләшмәсе «Игелекле Татарстан» бердәм брендына тупланды.

Муниципаль волонтерлар үзәкләре һәр муниципаль районда төзелде, 15 муниципаль берәмлектә ирекле хәрәкәтенә ярдәм итү һәм үстерү буенча муниципаль программалар кабул ителде, ирекле хәрәкәтен үстерү стандартларын гамәлгә кертү буенча эш дәвам иттерелә.

2023 ел конкурсы йомгаклары буенча республика 2024 елда ирекле хәрәкәтен үстерүгә 7,6 млн сум күләмендә федераль субсидия алды. Әлеге акча «Добрый край – Игелек җире» муниципаль волонтерлар үзәкләренә ярдәм итү республика конкурсын һәм Бөтенроссия конкурсының төбәк этабында җиңгән проектларны  гамәлгә ашыруга тотылачак.

Республиканың ирекле хәрәкәте һәр гражданга үзен кызыксындырган ирекле һәм хәйриячелек чаралары буенча юнәлеш бирүче «Игелек Үзәге» – иҗтимагый үсеш һәм волонтерлар, хәйриячелек һәм гражданлык башлангычларына булышлык итү үзәге федераль социаль франшиза составына керә. Татарстан Республикасында барлыгы 16 «Игелек Үзәге» ачылды.

2023 елда Биектау муниципаль районында «Игелек» волонтерлар өчен профильле лагерь ачылды. Лагерь «Без катнашабыз» мәктәп укучыларының ирекле (волонтерлар) хәрәкәтен үстерү республика проектының яшьләрне ирекле (волонтерлар) эшчәнлегенә җәлеп итү буенча комплекслы программаның бер өлеше булып тора.

2023 елда ирекле хәрәкәте өлкәсендәге казанышлары өчен «Кайнар йөрәк» бөтенроссия иҗтимагый-дәүләт инициативасының күкрәк билгесе белән Тәтеш муниципаль районыннан янган өйдән өлкән яшьтәге хатын-кызны коткарган Әбелханов Булат, Рыжов Игнат, Симаков Евгений; актив гражданлык позициясе һәм социаль  әһәмияткә ия башлангычларны гамәлгә ашыруга өлеш кертүе өчен Афонина Алена; үз гомере хисабына елгада батучы кызны коткарган Әхмәтгалиев Данил (вафатыннан соң) (Кукмара муниципаль районы) бүләкләнде. Экстремаль шартларда кешеләрне коткарганда кыюлык һәм тәвәккәллек күрсәтүе өчен Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин Казан студенты Данил Әхмәтгалиевны вафатыннан соң «Һәлак булучыларны коткарган өчен» медале белән бүләкләде.

### Патриотик тәрбия

Республика Россия Федерациясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча алдынгылар сафында. Ел саен 200 мең яшь татарстанлы эзләүчеләр отрядлары мәктәпләрендә, хәрби-патриотик сменаларда, хәрби хезмәт нигезләре буенча җыемнарда, тарихи реконструкцияләрдә һәм башка чараларда катнаша.

Республикада 174 хәрби-патриотик клубы бар, аларда 14,3 мең яшүсмер катнаша.

2023 елның иң әһәмиятле вакыйгасы булып «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 2023 елның 9 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул итү тора.

Яшьләр учреждениеләре челтәрендә «Геройлар вахтасы» дигән яңа федераль проекты гамәлгә ашырыла. 17 Россия Герое сәламәтләндерү лагерьларында һәм кадет сыйныфларында батырлык дәресләре сериясе уздырды.

2023 елда Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 10 сыйныф укучылары (үсмерләре) катнашында биш көнлек уку сменалары оештырылды, алар «Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (Казан шәһәре) (10 смена, 1 629 үсмер), «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (12 смена, 840 мәктәп укучысы); «Чистай муниципаль районының «Ватан» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (6 смена, 360 мәктәп укучысы) базасында үткәрелде. Әлеге чараларда катнашучы балалар хәрби әзерлек нигезләренә, беренчел медицина ярдәме күрсәтергә өйрәнә, физик әзерлек ала.

Биектау муниципаль районының «Чайка» балаларны сәламәтләндерү лагерында һәм Татарстан Республикасының «Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге республика үзәге» дәүләт автоном учреждениесендә «Геройлар вакыты» өч профильле хәрби-патриотик смена узды, анда 800 бала катнашты.

Уникаль проект – «Яшь десантчы» хәрби-патриотик профильле җәйге палата лагерьлары эшен дәвам итә. 2023 елда 7 лагерь ачылды, аларда 3 мең кеше, шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган 357 бала ял итте, 150 дән артык егет һәм кыз парашюттан сикерде. Лагерь сменалары барышында яшүсмерләр һава-десант, көрәш һәм кул көрәше, корал белән куллану һәм хәрби техникада йөрү күнекмәләре алды, тактик һәм медицина әзерлеге узды.

2024 елда «безнең заман геройлары» – яшь укытучылар, табиблар, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрбиләр, предприятие һәм социаль учреждение хезмәткәрләре, зур уңышларга ирешкән яшь эшкуарлар турында проект эшләү планлаштырыла.

«Җиңү» бөтенроссия хәрби-спорт уенының республика этабында яшьләр үзәкләре, яшүсмерләр клублары һәм патриотик клублар, берләшмәләр, шулай ук мәгариф оешмалары, урта һөнәри белем бирү оешмалары, кадет мәктәпләрендә һәм өстәмә белем бирү учреждениесе оешмалары укучылары командалары катнашты. 2023 елда «Идел буе федераль округының Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Татарстан кадет корпусы» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе командасы җиңүчесе булды.

2023 елның 24–25 июнендә Советлар Союзы Герое П.М. Гавриловның туган ягы Питрәч муниципаль районының Әлбәдән авылында «Әлбәдән – 2023» V юбилей тарихи реконструкция фестивале уздырылды. Фестивальдә 300 реконструктор катнашты һәм 12 меңнән артык кеше тамаша кылды.

2023 елның 16 августыннан 19 августына кадәр Югары Ослан муниципаль районының Соколка тавында «Җиңелмәс һәм Легендар» юбилей хәрби-тарихи фестивале кысаларында яшьләрне туган як тарихын өйрәнүгә җәлеп итү укыту-тренировка җыемнары булды.

**Яшьләр мәйданчыклары**

2023 елда яшьләр сәясәтенең 36 объектында эшләр башкарылды, шул исәптән:

түбәндәгеләр төзелде:

2 яшьләр үзәге (Казан шәһәре, Теләче муниципаль районы);

7 балалар өчен сәламәтләндерү лагеренда объектлар (Кама Тамагы, Кукмара, Тәтеш, Тукай, Яңа Чишмә, Ютазы муниципаль районнары, Казан шәһәре);

түбәндәгеләр төзекләндерелде:

6 яшьләр үзәге (Азнакай, Алексеевск, Баулы, Буа, Лениногорск, Мөслим муниципаль районнары);

7 балалар өчен сәламәтләндерү лагере (Әтнә, Биектау, Зеленодольск, Лаеш, Мөслим, Апас муниципаль районнары);

4 яшьләр (яшүсмерләр) клубы (Әлки, Әлмәт, Зеленодольск, Нурлат, Ютазы муниципаль районнары, Чаллы шәһәре, Казан шәһәре);

10 психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге (Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Бөгелмә, Зеленодольск, Чистай муниципаль районнары).

«Мәгариф» илкүләм проектының «Яшьләр төбәге» федераль проекты кысаларында 2023 елда Әлмәт шәһәрендә «Креатив процесслар фабрикасы» Казан шәһәрендә «Вертолет» яшьләр үзәге капиталь төзекләндерелде, әлеге эшләргә 168 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән 136,0 млн сум – федераль бюджеттан, 32,0 млн сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан. 2024 елда тармак проектларын үтәүгә һәм Химиклар мәдәният йортын төзекләндерүгә 232,8 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән 188,5 млн сум – федераль бюджеттан, 44,3 млн сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан.

**Балаларның ялын һәм сәламәтлеген ныгытуны оештыру**

Төрле милек рәвешендә булган 1 554 сәламәтләндерү учреждениесендә 208 409 бала төрле формада ял һәм сәламәтләндерү чаралары оештырылды, шулардан 796 лагерь – көндезге (мәктәп яны), 115 шәһәр яны стационар сәламәтләндерү лагере, 581 лагерь – хезмәт һәм ялны оештыру, 46 палата лагере, 13 санаторий-курорт учреждениесе, 4 лагерь Кара диңгез яр буенда.

Җәйге чорда балаларның сәламәтлеген ныгыту кампаниясе барышында 148 704 баланың ялы оештырылды, шулардан 131 шәһәр яны лагерьларында 81 029 бала, 1 377 көндезге (мәктәп яны) лагерьларда 67 675 бала ял итте. Палата тибындагы 46 лагерьда 11 457 кеше ял итте. «Кара диңгез» республика үзәге тарафыннан Кара диңгез яр буендагы 4 балалар өчен сәламәтләндерү лагерында 4 886 баланың ялы оештырылды. Махсуслаштырылган сменаларда сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле 1 300 бала ял итте.

Көзге каникуллар чорында балалар өчен сәламәтләндерү лагерьларында мобилизацияләнгән гражданнарның 709 баласы ял итте.

Луганск һәм Донецк халык республикаларыннан килгән 922 баланың сәламәтләндерү лагерында ялы оештырылды (психолог ярдәме, экскурсияләр, иҗади

һәм спорт чаралары кергән ял итү программасы).

Барлык сәламәтләндерү лагерьлары үз эшенә тәрбия программасын кертте, ул флаг күтәрү тантанасы һәм дәүләт гимнын башкару, цифрлы гигиена һәм цифрлы тәрбия мохите, сәламәт яшәү рәвеше, шулай ук һөнәр сайлау һәм «Минем Татарстан» төбәк модульләрен һәм башка чараларны үз эченә ала.

2023 ел Россия Федерациясендә Укытучы һәм остаз елы һәм Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителү белән бәйле рәвештә балаларны сәламәтләндерү лагерьларында тематик чаралар комплексы оештырылды.

**Вакыйгалар һәм чаралар**

Яшьләргә үз сәләтләрен һәм мөмкинлекләрен күрсәтү өчен шартлар тудыру яшьләр сәясәтенең иң өстенлекле бурычларыннан берсе. 2023 елда иҗади юнәлеш проектларында  480 мең бала һәм яшьләр катнашты.

Түбәндәге аеруча зур чаралар уздырылды:

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» халыкара икътисадый саммиты кысаларында IX Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең яшь эшкуарлар форумы;

VII Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең глобаль яшь дипломатлар форумы (чараның төп темасы – «Күпполяр яңа дөнья дипломатиясе»);

VI глобаль яшь дипломатлар форумы;

Казан глобаль яшьләр саммиты;

II Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең халыкара яшьләр фәнни конгрессы;

БРИКС һәм ШОС яшь лидерлары премиясе – БРИКС һәм ШОС илләренең талантлы яшьләрен ачыклау һәм яшь лидерларының өлеше тануга юнәлтелгән халыкара конкурс.

2023 ел дәвамында республикада яшьләр  өчен бик күп вакыйгалар булып узды, түбәндәгеләр алар арасында иң зурлары булып санала:

«Ел студенты – 2023» XIX республика премиясе;

«Югары уку йортының иң яхшы яшь укытучысы – 2023» беренче конкурсы;

һөнәри белем бирү оешмалары арасында «Ел студенты» бөтенроссия премиясе;

студентлар транспорт гранты (югары уку йортлары һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында укучылар арасында финанс ярдәме алучыларны сайлап алу буенча конкурс) (9 меңнән артык гариза, финанслау күләме – 60 млн сум);

XXIII «Созвездие-Йолдызлык – 2022» республика ачык телевидение яшьләр эстрада сәнгате фестивале;

XII «Наше время – Безнең заман» эшләүче яшьләр иҗатының еллык ачык республика телевидение фестивале (Татарстан Республикасының 190 предприятиесе һәм оешмасы катнашты, «СИБУР. Түбән Кама нефтехим» командасы гран-при яулады);

«Татарстан Республикасының яшь рационализаторы һәм уйлап табучысы» конкурсы;

Эшләүче яшьләр форумы (конгрессы);

«Әлбәдән–2023» хәрби уеннары» V юбилей бөтенроссия тарихи реконструкция фестивале;

Югары Ослан муниципаль районының Соколка тавында «Җиңелмәс һәм

Легендар» юбилей хәрби-тарихи фестивале;

«Яшьләр турында: Киләчәк гаиләсе. Киләчәк сәламәтлеге» республика конференциясе;

Татарстан Республикасының яшь гаиләләр фестивале;

«Сәләт» халыкара яшьләр мәгърифәти форумы;

«Ел казанышы – 2023» һөнәри белем бирү оешмаларында укучылар өчен республика премиясе»;

COMBOnation брейк-данс һәм урам сәнгате буенча халыкара турнир;

«Город – RE’ACTOR» креатив индустрияләр буенча төрле жанрлар фестивале;

«УРАМ» урам сәнгате фестивале;

Студентлар отряды бөтенроссия слеты.

2023 елда Татарстан Республикасы ирешкән казанышлар:

югары белем бирү мәгариф оешмалары студентлары өчен «Россия студентлар язы» бөтенроссия фестивалендә (Пермь шәһәре) 1 урын, «Төбәк программасы» юнәлешендә 2 урын;

һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен бөтенроссия фестивалендә (Ханты-Мансийск шәһәре) 3 урын, «Театр» юнәлешендә гран-при;

Студентлар хезмәт отрядлары республика хәрәкәте Россия Федерациясенең 81 төбәге арасыннан иң яхшы студентлар хәрәкәте дип танылды;

«Ел студенты» һөнәри белем бирү учреждениеләре арасында бөтенроссия премиясендә «Елның иң яхшы укучылар советлары рәисе», «Елның иң яхшы җәмәгать эшләрендә катнашучысы» һәм «Ел студент клубы» номинацияләрендә Татарстан Республикасыннан 3 җиңүче булды;

Югары белем бирү мәгариф оешмасы арасындагы яшьләр проектлары бөтенроссия конкурсында 6 югары уку йорты җиңү яулады һәм гомуми суммасы 37,2 млн сумга грант отты («Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе; Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе; «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе; «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе; «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе; «ТИСБИ» идарә университеты» югары һөнәри белем бирү дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениесе).

**Яшьләрне эшкә урнаштыру һәм аларның һөнәри яктан мөмкинлекләрен ачу**

Яшьләрне эшкә урнашу һәм һөнәри яктан мөмкинлекләрен ачу гаять мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора.

2023 елда 15 134 кеше вакытлыча, сезонлы һәм өстәмә эш белән тәэмин ителде, 2 466 кеше 32 млн сумга федераль грант акчалары хисабыннан 49 юнәлеш буенча һөнәри белем алды.

Студентлар хезмәт отрядлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан 24 югары белем бирү оешмасында һәм аларның филиалларында, 33 һөнәри белем бирү оешмасында һәм Татарстан Республикасының 22 муниципаль

берәмлегендә оештырылды. Студентларга икътисадның төрле тармаклары арасыннан эш юнәлеше сайлап алу, «һөнәр сайлау», шулай ук эшче һөнәрләр буенча белем алу мөмкинлеге бирелә.

Инженерлык отрядларын үстерү кысаларында студентлар отрядларының 30 вәкиллегендә эшләү өчен «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе базасында җир өстендә пилотсыз очу аппаратларына идарә итү чаралары операторы, электрон-исәпләү һәм исәпләү машиналары, чертежчы-конструктор һөнәрләренә бушлай укыталар.

Тулаем алганда, студентлар җитештерү һәм фәнни-җитештерү отрядлары юнәлеше буенча 2023 елда республиканың 34 сәнәгать предприятиесе, шул исәптән: «Казан оптика-механика заводы» акционер җәмгыяте, «Казан төгәл машина төзү заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» федераль казна предприятиесе, «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте, «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте эшкә җәлеп ителде.

**Яшь гаиләләргә ярдәм**

Республиканың 43 муниципаль берәмлегендә яшьләр үзәкләре һәм яшьләр яшүсмерләр клублары базасында 50 яшь гаилә клубы эшләп килә, аларның максаты – гаилә әгъзаларын уртак мәдәни-ял итү эшчәнлегенә җәлеп итеп, яшь гаилә институтын ныгыту. Аларда гаилә төзү һәм гаиләне һәм гаилә кыйммәтләрен саклау буенча әңгәмәләр алып барыла; гаилә төзү һәм гаилә мөнәсәбәтләре кору буенча күнекмәләр бирелә; мәдәни һәм спорт конкурслары, тренинглар һәм осталык дәресләре форматында эш алып барыла; психологик һәм мәгълүмат ярдәм күрсәтелә.

2023 елның 12 ноябрендә «Мега» сәүдә үзәгендә Татарстан Республикасының яшь гаиләләре фестивале узды, анда гаилә бюджетын нәтиҗәле файдалану һәм хуҗалык алып бару турында лекцияләр, фикер алышулар форматында гавами дискуссияләр, гаилә квизлары, «Кыска вакыт эчендә танышу» проекты, конкурслар һәм башка чаралар үткәрелде. Әлеге чарада 1,5 меңнән артык кеше катнашты.

2023 елның 1 декабрендә «Киләчәк гаиләсе. Киләчәк сәламәтлеге» Яшьләр республика конференциясе үткәрелде, ул идеяләр һәм тәҗрибә алмашу, үзара элемтәләр урнаштыру, яшьләр белән эшләүнең яңа формаларын тәкъдим итү буенча төп мәйданчык булып тора. Конференциядә Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте учреждениеләрендә эшләүче 200 хезмәткәр катнашты.

Дәүләт яшьләр сәясәтенең төп бурычы – яшь гаиләләргә ярдәм итү. Республикада яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуга бушлай субсидияләр, процентсыз өлешләп түләү, шулай ук социаль ипотека форматында дәүләт ярдәме күрсәтү программалары эшләп килә.

2023 елда 1,5 меңнән артык яшь гаилә торак шартларын яхшыртты (120 мең квадрат метр торак сатып алынды), шул исәптән гамәлдә булган дәүләт ярдәме механизмнары ярдәмендә 515 яшь гаилә, шулардан 431 яшь гаилә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы линиясе буенча.

**Яшьләр башлангычларына ярдәм итү**

2023 елда илкүләм максатлар һәм федераль проектлар кысаларында 39 яшьләр оешмасы белән берлектә 173 проект тормышка ашырылды, аларга 573 млн сум күләмендә дәүләт ярдәме күрсәтелде.

2023 елда республиканың яшьләр берләшмәләре өчен мөһим даталары билгеләп үтелде: Татарстан Халыклары Яшьләр Ассамблесенә 10 ел, Татарстан Республикасының «Ватан» берләшмәсе» төбәк иҗтимагый яшьләр оешмасына 30 ел һәм «Карлы десант» эзләүчеләр хәрәкәте оешуга 55 ел тулды.

Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» бөтенроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте илебезнең яшь гражданнарын тәрбияләү өчен яңа мөмкинлекләр формалаштыруга юнәлтелгән граждан җәмгыятенең яңа институты булып тора.

2023 елда яшьләр сәясәте учреждениеләре базасында «Беренчеләр хәрәкәте»нең беренчел бүлекләре ачылды, 150 мең кеше катнашында 63 төбәк чарасы уздырылды.

«Беренчеләр хәрәкәте» медиа берләшмәсен үстерүгә һәм «Беренчеләр вакыты» яшьләр автобус турын оештыруга, «XXI гасыр лидеры» бөтенроссия конкурсы һәм башка бик күп чараларны үткәрүгә 2023 елда 28 млн сум күләмендә акча бүлеп бирелде.

Татарстан яшьләре традицион рәвештә Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык уздырган форумнарда актив катнаша. Яшьләр эшләре буенча федераль агентлыктан грант яулап алу буенча Татарстан Россия төбәкләре арасында бишенче урынны алып тора. Республика яшьләренең башлангычларын тормышка ашыруга 70 млн сум күләмендә федераль акчалар җәлеп ителде.

# МӘДӘНИЯТ

Республикада мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәте Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр чорга мәдәниятне үстерү стратегиясе нигезендә алып барыла. Аның максаты – мәдәни үсеш өлкәсендә халыклар мәдәниятләренең гармонияле үсеше һәм алгарышы өчен шартлар тәэмин итәчәк, һәр шәхеснең һәм тулаем алганда җәмгыятьнең мәдәни һәм рухи потенциалын тормышка ашыруга этәргеч бирәчәк нәтиҗәле сәясәт формалаштыру.

Республикада барлыгы 3 809 мәдәният учреждениесе бар:

39 театраль-тамаша, шул исәптән 19 театр, 20 концерт оешмасы, 1 цирк;

1 507 китапханә (шулардан 1 297 – авылларда);

181 дәүләт һәм муниципаль музей челтәр берәмлеге;

1 892 мәдәни-ял итү учреждениесе, шул исәптән 73 күчмә мәдәният учреждениесе;

156 мәгариф оешмасы;

14 киноучреждение;

13 Халыклар дуслыгы йорты;

6 типик булмаган дәүләт мәдәният учреждениесе;

1 зоопарк.

Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында 1,5 млннан артык кеше катнашында 9 меңнән артык иҗат проекты һәм чара уздырылды.

**Театр-тамаша учреждениеләре.**

*Театрлар*

Республиканың дәүләт һәм муниципаль театрларында 100 премьера спектакле куелды, барлыгы 4 955 спектакль уйналды, шулардан 1 122се – балалар һәм яшүсмерләр өчен. Театрларга 1 460,9 мең тамашачы килде.

Театр гастрольләре вакытында 409 спектакль, шул исәптән 30 спектакль Россия Федерациясе төбәкләрендә уйналды.

Театр труппалары 41 төбәкара, бөтенроссия конкурсларында катнашты, 32 премия лауреаты дип танылды.

Иң күренекле театраль вакыйгалар булып түбәндәгеләр санала:

Муса Җәлил исемендәге татар академия дәүләт опера һәм балет театрында Ф.И. Шаляпин исемендәге XLI халыкара опера фестивале (2023 елның 30 гыйнварыннан 28 февраленә кадәр);

Муса Җәлил исемендәге татар академия дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә Рудольф Нуриев исемендәге XXXVI халыкара классик балет фестивале (2023 елның 12–30 мае);

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында XVI «Нәүрүз» халыкара театраль-мәгърифәти форум (2023 елның 5–11 июне);

Чаллы шәһәренең «Мастеровые» Рус драма театрында V чит илләрдәге рус театрлары халыкара фестивале (2023 елның 21–29 июне);

Өченче Качалов театр фестивале (2023 елның 6–26 октябре);

«Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесендә «Һөнәр» XV яшь режиссерларның бөтенроссия театр фестивале (2023 елның 1–7 декабре);

XIV балалар-яшүсмерләр театр (драма һәм курчак) коллективлары, студияләренең «Иделкәем& Кариев варислары» төбәкара фестиваль-конкурсы (2023 елның 1 июненнән 24 ноябрьгә кадәр);

Чаллы дәүләт курчак театры базасында «Эш аты» V төбәкара театраль мәгариф форум-фестивале (2023 елның 14–20 мае);

X «Ирекле сәхнә» иҗат лабораториясе (2023 елның 20–24 ноябре);

Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында «Киләчәк буын» II балалар театр коллективларының бөтенроссия фестивале (2023 елның 15–25 сентябре);

«Артмиграция» яшь режиссерларның бөтенроссия фестиваль-форумы (2023 елның 15–24 сентябре).

Татарстан «Театраль Идел буе төбәге» бөтенроссия фестивалендә 1 урын яулады.

2023 елда В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театрының Беларусь Республикасының Минск шәһәренә, Буа дәүләт драма театрының Казахстан Республикасының Актүбә шәһәренә, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Төркия Республикасының Анкара шәһәренә гастрольләр булды. 2023 елда Төркия, Кыргызстан, Үзбәкстан, Казахстан, Беларусь Республикалары театрлары Татарстан Республикасына гастрольләр белән килде.

**Концертлар оештыру**

Концертларны 2 206,4 мең кеше тамаша кылды.

Ел дәвамында концерт оешмалары республика муниципаль берәмлекләренә күчмә гастрольләр белән чыкты. Дәүләт һәм муниципаль концерт оешмалары тарафыннан 2 659 концерт программасы әзерләнде, шулардан 622 программа балалар һәм яшүсмерләр өчен, 322 яңа концерт программасы, гастрольләрдә 253 концерт оештырылды.

XXIII Федераль сабантуй һәм Кемерово шәһәрендә III Халыкара шахтерлар сабан туе, Әстерхан өлкәсенең Җәмәле авылында XIII бөтенроссия авыл сабан туе, Баку шәһәрендә (Азәрбайҗан Республикасы) илкүләм лидер Г.А. Алиевның тууына 100 ел тулуга багышланган сабан туе зур әзерлек белән оешкан төстә уздырылды. 2023 елда барлыгы 364 сабан туе, шул исәптән 297 – Россия Федерациясенең 54 төбәгендә, 67 – 25 якын һәм ерак чит илдә уздырылды.

Иң әһәмиятле чаралар түбәндәгеләр:

VIII «Мирас» Нәҗип Җиһанов исемендәге татар музыкасы фестивале;

IV халыкара орган фестивале;

«Паркларда һәм скверларда җиңү музыкасы» тынлы оркестрларның республика фестивале;

Сергей Рахманинов исемендәге XII «Ак канәфер» халыкара фестивале;

XXXIII «Бәхетле балачак» традицион фестивале;

Борис Березовскийның «Алабугада җәйге кичләр» V халыкара музыка фестивале;

София Гобәйдуллина исемендәге «Concordia» XIII халыкара заманча музыка фестивале;

XIII «Казан көзе» халыкара опера фестивале;

XI «Денис Мацуев дуслары янында» музыка фестивале;

VIII «Үзгәреш җиле» татар җыры фестивале;

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен «НУР – 2023. Хистойгылар кичерергә сәләтле кешеләр» II бөтенроссия интеграль иҗат фестивале;

XVI «Филармониада» халыкара сәнгать фестивале;

«Бие һәм җырла, минем Россия!» VI халык-сәхнә сәнгате бөтенроссия фестиваленең балалар төркемендә төбәк сайлап алу этабы;

II «Россия-Көнчыгыш» милли мәдәниятләр халыкара фестивале («Казанда Шәрыкъ базары»);

X «Джазлы Казан» халыкара фестивале.

Татарстан Республикасы Көненә, Футбол буенча Россия суперкубогы – 2023, «Динамо» спорт җәмгыятенең 100 еллыгына багышланган «Динамо спорт уеннары» чараларына багышланган концертлар узды. Концерт оешмалары катнашында Мәскәү шәһәрендә, Чечня Республикасында, Беларусь Республикасында һәм Төрекмәнстанда Татарстан Республикасы Мәдәнияте көннәре уздырылды.

*Цирклар эшчәнлеге*

Казан шәһәрендә циркка 269,9 мең тамашачы килде. Цирк мәйданында 204 чара уздырылды, шулардан 175е – тамаша.

2023 елда 5 яңа программа: «Морозко», «На грани», «Все будет хорошо!», «Багдасаровы. Про цирк», «Как Кот на Новый год счастье принес» күрсәтелде.

Казан дәүләт циркы үз манежында 2 гастроль цирк тамашасын – «Цирк туры эфирда» һәм Бурят дәүләт циркының «Бурятия легендалары» этнопрограммасын кабул итте.

Казан дәүләт циркында 2023 елның 1 ноябрендә «неЦирк» дигән социаль-иҗтимагый проекты старт алды, анда шәһәр кешеләре цирк сәнгате күнекмәләре ала, ә соңыннан манежда чыгыш ясый. Барлыгы 20 кеше сайлап алынды. Уку һәм тренировкалар Казан дәүләт циркының балалар цирк мәктәбендә узды.

I «Артист» халыкара цирк фестивалендә (Мәскәү шәһәре) Казан дәүләт циркының балалар цирк мәктәбендә укучылар Владимир Серов (17 яшь) һәм Елизавета Демидова (12 яшь) «Юниор» номинациясендә 1 урын яулады һәм халыкара цирк фестивальләрендә чыгыш ясау хокукына ия булды.

**Музей эше**

Музейлар челтәренә 181 дәүләт һәм муниципаль музей берәмлеге, шул исәптән структур бүлекчәләр керә (72 дәүләт музее һәм 109 муниципаль музей). 2023 елда музей челтәренә 3 яңа музей берәмлеге (Казан шәһәрендә Лев Толстой музее, Спас манарасы музее, Ютазы муниципаль районының тарих-туган якны өйрәнү музее) кертелде.

Музей фондлары күләме буенча Татарстан Республикасы Идел буе федераль округында беренче урында тора.

«Россия музейлары» беренче телевидение программалары бөтенроссия фестиваленең «Музей-партнер» махсус номинациясендә «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы җиңү яулады.

Республика музейларында 120,1 мең экскурсия, 3 735 массакүләм һәм 18,7 мең мәдәни-мәгърифәти чара, 3 101 күргәзмә, шәхси фондлардан 1 788 күргәзмә оештырылды. 2022 елда музей учреждениеләренә килүчеләр саны 10,5 млн кеше

тәшкил итте.

Татарстан Республикасы дәүләт музейлары һәм музей-тыюлыклары тарафыннан 817 күргәзмә проект оештырылды, шулардан Россия Федерациясенең башка төбәкләренә 64, чит илгә 6 күргәзмә проект алып барып күрсәтелде.

Татарстан Республикасында барлык гражданнар дәүләт музейларына, музей-тыюлыкларга һәм Татарстан Республикасы муниципаль музейларына һәр айның беренче сишәмбесендә бушлай керә ала.

**Китапханәләр**

Республикада халыкка хезмәт күрсәтүче 1 507 китапханә исәпләнә, шул исәптән 4 республика (Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе, Роберт Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсе, Республика сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус китапханә) һәм 1 503 муниципаль китапханә бар.

Барлык китапханәләр дә «PRO.Мәдәният.РФ» порталында теркәлгән. 2023 елда «PRO.Мәдәният.РФ» порталында теркәлгән муниципаль китапханәләр рейтингында Татарстан Республикасы Россия Федерациясе буенча икенче урында.

2023 елда федераль бюджет акчалары (20 млн сум) хисабына республикада 3 модельле китапханә: Чаллы шәһәренең Үзәкләштерелгән китапханә системасының үзәк балалар китапханәсе; Түбән Кама муниципаль районының авылара китапханә системасының 9 номерлы филиалы Ширәмәт авылы китапханәсе; Тәтеш муниципаль районының Тәтеш авылара китапханәсенең Keләш авылы китапханәсе төзелде.

Казан шәһәре муниципаль бюджетыннан өстәмә акчалар күчерелү хисабына 2023 елда Казан шәһәре үзәкләштерелгән китапханә системасының 27 номерлы филиалы китапханәсе яңартылды.

2023 елда «Россиянең иң күп китап укучы төбәге» бөтенроссия конкурсында Татарстан «Россиянең әдәби флагманы» исеменә лаек булды. Республикага җиңүне Роберт Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсенең «Күчмә китапханә» проекты китерде.

2023 елның 15 июнендә Мурманск шәһәрендә Россия китапханәчеләр ассоциациясенең Бөтенроссия китапханә конгрессы ябылу тантанасында казан шәһәре 2024 елда Россиянең китапханә башкаласы дип игълан ителде.

Татарстан Республикасының электрон китапханә каталогына 50 мең китапханә язмасы кертелде. Каталогта барлыгы 1,12 млн китапханә язмасы теркәлгән.

«Татарстан Республикасының Электрон милли китапханәсе» порталында (kitap.tatar.ru) «Электрон коллекцияләр» бүлегендә 13 818 тулы текстлы документ урнаштырылды.

Гомуми кулланылыштагы китапханәләрнең җыелма фонды 23,5 млн нөсхәдән тора.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе «Цифрлы нигезгә корылган мәдәният» төбәк проектын тормышка ашыру кысаларында кульъязма һәм басма китаплар дип танылган документларны цифрлаштыру эшен дәвам итә. «Кульъязма һәм басма китаплар» коллекциясенә 1 мең электрон документ кертә, фондларны цифрлаштыру барышында 33 мең нөсхә электрон документ булдырылды.

Республиканың гомуми кулланыштагы китапханәләренә 2023 елда 21,9 млн кеше килде, ә китапханәләр тарафыннан чараларда 3,8 млн кеше булды.

**Киноучреждениеләр**

Республиканың кино челтәренә 14 кино учреждениесе, 175 кино күрсәтү урыны, шул исәптән 1 дәүләт кинотеатры («Мир» кинотеатры), 7 муниципаль кинотеатрда 8 кино залы, мәдәни-күңел ачу учреждениеләрендә 43 муниципаль кино залы; 25 – коммерциячел кинотеатр, 27 – күчмә кино күрсәтү урыны керә.

2023 елда республика акчалары хисабына 24 фильм төшерелде, 162 фильм прокатка чыкты.

Түбәндәге фильмнар федераль прокатка чыкты: «Микулай» (режиссеры – Илшат Рәхимбай), «Җәдәч» (режиссеры – Байбулат Батулла).

2023 елның 5–9 сентябрендә республикада XIX Казан халыкара мөселман киносы фестивале узды, аның кысаларында грек, кытай, сирия, төрек, француз киносы көннәре үткәрелде.

2023 елда Татарстанда «Мир» кинотеатрында «Татарстан Республикасында Япония сезоны» фестивале, күренекле кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның тууына 95 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында кыргыз киносы көннәре уздырылды. Шулай ук 2023 елда Бишкәк шәһәрендә Татарстан киносы көннәре үткәрелде.

Кинотеатрларга һәм кино учреждениеләргә 4,3 млн кеше килде.

**Мәдәни-ял итү учреждениеләре**

Мәдәни-ял итү учреждениеләре 1 824 бинада урнашкан, шуларның 754е – терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарланган затлар, 12се – күрү сәләте начар булган затлар, 12се – ишетү сәләте начар булган затлар өчен.

40 муниципаль берәмлектә 73 күчмә мәдәният учреждениесе эшләп килә.

Мәдәни-ял итү учреждениеләрендә түбәндәгеләр эшли:

15 830 клуб формированиесе (210 916 кеше катнашында), шул исәптән 1 497 инклюзив (18 268 кеше катнашында);

8 468 үзешчән сәнгать коллективы, шул исәптән 592 коллектив «Үзешчән халык коллективы» һәм 58 коллектив «Үрнәк коллектив» дигән исемгә лаек, 787 коллектив халыкара конкурслар лауреатлары булды.

Мәдәни-ял итү учреждениеләрендә 32,2 млн кеше булды.

37 мәдәни-ял итү учреждениесе капиталь төзекләндерелде, шул исәптән 29 мәдәни-ял итү учреждениесендә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләрнең биналарга керә алуын тәэмин итү максатларында төзекләндерү эшләре башкарылды.

**Матди булмаган мәдәни мирас**

Татарстан Республикасының теркәлгән матди булмаган этномәдәни казанышларының гомуми саны 188 берәмлек тәшкил итә (2022 елда – 182 берәмлек).

Фәнни тикшеренүләр матди булмаган этномәдәни мирасны өйрәнүнең төп аспектларыннан берсе булып тора. Казан Кремленең Дәүләт учреждениеләре һәм административ биналар комплексында 2023 елның 26–29 маенда «Традицион славян мәдәнияте һәм хәзерге дөнья. Заманча җәмгыятьтә фольклор» дип аталган XXVIII халыкара конференция узды, анда 109 кеше катнашты.

«Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсенә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе «Россия фәннәр

академиясенең Урал бүлекчәсе Пермь федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе, «В.Д. Поленов исемендәге Халык иҗаты Россия дәүләт йорты» федераль дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе белән берлектә Татарстан Республикасы муниципаль районнарына фольклор-диалектология, фольклор-этнография һәм этнолингвистик экспедицияләр оештырылды. 2023 елда рус халкы тыгыз яшәүче Апас, Тәтеш, Теләче муниципаль районнарындагы торак пунктлар тикшерелде.

2023 елда Татарстан Республикасының чигелгән картасы тәкъдим ителде, эшкә республика муниципаль берәмлекләре район мәдәният йортлары, китапханәләр һәм музейларыннан чигү осталары җәлеп ителде.

Татарстан Республикасында Россиянең күпмилләтле мәдәниятенең үзенчәлекле чагылышы булган халык бәйрәмнәре һәм фестивальләрен саклауга һәм популярлаштыруга зур игътибар бирелә. Күп еллар дәвамында республикада яшәүче халыкларның гореф-гадәтләрен һәм йолаларын саклауга ярдәм итүче Татарстан халыкларының милли бәйрәмнәре: Сабантуй, Нәүрүз, «Каравон» төбәкара рус фольклор бәйрәме, мордва мәдәниятенең «Валда шинясь», «Троица» рус милли бәйрәме, мари мәдәниятенең «Семык», чуваш милли мәдәниятенең «Уяв», славян мәдәниятенең «Иван Купала», удмурт мәдәниятенең «Гырон быдтон», керәшен мәдәниятенең «Питрау» республика бәйрәмнәре уздырыла.

Ватандашларыбызның иҗади активлыгын үстерүгә «Түгәрәк уен» бөтенроссия татар фольклоры фестивале, «Идел-йорт» театр коллективларының төбәкара фестивале, «Татар моңы» яшь башкаручыларның халыкара телевизион конкурсы, Р. Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестивале, «Шома бас» татар биюләрен башкаручыларның халыкара конкурсы, «Татар кызы» бөтенроссия конкурсы, «Сөйкемле Шүрәле» бөтенроссия иҗат эшләре конкурсы кебек халыкара һәм төбәк конкурслары, мәдәни проектлар ярдәм итә.

2023 елда иң күренекле, җәмәгатьчелек тарафыннан танылган, ил һәм милли мәдәният үсешенә зур өлеш керткән әдәбият һәм сәнгать әсәрләре өчен бирелә торган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе гамәлгә куелуга 65 ел тулды. 2023 елда премия лауреатлары милли темага багышланган һәм күн мозаикасы техникасында башкарылган декоратив паннолар сериясе өчен рәссам Кумысникова Наилә Халит кызы, «Аучы җыры», «Чоңгыл», «Иман капка ачканда», «Себерем – үз җирем» шигырь җыентыклары өчен шагыйрь Сибгатуллин Шәүкәт Гаделша улы (Шәүкәт Гаделша), архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә ватан һәм татар милли мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен архитектор Ханов Фирдәвес Гайнетҗан улы булды.

2023 елның 21 маенда Болгар музей-тыюлыгы территориясендә Болгар дәүләте тарафыннан рәсми рәвештә ислам дине кабул ителү көнен билгеләп үтүгә багышланган «Изге Болгар җыены» киң колачлы тантаналы чара уздырылды. Әлеге чарада Россия Федерациясе субъектларыннан делегатлар, Россия Федерациясенең, якын һәм ерак чит илләрнең мөселманнар диния нәзарәтләре, илебезнең төрле почмакларыннан мөселман җәмгыятьләре вәкилләре, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» XIV халыкара икътисадый форумында катнашучылар катнашты.

**Мәдәният өлкәсендә белем бирү**

Республикада мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү буенча 156 мәгариф оешмасы эшләп килә: 105 балалар сәнгать мәктәбе һәм мәдәният идарәләре органнары карамагындагы 2 балалар үзәге, мәгариф идарәләре органнары карамагындагы 38 балалар сәнгать мәктәбе, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге 9 һөнәри белем бирү оешмасы (көллиятләр), 2 югары белем бирү мәгариф оешмасы.

Әлеге оешмаларда 43 345 укучы белем ала, шулардан 38 307 бала – балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында, 2 389 бала – һөнәри белем бирү оешмаларында (көллиятләрдә), 2 649 укучы – югары белем бирү мәгариф оешмаларында. Укытучылар составы 4 654 кешедән тора, шулардан өстәмә белем бирү оешмаларында 3 687 укытучы һәм концертмейстер, һөнәри белем бирү оешмаларында 638 укытучы, 329 кеше югары уку йортларының профессор-укытучылар составына керә.

2023 елда «Балалар сәнгать мәктәбенең иң яхшы укытучысы» һәм «Иң яхшы балалар сәнгать мәктәбе» гомумроссия конкурсларының төбәк этаплары уздырылды.

Сәнгать өлкәсендә «Россиянең сәләтле яшьләре» бөтенроссия яшүсмерләр олимпиадасының төбәк этабында 13 кеше призлы урын яулады.

«TAT·ARS·TAN» конкурс хәрәкәте кысаларында Республиканың сәләтле яшьләре конкурсы оештырылды, анда 253 кеше катнашты, 13 кеше олимпиада призеры булды.

Биектау муниципаль районының «Салих Сәйдәшев исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе Идел буе федераль округында «Иң яхшы балалар сәнгать мәктәбе (авыл)» гомумроссия конкурсларының II турында җиңү яулады.

2023 елның 28 октябрендә «Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» (техникум) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында балалар сәнгать мәктәпләре укытучылары арасында «МАЭСТРО» һөнәри осталык республика конкурсы уздырылды.

Илебезнең бердәм мәдәни-мәгариф киңлеген үстерүгә булышлык итүче, шулай ук дөнья гуманитар һәм мәдәни мәйданында Россиянең абруен арттыру, шул исәптән укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү, креатив индустрияләр өлкәсендә һөнәрләрне, белгечлекләрне һәм һөнәри юнәлешләрне популярлаштыру һәм үстерүдә иң мөһим юнәлешләрнең берсе – креатив индустрияләр мәктәбен булдыру.

Татарстан Республикасында беренче шундый мәктәп 2022 елда «Россиядә уйлап табылды» федераль проекты кысаларында «Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» (техникум) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында төзелде. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе һәм «Түбән Каманың Салих Сәйдәшев исемендәге музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында тагын шундый ике креатив индустрия мәктәбе ачылды.

**«Мәдәният» илкүләм проекты**

«Мәдәният» илкүләм проекты максатларына ирешү өчен «Мәдәни мохит», «Иҗади кешеләр» һәм «Цифрлы нигезгә корылган мәдәният» төбәк проектлары тормышка ашырылды. Аларга 1 530,5 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән

959,1 млн сум – федераль бюджеттан, 571,4 млн сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан.

*«Мәдәни мохит» төбәк проекты* кысаларында 2023 елда:

Апас, Әлки, Арча, Биектау, Кукмара, Кайбыч муниципаль районнарында 8 авыл мәдәният йорты төзелде;

түбәндәгеләр капиталь төзекләндерелде:

Әлмәт, Актаныш, Баулы, Биектау, Зеленодольск, Кукмара, Балык Бистәсе, Мамадыш муниципаль районы авылларында 13 мәдәният йорты;

Түбән Кама муниципаль районының «2 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, «Зеленодольск музыка театры» муниципаль бюджет учреждениесе;

Баулы, Кукмара, Зеленодольск һәм Арча муниципаль районнарында 4 музей;

Буа шәһәрендә «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе реконструкцияләнде (2022 елдан күчкән объект);

5 төбәк һәм муниципаль музей, «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе техник җиһазландырылды;

Тәтеш, Түбән Кама муниципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә 3 модельле китапханә төзелде.

*«Иҗади кешеләр» төбәк проектын* тормышка ашыру кысаларында:

3 фестиваль уздырылды (Казан шәһәрендә XLI Ф.И. Шаляпин исемендәге опера фестивале, XXXVI Рудольф Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивале, XVI «Нәүрүз» төрки халыкларның халыкара театр фестивале);

2 күргәзмә проекты оештырылды (Татарстан Республикасының Дәүләт сынлы сәнгать музеенда – «Рафаэль. Версияләр», «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында – «Архангелогородские изразцы» күргәзмәләре);

Сәләтле яшьләр республика конкурсы;

иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениесе һәм иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениесе хезмәткәренә дәүләт ярдәме күрсәтелде;

өзлексез белем бирү һәм мәдәният өлкәсе иҗади һәм идарәче кадрларның квалификациясен күтәрү үзәкләре базасында белгечләр квалификацияләрен күтәрү курслары узды;

үзешчән иҗат коллективларына грантлар бирелде.

*«Цифрлы нигезгә корылган мәдәният» төбәк проектын* гамәлгә ашыру кысаларында Казан шәһәренә китапларны цифрлы нигезгә күчерү эше башкарылды.

**Мәдәният өлкәсенә грант ярдәме**

2023 елда мәдәният өлкәсендә түбәндәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары каралган:

мәдәният һәм сәнгать муниципаль учреждениеләре иҗат коллективлары проектларына ярдәм итүгә (гомуми суммасы 11,5 млн сумга 65 җиңүче);

мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре хезмәткәрләренә ярдәм итүгә (гомуми суммасы 5,0 млн сумга 12 җиңүче);

шәһәр татар һәм рус мәдәни-ял итү мохитен булдыруга грант (гомуми суммасы 300,0 мең сумга 5 җиңүче);

дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография

учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә квалификацияләрен күтәрү, тәҗрибә алмашу чараларында катнашуга ярдәм итүгә (гомуми суммасы 3,0 млн сумга 53 җиңүче);

иң яхшы дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итүгә (гомуми суммасы 4,0 млн сумга 6 җиңүче);

балалар һәм яшүсмерләр өчен иң яхшы әдәби әсәр язган өчен Роберт Миңнуллин исемендәге бүләк (гомуми суммасы 900,0 мең сумга 12 җиңүче);

Татарстан Республикасындагы иҗтимагый оешмаларга һәм Россия Федерациясе төбәкләрендә гореф-гадәтләрне саклауга һәм милли мәдәниятне үстерүгә, этномәдәни һәм телләр күптөрлелеген саклауга, мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә булышлык итүгә (Россия Федерациясенең 13 субъектыннан гомуми суммасы 10,2 млн сумга 14 җиңүче).

Авыл җирлекләренең иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләренә һәм аларның хезмәткәрләренә акчалата бүләк (хезмәткәрләр арасыннан гомуми суммасы 2,0 млн сумга 40 җиңүче һәм учреждениеләр арасыннан гомуми суммасы 5,5 млн сумга 55 җиңүче).

Моннан тыш, Мәдәни инициативалар Президент фонды тарафыннан уздырылган мәдәният, сәнгать һәм креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга президент грантлары конкурсы йомгаклары буенча 2023 елда 43 оешма җиңүче дип танылды, грантның гомуми суммасы – 105,2 млн сум, шулардан гомуми суммасы 83,7 млн сумга социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның 18 проекты.

**«Пушкин картасы» программасын гамәлгә ашыру**

Татарстанда «Пушкин картасы» программасыннан 354 мең кеше файдалана, шулардан Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы мәгълүматлары буенча 2023 елның 31 декабренә – 284 мең кеше «Пушкин картасы»н рәсмиләштерде.

«Мәдәният өлкәсендә дәүләт хезмәтләре» мобиль кушымтасында «Пушкин картасы» федераль проектыннан файдаланучылар өлеше буенча Татарстан Республикасы 4 урынны алды.

«PRO.Мәдәният.РФ» порталында «Пушкин картасы» федераль проектыннан файдаланучылар сыйфатында Татарстан Республикасының 494 оешмасы теркәлде, бу исә 2022 ел белән чагыштырганда 2 тапкырга күбрәк (2022 елның 1 гыйнварына 243 оешма иде).

2023 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы мәдәният учреждениеләре тарафыннан гомуми суммасы 444,7 млн сумга 1 133 мең билет сатылган. Сатылган билетлар саны һәм билетлар сатудан кергән акчаның күләме буенча Татарстан Республикасы Россия төбәкләре арасында Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре һәм Башкортостан Республикасыннан кала, 4 урында тора. 2022 ел белән чагыштырганда сату күләме 7,4 % артты (2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында гомуми суммасы 413,8 млн сумга билетлар сатылган иде).

# КОММЕРЦИЯЧЕЛ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАРГА ЯРДӘМ ИТҮ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ

Граждан җәмгыяте институтлары белән актив хезмәттәшлек алып барыла. Идел буе федераль округында теркәлгән коммерциячел булмаган оешмалар (алга таба – КБО) саны ягыннан республика алдынгы урыннарның берсен алып тора. 2024 елның 1 гыйнварына республикада 6 211 КБО, шул исәптән 1 722 иҗтимагый оешма, 2 132 дини берләшмә, 2 238 коммерциячел булмаган башка оешмалар, шулай ук сәяси партияләрнең 19 төбәк бүлекчәсе теркәлгән.

Татарстанда «Татарстан Республикасының 2014–2025 елларга икътисадый үсеше һәм инновация икътисады» дәүләт программасының 2014–2025 елларга Татарстан Республикасы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба – СЮКБО) ярдәм буенча ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлдә. Аның максаты – Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешендә катнашуга СЮКБОга этәргеч бирү, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм милләтләр арасындагы татулыкны саклау, социаль сәясәтнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрнең балансланган булуы нигезендә иҗтимагый иминлеккә ирешү. 2023 елда Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 316,24 млн сум тәшкил итте.

2023 елда «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм» төбәк проектын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024–2026 елларга финанслауның гомуми күләме 982,63 млн сум тәшкил итте.

2022 елда КБОга грантлар бирүгә конкурслар уздыру буенча бердәм грант операторы итеп «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү буенча республика ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы билгеләнде (Татарстан Республикасы Президентының «Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантлары турында» 2021 елның 29 декабрендәге ПУ-1002 номерлы Указы).

2023 елда коммерциячел булмаган оешмаларга грантлар алуга 2 конкурс уздырылды:

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга грантлар бирүгә (конкурс фонды – 35 млн сум). Конкурс йомгаклары буенча грантлар 12 юнәлеш буенча 80 СЮКБОга бирелде;

гражданлык җәмгыятен үстерү өчен Татарстан Республикасы грантларын бирүгә (конкурс фонды – 106,6 млн сум, шуларның 53,3 млн сумы – Президент грантлары фондыннан финанслашу). Конкурс йомгаклары буенча грантлар 20 юнәлеш буенча 120 СЮКБОга бирелде, шулардан 14 СЮКБО Россия Федерациясе субъектларыннан.

Республикада КБОларның муниципальара ресурс үзәкләре эшли, алар Ярдәмче программа акчалары ярдәмендә укыту, консалтинг һәм КБОлар эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүне тормышка ашыра. КБОларның муниципальара ресурс үзәкләре Казан («Инновацияле үсеш һәм технологияләрне трансферлау» автоном коммерциячел

булмаган оешмасы), Әлмәт («Вертикаль» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Чаллы («Горизонт» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Кукмара («Вектор» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Буа («Буа Грант» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Чистай («Бердәмлек» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы) шәһәрләрендә урнашкан.

Ел дәвамында әлеге үзәкләр 745 консультация һәм 194 семинар уздырды, шулар арасында «Мәгълүмат ачыклык, КБО һәм социаль проектларны тәкъдим итү», «Социаль проектка 21 адым: проектның яшәү фазалары һәм аларны бәяләү төрләре», «Эксперт карашы: хаталарны анализлау», «Проектны тормышка ашыру: идеядән алып үтәүгә кадәр», «Социаль проектлар ясау һәм социаль проектларга идарә», «Яхшы тон: партнерлар КБОларның ачыклыгын ничек билгели». 2023 елда аларның ярдәме белән 35 СЮКБО төзелде.

9 халыклар дуслыгы йорты (Казан, Чаллы, Азнакай, Лениногорск, Менделеевск, Түбән Кама, Нурлат, Тәтеш һәм Буа шәһәрләрендә) һәм Татарстан халыклары ассамблеясе ресурс үзәкләре булып торган 4 халыклар дуслыгы йорты үзәге КБОларга этномәдәни һәм конфессияара хезмәттәшлек алып баруда ресурс үзәкләре булып тора. 4 муниципаль районда район мәдәният йортларының структур бүлекчәләре буларак халыклар дуслыгы үзәкләре эшләп килә (Апас, Чүпрәле, Яңа Чишмә һәм Спас муниципаль районнары).

Гражданлык инициативаларын хуплау һәм республикада граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы гамәлгә ашырыла. 2022 елда әлеге премияне дәгъвалауга үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча (гомуми приз фонды – 2,75 млн сум) 8 премия бирелде:

Н.А. Ермолаевага – «Гаиләнең рухи хәзинәләрен саклау үзәге» Татарстан төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесенә;

М.М. Гафиятуллинга – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, «Спорткультавтотовары» акционер җәмгыяте генераль директорына;

Т.С. Хөснуллинага – Татарстан Республикасының «Игелек планетасы» инвалид яшьләр һәм балалар төбәк иҗтимагый оешмасы рәисенә;

«Ватан юллары» физик культураны, спортны үстерүгә ярдәм итү һәм балаларга, яшьләргә патриотик тәрбия бирү төбәк үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасына;

«Казан шәһәренең мари милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасына;

Татарстан Республикасы «Казан әниләре» төбәк иҗтимагый хәйрия оешмасына;

«Россия ветераннар берлеге» бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасына;

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен «Рубаха» автоном коммерциячел булмаган оешмасына.

2015 елдан лауреат исеменә Татарстан Республикасының 26 күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм 39 КБО лаек булды.

Социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрында 29 дәүләтнеке булмаган оешма, шул исәптән:

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүче 20 оешма, 14 СЮКБОны да кертеп;

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләргә һәм авыр тормыш хәлендә калган балаларга социаль хезмәтләр күрсәтүче 9 оешма, 6 СЮКБОны да кертеп.

2023 елда социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның гомуми санында дәүләтнеке булмаган оешмаларның өлеше 20,6 процент тәшкил итте (2022 елда – 18,6 %, 2021 елда – 18,4 %). Дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан 10,6 мең кешегә хезмәт күрсәтелде.

2023 елда 19 оешма, шул исәптән сайлап алуда җиңгән 15 СЮКБО белән юридик затның социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарын компенсацияләү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр төзелде.

Гражданнарны граждан җәмгыятен үстерүгә җәлеп итү эше КБОларның Татарстан Республикасы ведомстволары һәм муниципаль иҗтимагый советларындагы, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарындагы вәкиллекләре аша алып барыла.

Территориаль иҗтимагый үзидарәләре гражданнарны территориядә булган мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү ресурсы буларак республиканың күп кенә муниципаль берәмлекләрендә актив кулланыла.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә СЮКБОларга ярдәм итү чараларын эшләү һәм үтәүдә методологик ярдәм күрсәтү максатларында СЮКБОлар белән хезмәттәшлекне көчәйтү, шулай ук алар эшчәнлегенең нәтиҗәле технологияләрен һәм ысулларын куллану буенча методик тәкъдимнәр эшләнде.

СЮКБОларның социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеген республика массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны үз эченә алган мәгълүмати ярдәмгә зур роль бирелә. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Татмедиа), шулай ук СЮКБОларга ярдәм итү буенча ресурс үзәкләре тарафыннан СЮКБОлар эшчәнлеген пропагандалау һәм популярлаштыру буенча эш алып барыла.

Татмедиа КБОларга әһәмиятле социаль гуманитар проектларны тормышка ашыруда, шулай ук ирекleләр хәрәкәте һәм хәйриячелек эшчәнлеге идеяләрен формалаштыруда мәгълүмати ярдәм күрсәтә.

2016 елдан башлап Татмедиа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы ярдәме белән СЮКБО эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырткан иң яхшы массакүләм мәгълүмат чаралары

билгеләү буенча конкурс үткәрү турында» 2016 елның 2 декабрендәге 885 номерлы карары нигезендә) үткәрелә. Конкурста ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, авторлар коллективлары һәм төркемнәре, шулай ук башка юридик затлар, шул исәптән СЮКБОлар да катнаша ала. 2023 елда конкурс 4 номинация буенча уздырылды: «Татарстан Республикасында СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы телевидение сюжеты (яисә тапшыруы)», «Татарстан Республикасында СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы радио сюжеты (яисә радио тапшыруы)», «Татарстан Республикасында СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча басма массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы мәкалә», шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы язма». 12 массакүләм мәгълүмат чаралары авторы җиңүче булды. Конкурсның гомуми приз фонды – 400 мең сум.

Һәр елны республиканың КБОлары Россия Федерациясе Президенты грантларын бирү буенча конкурсларда катнаша. 2023 елда Татарстан Республикасының 76 СЮКБО проекты җиңүче дип танылды, грантларның гомуми суммасы 151,6 млн сум тәшкил итте.

Моннан тыш, Мәдәни инициативалар Президент фонды тарафыннан уздырылган мәдәният, сәнгать һәм креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга президент грантлары конкурсы йомгаклары буенча республиканың 18 проекты җиңүче дип танылды, грантның гомуми суммасы – 83,7 млн сум.

КБОларга ярдәм итү максатында 2018 елдан республикада махсус портал булдырылды, анда коммерциячел булмаган оешмалар интернетта бушлай үз сәхифәләрен булдыра ала (http://www.nkort.ru/), бу киләчәктә СЮКБОларның имиджын үстерергә, аларны медиа киңлектә тагын да танытуга этәргеч бирәчәк. Порталда КБОлар өчен кирәкле барлык мәгълүмат: норматив хокукый база, республика һәм шулай ук федераль конкурсларны уздыру, социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыру йомгаклары, СЮКБОларга ярдәм итү буенча муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлеге, муниципальара ресурс үзәкләре тарафыннан эшләнә торган мәгълүмати-методик материаллар урнаштырыла.

КБО турында мәгълүматларны үзәкләштерү максатларында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан 2014 елдан Татарстанда ярдәмнән файдаланган СЮКБОның республика реестры алып барыла. Төп мәгълүматны СЮКБОларга төрле ярдәм чаралары күрсәтүче дәүләт хакимияте башкарма органнары бирә. Шундый ук реестрлар республиканың муниципаль берәмлекләрендә дә алып барыла. Реестр мәгълүматлары нигезендә 2023 елда 359 СЮКБОга финанс ярдәме күрсәтелде. Реестр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Эшчәнлек» бүлегендә (https://mert.tatarstan.ru/reestr.htm) урнаштырылган.

# МӘДӘНИЯТ, СОЦИАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ, СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ҺӘМ МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛГӘН ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ СЫЙФАТЫНА БӘЙСЕЗ БӘЯ БИРҮ

2013 елдан мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирү эше алып барыла (Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указын, «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 256-ФЗ номерлы Федераль законны, «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирүне камилләштерү мәсьәләләре турында Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 5 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән).

Күрсәтелгән хезмәтләрне бәяләү оешма турында мәгълүматтан һәркемнең куллана алуын тәэмин итү, хезмәт күрсәтү шартларының уңайлылыгы, шул исәптән хезмәт күрсәтүне көтү вакыты, оешма хезмәткәрләренең яхшы мөнәсәбәте, әдәплелеге һәм итагатьлелеге, күрсәтелгән хезмәтләрдән канәгатьлелек дәрәҗәсе, шулай ук сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләрнең хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү кебек критерийлар буенча алып барыла.

Сыйфатка бәйсез бәя бирүне Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлекне саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, шулай ук республика җирле үзидарәләре органнары карамагындагы иҗтимагый советлар карарлары нигезендә оештырылган иҗтимагый оешмалар уздыра.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәт шартлары турында мәгълүматны җыюны һәм гомумиләштерүне иҗтимагый советлар тарафыннан билгеләнгән оешмалар исемлеге нигезендә операторлар тарафыннан башкарыла.

2023 елда әлеге максатларга дәүләт хакимияте органнары тарафыннан 216,5 мең сум акча бүлеп бирелде, шулардан мәдәният өлкәсендә – 20,0 мең сум, мәгариф өлкәсендә – 108,0 мең сум, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә – 88,5 мең сум, сәламәтлек саклау өлкәсендә – 50,0 мең сум; җирле үзидарә органнарына – 285,9 мең сум, шулардан мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә – 1 мең сумнан алып 100,0 мең сумга кадәр (13 муниципаль берәмлектә операторлар бушлай яисә җәмәгать башлангычларында эшләде).

Законнар нигезендә бер үк оешманың хезмәтләренә бәйсез бәя бирү елга бер тапкырдан да ешрак һәм өч елга бер тапкырдан да кимрәк булырга тиеш түгел. 2023 елда түбәндәге оешмаларга карата хезмәтләргә бәйсез бәя уздырылды:

170 социаль өлкә дәүләт оешмасы (хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя уздырылырга тиешле оешмаларның 30 %), шуларга 9 мәдәният оешмасы,

52 медицина оешмасы, 72 белем бирү оешмасы, 37 социаль хезмәт күрсәтү оешмасы керә;

1 170 социаль өлкә муниципаль оешмасы (хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя уздырылырга тиешле оешмаларның 30 %), шулардан 77 мәдәният оешмасы, 1 093 мәгариф оешмасы.

Социаль өлкә оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләргә бәйсез бәя бирү нәтиҗәләре буенча тулаем алганда уңай бәя бирелде.

Анкета һәм социологик сораштыру уздыру нәтиҗәләре буенча социаль өлкә оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфаты турында кулланучылар фикере тупланды. 2023 елда анкета һәм социологик сораштыруда 136 223 кеше катнашты.

Сораштыру һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча республиканың дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, бәяләү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү планнары расланa. Әлеге планнарда хезмәт күрсәтү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затларга башкалар белән беррәттән хезмәтләрдән файдалану өчен шартлар булдыру өчен төзекләндерү эшләре алып бару, социаль өлкә хезмәткәрләренең квалификацияләрен арттыру, өлкән яшьтәге гражданнар һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар белән эшләүдә технологияләр куллану, оешмаларның рәсми сайтларында һәм мәгълүмати стендлардагы мәгълүматны вакытында яңартып тору һәм социаль өлкә оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән башка чаралар уздыру каралган.

Гражданнарга бәйсез бәя уздыруда катнашу мөмкинлеге турында хәбәр итү максатларында дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгълүмати-аңлату эшләре алып барыла.

Бәйсез бәя бирү процессын башкару социаль өлкә оешмаларының эш сыйфатын яхшыртуга, иҗтимагый оешмаларны әлеге эшне башкаруга җәлеп итү өчен шартлар булдыруга юнәлтелгән.

## ТУРИСТЛЫК

Татарстан Россиянең иң зур туристлык үзәкләренең берсе булып тора һәм традицион рәвештә илебезнең әйдәп баручы туристлык юнәлешләре унлыгына керә.

2023 елда Татарстан Республикасына туристлар агымы 4 млн кеше тәшкил итте. Әлеге күрсәткеч буенча республика Россия Федерациясе төбәкләре арасында 7 нче урында һәм Идел буе федераль округында 1 нче урында.

Республикада туристлыкны үстерүгә түбәндәгеләр ярдәм итә:

туристлык инфраструктурасын үстерү (25 меңнән артык кунакханә номеры, 2 халыкара аэропорт, 2 зур федераль трасса (М-7 һәм М-12) һәм башкалар);

истәлекле урыннарның күп булуы, шул исәптән ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән 4 объект. Татарстан – әлеге статустагы объектлар саны буенча Россиянең бердәнбер төбәге;

кызыклы этномәдәни компонент һәм милли гастрономиянең бай традицияләре.

Республиканың төп туристлык үзәкләрендәге музейларда 8,3 млн кеше булды, бу исә 2022 ел белән чагыштырганда 20,3 % күбрәк (6,9 млн кеше).

**Татарстан Республикасының төп туристлык үзәкләрендә музейларга килүчеләр динамикасы, кеше**

| Татарстан Республикасының төп туристлык үзәкләре | 2022 ел | 2023 ел | 2022 белән чагыштырганда % |
|---|---|---|---|
| «Казан Кремле» музей-тыюлыгы | 3 728 728 | 4 518 898 | 121,2 |
| «Свияжск утрау-шәһәре» музей-тыюлыгы | 1 388 267 | 1 740 440 | 125,4 |
| Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгы | 595 759 | 735 386 | 123,4 |
| Алабуга музей-тыюлыгы | 935 224 | 1 005 029 | 107,5 |
| Чистай музей-тыюлыгы | 83 240 | 35 333 [1] | 42,4 |
| Тәтеш төбәге тарихы музее | 169 749 | 199 989 | 117,8 |

[1] реконструкция эшләре алып барылу сәбәпле Чистай шәһәренең елга порты 2023 елда круиз суднолары кабул итмәде

### «Туристлык һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проекты

2023 «Туристлык һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проекты кысаларында Татарстан Республикасында өч төбәк проекты тормышка ашырылды: «Туристлык инфраструктурасын үстерү», «Туристлык продуктларыннан файдалану алу мөмкинлекләрен арттыру», «Туристлык өлкәсендә идарәне камилләштерү», әлеге максатларга 817,4 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән федераль бюджеттан – 681,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына – 136,1 млн сум.

Илкүләм проект кысаларында республикада пляжлар төзүгә һәм яр буйларын төзекләндерүгә модульле капитал булмаган чаралар буенча проектлар биргән 49 эшкуарга ярдәм күрсәтелде. Әлеге ярдәм чаралары нигезендә шәһәр яны объектларында 839 урынга исәпләнгән 229 номер, туристларның табигать кочагында ял итүе өчен уңайлы шартлар булдыру максатыннан 22 пляж төзелде.

2023 елда Казан шәһәренең Иске татар бистәсен һәм Алабуга шәһәре үзәге туристлык кодын проектлаштыру буенча чаралар кысаларында түбәндәгеләр башкарылды: туристлар өчен навигация булдырылды, арт-объектлар архитектур үзенчәлекләрне күрсәтү өчен утлар белән яктыртылды, җәмәгать санузеллары төзекләндерелде, кече архитектура формалары һәм урам сәхнәләре куелды.

2023 елның 8–9 сентябрендә Казан шәһәрендә «СоТворение» халыкара музыка фестивале уздырылды, анда 57 мең кеше катнашты.

2023 елда «Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе базасында Туристлык тармагының кадрлар потенциалын үстерү үзәге төзелде.

Әлеге үзәкнең эшчәнлеге туристлык инфраструктурасын булдыруда катнашучы кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләре җитәкчеләренең һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары вәкилләренең квалификацияләрен күтәрү буенча чараларны тормышка ашыруга юнәлтелгән. 2023 елда Самара өлкәсе, Башкортостан Республикасы һәм Татарстан Республикасыннан өч төбәк командасы уку узды.

«Туристлык һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проекты кысаларында гамәлгә ашырылган чараларның аерым юнәлеше – Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты һәм «Корпорация Туризм.РФ» акционер җәмгыятенең (алга таба – Корпорация) уртак эше.

Корпорация катнашында республикада «Казан марина» – Россиядә моңарчы тиңе булмаган яңа туристлык территориясе проектын эшләү планлаштырыла, аның кысаларында 73 га мәйданда, елның теләсә кайсы фасылында ял итү мөмкинлеге булган, 3 һәм 4 йолдызлы кунакханәләр, СПА-үзәкләр, рестораннар, глэмпинглар, пляж ялы өчен инфраструктура объектлары төзү эше алып барыла. Проектның үзенчәлеге яхта маринасы һәм яхта хуҗалары өчен яхталарга техник хезмәт күрсәтү мөмкинлеге булган яр буенда сервис инфраструктурасы һәм кыш көне кече судноларны саклау урыны төзү булып тора.

Яңа туристлык кластеры Лаеш муниципаль районында Кама елгасы яр буенча төзеләчәк, анда елның теләсә кайсы фасылында гаилә белән ял итүнең төрле вариантлары тәкъдим ителәчәк.

Беренчел исәпләүләр буенча дәүләт һәм хосусый инвестицияләр күләме 21 млрд сумнан артык дип билгеләнде. Фаразлар буенча туристлык инфраструктурасын үстерү ярдәмендә 2030 елга Лаеш муниципаль районына килүче туристлар саны елына 620 мең кешедән артып китте. Яңа туристлык кластерының эшен тәэмин итү өчен 1,9 мең эш урыны булдыралачак.

2023 елның 10 гыйнварыннан Корпорация тарафыннан «Казан марина» туристлык территориясен төзү буенча мастер-план төзү эше башланды.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов катнашында 2023 елның 31 маенда узган Татарстан Республикасы Инвестиция советы утырышы йомгаклары буенча «Казан марина» туристлык территориясен төзү проекты масштаблы инвестиция проекты дип танылды һәм Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумының өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә кертелде.

2023 елның 4 сентябрендә Корпорациянең Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Д.Н. Чернышенко катнашында узган Директорлар советы

утырышы кысаларында Корпорация тарафыннан эшләнгән «Казан марина» туристлык территориясен төзү буенча мастер-план расланды.

**Туристлык маршрутлары челтәрен үстерү**

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан конкурентлыкка сәләтле туристлык маршрутлары төзү эше дәвам иттерелә.

«Бөек Болгар юлы» төбәкара маршрутына Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгы каршындагы Эксперт советы тарафыннан эчке һәм тышкы туризмны үстерүдә аның мөһим урын тотуын билгеләүче «илкүләм туристлык маршруты» дигән статус бирелде.

«Бөек Болгар юлы» төбәкара маршруты Идел буеның өч төбәге – Татарстан, Чувашстан һәм Мари Эл аша уза. «Бөек Болгар юлы» маршрутын туплап торучы төбәк ул – Татарстан Республикасы. Маршрут Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан 2016 елда оештырылган шул ук исемдәге төбәкара проекты кысаларында үстерелә.

2023 елда төбәкләр арасында хезмәттәшлекне үстерү кысаларында Казан – Чабаксар һәм Чабаксар – Казан, шулай ук Казан – Ульяновск һәм Ульяновск – Казан маршрутлары буенча «Метеор-2020» пассажир судноларында төбәкара турлар җибәрелде. Әлеге турлар ял көннәре туры форматында (2 көн/1 төн) төзелде һәм аңа Казан, Чабаксар һәм Ульяновск шәһәрләренең төп истәлекле урыннарына экскурсияләр кертелгән.

2023 елның табигать туризмы өлкәсендәге иң әһәмиятле проектларының берсе «Идел юлы» проектын рәсми рәвештә эшләтеп җибәрү. «Идел юлы» – ул Идел елгасы яры буенча Ульяновск өлкәсе һәм Чувашстан Республикасы чигенә кадәр Казан шәһәре һәм Зәңгәр күлләр аша 350 км озынлыкта җәяүлеләр өчен юл. Бу исә иң матур урыннар буйлап сәяхәт итү өчен төн куну һәм туклану урыннары кергән әзер маршрут. Трек профильле туристлык берләшмәләре, гидлар һәм юл күрсәтеп, озата баручыларны җәлеп итеп планлаштырылды.

Мөстәкыйль рәвештә сәяхәт итүчеләр өчен – Идел юлы буйлап сәяхәттә ышанычлы юл күрсәтүче мобиль кушымта эшләнде. Анда иң кызыклы җирләр, кемпинг өчен урыннар, чишмәләр, урнашу объектлары, кибетләр турында төп мәгълүмат бирелгән.

Россия һәм чит ил базарларында республиканың туристлык өлкәсендәге мөмкинлекләрен таныту максатларында 2023 елда түбәндәге чаралар тормышка ашырылды:

Татарстан Республикасы өч халыкара туристлык күргәзмәсендә катнашты: MITT (16–18 март, Мәскәү шәһәрендә), «Интурмаркет» (13–15 март, Мәскәү шәһәрендә), «Здравница» форумы (31 май–2 июнь, Хабаровск шәһәрендә);

туристлык компанияләре вәкилләре өчен 11 таныштыру туры уздырылды – Россиянең 17 шәһәреннән һәм дүрт чит илдән 191 туроператор республикага эшкә кабул ителде (Иран, Азәрбайҗан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Согуд Гарәбстаны), Татарстан Республикасы территориясендә 4 тревэл-тапшыру төшерелде;

Татарстанның туристлык мөмкинлекләрен күрсәтү максатыннан 7 имидж реклама кампаниясе төшерелде: Түбән Новгородтан Казан шәһәренә бара торган шәһәр яны поездларында, Мәскәү – Казан маршруты буенча ерак арага йөри торган «Премиум» поездында, Мәскәү шәһәренең «Шереметьево» аэропортында эчке

рейсларның очып китү терминалында, шулай ук Интернет челтәрендә.

«Тарихи тамырларыбызга сәяхәт» XIV республика конкурсы уздырылды. Ул Татарстанда балалар һәм яшүсмерләр аудиториясенә юнәлтелгән беренче конкурс, аның максаты – тарихи мирас һәм өстенлекле туристлык үзәкләре белән бәйле хосусый инновация проектларын тормышка ашыру аша Татарстан Республикасында эчке һәм тышкы туристлыкны үстерү.  Конкурс тугыз номинациядә: «Татарстан Республикасында мин барырга теләгән урын» темасына иң яхшы рәсем», «Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты», «Иң яхшы авыл туризмы маршруты», «Иң яхшы этнотуризм маршруты», «Иң яхшы актив туризм һәм ял итү маршруты», «Иң яхшы гастрономик туризм маршруты», «Татарстан Республикасы буенча иң яхшы виртуаль экскурсия», «Туристлык өлкәсендә иң яхшы проект» һәм «Иң яхшы видео-экскурсия» уздырылды. 2023 елда конкурста катнашуга республиканың 20 муниципаль районыннан 156 гариза кабул ителде. Конкурс йомгаклары буенча 28 эш иң яхшылары дип танылды, аларның авторларына дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

**Волонтерлар хәрәкәте**

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты «Татарстан Республикасының туристлык волонтерлары ассамблеясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән берлектә еллык «Кунакчыл Казан» проекты тормышка ашырылды, аның кысаларында республиканың югары белем бирү мәгариф оешмалары туристлык факультетлары студентлары туристларга Татарстанның төп туристлык үзәкләре турында мәгълүмат бирде, туристлык үзәкләрендә хәрәкәт итәргә булышты, шулай ук Казан шәһәре, Бөек Болгар һәм Свияжск утрак-шәһәренең өч телдә бастырып чыгарылган туристлык карталарын тәкъдим итте.

Волонтерлар теория һәм гамәли күнекмәләр буенча белем алды. Проектны тормышка ашыру барышында Россия Федерациясенең төрле шәһәрләреннән (Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Түбән Новгород, Самара, Махачкала, Новосибирск һ.б.) һәм чит илләрдән (Германия, Франция, Мисыр, Испания, Португалия, Грузия, Һиндстан, Кытай, Бөекбритания, Иран, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) волонтерларга 40 меңнән артык турист мөрәҗәгать итте.

# ЭКОЛОГИЯ

## Атмосфера һавасын саклау

Автотранспортның атмосфера һавасы торышына тискәре йогынтысын киметү максатларында 2023 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафннан Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе белән берлектә линиягә чыгарыла торган һәм кулланылышта булган автотранспорт чаралары ташлаган эшкәртелгән газларда пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларның билгеләнгән нормативларын үтәүне тикшереп тору буенча оператив-профилактик чаралар уздырылды («Чиста һава» операциясе). Операция кысаларында 6 886 автомашина тикшерелде, шуларның 184 автомашина кирәкле чыгарып ташлау нормативларына туры килмәде.

2023 елда Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов йөкләмәсе буенча республикада климат сәясәте һәм Татарстан Республикасын декарбанлаштыру планнары мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем үз эшен дәвам итте. Эшче төркем эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында 2050 елга кадәр парник газлары чыгару дәрәҗәсе түбән булган социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы расланды. Аңа 57 чара кертелгән, аларны гамәлгә ашыру буенча 28 җаваплы башкаручы билгеләнгән. Максат – 2050 елга углерод нейтральлегенә ирешү.

2023 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан 2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә парник газларын чыгаруны һәм йотуны инвентарьлаштыру эше үткәрелде. Парник газларын әйләнә-тирә мохиткә чыгаруга төп өлешне энергетика тармагы, сәнәгать, авыл хуҗалыгы, каты коммуналь калдыкларны күмү полигоннары кертә, дип билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 декабрь, 1390 нчы карары белән расланган 2022–2030 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планының үтәлешен күзәтү алып барыла.

2023 ел дәвамында хуҗалык итүче субъектлар белән аларның атмосфера һавасына тискәре йогынтысын киметү максатында планлы эш алып барылды.

## Су объектларын саклау

*Су объектлары чикләрен билгеләү*

Республикада су объектларының чикләрен билгеләү эше дәвам итә, 15 746,16 км озынлыктагы чикләр билгеләнгән, ягъни республикада урнашкан барлык су объектларының яр буе линияләренең гомуми озынлыгының 36,69 %ы, шул исәптән 2023 елда яр сызыкларының озынлыгы 1 291,51 км булган 46 су объектында чикләр билгеләнгән.

Шулай ук 13 су объектында җирлектә су саклау зоналары һәм яр буен саклау полосалары чикләрен 109 берәмлек махсус мәгълүмат билгеләре белән беркетү чаралары уздырылды. Урында билгеләнгән махсус мәгълүмат билгеләренең гомуми саны 1 859 берәмлек тәшкил итә.

Яр буе линияләренең урнашу урынын (су объектлары чикләрен), су саклау зоналары чикләрен һәм су объектларының яр буе саклау полосалары чикләрен билгеләү чаралары территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә җир кишәрлекләрен законсыз бүлеп бирү очракларын, җирләрне үз белдеге белән алу очракларын тулысынча кисәтергә, шулай ук су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә, шул исәптән су саклау зоналары һәм аларның яр буе саклау полосалары чикләрендә табигатьне саклау законнары таләпләрен бозучы хуҗалык субъектларына карата Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексында каралган административ йогынты чараларын куллану өлешендә, төбәк дәүләт күзәтчелегенең нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

*Казансу елгасының пычрану чыганакларын бәяләү һәм экологик торышын анализлау буенча фәнни-тикшеренү эшләре.*

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан, тискәре йогынты сәбәпләрен ачыклау һәм аларны ранжировкалау өчен, алга таба су объектларының экологик торышын яхшырту буенча чаралар комплексын эшләп чыгару өчен, сайланган пилот су объекты Казансу елгасы үрнәгендә, фәнни-тикшеренү эшләре буенча пилот проекты гамәлгә ашырыла.

Эшләү кысаларында:

су объектларының гидрохимик һәм геоэкологик мониторингының мөмкин булган мәгълүматларына, инспекция тикшерүләре нәтиҗәләренә һәм авыл хуҗалыгы кырларының агрохимик мониторингына, су җыю территориясен хуҗалык өчен файдалану турындагы мәгълүматларга, шулай ук гидрографик челтәр элементларын инвентаризацияләүгә анализ ясалды;

Казансу елгасының диффуз пычрануының төп потенциаль чыганаклары ачыкланган;

Казансу елгасы бассейнында характерлы су җыелмаларында контроль кыр тикшеренүләре комплексы гамәлгә ашырылган;

биоген һәм үлчәнгән матдәләр буенча Казансу елгасының йөкләнешен бәяләү һәм Казансу елгасының диффуз пычрануын киметү һәм су сыйфатын яхшырту буенча фәнни-нигезләнгән тәкъдимнәр әзерләү башкарылган.

*«Ирекле ток» проекты*

2023 елда «Ирекле ток» проекты кысасында Казансу елгасы акваториясеннән агач өемнәрен чыгару чаралары гамәлгә ашырылды (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы елгаларының һәм сулыкларының экологик торышын яхшырту» сынау фәнни-тикшеренү проектының икенче этабы кысаларында). 25 урында агачларның өеме эшкәртелгән, Казансу елгасы акваториясеннән 1 700 куб. м үзагач (1 200 тонна ауган агач) алынган.

Агачлар аз үлчәмле суднолар өчен куркыныч тудыра, балыклар яшәү тирәлегенең табигый шартларын боза, торак пунктлардан елгага керә торган көнкүреш калдыкларының тупланмасы булып тора һәм елганың агым тизлеген киметә, бу исә су агымының ләмләнүенә китерә. Казансу елгасы акваториясен агач өемнәреннән чистарту аны савыктыруга, экологик һәм эстетик хәлен яхшыртуга, су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын яхшыртуга, ташу чорында янәшә территорияләрне су басу куркынычы кимүгә ярдәм итәчәк.

**Җир асты сулары запасларын торгызу**

2024 елның 1 гыйнварына республика территориясендә расланган эксплуатация запаслары 2 389,1 мең куб. м/тәүлек тәшкил иткән җир асты суларының 535 ятмасы һәм җир асты сулары чыганаклары кишәрлекләре разведкаланган.

2023 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 1 гыйнварына кадәр җир асты сулары запасларының гомуми үсеше 7 яңа чыганак һәм җир асты сулары чыганаклары кишәрлекләре буенча 3,23 мең куб. м/тәүлек тәшкил итте.

**Гомумтаралган файдалы казылмалар**

Минераль-чимал базасын торгызу өчен 2023 елда гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын 68,2 млн куб. м күләмендә арттыру тәэмин ителгән, шул исәптән файдалы казылмалар төрләре буенча: комлы-вак ташлы токымнар – 22,3 млн. куб. м; төзелеш өчен ташлар (известьташ) – 5,5 млн. куб. м; төзелеш комы – 33,6 млн. куб. м; комлы-балчыклы токымнар – 3,3 млн. куб. м; кирпеч-чирәп чималы – 2,7 млн. куб. м; ком – 0,8 млн. куб. м.

Җир асты байлыкларыннан тигез файдалану өчен республиканың гомумтаралган файдалы казылмалар запаслары белән тәэмин ителешен даими тикшереп тору алып барыла.

2024 елның 1 гыйнварына республика территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына 2 093 лицензия гамәлдә булды:

316 лицензия (җир асты байлыкларының 112 кишәрлеге елгалар акваторияләрендә урнашкан, 204 – коры җирдә), алар гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару максатларында 196 предприятие тарафыннан рәсмиләштерелгән. 65 лицензия туктатып тору хәлендә;

1 777 лицензия төрле милек рәвешләрендәге 1 060 предприятиегә, бакчачылык ширкәтләренә һәм шәхси эшмәкәрләргә җир асты суларын геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен рәсмиләштерелгән, алар эчәргә яраклы су һәм техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла һәм аларны чыгару күләме 500 куб. м/тәүлектән артмаган.

**Әйләнә-тирә мохит торышын күзәтү буенча территориаль системасын үстерү**

Әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтү территориаль системасы кысаларында республика территориясендә атмосфера һавасының пычрануын контрольдә тотуның 17 автомат станциясеннән (алга таба – станцияләр) һәм 6 күчмә экологик лабораториядән (алга таба – лабораторияләр) торучы атмосфера һавасының пычрануын күзәтү челтәре формалашты.

2023 елда 115 күзәтү пунктында су объектларының гидрохимик торышын даими мониторинг күзәтеп торуы башкарылган, 141 күзәтү пунктында тискәре йогынтылы объектлар тәэсиренә дучар булган су объектларының торышын күзәткәннәр. Барлыгы 95 су өстендәге объект күзәтүләр астында булган. Су өстендәге объектларының сыйфатын күзәтү кысаларында мәгълүмат «Татарстан Республикасының экологик картасы» дәүләт мәгълүмат системасына интеграцияләнде. Бу экологик вәзгыятьне яхшыртуны тоткарлаучы факторларны комплексы бәяләргә һәм ачыкларга мөмкинлек бирә.

Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының өске суларына экологик мониторинг үткәрү өчен, 2022 елда модернизация узган «Идел-М» суднолы табигатьне саклау комплексы (СПК) урнаштырылган «Фламинго» фәнни-тикшеренү судносы кулланыла. 2023 елда «Фламинго» фәнни-тикшеренү судносы тарафыннан республика чикләрендә Куйбышев сусаклагычында тикшерү уздырылган. 1,5 млн.нан артык гидрохимик күрсәткечләр үлчәнде, Идел елгасының өске суларының маршрут мониторингы, биологик чистарту корылмалары чыгарылмалары анализы, пычраткыч матдәләрне чиктән тыш күчерү мониторингы гамәлгә ашырылды.

**Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)**

2023 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының территориаль идарәләре тарафыннан контрольдә тотыла торган затлар адресына мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамаганлыгы һәм аларның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрү зарурлыгы турында 3 428 кисәтү бирелде.

Эшчәнлекләре нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохит компонентларына зыян килергә мөмкин булган затларга профилактик һәм кисәтү характерындагы чаралар комплексын кабул итү максатында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2023 елның 24 августындагы 990-б номерлы һәм 991-б номерлы боерыклары белән профилактик визитлар уздыру графиклары расланган. Тикшерелә торган зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча 43 профилактик чара, шәхси кабул итү рәвешендә 429 консультация үткәрелде.

2023 елда төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кысаларында табигатьне саклау законнарын бозуның 3 898 очрагы ачыкланган һәм бетерелгән.

Хокук саклау органнары материаллары буенча 4,1 млн сумлык 163 административ штраф салынган, 183 кисәтү чыгарылган, шулай ук 4 телдән кисәтү ясалган.

Әйләнә-тирә мохит компонентларына зыян китерү фактлары буенча 348 дәгъва таләпләре белдерелгән, шуларның 211е – ачыкланган хокук бозуларны бетерүгә мәҗбүр итү, 137е – 302,3 млн сумлык зыянны каплау турында.

**«Экология» илкүләм проекты**

2023 елда республикада «Экология» илкүләм проектының 4 федераль проектын гамәлгә ашыруга 3 469,3 млн сум акча бүлеп бирелгән һәм тотылган, шул исәптән федераль бюджеттан – 2 728,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 741,0 млн сум, шул исәптән:

1) «Иделне сәламәтләндерү» федераль проектының ике юнәлеше буенча 2 833,9 млн сум бүленгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан – 2 281,1 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 552,8 млн сум, шул исәптән:

«Идел елгасына пычранган агып төшүче суларны чыгаруны киметү» юнәлеше буенча – Казан шәһәренең канализациясенең биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләгәндә 807,8 млн сум үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 654,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 153,5 млн сум;

«Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ликвидацияләү

(рекультивацияләү) һәм Идел елгасына куркыныч тудыручы әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян чыганакларын изоляцияләү» юнәлеше буенча Идел елгасына куркыныч тудыручы тупланган зыянлы ике объект буенча 2023 елда 2 026,1 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 1 626,8 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты – 399,3 млн сум, шул исәптән:

Куйбышев сусаклагычының су саклау зонасында урнашкан тупланган экологик зыянның зур объектын бетерү эшләрен дәвам итүгә – якынча 100 га мәйданлы Казан шәһәренең биологик чистарту корылмаларының ләм кырларын рекультивацияләүгә 1 395,6 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 1 130,4 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 265,2 млн сум;

«Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә Озерное чыганагының эшләми торган торба үткәргечләрен сүтү» чарасын тәмамлауга 2023 елда 630,5 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 496,4 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 134,1 млн сум. Чараны гамәлгә ашыру срогы – 2022–2023 еллар. Эшләми торган нефть торбаүткәргечләрен сүтү эшләре тулысынча төгәлләнде, Түбән Кама сусаклагычы суына тискәре йогынты ясауның потенциаль куркынычы бетерелде. Эшләр уздыру нәтиҗәсендә 1 250,2 мең кешегә тискәре йогынты ясауның мөмкин булган куркынычы бетерелде.

2) «Чиста ил» федераль проекты буенча 2023 елда 470,5 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 282,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты – 188,2 млн сум, шул исәптән:

Казан шәһәренең Мамадыш тракты урамы буенча Самосырово полигонын рекультивацияләү буенча чараны тәмамлауга 2023 елда 373,8 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан – 224,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 149,5 млн сум. Чараны гамәлгә ашыру срогы – 2021–2023 еллар. Объектта эшләр төгәлләнгән, 14,14 гектар рекультивацияләнгән. Эшләр үткәрү нәтиҗәсендә 342,9 мең кешенең экологик яшәү шартлары яхшыртылды (чараны гамәлгә ашыруның гомуми бәясе – 872,2 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 517,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты – 354,9 млн сум);

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән авылында Завод урамында нефть белән пычранып бозылган җирләрне рекультивацияләү» чарасын гамәлгә ашыра башлауга 2023 елда 96,7 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 58,0 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 38,7 млн сум.

3) «Уникаль су объектларын саклау» федераль проекты буенча 2023 елда Мамадыш муниципаль районының Кама Леспромхозы авылы янында Бөрсет елгасы үзәнен чистарту чараларын төгәлләүгә 68,7 млн сум күләмендә федераль субвенцияләр бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән. Чараны гамәлгә ашыру срогы – 2022–2023 еллар. Объектта эшләр тәмамланган, чистартуның озынлыгы 7,0 км тәшкил иткән. Эшләр үткәрү нәтиҗәсендә 2,5 мең кешенең экологик яшәү шартлары яхшырган.

4) «Урманнарны саклау» федераль проекты буенча 2023 елда федераль бюджеттан 111,5 млн сум күләмендә субвенцияләр бүленде һәм үзләштерелде, шул

исәптән урман орлыклары запасын булдыру, урман торгызу һәм урман үрчетүне тәэмин итү, урманнарны янгыннардан саклау техникасы һәм җиһазлары белән җиһазландыруга, учреждениеләрне урман торгызу һәм урман үрчетү өчен махсус техника һәм җайланмалар белән җиһазландыруга.

**Табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану**

*«Табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Россия Федерациясе дәүләт программасы.*

2023 елда 20 чараны гамәлгә ашыруга 171,5 млн сум акча тотылган (федераль бюджеттан – 111,0 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 60,5 млн сум), шул исәптән:

95,8 млн сум (федераль бюджет акчалары – 57,5 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 38,3 млн сум) – Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогында яр ныгыту эшләренә;

55,4 млн сум (федераль бюджет акчасы – 33,2 сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 22,2 млн сум) – Алабуга, Мамадыш, Питрәч, Саба, Чирмешән, Биектау, Чистай, Зеленодольск муниципаль районнарында 14 гидротехник корылмаларда капиталь ремонтны дәвам итү өчен;

Су мөнәсәбәтләре өлкәсендәге аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга – 20,3 млн. сум (федераль бюджет акчалары).

*«Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы.*

Татарстан Республикасы бюджетыннан табигатьне саклау буенча 71 чараны гамәлгә ашыруга түбәндәге ярдәмче программалар буенча 594,3 млн сум акча бүленгән:

«Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохите сыйфатын җайга салу» – 44,1 млн сум;

«Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе» – 5,5 млн сум;

«Татарстан Республикасының җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе» – 72,8 млн сум;

«Татарстан Республикасының су хуҗалыгы комплексын үстерү» – 471,9 млн сум.

**Җирле бюджет акчалары исәбеннән табигатьне саклау чараларын финанслау**

Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында ел саен, 2012 елдан башлап, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов карары буенча, экологик түләүләрдән кергән керемнәр күләмендә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән табигатьне саклау чаралары гамәлгә ашырыла (әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләү, гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруга салым, табигатьне саклау законнары таләпләрен бозган өчен түләтелгән акчалар).

2023 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы республика муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыруга барлыгы 316,3 млн сумлык 45 килешү төзегән, шул исәптән 78,3 млн сум – 2022 елның файдаланылмаган

калдыклары исәбенә, 9,3 млн  сум – 2023 елның өстәмә керемнәре хисабына.

**«Лачын-балобанның Идел-Кама популяциясен торгызу» проекты**

2023 елда «СИБУР Холдинг» ГАЖ грант ярдәме белән Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Лачын-балобанның Идел-Кама популяциясен торгызу буенча пилот проекты гамәлгә ашырылды, аның оясы соңгы тапкыр 1974 елда Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгының Саралан участогы территориясендә теркәлгән.

Проектны гамәлгә ашыру кысаларында Мәскәү өлкәсеннән республиканың Кама Тамагы муниципаль районына китерелгән кошчыклар әзерләнгән һәм табигый яшәү тирәлегенә  уңышлы чыгарылган.

Халык тавыш бирүе нәтиҗәләре буенча проект «Бәллүр компас» милли премиясенең иң яхшы проектлары өчлегенә керде һәм «Ышанычлы партнер - Экология» V Бөтенроссия конкурсының «Биологик төрлелекне саклау өлкәсендә иң яхшы проект» номинациясендә җиңүчесе булды. Шулай ук проект 2023 елның сентябрендә Владивостокта узган Көнчыгыш икътисади форумы кысаларында «Лачын көне» беренче халыкара форумында билгеләп үтелде.

**Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фондын үстерү**

Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен булдыру табигать байлыкларын саклауның һәм арттыруның иң нәтиҗәле механизмы булып тора, бу экологик балансны һәм табигый биотөрлелекне сакларга, шулай ук халыкның тормыш сыйфатының мөһим компонентларының берсе буларак республиканың экологик иминлеген тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Республиканың табигать-тыюлык фонды гомуми мәйданы 465,1 мең гектар булган (Татарстан Республикасының гомуми мәйданының 7 %) 194 махсус сакланыла торган территорияне төзи, анда табигый комплексларны, ландшафтларны һәм биологик төрлелекне саклау һәм торгызу өчен оптималь шартлар тәэмин ителгән, шуларның 3 есе – федераль әһәмияттәге, 187се – төбәк әһәмиятендәге, 4е – җирле әһәмияттәге.

Төбәк әһәмиятендәге аерым сакланыла торган территорияләрне булдыру өчен перспективалы кишәрлекләрне ачыклау максатларында Югары Ослан, Кайбыч, Кама Тамагы, Лаеш, Зеленодольск муниципаль районнары территориясендә хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең төр төрлелеген ачыклау буенча фәнни-тикшеренү эшләре алып барылды. Эш нәтиҗәләре буенча аларга махсус сакланыла торган табигать территориясе статусы бирү өчен потенциаль территорияләр буларак каралачак 3 участок билгеләнгән. Республика территориясендә моңарчы очрамаган сирәк очрый торган хайван һәм үсемлек төрләренең яңа яшәү урыннары ачыкланды.

Махсус сакланыла торган территорияләр булдыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектлары эшләнде:

«Минзәлә муниципаль районы территориясендә «Шифа» чишмәсе тирәсендә табигать комплексы;

Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары территориясендә «Акчарлаклар колонияләре»;

Азнакай муниципаль районы территориясендә «Байбаклар колонияләре»;

Түбән Кама муниципаль районы территориясендә «Зур ак челән оя кору урыны»;

Алексеевск муниципаль районы территориясендә «Юеш Көрнәле»;

Апас муниципаль районы территориясендә «Сфагново-верховое сазлыгы».

Өстәмә рәвештә 71 төбәк әһәмиятендәге су саклау территориясе өчен махсус сакланыла торган зоналары булдыру турында Татарстан Республикасы Рәисе указлары проектлары эшләнде.

**Урман комплексын үстерү**

Татарстан Республикасы урманнарының гомуми мәйданы 1 267,2 мең гектар (Татарстан Республикасының гомуми мәйданыннан 18,7 %).

«Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы һәм «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проекты кысаларында «Экология» илкүләм проектының «Урманнарны саклау» федераль проекты кысаларында түбәндәге чаралар уздырылды:

3 517,5 гектар гомуми мәйданда урман торгызу (шул исәптән 1 421,5 гектар мәйданда урман культуралары утырту, 2 092 гектар мәйданда табигый урман торгызу, 4 гектар мәйданда катнаш урман торгызу);

143,7 гектар мәйданда урман үрчетү;

булдырылган урман культураларын бетүдән саклап калу максатларында 17 055 гектар мәйданда агротехник тәрбия уздырылды, шулай ук 4 043,6 гектар мәйданда урман культуралары тулыландырылды. 2024 елда 1 408,5 гектар мәйданда урман культураларын утырту өчен туфрак әзерләнде. 105,3 гектр мәйданда утыртылганн урман орлыкчылыгы объектларын карау уздырылды;

урман хасил итүче төп токымнарның 12,8 тонна орлыгы әзерләнгән, 30,9 млн данә утырту материалы җитештерелгән.

Янгынга каршы эшләр кысаларында 111,3 км урман юллары төзелде, урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән 426,5 км урман юлы реконструкцияләнде. Минераллаштырылган полосаларны төзү 2 395,2 км арада башкарылган. 4 806,9 км озынлыктагы минераллаштырылган полосаларны карау уздырылган. 330 гектар мәйданда контрольдә тотыла торган профилактик яндыру үткәрелде. 2 796,7 гектар мәйданда файдаланылмый торган агач җыештырылды.

2023 елда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) һәм урман саклауны патрульләү һәм контроль (күзәтчелек) чараларын уздыру рәвешендә гамәлгә ашырганда 40 меңнән артык чара үткәрелгән. Үткәрелгән чаралар барышында урманнарга 47,5 миллион сумлык зыян китерү белән урман законнарын бозуның 292 очрагы ачыкланган, шул исәптән урман утыртмаларын 4,7 миллион сумлык зыян белән законсыз кисүнең 117 очрагы, законсыз рәвештә әзерләнгән агач күләме 398,2 кубометр тәшкил иткән.

2023 елда судка кадәр тәртиптә куелган 280 таләп буенча 44,3 млн сумлык зыян түләнгән.

Урманчылыклар белән берлектә 305 административ эш кузгатылган. Барлыгы 281 зат 1 332,5 мең сумлык административ җаваплылыкка тартылды. 1 087,3 мең сумлык административ штрафлар алынды.


Федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кысаларында 4,9 меңнән артык профилактик чара үткәрелде, шул исәптән: 3 433 мәгълүмат

җиткерү, 1 408 консультация бирү, 77 мәҗбүри профилактик визит үткәрү, мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турында 52 кисәтү игълан ителде.

## ТӨП ИКЪТИСАДЫЙ КҮРСӘТКЕЧЛӘР

Татарстан Республикасы тулаем төбәк продукты һәм төп капиталга инвестицияләр күләме буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында 6 урында тора, төзелеш – 2 урында, сәнәгать житештерүе һәм авыл хуҗалыгы продукциясе – 5 урында, ваклап сату әйләнеше – 7 урында.

**2023 елда Татарстан Республикасында тулаем төбәк продукты**




2023 ел нәтиҗәләре буенча тулаем төбәк продукты күләме, бәяләүләр буенча, 4 320,0 млрд сум тәшкил иткән, яки 2022 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 103,6 %.

**Татарстан Республикасында 2023 елда икътисадый эшчәнлек төрләре буенча тулаем төбәк продукты житештерү структурасы (бәяләү), %**




Икътисад структурасында иң зур чагыштырма авырлыкны сәнәгать били – 45,8 % (шул исәптән, файдалы казылмалар чыгару – 24,6 %, эшкәртү производстволары – 19,1 %, электр энергиясе, газ, пар белән тәэмин итү; һаваны кондиционлаштыру – 1,7 %, су белән тәэмин итү; су чыгару, калдыкларны җыю һәм утильләштерүне оештыру, пычрануларны бетерү эшчәнлеге – 0,4 %), авыл хуҗалыгы – 3,9 %, төзелеш – 7,3 %, күпләп һәм ваклап сату – 10,6 %, транспортировка һәм саклау – 4,6 %.

**Сәнәгать**

2023 елда сәнәгать җитештерүе индексы 2022 ел дәрәҗәсенә карата 103,3 % тәшкил итте, төяп җибәрелгән продукция күләме – 4 742,3 млрд. сум.

**2023 елда сәнәгать җитештерүе**





Файдалы казылмалар чыгаруда җитештерү индексы 2022 ел дәрәҗәсенә карата 99,5 %, эшкәртү производстволарында – 106,0 %, электр энергиясе, газ, пар, һаваны кондицияләү белән тәэмин итү – 100,3 %, су белән тәэмин итү, су чыгару, калдыклар җыюны һәм утильләштерүне, пычракларны бетерү эшчәнлеген оештыру 100,8 % тәшкил итте.

Эшкәртү производстволарында үсеш түбәндәге тармакларда күзәтелә: кокс һәм нефть продуктлары җитештерү (2022 ел дәрәҗәсенә карата 102,4 %), резина һәм пластмасса әйберләр (102,4 %), дарулар һәм медицина максатларында кулланыла торган материаллар (108,0 %), автотранспорт чаралары, тагылмалар һәм ярымтагылмалар (119,2 %), компьютерлар, электрон һәм оптик эшләнмәләр (128,8 %), әзер металл эшләнмәләр, машиналар һәм җиһазлардан тыш (107,1 %), электр җиһазлары (142,2 %), башка транспорт чаралары һәм җиһазлар (130,6 %), башка төркемнәргә кертелмәгән машиналар һәм җиһазлар (101,9 %), металлургия җитештерүе (113,3 %), башка металл булмаган минераль продукция җитештерү (110,4 %), азык-төлек продуктлары (105,5 %), кием (105,9 %), текстиль эшләнмәләр (101,7 %), җиһазлар (124,8 %), башка әзер эшләнмәләр (102,1 %).

Сәнәгать җитештерүе күләмнәренең кимүе химик матдәләр һәм химик продуктлар җитештерүдә (2022 елга карата 95,0 %), агач эшкәртү һәм агач һәм бөке эшләнмәләр җитештерүдә (93,4 %), кәгазьләр һәм кәгазь эшләнмәләр (86,7 %), күн һәм күн эшләнмәләр (97,1 %), эчемлекләр (99,9 %) җитештерүдә күзәтелде.

Төяп җибәрелгән продукция структурасында файдалы казылмалар чыгару өлеше 23,7 %, эшкәртү производстволары - 71,2 %, электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү өлеше; һаваны кондицияләштерү – 3,8 %, су белән тәэмин итү; су чыгару, калдыкларны җыюны һәм утильләштерүне оештыру, пычрануларны бетерү эшчәнлеге – 1,3 %.

**2023 елда Татарстан Республикасының төяп җибәрелгән продукция күләме структурасы, %**





## Авыл хуҗалыгы

2023 ел нәтиҗәләре буенча авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 289,2 млрд сум тәшкил итте, яки 2022 ел белән чагыштыргандагы бәяләрдә 92,1 %. Үсемлекчелек продукциясен җитештерү 2022 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә – 81,5 %, терлекчелек продукциясен җитештерү – 102,1 %.

3 603,7 мең тонна бөртекле ашлык (эшкәрткәннән соң үлчәүдә), 879,2 мең тонна бәрәңге, 1 758,2 мең тонна шикәр чөгендере, 264,3 мең тонна ачык һәм сакланган грунт яшелчәләре җыеп алынды.

2 190,0 мең тонна сөт савылган, 512,9 мең тонна терлек һәм кош ите (тере үлчәмдә), 1 562,6 млн данә йомырка җитештерелде.


**2023 елда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме**



**Төзелеш**

2023 ел нәтиҗәләре буенча төзелеш эшләре күләме 708,1 млрд сум тәшкил итте, яки 2022 ел белән чагыштыргандагы бәяләрдә 115,1 %.

**2023 елда «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча эшләр күләме**




3 436,5 мең кв.м гомуми торак мәйданы (2022 ел дәрәҗәсенә карата 111,1 %) эксплуатациягә кертелгән.

**Кулланучылар базары**


2023 ел нәтиҗәләре буенча ваклап сату әйләнеше 1 400,1 млрд сум тәшкил итте, ягъни 2022 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 111,3 %, шул исәптән азык-төлек продуктлары – 627,7 млрд сум (2022 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 106,3 %), азык-төлек булмаган товарлар – 772,4 млрд сум (115,6 %).

**2023 елда ваклап сату әйләнеше**




Халыкка түләүле хезмәтләр күләме 2023 елда 400,0 млрд сум тәшкил итте (2022 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 105,7 %), җәмәгать туклануы әйләнеше – 67,3 млрд сум (114,8 %).

## 2023 елда халыкка түләүле хезмәтләр күләме





## 2023 елда җәмәгать туклануы әйләнеше




Куллану бәяләре индексы 2023 елның декабрендә 2022 елның декабренә карата 107,1 % тәшкил итте, шул исәптән азык-төлек товарларына – 108,1 %, азык-төлек булмаган товарларга – 105,2 %, хезмәт күрсәтүләргә – 108,6 %.

## Куллану бәяләре индексы (2022 елның декабренә, %)



## СӘНӘГАТЬ

### Нефть һәм газ химиясе комплексы

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ нефть, шул исәптән югары үзле нефть эшкәртү һәм чыгару буенча уникаль компетенцияләргә ия. Компания Казакъстан, Төрекмәнстан, Төркия, Үзбәкстанга технологияләр һәм җиһазлар инжинирингы буенча хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итә.

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ парник газларын чыгаруны киметү буенча планлы эше ESG-көн тәртибен гамәлгә ашыру буенча мөһим өлешләрнең берсе булып тора.

Хәзерге вакытта Россиядә углерод берәмлекләре базары реестрында компаниянең өч проекты теркәлгән:

«Баулынефть» нефть-газ чыгару идарәсенең дожимлы насос станцияләрендә гамәлгә ашырыла торган проект газны җыю системасын киңәйтү белән бәйле һәм шулай ук факелларда газны яндырудан углекислый газ чыгаруны киметүгә юнәлдерелгән;

Миңнебай газ эшкәртү заводының («Татнефтегазпереработка» идарәсе) факель системасын модернизацияләүне һәм факелда коры кайтартылган газ куллануны киметүне күздә тоткан проект;

«Елховнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең 5 нче дожимлы насос станциясендә гамәлгә ашырыла торган проект, аның нигезендә иярчен нефть газы элементар күкерт һәм товар газы алу өчен эшкәртү заводына юнәлдереләчәк.

Түбән Кама шәһәрендә Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексын («ТАНЕКО» АҖ) төзү проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2023 елның 22 декабрендә төп технологик җайланмаларны эксплуатацияләү өчен гомумзавод хуҗалыгы объектлары комплекслы сынау режимында гамәлгә кертелде: амин чистарту һәм әче суларны җибәрү катнаш җайланмасы, 4нче номерлы су блогы, азот станциясе һәм һава компрессорлы.

Россия җиһазларыннан файдалану дәрәҗәсе 90 %.

«Сибур Холдинг» ГАҖ тарафыннан катализаторлар, урта һәм аз тоннажлы химия җитештерү буенча проектларны гамәлгә кертү алып барыла.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖндә 2025 елга кадәр предприятиене үстерүнең стратегик программасы гамәлгә ашырыла, аның төп проектларының берсе – полимерлар җитештерү белән ЭП-600 яңа олефин (этилен) комплексы (2025 елда гамәлгә кертү планлаштырыла).

2023 елда «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖндә галобутиль каучуклар җитештерү заводын модернизацияләү тәмамланды, анда елына 150 мең тоннадан 200 мең тоннага кадәр егәрлек үстерелде. Модернизацияләү барышында 6 яңа җитештерү җайланмасы төзелде, 16 – яңартылды.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖндә гексен җитештерү проекты гамәлгә ашырыла. Әлеге продукт Россия өчен уникаль булып тора. Проектны 2025 елда төгәлләү планлаштырыла.

«Казаноргсинтез» ГАҖндә түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм эшкәртү заводында «В» реакторын модернизацияләү эше дәвам итә, җитештерү куәтләрен елга 220 мең тоннага кадәр арттыру планлаштырыла (2024 елда тәмамлау планлаштырыла).

2023 елның 28 августында «Казаноргсинтез» ГАҖндә изопропилбензол җитештерү җайланмасы эшләтеп җибәрелде. Предприятие үзе тулысынча җитештерә торган әлеге чимал поликарбонат алганда яңадан эшләү чылбырында беренче ярымпродукт булып тора. Яңарту һәм реконструкция атмосферага ташлауларны 20 %ка киметергә, шулай ук энергия ресурсларын куллануны 68 %ка киметергә мөмкинлек бирде.

2023 елда «Нәфис Косметикс» АҖ «Көнкүреш химиясе һәм техник продукция җитештерүне киңәйтү һәм техник яктан яңадан коралландыру», «Татарстан Республикасының Зеленодольск районында склад комплексы төзү» проектларын гамәлгә ашыруны дәвам итте.

«Көнкүреш химиясе һәм техник продукция җитештерүне киңәйтү һәм техник яктан яңадан коралландыру» проекты кысаларында 2023 елда кер юу өчен гельләр җитештерү куәтләрен киңәйтү эшләре башкарылды, гель-гранул өстәлеп, кер юу порошогы җитештерүнең яңа технологиясе эшли башлады, склад операцияләренең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен склад техникасы паркы яңартылды һәм башка эшләр башкарылды.

KAMA TYRES «Эре габаритлы шиннар җитештерүне оештыру һәм цельнометаллокорд йөк шиннары җитештерүне арттыру» проектын һәм башка проектларны гамәлгә ашыра.

2023 елда «Түбән Кама йөк шиннары заводы» ҖЧҖндә һәм «Түбән Кама шин» ГАҖндә KAMA PRO NF 102 шиннары линейкасы, 7.50R16LT KAMA-312 һәм 225/75R16 бертип размерда KAMA FLAME M/T шиннары сериялəп җитештерүгә җибәрелде.

Шулай ук компания KAMA QUADRO ATM квадроцикллары өчен шиннар җитештерә (26х11-12 һәм 27х9-12 бертип размерларда).

Менделеевск муниципаль районында «Аммоний» АҖ ашламалар җитештерү буенча индустриаль кластер булдыра. Предприятие гомуми суммар куәте елына 2,95 млн тонна булган аммиак һәм карбамид эре тонналы җитештерү буенча «Аммоний 2» проектын гамәлгә ашыруны дәвам итә. 2023 елның 1 ноябрендә XII Петербург халыкара газ форумы кысаларында «Газпром межрегионгаз» ҖЧҖ белән елына 1,3 млрд кубометрга кадәр табигый газ китерү турында килешү «Аммоний 2» проекты буенча әһәмиятле вакыйга булып тора.

«СИЛИКОН» ҖЧҖ «Казан синтетик каучук заводы» АҖ мәйданчыгында кремнийорганик материаллар җитештерү буенча проектны гамәлгә ашыруны дәвам итте.

Полимерлар эшкәртү буенча проектлар гамәлгә ашырыла:

«ДАНАФИЛМЗ» ҖЧҖ икенчел эшкәртү өчен яраклы яңа буын пленка материаллары җитештерү;

«КАО Поволжье» ҖЧҖ тарафыннан пенополистиролдан форма эшләнмәләре җитештерү;

«АЙ-ФЛЭКС» ҖЧҖендә азык-төлек продукциясе һәм көнкүреш техникасы өчен сыгылмалы төргәкләр җитештерү;

«Техстрой» ҖЧҖендә төрле диаметрлы полимер торбалар һәм фитинглар җитештерү;

«СИМПЛ» ҖЧҖендә полипропилен торбалар, фитинглар, XPS-плиталар һәм башка материаллар җитештерү;

«Чистай пластмасса заводы» ҖЧҖ тарафыннан пластмассалардан эшләнмәләр җитештерү.

**Энергетика комплексы**

Республика энергетика системасы Урта Идел берләштерелгән энергетика системасының электр куллану территориаль структурасында иң зурысы булып тора. Анда электр энергиясе җитештерүчеләр арасыннан иң зурлары – «Татэнерго» АҖ, «ТГК-16» АҖ, «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ эшли.

Республикада иң эре электр челтәре оешмасы – «Челтәр компаниясе» АҖ. 2024 елның 1 гыйнварына 18 территориаль челтәр оешмасы эшли.

Республика территориясендә гарантияле тәэмин итүче булып «Татэнергосбыт» АҖ тора.

Татарстан Республикасы энергетика системасының эш режимнары белән оператив-диспетчерлык идарә итү эшчәнлеген «СО ЕЭС» АҖ филиалы «Татарстан Республикасы энергосистемасының төбәк диспетчерлык идарәсе» (алга таба – Татарстан ТДИ) башкара.

2023 елда энергетика системасы кулланучыларны ышанычлы һәм куркынычсыз энергия белән тәэмин итте.

Татарстан ТДИ мәгълүматлары буенча, 2023 елда бүленгән генерация объектларын исәпкә алып, электр энергиясе җитештерү 28,2 млрд кВт*сәг тәшкил иткән (2022 ел дәрәҗәсенә карата 100,4 %) .

Татарстан Республикасының барлык кулланучыларын электр һәм җылылык энергиясе белән ышанычлы тәэмин итү, шулай ук конкурентлык сәләтен арттыру һәм энергетика тармагын тотрыклы үстерүне тәэмин итү өчен энергия системасының җитештерү объектларын модернизацияләү һәм яңа куәтләр кертү беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия.

Соңгы елларда Татарстанда 4 эре энергетика станциясе модернизацияләнде, шул исәптән җылылык станцияләрен модернизацияләүнең федераль программасы буенча (куәт бирү турындагы шартнамә буенча), бу энергия системасының куәтен 1,2 ГВтка, шул исәптән Казан ТЭЦ-1 һәм «Татэнерго» АҖ ТЭЦ-2, «ТГК-16» АҖ Казан ТЭЦ-3, «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ станциясе куәтен арттырырга мөмкинлек бирде.

«Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ Түбән Кама ТЭЦда (ПТК-2) 155 МВт куәтле газ-турбина җайланмасын төзү планлаштырыла.

«Татэнерго» АҖ Яр Чаллы ТЭЦында 230 МВт куәтле пар-газ җайланмасын төзү мәсьәләсе карала (җылылык электр станцияләренең генерацияләү объектларын модернизацияләү буенча федераль программа кысаларында).

Республикада өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып углеродсыз энергетиканы үстерү, аерым алганда, җил энергетикасын үстерү тора.

Торгызыла торган энергия чыганакларыннан файдалану нигезендә эшли торган квалификацияле генерация объектлары тарафыннан куәт бирү турындагы шартнамәләр кысаларында гамәлгә ашыру планлаштырыла торган 2023 елда республика территориясендә конкурс нигезендә проектларны сайлап алу йомгаклары буенча «Уралэнергосбыт» ҖЧҖ тарафыннан гомуми куәте 349 МВт булган җил электр станцияләре төзү планлаштырыла.

2023 елда «Челтәр компаниясе» АҖ тарафыннан реконструкцияләнгәннән соң «Бөгелмә» 500 кВ ЯС 220 кВ ачык бүлү җайланмасы, шулай ук Казан шәһәрендә

«Азино» 110 кВ ЯС, Лаеш муниципаль районында «Каипы» 35 кВ ЯС файдалануга тапшырылды.

«Челтәр компаниясе» АҖ электр челтәре хуҗалыгын модернизацияләү эшен дәвам итә. Гамәлгә ашырылучы төп инвестиция проектлары арасында: «Водозабор» 110 кВ ЯС реконструкцияләү, «Сокуры» 110 кВ ЯС төзү.

*Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү*

2013 елдан «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән расланган), ул энергияне сак тоту буенча алдагы программаларның мантыйкый дәвамына әверелде.

Программаның төп индикаторы булып тулаем төбәк продуктының энергия сыйдырышлылыгын киметү тора. 2023 ел йомгаклары буенча тулаем төбәк продуктының энергия сыйдырышлылыгы индикаторының күрсәткече 21,3 т.у./млн сум тәшкил итте (төп 2007 елга карата 22,3 % кимегән).

Татарстанның энергия нәтиҗәлелеге дәрәҗәсен бәяләү максатын да муниципаль районнар һәм шәһәр округлары, тармак министрлыклары киселешендә бюджет даирәсенең ирешелгән энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә квартал саен мониторинг кертү тәэмин ителде.

Энергияне сак тотуның дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның мөһим юнәлеше – энергияне нәтиҗәле тотучы проектларны гамәлгә ашыруга бюджеттан тыш финанслауны җәлеп итү. Әлеге юнәлешне гамәлгә ашыру инструментларының берсе – энергия сервисы контракты механизмнарын куллану (алга таба – ЭСК).

2023 елда энергетика ресурсларын куллануны экономияләүгә юнәлдерелгән республиканың сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә 4 бюджет учреждениесе буенча ЭСК төзүгә конкурс процедураларын әзерләү һәм уздыру тәэмин ителде. Төзелгән энергия сервисы контрактларында каралган төп чаралар: автоматлаштырылган индивидуаль җылылык пунктлары, һава җайга салу төеннәре урнаштыру, урамнарны һәм эчке яктыртуны модернизацияләү.

Бюджет өлкәсендә төзелгән ЭСК гомуми саны 1 662,2 млн сумга 94 берәмлек тәшкил итә (шул исәптән муниципаль учреждениеләр буенча 67 ЭСК – 1 546,5 млн сумга, дәүләт учреждениеләре буенча 27 ЭСК – 115,7 млн сумга).

Энергияне саклауны популярлаштыру һәм пропагандалау, энергия ресурсларын нәтиҗәле куллануны арттыру, шулай ук «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасы чараларын үтәү максаты белән ел саен энергетика һәм энергия ресурслары нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы уздырыла. 2023 елда аның кысаларында узды:

TatEnergyExpo махсуслаштырылган күргәзмәсе, анда Россиянең 17 төбәгеннән 73 экспозиция һәм Татарстан Республикасыннан 3 компания тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «2022 елда «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын тормышка ашыру барышы һәм 2023 елга бурычлар турында» утырышы.

Барлыгы 2023 елның 5 апреленнән 7 апреленә кадәр форум кысаларында энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, ягулык-энергетика комплексын үстерү, энергиянең, водород энергетикасының альтернатив чыганакларын куллану, газ-мотор

ягулыгы базарын үстерү, энергетика комплексында цифрлаштыру, электр транспорт чараларын һәм зарядка инфраструктурасын куллану мәсьәләләре буенча 23 чара, шулай ук мәктәп укучылары, студентлар һәм энергетика компанияләре яшьләре катнашында Яшьләр көне үткәрелде.

Пилот төбәкләр территориясендә заряд инфраструктурасын үстерү буенча «Электромобиль һәм водородлы автомобиль» федераль проектын гамәлгә ашыру уңышлы дәвам итә. 2023 елда республикада, заряд станцияләре операторларына тотылган чыгымнарны каплауга 42,780 млн сум күләмендә ярдәм чаралары күрсәтеп, 23 заряд станциясе урнаштырылган.

Республика җитештерүчеләренең «ЭнергоИнновация» ҖЧҖ (E-prom моделе станциясе) һәм «Энергоразвитие» ИК» ҖЧҖ (Relevant MAX моделе) заряд станцияләре урнаштырылды.

Республиканың 26 муниципаль берәмлегендә пилот проектын гамәлгә ашыруның ике елында эре шәһәрләрдә һәм торак пунктларда 118 заряд станциясе урнаштырылган, федераль бюджеттан 219,5 млн сум акча җәлеп ителгән.

**Газлаштыру һәм газ белән тәэмин итү**

2023 ел йомгаклары буенча республикада табигый газ куллану 17 639 млн куб. м тәшкил итте (2022 ел дәрәҗәсенә карата 99,2 %).

Республиканы газлаштыру дәрәҗәсе 99,25 %. Газлаштыруның югары күрсәткечләре шәһәрләрдә дә, авыл торак пунктларында тәэмин ителгән.

«Социаль газлаштыру» программасын гамәлгә ашыру чорында газүткәргеч 22 131 йорт биләмәсе чикләренә кадәр үткәрелгән, 16 450 йорт биләмәсе газга тоташтырылган.

Татарстанда газ-мотор ягулыгы базары актив үсеш ала. 2023 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү республика программасы буенча (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган) 792 берәмлек транспорт чарасы метанга күчерелгән һәм моторы газ белән эшли торган 67 берәмлек транспорт чарасы сатып алынган.

«2019–2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ сала торган компрессор станцияләрен төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 18 сентябрь, 789 нчы карары белән расланган) 2023 елда 3 автомобильләргә газ сала торган компрессор станциясе төзелде һәм файдалануга тапшырылды.

Республикада барлыгы 47 автомобильләргә газ сала торган компрессор станциясе һәм 4 криоген автозаправка станциясе урнашкан.

**Машиналар төзү комплексы**

Тармакның эш йомгаклары, беренче чиратта, «КАМАЗ» ГАҖ күрсәткечләре белән билгеләнә.

«КАМАЗ» ГАҖ оешмалары төркеменең бердәм җитештерү комплексы йөк автомобильләре җитештерүнең бөтен технологик циклын үз эченә ала – автотехника һәм автокомпонентлар эшләүдән, әзерләүдән, җыюдан башлап, әзер продукцияне сату һәм сервис белән тәэмин итүгә кадәр.

2023 елның февралендә «КАМАЗ» ГАҖ К5 буыны йөк машиналарын яңа санкцион тотрыклы компонент базасында җитештерүне яңартты: автомобиль заводында, Россиядә һәм дустанә илләрдә эшләнгән компонентлар кулланып, беренче КамАЗ-54901 автомобиле җыелган иде.

«КАМАЗ» ГАҖ импортны алыштыру һәм комплектлаучы альтернатив тәэмин итүчеләрне эзләү чараларын оператив рәвештә гамәлгә ашырды. Бары тик КамАЗ-54901 моделе өчен генә дә 2,3 мең компонент локальләштерелгән. Шул ук вакытта тягачның яңа версиясендә техник характеристикалар яхшыртылган.

2023 елның ноябрендә беренче импортны алыштыручы К5 үзбушаткычы җыелган.

2023 елда «Компас-5» һәм «Компас-6» кече тонналы йөк машиналарын серияле җитештерү башланды.

2024 ел дәвамында компания «Компас-3» проектын гамәлгә ашыруны планлаштыра. Хәзерге вакытта яңа модель прототибы эшләнә.

2023 елның 14 июнендә «Нева» М-11 федераль трассасында КАМАЗ пилотсыз магистраль йөк машиналары хәрәкәтен эшләтеп җибәрү булды.

«Соллерс Алабуга» ЖЧЖ 2023 елда Sollers бренды астында автомобильләрнең яңа линейкасын локальләштерүнең масштаблы программасын башлап җибәрде, ул 2,0 һәм 2,7 л күләмдәге дизель двигательләрен җитештерүне, шулай ук детальләрне коюны һәм механик эшкәртүне, штамплы җитештерүне, төп электрон компонентларны, шасси элементларын, пластик эшләнмәләрне локальләштерүне үз эченә ала.

«Соллерс» заводында «Алабуга» махсус икътисадый зонасында 2023 елның 10 июлендә Иннопром-2023 сәнәгать күргәзмәсе кысаларында дизель двигательләрен сериялэп җитештерү башланды. Двигательләр заводы 2015 елда төзелгән һәм хәзерге вакытта тулысынча Евро-6 экология стандартына туры килә торган 2 һәм 2,7 л күләмдәге заманча дизель двигательләрен чыгаруга юнәлдерелгән. Предприятиенең максималь егәрлеге – елына 50 мең двигатель. Двигательләрнең локаль линейкасы автомобильнең теләсә нинди шартларда ышанычлы эшен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган берничә конструктив чишелешләргә ия.

Проектта шулай ук башка Россия автоҗитештерүчеләре һәм тәэмин итүчеләр белән технологик операцияләр буенча компонент базасын максималь унификацияләү һәм Россиядә төзелгән металл кою, механик эшкәртү һәм башка эшкәртү куәтләрен эшләтеп җибәрү максатыннан киң кооперация каралган. Якындагы ике елда чуен кою җайланмалары, теземнәр һәм поршень төркемнәре җитештерүне үзләштерү планлаштырыла.

2023 елның 25 августында Казанда «Идея» инновацион-җитештерү технопаркында «Соллерс» ГАҖнең Инжиниринг һәм продуктны үстерү үзәге ачылды.

«КАМАЗ» ГАҖ рәсми партнеры «РИАТ» ААҖ КамАЗ шассие базасында «РИАТ-ЭКО» чүп ташу машиналары линейкасын төзеде һәм базарга чыгарды. Коммуналь машиналар буенча «РИАТ-ЭКО» проекты 2022 елда старт алды, линейканың беренче моделе КамАЗ шассие базасында кузовы 8 куб. м файдалы күләмле «Компас-9» чүп ташу машинасы булды.

2023 елның язында «РИАТ-ЭКО» коммуналь махсус техника линейкасын КАМАЗ шасси базасында кузовы 10 куб. м. күләмле «Компас-12» чүп ташу машиналары тулыландырды.

Линейканың тагын бер моделе – ике күчәрле КамАЗ-53605 шассие базасында җыелган зур чүп ташу машинасы.

Компания шулай ук АКНС – 10 нефть конденсатын җыю өчен агрегатлар җитештерә башлады.

Кран-манипулятор җайланмасының (алга таба – КМҖ) «РИАТ-Кран» тәҗрибә үрнәге төзелде һәм сертификация үтте. КМУ серияле җитештерү өчен пилот партиясе әзерләнә, технологик процессны эшләү тәмамланып килә.

«РариТЭК автомобиль заводы» ҖЧҖ 10,5 м озынлыктагы шәһәр газ-мотор автобусы проектын үзенең LOTOS бренды астында гамәлгә ашыра. Автобус тулы цикл буенча Яр Чаллы шәһәренә үз җитештерү мәйданчыкларында җыела. Шулай ук шәһәр автобусы базасында LOTOS автобусының шәһәр яны версиясе эшләнде һәм сертификацияләнә.

«РариТЭК-Газ-мотор ягулык системалары» ҖЧҖ, «РариТЭК Холдинг» АҖ бүлендек предприятиесе, 2023 елның 18 ноябрендә криоген баклар әзерләү буенча уникаль линияне эшләтеп җибәрде.

«ТПК МТЗ-Татарстан» ҖЧҖ «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү ФДАМУ, «Минск трактор заводы» ААҖ белән берлектә Беларус 3522 тракторы базасында «Автоном трактор» проектын эшләде. Әлеге модель тракторы зур куәткә ия, заманча техник җиһазланган, гидромеханик трансмиссиягә ия, зур мәйданнарны эшкәртү өчен уңайлы булачак.

«РариТЭК ХОЛДИНГ» АҖ белән берлектә ММЗ 262NG газ двигателе белән Беларус 1221GT тракторы эшләнгән, сертификацион сынаулар тәмамланган һәм туры килү сертификаты алынган. 2024 елда предприятие газ двигателе белән Беларус 1221GT тракторларын серияләп җитештерүне планлаштыра.

«АлАЗ җитештерү берләшмәсе» АҖ ППС-5 платформасы базасында АПР-80С скважиналарын ремонтлау һәм бораулау өчен агрегатның яңа модификациясен серияләп җитештерә башлады, вертолетның тышкы подвескасында һава транспортировкасы шартлары өчен шассига югары җиһазлар монтаж – демонтаж мобиль системасы булган АПРС-50С4 күтәрү агрегатын эшләде һәм әзерләде. Импортны алыштыру һәм Россия җитештерүчесе статусын алу максатларында 880 модельле «ELAZ-BL» экскаватор-төягечләренә ЯМЗ-534 двигателен бәйләү эшләре төгәлләнде. Серияле җитештерү башланды. «ELAZ-G20» автогрейдерының үз производствосы төеннәре базасында: сырт рамнары, машинист кабинасы, капот, канатлар, бульдозер отвалы, сынау үрнәге эшләнде.

«Казаньсельмаш» ҖЧҖендә 2023 елның 5 маенда үзйөрешле сиптергечләрнең электрон компонентларын җитештерү өчен яңа цех, эретеп ябыштыру цехын һәм пыяла-пластик эшләнмәләр әзерләү цехын ачу тантанасы булды. 2023 елда предприятие тарафыннан сиптергечләрнең яңа модельләре эшләнгән: механик йөрешле ОС-2500-1, гидростатик йөрешле ОС-2500М2, аларда үтүчәнлекне арттыру өчен бәйсез подвеска белән яңа мостлар һәм түбән басымлы шиннар белән көпчәкләр урнаштырылган.

«Агромастер» ПК» ҖЧҖ бүгенге көндә 250 исемдә авыл хуҗалыгы техникасы җитештерә. Предприятиенең 2023 елгы яңалыклары:

яңартылган чәчү комплексы (9 һәм 12 м киңлектә). База комплектациясенә вараторлы дозатор урнаштыру аркасында орлыкларны тигез итеп чәчү тәэмин ителә;

«Agrator Disk - 6000M» механик дисклы чәчү комплексы (киңлеге 6 м). Әлеге комплексның үзенчәлеге - гомуми файдаланудагы юллар буенча хәрәкәт итүгә җайлашу.

«Хайер Индастри Рус» ҖЧҖ Россиянең иң яхшы предприятиеләре исемлегенә керде һәм «2023 Тармак лидеры» исеменә номинацияләнде. Татарстан Республикасында суыткычлар һәм көнкүреш туңдыргычлары, кер юу машиналары, телевизорлар, штампланган детальләр җитештерү буенча заводлар, шулай ук логистика комплексы төзелде һәм эшли. 2024 елда электр суҗылыткычлары җитештерү буенча яңа завод файдалануга тапшыру планлаштырыла, анда соңгы буын автоматлаштырылган җиһазлар урнаштырылачак.

«Эйдос» ҖЧҖ «КАМАЗ» ГАҖ производствосында эретеп ябыштыру эшләрен автоматлаштыру өчен өч күчәрле позиционер белән эретеп ябыштыру ячейкалары кертте, бу җитештерүнең тизлеген һәм сыйфатын тотрыкландырды һәм хезмәткәрләр өчен куркынычларны киметте. Предприятие шулай ук тормыш белән тәэмин итүнең киңәйтелгән беркетмәсен үткәрү күнекмәләрен әзерләү өчен яңа «Low Fidelity» классындагы Lisa ALS өлкән пациент симуляторын булдырды. Симулятор укытуда куллану һәм төрле дәрәҗәдәге медицина процедураларын үткәрү күнекмәләрен өйрәнү өчен каралган: төп дәрәҗәдән алып киңәйтелгән дәрәҗәгә кадәр.

ПКФ «Бетар» ҖЧҖ җитештерүгә үз эшләнмәләрен кертте - СГВ/СХВ-15 су счетчигы крыльчаткасына күчәр кую буенча автомат комплекс. Шулай ук компания «КАМАЗ Тормоз Системалары» ҖЧҖндә демпферларны силикон белән тутыру өчен насос станциясен эшләгән һәм җитештерүгә керткән.

«Казанькомпрессормаш» АҖендә «В.Б.Шнепп ис. НИИтурбокомпрессор» АҖ белән берлектә төрле җитештерүчеләрнең компрессор машиналарын һәм мультипликаторларын шуыштыруның терәк һәм нык торучан подшипниклары проектланган һәм әзерләнгән.

2023 елда «ТЭМ-ПО» НТЗ» АҖ коррозиягә каршы торучан 09ГСФ маркадагы термоизоляцияләнгән обсадный торбалар, зур диаметрлы торбалар (диаметры 720 мм) җитештерүне үзләштерде. Биметаллик прокаттан электр эретеп ябыштыру торбаларын җитештерү технологиясен үзләштерү планлаштырыла.

«РИМЕРА-АЛНАС» ҖЧҖ минутына 6 000 әйләнешле электр үзәктән кугыч насосларның, кече габаритларның (2А,3), зур габаритларның (7А, 8, 9) энергия нәтиҗәлелеге җайланмаларын эшләүне төгәлләде, шулай ук кою производствосы өчен 3D-басма ком-полимер формалары технологиясен гамәлгә кертте.

«Джошкуноз Алабуга» ҖЧҖ «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонада «АвтоВАЗ» автомобильләре өчен шасси детальләрен серияле җитештерүне башлап җибәрде.

С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводында – «Туполев» АҖ филиалында җитештерүне киңәйтү һәм модернизацияләү, импортны алыштыру, самолетлар җитештерүнең цифрлы технологияләренә күчү, шулай ук сатканнан соң эксплуатацияләүгә ярдәм итү системасын булдыру буенча масштаблы чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

2023 елның июлендә Ту-160М беренче сынау модернизацияләнгән стратегик ракета йөртүчесе дәүләт сынаулары программасын үтәүгә кереште.

Предприятие алдында Ту-214 пассажир самолетларын эшләп чыгаруны арттыру бурычы тора.

«Казан вертолет заводы» АҖендә Ансат вертолетын модернизацияләү дәвам итә: тәҗрибә үрнәген җитештерәләр һәм вертолетның импортны алыштырган яңа ВК-650В двигательләре белән очу сынауларын башлап җибәрергә әзерләнәләр.

«А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» АҖ 2023 елда 8 корабль һәм судно тапшырылган, шул исәптән «Татарстан Республикасы флоты» АҖ суднолар йөреше компаниясе өчен су асты канатларында тиз йөрешле пассажир судноларын да кертеп.

2023 елда Россиядә беренче тапкыр водород ягулыгында эшләүче 00393 проектында тәҗрибә йөреп кайту-экскурсия судносы, 03182Р проектында ике фәнни-тикшеренү судносы гамәлгә салынган.

2023 елның 16 августында Кронштадт шәһәрендә 22100 проектының чик буе саклау кораблен – «Анадырь»да флаг күтәрү тантанасы булды.

2023 елның декабрендә «Наро-Фоминск» кече ракета корабле дәүләт сынауларын тәмамлаган һәм Балтыйк флотының ракета корабларын тоташтыру составына кертелгән.

«Ростех» дәүләт корпорациясенең «Серго исемендәге завод» ҖБ» АҖ (POZIS) яңа буын лазер эретеп ябыштыру аппаратын файдалануга тапшырды. Ул төгәл зурлыклары булган югары сыйфатлы металл конструкцияләрен эшләргә һәм технологик яктан катлаулы продукция җитештерүне шактый оптимальләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

Предприятие «КАМАЗ» ГАҖ заказы буенча азык-төлек саклау өчен кабиналы суыткычларны сериялəп җитештерүгә керешти. Җиһаз импортны алыштыру программасы кысаларында төзелгән һәм К5 буыны йөк автомобильләрендә кулланылачак.

«КМПО» АҖ газ турбиналы двигательнең цифрлы игезәген булдыру программасын гамәлгә ашыра һәм аның бер этабы – яну камерасын модернизацияләү төгәлләнде, ул елның салкын вакытында двигатель эшләп чыгара торган файдалы гамәл коэффициентын арттырырга мөмкинлек бирде.

«КМПО» АҖендә гамәлгә ашырыла торган импортны алыштыру программасы кысаларында аеруча җаваплы детальләр һәм җыю берәмлекләрен (газ турбиналы двигатель һәм трансмиссия маен һава суыту аппаратларын) эшләү һәм мөстәкыйль җитештерү үзләштерелде, алар җитештерелә торган газ-энергетика җиһазларының ышанычлылыгына һәм нәтиҗәлелегенә турыдан-туры йогынты ясый.

«КАПО-Композит» АҖ перспектив программаларны гамәлгә ашыра, алар арасында канатның полимер-композицион детальләрен, МС-21 самолетының механизация һәм койрык терәге агрегатларын әзерләү, шассиның төп терәге капкачларын, SJ-NEW самолеты канатын һәм рульләрен механикалаштыру агрегатлары әзерләү, шулай ук ПД-8 проекты кысаларында тышкы двигатель соплосы капкачын һәм хәрәкәтчән двигатель капкачын әзерләү эшләре. Предприятие МС-21 пассажир лайнеры өчен үзебезнең материаллардан агрегатларны һәм канатны механикалаштыру элементларын серияләп чыгара башлады.

**Урман эшкәртү сәнәгате**

«Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ 2023 елда яңа продукция – «Acrymat» чыгара башлый  (җиһаз фасадлары һәм декор әзерләү өчен тонык өслекле акрил битләр).

2023 елның сентябрендә предприятие Evosoft ике яклы ультратонык декоратив панельләренең яңа брендын күрсәтте. Коллекция 14 уникаль декордан тора.

«Татарстан агач эшкәртү комбинаты» ҖЧҖ җитештерүне яңарту, искергән җиһазларны заманча модельләргә этаплап алыштыру эшләрен актив алып бара, алар хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга һәм продукция күләмен арттырырга мөмкинлек бирә. 2023 елда предприятие ассортиментны киңәйтте һәм җитештерелә торган продукциясе белән  универсаль махсуслаштырылган сәүдә челтәрләрен, башка форматтагы ритейлларны, online-сатуларны колачлады.

«С.П.Титов исемендәге Яр Чаллы картон-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» ХЯАҖ 2023 елда төп җитештерү фондларын үстерү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү программасын гамәлгә ашыру кысаларында котельня  бинасын киңәйтте һәм 160 т. пар/сәг. куәте булган яңа Е-160 пар казаны урнаштырды. Шулай ук 2023 елда предприятие яңа җитештерү линияләрен – катлаулы конструкцияне гофртартмалауны яссы эшкәртү ысулы белән башкара торган ETERNA-1650 агым линиясен  һәм лоток тибындагы гофртартма җитештерү буенча FG 1228 агым линиясен  урнаштырды.

«Хәят Кимья» ҖЧҖ 2023 елда Papia брендының яңалыкларын эшкә кертеп җибәрде. Papia бәдрәф кәгазенең бөтен линейкасы кәгазьне бизәкләү өчен җылыту элементын кулланып, Thermo Power Tech уникаль инновацион технологиясен кулланып җитештерүгә күчте.

«Драйлок Текнолоджиз» ҖЧҖ «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона территориясендә беренче кирәк-ярак товарлары (бер тапкыр кулланыла торган подгузниклар) һәм тернәкләндерү индустриясе продукциясе (ятып торучы авырулар өчен медицина билгеләнешендәге товарлар) җитештерү проектын гамәлгә ашыра. 2023 елда предприятие продукциянең яңа линейкасын эшләтеп җибәрде - яңа туган балалар өчен NewBorn  подгузниклары.

«ЭкоПак» ҖЧҖ формалаштырылган целлюлоза сүсеннән бер тапкыр кулланыла торган биотаркала торган савыт-саба җитештерү проектын гамәлгә ашыра. 2023 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона территориясендә заводның беренче чираты сафка бастырылды. Хәзерге вакытта бер тапкыр кулланыла торган савыт-саба җитештерү буенча 3 линия эшли башлады.

**Җиңел сәнәгать**

«Завод Эластик» ҖЧҖендә сәнәгатьнең төрле тармаклары өчен (шул исәптән медицина, авыл хуҗалыгы, төзелеш, автомобиль төзелеше һ.б.) барлыгы 150 төрдән артык продукция җитештерелә.

«Эластик заводы» ҖЧҖ һәм «Здравмедтех» ҖЧҖ арасындагы стратегик партнерлык бер тапкыр кулланыла торган хирургия киеменең киң спектрын, бер тапкыр кулланыла торган эчке киемне һәм инфекционист табиблар өчен саклау комплектлары базарга чыгарырга мөмкинлек бирде. 2023 елда завод гигиена эшләнмәләрен эре җитештерүчеләр белән килешүләр төзеде.

Җөйләрне һәм детальләрне ультратавыш тоташтыру технологиясен кулланып, пациентларны һәм медицина персоналын яклау өчен бер тапкыр кулланыла торган киемнәр һәм эчке кием җитештерүдә махсуслашкан «Дарпикс» ҖЧҖ 2023 елның гыйнварында «Зеленодольск» сәнәгать паркы территориясендә гомуми мәйданы 4 мең кв. м булган заводның 1 чиратын файдалануга тапшырды.

«Азнакай киемнәре» АҖ - эре нефть компанияләре, төзелеш оешмалары, шулай ук мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә оешмалар өчен махсус сеңдермәләр белән тукымалардан (су үткәрми, май-судан какшамас, утка чыдам һәм җилдән саклау) махсус кием эшләп чыгаручы тармакның әйдәп баручы предприятиесе. 2023 елда предприятие тегү цехын зурайту юлы белән үз производствосын киңәйтте. Яңа җиһазлар сатып алынган һәм урнаштырылган, цехлар махсус киемнәр җитештерүнең тулы циклы өчен барлык кирәкле җиһазлар белән җиһазландырылган. Әзер продукция В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ җибәрелә.

«Кукмара тегү фабрикасы» АҖ – балалар һәм өлкәннәр өчен суүткәрми торган итеп эшкәртелгән тукымалардан тегелгән өске кием чыгаруда махсуслашкан тармакның әйдәп баручы предприятиеләреннән берсе. Предприятиедә ел саен 70 тән артык яңа модель эшләнә һәм тегелә. «Graf Kids» үзебезнең сыйфатлы балалар өске киемнәре җитештерүчеләр арасында танылган һәм популяр бренд булып тора. 2023 елда предприятие мәктәп формасын җитештерүне җайга салуга керешкән.

«Бросско» ҖБ ҖЧҖ Татарстанның һәм Россиядәге башка төбәкләрнең 160 тан артык уку йорты өчен укучыларга һәм укытучыларга, шулай ук «Бросско» корпоратив киемнәргә заказ бирүче зур һәм кече предприятиеләр өчен форма җитештерә. «Лидер» флис курткалары җитештерү буенча яңа линияләр эшләтеп җибәрелде.

«БАРС аяк киеме компаниясе» ҖЧҖ – Россиянең иң эре махсуслаштырылган аяк киеме җитештерүчеләрнең берсе. 2023 елда предприятие полиуретаннан җитештерү куәте елына 250 мең пар аяк киеме җитештерү буенча гомуми мәйданы 1 500 кв. м булган яңа цех төзеде. Металл элементлар кулланмыйча, шумый торган аяк киеме җитештерү технологиясе эшләнде һәм патентланган.

**Эчемлекләр җитештерү**

«Татспиртпром» АҖ – Россия Федерациясендә иң эре алкоголь компанияләренең берсе. Компаниянең тышкы икътисадый эшчәнлегенең стратегик бурычларының берсе – чит илдә контракт производствосын үстерү, компания брендлары Беларусь Республикасында, Монголия, Үзбәкстан Республикасында чыгарыла. 2023 елның августында Казахстан Республикасында «ГЕОМ» ТОО заводында компания продукциясен җитештерү эшли башлады.

«Татспиртпром» АҖ филиалы Мамадыш спиртзаводында 2023 елда җитештерү куәте елына 160 мең дал булган виски дистиллятлары җитештерүнең яңа цехы төзелгән.

Казан шәһәрендә «АБ ИнБев Эфес» АҖ филиалы 2023 елда төп җиһазларны, җитештерү корпусы биналарын, әзер продукция складын һәм солод комплексы бинасын модернизацияләү һәм реконструкцияләү буенча берничә инвестиция проекты гамәлгә ашырылды.

«Булгарпиво» ААҖ – җитештерелә торган сыра кайнату продукциясе күләме буенча республиканың өченче предприятиесе. 2023 елда предприятие квас, лимонад, эчә торган һәм минераль су сату күләмнәрен арттырган.

**«Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты**

Проект 2018 елдан башлап Россия товарларының һәм хезмәт күрсәтүләренең конкурентлыкка сәләтен арттыру максатларында гамәлгә ашырыла һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру хисабына икътисад үсешен тулаем ил буенча кимендә 5 процентка арттыруга юнәлтелгән.

Республикада аны гамәлгә ашыру «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча системалы чаралар» һәм «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм» дигән ике төбәк проекты кысаларында бара.

«Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча системалы чаралар» төбәк проекты күп дәрәҗәдә оештыру чараларын гамәлгә ашыруга – остазлык конкурсының төбәк өлешен уздыруга, илкүләм проектта катнашучы предприятиеләрне күрсәтелгән ярдәм чараларына җәлеп итүгә, предприятиеләрне илкүләм проектка җәлеп итүгә юнәлтелгән.

«Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм» төбәк проекты төрле тармак предприятиеләрендә сакчыл җитештерү культурасын гамәлгә кертү, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның һәм хезмәткәрләрне укытуның иң яхшы практикаларын файдалану өчен хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендә төбәк компетенцияләр үзәген төзүгә һәм аның эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Предприятиеләргә адреслы ярдәм «Татарстан Республикасы Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» ДАУ базасында төзелгән Татарстан Республикасының Хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендәге төбәк компетенцияләр үзәге (алга таба – ТКҮ) тарафыннан күрсәтелә.

ТКҮ тотрыклы рәвештә илнең иң яхшы төбәк компетенцияләр үзәкләре бишлегенә керә. 2023 ел йомгаклары буенча ТКҮ «Хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендә компетенцияләрнең федераль үзәге» АКБО үткәргән төбәк компетенцияләр үзәкләре рейтингында дүртенче урынны алып тора.

Практик тренинглар үткәрү өчен ТКҮ базасында «Җитештерү процесслары фабрикасы» һәм «Офис процесслары фабрикасы» төзелде.

2023 елда илкүләм проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре:

248 предприятие, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән килешү төзеп, илкүләм проектта катнаша;

илкүләм проектта катнашучы предприятиеләрнең һәм төбәк хакимият органнары вәкилләренең 4 509 хезмәткәре хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру инструментларына өйрәтелгән;

Илкүләм проектта катнашучы предприятиеләрнең 19 хезмәткәре «Җитештерү лидерлары» идарә кадрларын укыту программасын узды (2019 елдан башлап 500 кеше укыды);

Илкүләм проектта катнашучы 2 предприятие «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» программасы буенча 5 елга кадәр проектларны гамәлгә ашыруга еллык 3-5% ставка буенча займнар алды: «АММОНИЙ» АҖ (300 млн сум); «НӘФИС КОСМЕТИКС» АҖ (300 млн сум) (2019 елдан илкүләм проектта

катнашучы 12 предприятиегә ярдәм күрсәтелгән, ярдәмнең гомуми суммасы 2 млрд сумнан артык);

остазлыкның иң яхшы тәҗрибәләре бәйгесенең төбәк этабы үткәрелде. Төбәк этабында җиңүчеләр дип танылдылар: «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның алгарышлы технологияләре» номинациясендә – «Татнефть-Пресскомпозит» ҖЧҖ; «Яшьләрне һөнәри үстерү» номинациясендә – «Казан вертолет заводы» АҖ; «Предприятиедә цифрлы инновацияләр» номинациясендә – «А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» АҖ; «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча остазлыкның иң яхшы практикасы» номинациясендә «В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ТатНИПИнефть» институты; «Социаль өлкәдә остазлык» номинациясендә – «Татарстан Республикасы Мәгариф үсеше институты» ӨҺБ ДАМУ.

2023 елның 20–21 июлендә Казан шәһәрендә «Җитештерүчәнлек 360» V Федераль форумы узды. Бу хокукны республика, 2021 ел йомгаклары буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында хезмәт җитештерүчәнлеге рейтингы лидеры булып, алды. Форум Бәшир Рәмиев исемендәге «ИТ-парк» югары технологияләр технопаркы мәйданчыгында узды. Чарада Россия Федерациясенең 75 субъектыннан 1 142 катнашучы булды. Ике көн эчендә 20 эшлекле чара уздырылды. «Нәфис Косметикс» АҖ, «Здравмедтех-Поволжье» ЯАҖ, «Данафлекс-Нано» ҖЧҖ, «ЛЕДЕЛ» ҖЧҖ һәм «Казметрострой» АҖ форумның демонстрация мәйданчыгы булдылар һәм илкүләм проектта катнашуның алдынгы тәҗрибәсе белән уртаклаштылар.

Россия Федерациясе субъектлары арасында хезмәт җитештерүчәнлегенең башлангыч рейтингы нигезендә 2023 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы 1 урында тора.

**«Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты**

Проект кысаларында «Татарстан Республикасында халыкара кооперацияне һәм экспортны үстерү буенча системалы чаралар» һәм «Агросәнәгать комплексы продукциясе экспорты» төбәк проектлары гамәлгә ашырыла.

Хәзерге вакытта экспортка ярдәм итүгә юнәлтелгән федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге институтлар булдырылды, Төбәк экспорт стандарты 2.0 эшләнде. Федераль проектның паспорты нигезендә Татарстан Республикасында 2023 елда Төбләк экспорт стандарты 2.0. 13 инструменты гамәлгә кертелде

Татарстан Республикасында илкүләм максатларга һәм максатчан параметрларга ирешү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 28 декабрь, 1701 нnче карары белән 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясе расланды.

Илкүләм проектны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм «Россия экспорт үзәге» АҖ (алга таба - Россия экспорт үзәге) белән хезмәттәшлек итә. Татарстан предприятиеләре Россия экспорт үзәге, «Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» коммерцияле булмаган микрокредит компаниясенең экспортны яклау үзәге (алга таба – Экспортка ярдәм үзәге), Татарстан

Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аша ярдәм, шул исәптән финанс ярдәме ала ала.

Россия экспорт үзәге һәм Экспортка ярдәм үзәге экспорт эшчәнлеген үстерүдә булышлык һәм предприятиеләргә тышкы базарларга чыгуның барлык этапларында ярдәм күрсәтә. 2023 елда республика экспортерлары өчен иң кирәкле ярдәм чаралары булып түбәндәгеләр торган:

сәнәгать продукциясен транспортлауга чыгымнарны компенсацияләү (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәнәгать продукциясен транспортлауга чыгымнарны компенсацияләү максатларында Россия сәнәгать оешмаларына дәүләт ярдәме турында» 2022 елның 28 июлендәге 1 347 номерлы карары);

авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек продукциясен транспортировкалауга чыгымнар өлешен компенсацияләү (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек продукциясен транспортлауга чыгымнар өлешен компенсацияләү өчен Россия оешмаларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 1104 номерлы карары);

конкурентлыкка сәләтлелекне арттыру буенча корпоратив программаларны гамәлгә ашыручы сәнәгать предприятиеләренә дәүләт ярдәме (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Конкурентлык сәләтен үстерүнең корпоратив программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларга дәүләт ярдәме турында һәм «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясенә Россия Федерациясенең мөлкәти взносы рәвешендәге субсидия бирү кагыйдәләренә югары технологияле продукция җитештерүгә ярдәм итүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга кертү хакында» 2019 елның 23 февралендәге 191 нче карары).

## АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫ

Татарстан Республикасы илнең 2 % якын авыл хуҗалыгы җирләрен били, 3,5 % авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерә.

Авыл хуҗалыгы республика халкын үзенең сыйфатлы продукциясенең төп төрләре белән тулысынчы тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасы республика авыл хуҗалыгы тармагының төп программа документы булып тора. Программада авыл хуҗалыгының, азык-төлек һәм эшкәртү тармагының максатлары, бурычлары, үсеш юнәлешләре, чаралары һәм аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү, максатларга ирешүне характерлый торган һәм көтелгән нәтиҗәләр билгеләнә.

2023 елда корылык аркасында республиканың барлык муниципаль районнарында гадәттән тыш хәл режимы кертелде. Катлаулы һава шартларына карамастан, республика игенчеләре 3,6 млн тонна ашлык суктырган (эшләнеп бетергәннән соң авырлыкта). Бу күләм он тарту һәм икмәк пешерү предприятиеләрен икмәк пешерү өчен чимал, ә республика терлекчелеген – тупланган азык белән тулысынча тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

Төп техник культура шикәр чөгендеренең тулаем җыемы 1 758,2 мең тонна тәшкил итте. Эшкәртүгә юнәлдерелгән чөгендер-шикәр субкластеры җирле чимал белән тулысынча тәэмин ителде. 264,3 мең тонна яшелчә, 879,2 мең тонна бәрәңге җыеп алынган.

Республика Россия Федерациясе субъектлары арасында сөт җитештерү буенча 1 нче урында тора, бәрәңге җыю буенча – 2 нче урында, йомырка җитештерү буенча – 6 нчы урында, терлек һәм кош ите җитештерү буенча – 8 нче урында, шикәр чөгендере җитештерү буенча – 9 нчы урында, ашлык җитештерү буенча – 13 нче урында.

2024 ел уңышы өчен түбәндәге эшләр башкарылды:

чәчү мәйданнарын 2023 ел дәрәҗәсендә саклап калырга планлаштырыла;

1,8 млн гектар мәйдан туфракта төп эшкәртү эшләре үткәрелде;

бөртекле һәм кузаклы культуралар орлыклары белән тәэмин ителеш ихтыяҗның 126 % тәшкил итә;

550 мең гектар мәйданда уҗым культуралары чәчелде, аларның торышына мониторинг уздырыла.

Кайтартыла торган орлыклар белән тәэмин итүгә контрактлар төзү эше алып барыла. Бүгенге көндә шикәр чөгендере орлыкларының 98 %ы, кукуруз орлыгының 67 %ы, көнбагыш орлыкларының 63 %ы контрактка кертелгән.

Кыр эшләрен планлаштыруны җиңеләйтү өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының агросәнәгать комплексы дәүләт мәгълүмат системасы гамәлгә кертелде. Бу – авыл хуҗалыгы җитештерүе этапларын нәтиҗәле файдалану, планлаштыру һәм контрольдә тоту, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне күзәтү һәм мониторинглау өчен веб-сервис.

Республика үзен терлекчелек продукциясе белән тулысынча тәэмин итә.

Татарстанда илнең иң эре мөгезле терлекләр саны – 890,4 мең баш, шул исәптән

322,8 мең баш сыер тупланган.

2023 елда барлык төр хуҗалыклар буенча сөт саву 2,19 млн тонна тәшкил итте (2022 ел дәрәҗәсенә карата 107,5 %), 512,9 мең тонна терлек һәм кош ите (97,5 %) һәм 1562,6 млн данә йомырка (101,5 %) җитештерелде.

10,6 мең башка исәпләнгән 19 сөтчелек комплексы файдалануга тапшырылган.

Нәсел хуҗалыклары сөтчелек юнәлешендә гамәлгә ашырыла торган һәм яңа проектларның җитештерү куәтләрен югары генетик потенциалы булган таналар белән тәэмин итә ала.

Сөт терлекчелеге системасын энергия сыйдырышлы һәм югары протеинлы азыкларны куллануны үз эченә алган җитештерүнең югары интенсив формаларына күчерү исәбенә сөт җитештерү күләмнәрен тагын да үстерүгә ирешү планлаштырыла.

Терлекләрне азык белән тәэмин итү өстенлекле бурыч булып кала. Терлек азыгы үзәкләрен төзү дәвам итә. Хәзерге вакытта 47 үзәк кулланыла, алар 23 муниципаль районда 164 мең баштан артык эре мөгезле терлеккә хезмәт күрсәтә.

2024 елның гыйнварында муниципаль районнар терлекчелек тармакларын үстерү буенча үзләренең юл карталарын якладылар. 2024 елга 6,6 мең баш сыерга исәпләнгән 11 объект, шулай ук 6 муниципаль районда 9 терлек азыгы үзәге төзү планлаштырыла.

Сөт җитештерүне стимуллаштыру өчен барлыгы 1,3 млрд сумга субсидияләр каралды (2023 елга караганда 3,9 % артыграк).

**Техник модернизацияләү**

Машина-трактор паркы яңартыла. 2023 елда хуҗалыклар тарафыннан 12,9 млрд сумнан артык суммага 2 988 берәмлек авыл хуҗалыгы техникасы һәм җайланма, шул исәптән 558 трактор, 183 ашлык җыю комбайны, 43 терлек азыгы җыю комбайны һәм 2 204 берәмлек башка техника сатып алынды.

Республика Россия төбәкләре арасында инвестиция чыгымнары һәм сатып алынган техника саны буенча алдынгы урыннарны алып тора.

Сатып алынган техника чыгымнарын 70/30 схемасы (70 процентын җитештерүче түли) буенча субсидияләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 1,4 млрд сум акча бүлеп бирелде.

**Хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү**

Хуҗалык итүнең кече формалары актив үсә.

2023 елда хуҗалык итүнең кече формалары өчен 1,3 млрд сум күләмендә турыдан-туры дәүләт ярдәме күрсәтелде, шул исәптән федераль бюджеттан 431 млн сум (34 %) акча бирелде.

Ярдәмнең иң мөһим юнәлешләре – фермерларга һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына грантлар. Грантларны 17 фермер алды, шул исәптән 12 фермер «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының акселерациясе» төбәк проекты кысаларында «Агростартап» юнәлеше буенча 49,9 млн сум һәм 5 гаилә фермасына 114,6 млн сум.

2023 елда алынган грантлар нәтиҗәсендә, 2026 елга эре мөгезле терлекләр санын 1,3 мең башка (шул исәптән сыерлар - 590 башка), кош-корт санын 12 мең башка арттыру планлаштырыла.

2 кооператив авыл хуҗалыгы кооперативларының матди-техник базасын

үстерүгә гомуми суммасы 50,0 млн сумлык грант отты.

2022 елдан федераль дәрәҗәдә «Агротуризм» дигән яңа юнәлеш – туристлар урнаштыру һәм инфраструктура булдыру өчен объектлар төзүгә грант ярдәме гамәлгә кертелде. Республикада 50 дән артык эшкуар агротуризм өлкәсендә эшчәнлек алып бара. Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы грантларын 3 эшкуар алды, гомуми суммасы 19 млн сум. Тагын дүрт эшмәкәр 2024 елда 38 млн сумлык грант алачак.

«Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында «Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр» юнәлеше буенча 352,4 млн сумга 74 кооператив субсидия алды.

2022 елдан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына – мини-сөт парклары территориясендә сөтчелек юнәлешендә эре мөгезле терлекләр асрау фермаларын төзүгә субсидияләрнең яңа төре кертелде. 2023 елда 33 млн сумлык 4 кооперативка субсидияләр бирелгән.

2023 елдан 2018–2019 елларда гамәлдә булган яшь кооперативларга Татарстан Республикасы бюджетыннан грант ярдәме яңартылды. Грант 5 млн сумнан 10 млн сумга кадәр арттырылган, шул ук вакытта 10 % кооперативның үз акчалары булырга тиеш. Гомуми суммасы 99,8 млн сумлык грантларны 10 кооператив алды.

Шулай ук ярдәмнең мөһим төре – шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр бирү. Бу максатлар өчен 2023 елда 500,0 млн сум акча җибәрелде, субсидиядән 45 мең граждан файдаланды.

**Ярминкәләр үткәрү**

Авыл хуҗалыгы ярминкәләре – республика җитештерүчеләре тарафыннан җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кооперативлары һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар продукциясен сатуның иң кирәкле форматларыннан берсе.

Казан шәһәрендә ярминкәләр үткәрү өчен 14 мәйданчык, Түбән Кама шәһәрендә – 3 мәйданчык, Яр Чаллы шәһәрендә һәм Зеленодольск муниципаль районында 2 мәйданчык каралган.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан республиканың дүрт эре шәһәрендә (Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Зеленодольск шәһәре, Түбән Кама шәһәре) оештырылган сезонлы 23 ярминкә көне йомгаклары буенча 1,5 млрд сумнан артык продукция сатылган. Болар 9 464,2 тонна яшелчә, шул исәптән 5 674,4 тонна бәрәңге, 346,7 тонна сөт, 1 718,7 тонна ит, 969,8 тонна шикәр комы, 3 774,8 мең данә тавык йомыркасы.

Авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә ярдәм күрсәтү максаты белән ярминкәләрдә катнашучыларга ягулык-майлау материаллары чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бүлеп бирелә. 2023 ел йомгаклары буенча бу максатларга 13,8 млн сум бүлеп бирелгән. Шул ук вакытта ярминкәләрдә катнашучыларга сәүдә урыннары бушлай бирелә.

Шушы чаралар ярдәмендә товар җитештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы продукциясен ярминкәләрдә халыкка уртача ваклап сату бәясеннән 10–20 процентка түбәнрәк бәягә сатырга мөмкинлеге бар.

Моннан тыш, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар тарафыннан җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясен ел әйләнәсе көн дә сату өчен республика шәһәрләрендә 147 махсуслаштырылган мәйданчыклар каралган. Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән чатырдан эшләнгән 9 мәйданчык төзелде, аларда ел әйләнәсе көн саен авыл хуҗалыгы продукциясен сату өчен шартлар тудырылды.

Шулай ук Казан шәһәрендә гомуми мәйданы 8 гектардан артык булган «Казан» агросәнәгать паркы эшләп килә, аның эше авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлегенең кече һәм урта формаларына ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүчеләр һәм китерүчеләр белән төбәкара хезмәттәшлеккә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми сайтында («Эшчәнлек/Авыл хуҗалыгы ярминкәләре» бүлегендә) кулланучылар һәм продукция җитештерүчеләр өчен ярминкә чаралары турында актуаль мәгълүмат бирелеп тора.

**«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру**

Тармакны үстерү өчен мөһим юнәлеш – авыл халкы өчен уңайлы шартлар тудыру.

2023 елда «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруга 3,0 млрд сум акча тотылды. Түбәндәге чаралар гамәлгә ашырылды:

авылда 10,2 мең кв. м торак файдалануга тапшырылган;

37 муниципаль районда 169 иҗтимагый киңлек булдырылган;

Саба, Тукай, Кукмара муниципаль районнарында компакт торак төзелеше өчен инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру һәм мәйданчыкларны уңайлаштыру буенча 3 проект гамәлгә кертелде;

Кукмара, Мамадыш, Алексеевск, Биектау, Саба муниципаль районнарында 19 социаль һәм коммуналь инфраструктура объекты файдалануга тапшырылган, шул исәптән:

140 урынлы балалар бакчалары белән 320 урынлы 2 мәктәп (Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәрендә 120 урынлы балалар бакчасы белән 240 урынлы мәктәп, Биектау муниципаль районының Коркачык авылында 20 урынлы балалар бакчасы белән 80 урынлы мәктәп), Кукмара муниципаль районының Поршур авылында КФҮ, Биектау муниципаль районының Татар Әйшәсе авылында 45 урынлы авыл мәдәният йорты, Алексеевск муниципаль районының Алексеевск штп. спорт комплексы;

Биектау муниципаль районының Коркачык авылында, Кукмара муниципаль районының Югары Чура авылында һәм Поршур авылында 3 мәдәният йорты, Кукмара муниципаль районының Югары Чура авылында һәм Кече Чура авылында 2 балалар бакчасы, Кукмара муниципаль районының Югары Чура авылында мәктәп төзекләндерелде;

28,7 км озынлыктагы су белән тәэмин итү челтәрләре (Саба муниципаль районының Мичәнбаш авылында, Биектау муниципаль районының Коркачык

авылында, Кукмара муниципаль районының Югары Чура авылында һәм Пчеловод авылында, Алексеевск муниципаль районының Алексеевск штб.) сузылды, Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш» совхозы поселогында 5,2 км яктырту челтәрләре һәм 5,7 км су чыгару челтәрләре төзелде;

3 социаль һәм коммуналь инфраструктура объектына һәм 3 агросәнәгать комплексы объектына 19,2 км автомобиль юлы норматив хәлгә китерелде.

2024 елда әлеге эш дәвам итәчәк. Финанслау күләме 5 млрд сумга кадәр арткан.

**Илкүләм проектларны гамәлгә ашыру**

Фермерларга һәм кооперативларга ярдәм «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проектының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары акселерациясе» төбәк проекты, шулай ук «Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты кысаларында гамәлгә ашырыла.

2023 елда:

кече һәм урта эшкуарлыкның 86 субъекты дәүләт ярдәмен алды (алга таба – КУЭ);

18 яңа эш урыны булдырылды;

авыл хуҗалыгы кооперациясе өлешендә республика өчен 2 182 яңа әгъзаны җәлеп итү буенча план-бирем билгеләнде. 2024 елның 1 гыйнварына 2 948 яңа әгъза кабул ителгән (планнан 135,1 %).

«2019–2024 еллар чорына Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексы продукциясе экспортын үстерү» төбәк проекты кысаларында түбәндәге өч юнәлеш буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

1) 2023 елда җирләрне мелиорацияләү өлешендә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 5 объект сайлап алынган (Дәүләтов КФХ – 192,8 гектар; »Август-Мөслим» ҖЧҖ – 271 гектар; «Агрофирма Заря» ҖЧҖ – 60 гектар; «Ярыш» ҖЧҖ – 1 079 гектар; Мостафин КФХ – 250 гектар). Тапшыру буенча күрсәткеч 1 852,8 гектар тулысынча үтәлгән (100%).

2019–2023 елларда гидромелиорация, культуртехник чаралар уздыру һәм сугару җирләрен техник җиһазландыру исәбенә 7,3 мең гектар мелиорацияләнгән җир файдалануга тапшырылды (күрсәткеч планның 136 % үтәлде).

Федераль проектта катнашучылар тарафыннан 1,3 млрд сумнан артык инвестицияләр җәлеп ителде. Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан 628,1 млн сум кайтарылган;

2) майлы культуралар җитештерүне арттыруны стимуллаштыру өлешендә җитештерү күләме арту күрсәткече 1,9 мең тоннага кадәр җиткерелде. Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан 9,4 млн сум акча бүлеп бирелде;

3) агросәнәгать комплексы продукциясе экспортын үстерү өлешендә. 2023 елда Татарстан Республикасы экспортерлары 10 халыкара күргәзмәдә катнашты. Агросәнәгать комплексы продукциясе тышкы икътисадый эшчәнлекнең 160 катнашучысы тарафыннан дөньяның 54 иленә экспортлана. Экспортка чыгарыла торган авыл хуҗалыгы продукциясенең күп кенә категорияләре буенча китерелгән продукция күләменең уңай динамикасы күзәтелә.

«Хәләл» юнәлеше уңышлы үсеш алды. Әлеге продукцияне экспортлау күләме 2023 елда 2022 елга карата 1,7 тапкырга арткан. «Хәләл» стандартлары буенча ит һәм

сөт продукциясе белән төп тәэмин итүчеләр булып түбәндәгеләр тора: «MLK GROUP» ҖЧҖ, «Вамин Татарстан» ҖЧҖ, «Агрокөч» АҖ, «Эссен Продакшн АГ» АҖ һәм «ПК Акульчев» ҖЧҖ кондитер продукциясе.

## ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ

**Юл тармагы эшенә йомгак**

Юл эшләре программасына 2023 елда 90,7 млрд сум бүлеп бирелгән, шул исәптән 24,8 млрд сум – федераль бюджеттан, 65,9 млрд сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан (муниципаль юл фондыннан 1,3 млрд сум кертеп).

Гомуми озынлыгы 2 697,26 погонлы метрга тигез булган 34 күпер файдалануга тапшырылды.

505 км муниципаль юл-урам челтәре норматив хәлгә китерелде, шул исәптән:

төзелеш һәм реконструкция - 31,09 км;

торак пунктларның 119,2 км юлларын ремонтлау (250 урам – муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән);

торак пунктларның 122 км юлына вак таш салу (380 урам);

197 км торак пунктлар юлларын ремонтлау (340 урам);

35,7 км озынлыктагы гаилә фермаларына, терлекчелек комплексларына, бакча җәмгыятьләренә һәм балаларны савыктыру лагерьларына 37 килү юлын төзекләндерү.

Федераль проектлар өлешендә:

федераль юл проектлары төзелеше дәвам итте: М-12 «Көнчыгыш» (143 км) һәм Түбән Кама һәм Яр Чаллы шәһәрләрен урап узу өлешендә М-7 «Идел» (81,1 км);

2023 елның 21 декабрендә М-12 «Көнчыгыш» тизйөрешле автомобиль юлы буенча хәрәкәт ачылды. Юл республиканы тизйөрешле автомобиль юллары белән Идел буе федераль округы һәм Үзәк федераль округ төбәкләре белән тоташтырды. Юлның 7 һәм 8 этаплары ачылды, шул исәптән Идел елгасы аша күпер кичүе – М-12 (3362 м) федераль трассасы составындагы иң озын ясалма корылма;

2023 елның 15 ноябрендә М-7 «Идел» федераль трассасында Зөя елгасы аша 392,2 м озынлыктагы күпер кичүе ачылды. Күперне реконструкцияләү юлның үткәрүчәнлеген ике тапкырдан күбрәккә арттырырга мөмкинлек бирде;

Мәскәү – Казан – Екатеринбург – Төмән маршруты кысаларында М-7 «Идел» федераль трассасы участокларын реконструкцияләү алып барыла.

«Идел-Нократ идарәчесе» ФКУ заказы буенча Сокуры авылыннан урап узу юлын төзү белән Казан – Оренбург автомобиль юлы участогы төзекләндерелә башлады.

«Европа - Көнбатыш Кытай» халыкара транспорт маршрутын перспективалы үстерү максатында Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык шартларында «Алексеевск – Әлмәт» автомобиль юлын төзү проекты гамәлгә ашырыла.

Муниципаль юлларда түбәндәге эшләр башкарылды:

Казан шәһәренең Киров районында «Серебряный бор» торак комплексы аша Несмелов урамыннан М-7 «Идел» федераль әһәмияттәге автомобиль юлына кадәр 5,5 км озынлыктагы автомобиль юлы эксплуатациягә кертелгән;

Казан шәһәренең Совет районында Гвардия урамыннан алып Җиңү проспектына кадәр 3,8 км озынлыктагы участогында Вознесенский тракты эксплуатациягә тапшырылган (I этап);

Казан шәһәрендә Кабан күле аша күпер белән Нурсолтан Назарбаев урамында 0,436 км озынлыкта реконструкция үткәрелде.

2024 елда дәвам ителәчәк:

Җиңү проспектыннан «Идел» М-7 автомобиль юлына кадәр участокта Вознесенский трактының II этабын төзү;

Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесын Музыкаль урамыннан алып федераль әһәмияттәге М-7 «Идел» автомобиль юлына кадәр реконструкцияләү.

**«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты**

Проектны гамәлгә ашыруга 2023 елда 15 072,9 млн сум тотылган, шуларның 7 903,4 млн сумы – федераль бюджет акчалары хисабыннан, 7 169,6 млн сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан, шул исәптән:

«Төбәк һәм җирле юл челтәре» төбәк проекты кысаларында 409,3 км дан артык юлны ремонтлауны күздә тоткан юл челтәренең 189 объектын норматив хәлгә китерү чараларына. Финанслауның гомуми күләме 14 848,6 млн сум тәшкил итте, шуларның 7 679,0 млн сум – федераль бюджет акчалары хисабыннан, 7 169,6 млн сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан;

Казан шәһәрендә һәм Яр Чаллы шәһәрендә юл хәрәкәте белән идарә итү процессларын автоматлаштыруны күздә тоткан интеллектуаль транспорт системаларын гамәлгә кертүгә, шул исәптән Транспорт системасы белән идарә итүнең бердәм платформасын гамәлгә кертүгә һәм «Юл хуҗалыгын үстерүнең гомумсистема чаралары» төбәк проекты кысаларында адаптив светофор объектларын урнаштыруга – федераль бюджет акчалары хисабына 224,3 млн сум.

**Транспорт тармагы**

**Һава транспорты предприятиеләре эшчәнлеге**

Татарстан Республикасында һава транспорты түбәндәге эшчәнлек белән күрсәтелә:

өч аэропорт: «Казан» һәм «Бигеш» халыкара аэропортлары, «Бөгелмә» төбәк аэропорты;

Татарстан аэропортларыннан төбәк авиаташуларын башкара торган биш «ЮВТ АЭРО» АҖ авиакомпаниясе, шулай ук «Бизнес авиация» һәм «Вертолет белән ташулар» сегментында эшчәнлек башкаручы «Тулпар Эйр» авиакомпаниясе» ҖЧҖ, «Тулпар Экспресс» ҖЧҖ, «Казан авиапредприятиесе» АҖ һәм «Авиасервис» ҖЧҖ авиакомпанияләре.

2023 елда пассажирлар агымының гомуми күләме республиканың барлык аэропортлары буенча 5,86 млн пассажир тәшкил итте (2022 елда – 4,68 млн пассажир).

2023 елда «Бигеш» халыкара аэропортын реконструкцияләү кысаларында:

гомуми мәйданы 8 501,8 кв.м (3 кат), сыйдырышлылыгы очып китү өчен 200 пасс/сәг һәм очып килү өчен 200 пасс/сәг булган пассажир терминалының яңа бинасы төзелеп беткән һәм файдалануга тапшырылган;

аэропорт территориясенә керү алдында 410 машина урынлы бушлай парковка төзелеше тәмамланды.

**Тимер юл транспорты предприятиеләре эшчәнлеге**

Республикада тимер юл пассажирлар транспорты белән эшчәнлек «Содружество» акционерлык җәямгыяте шәһәр яны компаниясе тарафыннан алып барыла.

2023 елда Татарстан буенча шәһәр яны тимер юл транспортында 6,6 млн пассажир йөртелгән, бу 2022 ел дәрәҗәсенә карата 9,3 % ка арткан (6,04 млн пассажир). Яңа маршрутлар буенча поездлар йөри башланды: Казан – Ульяновск – Казан, Бөгелмә – Кандры – Бөгелмә, Яр Чаллы – Бөгелмә – Яр Чаллы. Казан – Аэропорт – Казан маршруты буенча поездлар саны 17 дән 20 берәмлеккә кадәр артты.

Тимер юл транспорты белән республика территориясе буйлап 16,33 млн тонна йөк ташылган (2022 елда – 16,56 млн тонна). Куйбышев тимер юлы полигонында йөк күләме 14,92 млн тонна тәшкил иткән, Горький тимер юлында – «РЖД» ААҖ филиалында – 1,41 млн тоннадан артык.

Казан шәһәренең боҗра тимер юл хәрәкәте проекты кысаларында Яңа Аракчино ст. һәм Дәрвишләр бистәсе ст. районында ике яңа тимер юл съезды, өченче юллар һәм ясалма корылмалар төзү каралган. Боҗраның гомуми озынлыгы 48 км тәшкил итәчәк һәм 17 тукталыш пунктын тоташтырачак, шул исәптән ике яңа тукталыш пунктын: «Абжалилова» т.п. һәм «Торфяная» т.п.

Проектны гамәлгә ашыру аэропорт, Казан-1, Казан-2 тимер юл вокзаллары һәм шәһәр транспорты (метро, автобус, трамвай, троллейбус) арасында ышанычлы уңайлы элемтә булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

2023 елда Казан шәһәренең Боҗралы тимер юл хәрәкәтен оештыруның I этабында «Транспорт иминлеге» бүлеген проектлау буенча эш алып барылды.

2024 елда күрсәтелгән бүлекне эшләүне төгәлләү һәм тулаем проект буенча «Россия баш дәүләт экспертизасы» ФАУ бәяләмәсен алу планлаштырыла.

**Эчке су транспорты предприятиеләре эшчәнлеге**

Республика чикләрендә эчке су юлларының гомуми озынлыгы – 1 057 км, шул исәптән Идел бассейнында – 788 км һәм Кама бассейнында 269 км тәшкил итә.

Республика территориясендә 8 пассажир причалы (Казан, Свияжск, Болгар, Тәтеш, Чистай, Алабуга, Түбән Кама), 2 пар кичүе (Зеленодольск – Карамалы Тау, Аракчино – Югары Ослан), 4 боз кичүе (Зеленодольск – Карамалы Тау, Аракчино – Югары Ослан, Соколка – Яңа Закамский, Покровский – Красный Ключ) эшли.

2023 елгы навигациягә 13 пассажир теплоходы, шул исәптән «Метеор» тибындагы 3 тизйөрешле судно һәм «Мәскәү» һәм «ОМ» тибындагы 10 сууткәргеч судно, шулай ук 11 дебаркадер җәлеп ителгән.

Эчке су транспортында пассажирлар йөртүне актив үстерү һәм Татарстан Республикасында туристлык агымын алга таба арттыру максатларында 2023 елның 24 маенда устав капиталында Татарстан Республикасы 100 % катнашкан – «Татарстан Республикасы Флоты» АҖ суднолар йөреше компаниясе төзелде. Моннан тыш, республика территориясендә су транспорты белән шәһәр яны пассажирлар йөртү «Татфлот» АҖ һәм «Яр Чаллы» руда булмаган материаллар җитештерү берләшмәсе» ҖЧҖ тарафыннан башкарыла.

**Автомобиль транспорты**

Республиканың автомобиль транспорты төрле милек рәвешләрендәге 45 йөртүче, шул исәптән 15 эре автотранспорт предприятиесе эшчәнлеге белән күрсәтелә.

Республиканың пассажир транспорты предприятиеләре тарафыннан 2023 елда 388,5 млн пассажир (2022 елда – 370,7 млн пассажир) йөртелгән, шулардан автотранспорт предприятиеләре тарафыннан 290,2 млн пассажир, электр транспорты белән – 98,3 млн пассажир йөртелгән.

2023 елда Татарстан җәмәгать транспортын яңарту проектында катнашты, аны гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып махсус казначылык кредитлары тора, аның кысаларында республиканың 12 муниципаль берәмлеге өчен 119 автобус сатып алынган.

Республиканың җәмәгать электр транспортын үстерү өчен 2023 елда электр транспорты предприятиеләренең троллейбус паркы 30 яңа троллейбус белән тулыланды. Лизинг килешүләре буенча «Метроэлектротранс» МУП 25 яңа МАЗ-303Т20 түбән ополь троллейбусларын сатып алган. Әлмәт шәһәренең башкарма комитеты 5 яңа троллейбус алуга контракт төзегән.

Моннан тыш, 2023 елда Әлмәт шәһәрендә яңа җәмәгать транспорты – электробуслар барлыкка килде. Һәрберсе 70 пассажир сыйдыра һәм 300 км га кадәр зарядкасыз уза ала.

**Юл эшләре планы**

Юл эшләре программасын гамәлгә ашыруга 2024 елда 56,1 млрд сум бүлеп бирелгән, шул исәптән 9,0 млрд сум - федераль бюджеттан; 47,1 млрд сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан (муниципаль юл фондыннан 1,5 млрд сум кертеп).

Төбәк автомобиль юлларында түбәндәгеләр планлаштырыла:

төбәк әһәмиятендәге 208,28 км юлны төзергә, реконструкцияләргә һәм ремонтларга;

бакча ширкәтләренә килү юлларын 0,3 млрд сумлык ремонтларга;

программа кысаларында юлларга вак таш салу буенча 1,0 млрд сумлык эш башкарырга;

торак пунктларда 1,0 млрд сумлык асфальт-бетон өслекне ремонтларга;

муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән 1,55 млрд сумлык эш башкарырга.

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Казан, Яр Чаллы һәм Түбән Кама агломерацияләрендә һәм төбәк челтәрендә 79 км чамасы автомобиль юлларын һәм 18 км юл-урам челтәрен ремонтлау, 15 күперне төзү һәм реконструкцияләү, 13 күперне капиталь ремонтлау планлаштырыла. Чараларны гамәлгә ашыруга 8,3 млрд сум каралган, шул исәптән 2,5 млрд сум – федераль бюджет, 5,8 млрд сум – Татарстан Республикасы бюджеты. Илкүләм проект кысаларында түбәндәге эшләр планлаштырыла:

Казан агломерациясе автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү – 1 368,4 млн сум, шул исәптән 225,3 млн сум – федераль бюджет;

Чаллы агломерациясе автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү – 1 281,3 млн сум (Татарстан Республикасы бюджеты);

Түбән Кама агломерациясе автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү – 657,6 млн сум (Татарстан Республикасы бюджеты);

төбәк автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү – 2 207,5 млн сум;

автомобиль юлларын һәм ясалма корылмаларны норматив хәлгә китерү – 2 718,1 млн сум, шул исәптән 2 201,6 млн сум – федераль бюджет;

«Юл хуҗалыгын үстерүнең гомуми система чаралары» федераль проекты

кысаларында интеллектуаль транспорт системасын гамәлгә кертү – 141,5 млн сум, шул исәптән 114,6 млн сум – федераль бюджет, 26,9 млн сум – Татарстан Республикасы бюджеты.

## ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК

2023 елда 126,5 млрд сумга социаль инфраструктураның 4 143 объектын төзү һәм капиталь ремонтлау чаралары гамәлгә ашырылган, шул исәптән:

44 республика программасы – 54,02 млрд сумга 3 456 объект;

7 илкүләм проект – 24,84 млрд сумга 288 объект;

5 дәүләт программасы – 5,67 млрд сумга 86 объект;

программадан тыш чаралар – 41,96 млрд сумга 313 объект;

Моннан тыш, инфраструктура проектлары кысаларында 17,38 млрд сумга 9 объект гамәлгә ашырылган.

**Торак төзелеше**

Республика ел саен торакны файдалануга тапшыру күләмнәре буенча алдынгы урыннарны били һәм Россия Федерациясе субъектлары – лидерлары исемлегенә керә.

2023 ел йомгаклары буенча 3 436,5 мең кв. м торак (2022 ел дәрәҗәсенә карата 111,1 %) файдалануга тапшырылды, шул исәптән:

гомуми мәйданы 1 577,0 мең кв. м булган 190 күпфатирлы йорт;

гомуми мәйданы 1 698,8 мең кв. м булган 12 474 индивидуаль торак йорт;

Социаль ипотека программасы кысаларында гомуми мәйданы 160,7 мең кв. м булган 64 торак йорт.

Социаль ипотека программасына яшь гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, үзләренә беркетелгән торак урыны булмаган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларны, радиация һәлакәтләре һәм катастрофалар аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны, Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән территорияләрдән күченеп киткән гражданнарны, мәҗбүри күченгән затларны, инвалидларны, 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү, шулай ук запаска азат ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм аларга тиңләштерелгән затлар өчен торак төзү буенча федераль механизмнар интеграцияләнде.

2023 ел йомгаклары буенча республиканың бер кешесенә исәпләгәндә торакның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш 29,5 кв. м (бәяләү) тәшкил итте. 2024 елда 3 150,0 мең кв. м торак файдалануга тапшыруга планлаштырыла.

*«Аренда торагы» программасы*

Аренда торагын төзү яңа җитештерү мәйданчыкларын ачуга, махсус икътисадый зоналар, сәнәгать паркларын булдыруга, ИТ-өлкә, нефть химиясе сәнәгате предприятиеләрен, шулай ук белгечләр – бюджет өлкәсе хезмәткәрләрен (табиблар, укытучылар, мәдәният, спорт өлкәсе, көч структуралары хезмәткәрләре һ.б.) җәлеп итүгә ихтыяҗ аеруча кискен булган өлкәләрне үстерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Аренда торагы предприятие хезмәткәрләренә дә, чакырылган белгечләр – бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә дә бирелә.

2023 елда – гомуми мәйданы 11,8 мең кв.м. булган 28 арендалы йорт файдалануга тапшырылган.

*Өлешле төзелешнең проблемалы объектлары*

Өлешле төзелештә алданган катнашучылар проблемасы системалы рәвештә хәл

origitelə. 2007 елдан 2023 елга кадәр мәйданы 1 350,8 мең кв.м. булган 146 проблемалы төзелеш объекты файдалануга тапшырылган, аларда 18 664 өлешче торак алган.

2023 ел нәтиҗәләре буенча Проблемалы объектларның бердәм реестрыннан (алга таба – ПОБР) гомуми мәйданы 15,99 мең кв. м булган 4 объект чыгарылган, шул исәптән:

Вахитов проспекты буенча 2 торак йорт, 23 йорт (А һәм Б блоклары), Түбән Кама шәһәре;

Ак. Губкин урамындагы 2 паркинг, «Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» ТКсы 1 йорт (1 нче һәм 2 нче этаплар), Казан шәһәре.

Татарстан Республикасы буенча ПОБРда бүгенге проблемалы өлешле объектлар юк.

*Дәүләт ярдәме программалары*

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак урыннары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру дәвам итә. Әлеге категория гражданнары өчен торак сертификатлары 2007 елдан рәсмиләштерелә. 2007 елдан 2023 елга кадәр Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчага торак белән барлыгы 2 225,8 млн сумга 596 күпбалалы гаилә, шул исәптән 2023 елда – 243,03 млн сумга 34 гаилә тәэмин ителде.

Торак шартларын яхшырту федераль законнар белән гарантияләнгән гражданнар алдында дәүләт йөкләмәләрен үтәүгә юнәлдерелгән «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы гамәлгә ашырыла. Болар – Ерак Төньяк районнарыннан күченгән гражданнар, Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган, шулай ук күченергә мәҗбүри булган гражданнар.

2023 елда 29,2 млн сумга 6 субсидия рәсмиләштерелде, шул исәптән:

3 дәүләт торак сертификаты – 17,9 млн сумга Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга;

1 дәүләт торак сертификаты – 6,4 млн сумга билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри күченүчеләр дип танылган гражданнарга;

2 дәүләт торак сертификаты – 4,9 млн сумга Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән китүче (чыгып киткән) гражданнарга.

Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме программасы («Гаилә ипотекасы») гамәлгә ашырыла, әлеге программада ипотеканың барлык срогы дәвамында елына 6 процентка кадәр ставка белән торак кредиты буенча ипотека алу күздә тотыла (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1711 номерлы карары нигезендә).

Программа гамәлгә кергәннән башлап (2019 елның 1 апреленнән) республикада барлыгы 154,4 млрд сумга 38 064 кредит, шул исәптән 2023 елда 93,2 млрд сумга 18 990 кредит бирелде.

Ташламалы ипотека программасын гамәлгә ашыру дәвам итә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020–2024 елларда Россия Федерациясе гражданнарына бирелгән торак (ипотека) кредитлары (заемнары) буенча кредит һәм башка оешмаларга алынып бетмәгән керемнәрне каплау кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 апрелендәге 566 номерлы карары кысаларында).

Ташламалы ипотека программасы гамәлгә кергәннән алып (2020 елның 2 маеннан) барлыгы 170,0 млрд сумга 46 119 ипотека кредиты, шул исәптән 2023 елда – барлыгы 71,1 млрд сумга 14 883 кредит бирелде.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 ноябрендәге 1567 номерлы карары белән Авыл территорияләрендә торак төзү яки сатып алу өчен бирелгән ипотека кредитлары буенча алынмаган керемнәрне каплау өчен Россия кредит оешмаларына субсидияләр бирү кагыйдәләре расланды.

Авыл ипотекасы программасы эшли башлаганнан бирле (2020 елның апреленнән) республикада барлыгы 11,0 млрд сумга 4 206 ипотека кредитлары, шул исәптән 2023 елда барлыгы 3,9 млрд сумга 1 088 кредит бирелде.

**Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау**

Капиталь ремонт программасы буенча 730 күпфатирлы йортка (4,3 млн кв. м) ремонт ясалды. Программа гамәлгә ашырылганга күрә, республиканың 158 меңнән артык гражданы үзләренең торак шартларын яхшыртты.

Эшләр барышында эксплуатацияләнергә яраксыз дип танылган 257 берәмлек лифт җиһазы алыштырылды, 286 йортта 294 мең кв. метрдан артык түбә, 259 йортта 664,5 мең кв. метрдан артык фасад ремонтланды, йорт эчендәге электр, газ, җылылык, су белән тәэмин ителә һәм су чыгарыла торган 726 мең погонлы метрдан артык инженерлык челтәрләре алыштырылды.

2024 елда капиталь ремонт үткәрергә планлаштырыла торган 4 күпфатирлы йортның проект документациясе эшләнде.

Гомуми финанслау күләме – 6,46 млрд сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1,14 млрд сум, муниципаль берәмлекләр бюджеты акчасы – 1,078 млрд сум, гражданнар акчасы 4,24 млрд сум тәшкил итте.

**«Безнең ишегалды» программасы**

2020 елдан ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча «Безнең ишегалды» республика программасы гамәлгә ашырыла.

Программа кысаларында түбәндәге эшләр башкарыла: юллар һәм тротуарларны, урам яктырткычларын ремонтлау, эскәмияләр һәм урналар урнаштыру, каты коммуналь калдыклар мәйданчыкларын, комлы-чуерташлы катнашма җәелгән балалар мәйданчыкларын төзекләндерү, өлешчә яшелләндерү.

2023 елда 960 ишегалды территориясе төзекләндерелде, финанслау күләме 9 млрд сум тәшкил итте.

**«Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты**

2023 елда «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектын гамәлгә ашыру (84 объект) өчен 10 989,7 млн сум (федераль бюджеттан – 9 034,0 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 955,7 млн сум) күләмендә акча җибәрелде, шул исәптән:

«Торак» төбәк проекты (26 объект) өчен – 8 264,0 млн сум (федераль бюджеттан – 6 693,8 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 570,2 млн сум).

Проект кысаларында Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Лаеш, Питрәч, Биектау, Зеленодольск, Буа, Мөслим һәм Тукай муниципаль районнарының яңа торак комплексларында юл һәм инженерлык инфраструктурасы төзелде.

«Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» төбәк проекты (54 объект, шул исәптән кече шәһәрләр конкурсы буенча 46 парк белән сквер һәм 8 объект ) – 2 123,3 млн сум (федераль бюджеттан – 1 851,4 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 271,8 млн сум);

«Чиста су» төбәк проекты (4 объект) өчен – 532,6 млн сум (федераль бюджеттан – 431,457 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 101,2 млн сум);

«Яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы рәвештә киметүне тәэмин итү» төбәк проекты өчен – 69,7 млн сум (федераль бюджеттан – 57,2 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 12,5 млн сум).

**Концессия килешүләре һәм инвестиция программалары кысаларында коммуналь объектларны реконструкцияләү һәм модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру**

Республикада 19 муниципаль районда 111 концессия килешүе гамәлдә, алар нигезендә концессионерларга 1 194 коммуналь инфраструктура объекты, шул исәптән 1 193 муниципаль милек объекты, 1 Татарстан Республикасы милке объекты тапшырылды.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә – 69 концессия килешүе, шул исәптән Татарстан Республикасы милкендәге объект буенча – 1 концессия килешүе, су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә – 35 концессия килешүе, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә 7 концессия килешүе төзелде.

**Инвестиция программалары**

Коммуналь хуҗалыкка өстәмә инвестицияләр җәлеп итү, торак фондын төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру, коммуналь инфраструктураның тузуын акрынайту максатларында, республиканың коммуналь комплексы оешмалары тарафыннан коммуналь инфраструктура объектларын үстерү, модернизацияләү һәм реконструкцияләү буенча инвестиция программалары гамәлгә ашырыла.

2023 елда 14 коммуналь комплекс оешмасы өчен су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә 33 инвестиция программасы гамәлгә ашырылды. 2023 елда, инвестиция программалары чараларының үтәлешен оператив мониторинглау мәгълүматлары буенча, оешмалар буенча тулаем алганда – 6 635,2 млн сум, шул исәптән су белән тәэмин итү буенча – 2 545,4 млн сум, су чыгару буенча 4 089,8 млн сум тәшкил итте.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә коммуналь предприятиеләрнең (җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында эшләүче предприятиеләрдән тыш) 15 инвестиция программасы гамәлгә ашырылды. 2023 елда, оператив мониторинг мәгълүматларына караганда, оешмалар буенча тулаем алганда инвестиция программалары чараларының үтәлеше 540,8 млн сум тәшкил итте.

**Коммуналь инфраструктураны модернизацияләү буенча федераль программа**

Инженерлык челтәрләрен яңарту өчен коммуналь инфраструктураны модернизацияләү буенча яңа федераль программа тагын бер инструмент булып тора.

Республикада 2023–2027 елларга төбәк программасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 24 май, 633 нче карары) расланды, ул гомуми суммасы 4,7 млрд сумнан артык (шул исәптән «Территорияләрне үстерү фонды» гавами хокукый компаниясе акчасы – 2,1 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджеты – 0,67 млрд сум, бюджеттан тыш чаралар – 1,96 млрд сум) булган 67 объектны үз эченә ала.

124,7 км гомуми озынлыктагы инженерлык челтәрләрен (19,2 км канализация, 42,6 км суүткәргеч, 62,9 км җылылык белән тәэмин итү), шул исәптән 22 су белән тәэмин итү объектын, 1 су чыгару объектын, 44 җылылык белән тәэмин итү объектын төзү (реконструкцияләү) планлаштырыла.

2023 елда 19 объектта (17 – җылылык белән тәэмин итү, 1 – су белән тәэмин итү, 1 – су чыгару объектында) 1 901,6 млн сум, шул исәптән «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчасы – 950,76 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 444,0 млн сум, бюджеттан тыш чаралар 506,8 млн сум күләмендә эшләр тулысынча тәмамланды. 37,3 км инженерлык коммуникацияләре (шул исәптән 19,2 км – су чыгару, 12,6 км – җылылык белән тәэмин итү, 5,5 км – су белән тәэмин итү) төзелде һәм реконструкцияләнде.

**ИНВЕСТИЦИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ**

Татарстан Республикасы Хөкүмәте төбәкнең инвестицион потенциалын алга этәрүгә һәм аның инвестицион климатын яхшыртуга, шулай ук инвесторлар өчен бизнес алып баруга уңайлы шартлар тудыруга зур игътибар бирә.

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы нигезендә 2030 елга төп капиталга инвестицияләрнең реаль үсешенә ирешү буенча максатчан күрсәткеч, 2020 ел күрсәткече белән чагыштырганда, кимендә 70 процент күләмендә билгеләнде.

2023 елда төп капиталга инвестицияләр күләме 1 180,4 млрд сум, ягъни 2022 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 122 % тәшкил итте.

2023 ел йомгаклары буенча кече эшкуарлык субъектларына карамаган оешмалар буенча төп капиталга инвестицияләрнең шактый күләме – 38,7 % эшкәртү җитештерүләрен үстерүгә тотылды, шул исәптән инвестицияләрнең 10,9 проценты химик матдәләр һәм химия продуктлары җитештерүгә, 6,9 проценты кокс һәм нефть продуктлары җитештерүгә туры килә. Төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләменнән 22,5 проценты – транспорт белән ташуга һәм саклауга, 12,2 проценты – файдалы казылмалар чыгаруга, 5,5 проценты – күчемсез мөлкәт белән операцияләр ясау эшчәнлегенә, 3 проценты – авыл хуҗалыгына, урман хуҗалыгына, аучылыкка, балыкчылыкка һәм балык үрчетүгә, 2,9 проценты электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итүгә, һаваны кондиционерлауга җибәрелде.

Предприятиеләр һәм оешмаларның үз акчасы өлеше төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләмендә 67 % (2022 елда – 56,5 %) тәшкил итте, җәлеп ителгән акчаның чагыштырма авырлыгы 33 % (2022 елда – 43,5 %) тәшкил итте.

Ел саен «Яңа проектларны этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан төбәкләр Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы кысаларында бизнес алып бару шартлары буенча бәяләнә. Республика лидерлар өчлеге арасында үз позициясендә нык тора: 2023 елда республика, интеграль индексны 15,97 баллга яхшыртып, икенче урынны алды (2023 елда индекс 302,45 балл, 2022 елда – 286,48 балл тәшкил итте).

Шул ук вакытта күрсәткечләр буенча алдынгы позицияләрен саклап калу өчен бизнесны алып бару шартларының сыйфатын яхшырту өчен булган резервларга даими анализ ясала.

Төбәкләрнең инвестицион җәлеп итүчәнлеген яхшыртуга юнәлдерелгән төп инструментларның берсе – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2021 елның 30 сентябрендәге 591 номерлы боерыгы белән расланган төбәк инвестиция стандарты.

Стандарт яңа инвестиция проектларын башлап җибәрүнең бердәм принципларын һәм шартларын булдыруга юнәлдерелгән 5 төп элементны үз эченә ала:

инвестиция декларациясе;
инвестиция советы;
инвестицион үсеш агентлыгы;
инвестиция картасы;

инвестиция кагыйдәләре җыелмасы.

Стандартны һәм аның элементларын гамәлгә ашыру инвесторларның дәүләт структуралары белән үзара хезмәттәшлегенең үтә күренмәлелеген тәэмин итә, төп хезмәтләр һәм ярдәм чаралары күрсәтелә торган этапларның һәрберсендә инвесторларның (эшкуарларның) хокукларын яклау механизмнарын җайга сала.

Инвестиция декларациясе Татарстан Республикасы Президентының «2028 елга кадәр Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе турында» 2012 елның 18 июнендәге ПУ-477 номерлы Указы белән расланды. Документта инвесторларның Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру шартлары буенча йөкләмәләре, аларның бозылмавы турында һәм республика инвестиция командасында җаваплылыкның бүленеше турында мәгълүмат бирелә.

Татарстан Республикасының Инвестиция советы Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указы белән оештырылды, аның рәисе – Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов. Совет инвестиция эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, инвесторның Татарстан территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, вәкаләтле оешмалар белән барлыкка килгән, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы (алга таба – Агентлык) тарафыннан җайга салынмаган каршылыкларын һәм бәхәсләрен судка мөрәҗәгать иткәнгә кадәр хәл итү максатларында эшли.

Инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү Агентлык тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 ел, 20 февраль, 118 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламенты нигезендә башкарыла.

Татарстан Республикасының инвестиция картасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Инвестиция порталында (invest.tatarstan.ru/ru/map) урнаштырылды. Әлеге инструмент ярдәмендә инвесторларның республика территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен ресурсларны, кирәкле инфраструктураны, мәйданчыкларны бүлү, преференция режимнары (үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр, махсус икътисадый зоналар) булу өлешендә Татарстан Республикасы турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге тәэмин ителә.

Россия Икътисадый үсеш министрлыгы каршындагы федераль төркем тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк стандартын гамәлгә кертү расланды (Россия Федерациясе субъектларында яңа инвестиция проектларына ярдәм күрсәтү системасын гамәлгә кертүне раслау буенча федераль төркем утырышы беркетмәсе (2023 елның 3 октябрендәге 50-МК номерлы «Төбәк инвестиция стандарты»).

Стандартның эчтәлеге буенча иң әһәмиятле элементы – инвестиция кагыйдәләре җыелмасы. Бу дәүләт органнары, муниципалитетлар, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар һәм инвесторларның үзләре тарафыннан инвестиция

проектларын гамәлгә ашырганда таләп ителә торган хезмәтләр буенча гамәлләр кылу алгоритмнары, шул исәптән объектлар төзелешенә, аларны файдалануга тапшыруга, электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәрләренә тоташтыруга, җир кишәрлекләрен арендага алуга рөхсәтләр бирү.

Булган резервлар буенча чаралар эшләү, шулай ук гамәлдәге административ киртәләрне минимальләштерү өчен 2023 елда «Росатом» дәүләт корпорациясенең методологик ярдәме белән, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенең Беренче урынбасары А.Р. Белоусовның турыдан-туры җитәкчелегендә республикада инвесторның 9 гамәл кылу алгоритмы кысаларында «Тоташ инвестиция агымы» проектын гамәлгә ашыру дәвам ителде:

«150 кВт ка кадәр электр челтәрләренә тоташтыру» һәм «150 кВт тан югары электр челтәрләренә тоташтыру»;

«Газ бүлү челтәрләренә тоташтыру»;

«Су белән тәэмин итү һәм су чыгару объектларына тоташтыру»;

«Җылылык челтәрләренә тоташтыру»;

«Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт алу»;

«Төзелешкә рөхсәт алу»;

«Сатуларда җир кишәрлеген алу»;

«Җир кишәрлеген сатуларсыз арендага алу».

Проектның төп максаты – инвесторның идеясе барлыкка килгәннән алып капитал салуларны башкарганга кадәр үтә торган юлын кыскарту. Башка төрле әйткәндә, төбәктә «сакчыл җитештерү» принципларын кертү ярдәмендә инвестиция проектын әзерләүгә һәм гамәлгә ашыруга, шул исәптән инвесторның барлык төп процедуралар узуына сарыф ителә торган вакытны кыскарту һәм ресурсларны киметү буенча резервлар эзләү алып барыла.

Эш барышында процессларның агымдагы, идеаль, максатчан торышлары анализланды (аларның картасы ясалды); максималь озак срок белән башкарыла торган проблемалы участоклар ачыкланды; административ киртәләрнең төп сәбәпләрен (норматив җайга салу өлешендә дә, республикада эшне алып бару тәртибен оештыруда да) эзләү алып барыла.

«Росатом» дәүләт корпорациясе проекты кураторы җитәкчелегендәге барлык эш төркемнәре тарафыннан инвесторлар заявкалары белән эшләүгә җитештерү анализы алып бара, электрон төрдә һәм кәгазь рәвешендә үзара хезмәттәшлекне исәпкә алып, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә, инженерлык инфраструктурасы челтәрләренә технологик тоташтыру буенча хезмәтләр күрсәтүдә кайбер этапларның срокларын тоткарлау сәбәпләре ачыклана; шулай ук һәр документны килештерү этаплары санына һәм катнашучыларның ведомствоара хезмәттәшлеге механизмнарына аерым игътибар бирелә.

**Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы**

Инвестиция эшчәнлегендә катнашучылар хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 декабрь, 1296 нчы карары белән 2023–2025 елларга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы расланды, анда республикада инвестиция эшчәнлеге үсешенең өстенлекләре билгеләнде.

Дәүләт инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре дип түбәндәгеләр билгеләнде: инвестицияләр җәлеп итү һәм республика җитештерүчеләре продукциясен яңа базарларга чыгару өлкәсендә Россия Федерациясе төбәкләре һәм чит ил партнерлары белән хезмәттәшлекне үстерү, халыкара икътисадый кооперация пространствосыннан актив файдалану, электрон сәүдәне үстерү, шул исәптән Республика маркетинг үзәге потенциалыннан файдалану; эшкуарлыкка, шул исәптән махсус икътисадый зоналарга, үсеше алдан билгеләнә торган территорияләргә, инновацион фәнни-технологик үзәкләркә, технопаркларга, индустриаль паркларка ярдәм күрсәтү инфраструктурасын үстерү; цифрлы икътисадны булдыру һәм үстерү; технологик суверенитетны тәэмин итүгә ярдәм итә торган проектларны гамәлгә ашыру; экспортка юнәлтелгән тармакларда (импортны алыштыра торган товарлар, чимал һәм материаллар) проектларны гамәлгә ашыру, азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүгә һәм авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру.

2023 елга Татарстан Республикасының өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1464 нче карары белән расланды, аңа 140 өстенлекле инвестиция проекты, шул исәптән «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы һәм «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналары территорияләрендә, технопарклар, индустриаль (сәнәгать) парклар, инновацион фәнни-технологик үзәкләр (шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары нигезендә төзелгән) территорияләрендә, үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрдә гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган инвестиция проектлары; җир кишәрлекләрен, сатулар үткәрмичә, арендага биреп; капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында, дәүләт партнерлыгы һәм хосусый партнерлык турында килешүләр һәм концессия килешүләре төзеп гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган масштаблы инвестиция проектлары керде.

2024 елга Татарстан Республикасының өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 декабрь, 1637 нче карары белән расланды. Аңа Татарстан Республикасының 137 өстенлекле инвестиция проекты керде.

**Инвестиция активлыгын стимуллау чараларын гамәлгә ашыру, инвестиция проектларын гамәлгә ашыру ысулларын һәм механизмнарын камилләштерү**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвесторлар өчен оешма тарафыннан проектны гамәлгә ашыруга булдырылган яки сатып алынган мөлкәткә салым ставкасын 0,1 процентка кадәр киметү каралды. Инвестиция эшчәнлеге субъектларына ташламалар проектларның чыгымы каплану срогына бирелә, әмма ул 7 елдан да артмаска тиеш, ә машиналар төзү тармагында салым ташламасы инвестицияләр кертелә башлаган вакыттан алып 13 елга кадәр срок белән бирелергә мөмкин.

Дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 ел, 7 май, 284 нче һәм «Инвестиция эшчәнлеге субъекты белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы арасында инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне һәм Инвестиция проектын тормышка ашыру турындагы шартнамә формасын раслау хакында» 2006 елның 24 июлендәге 377 нче карарлары белән регламентлаштырылды.

2023 елда инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында гамәлдәге шартнамәләр кысаларында 11 инвестиция проекты гамәлгә ашырылды.

2006 елдан 2023 елга кадәр республикада инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә, алдан бәяләү буенча, барлыгы якынча 16 млрд сумга салым ташламалары бирелде. Әлеге инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында 762 млрд сум күләмендә инвестицияләр җәлеп ителде, Татарстан Республикасы бюджетына салым түләүләре 27,5 млрд сум күләмендә бәяләнә. Ярдәм күрсәтелә торган инвестиция проектлары кысаларында 18 меңнән артык яңа эш урыны булдырылды.

Шулай ук кайбер территорияләрне, шул исәптән «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы һәм «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналарын тизләтеп үстерү өчен шартлар тудыруга һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып баруның преференциаль шартларын булдыруга юнәлдерелгән инвестиция мәйданчыклары уңышлы эшләвен дәвам итә, әлеге шартларны булдыру мөмкинлеге федераль законнарда карала.

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ республиканың нәтиҗәле инвестиция мәйданчыгына ачык мисал булып тора. Аның резидентлары арасында бөтен дөньяга танылган UMATEX (Росатом ДК), Rockwool, Knauf, Kastamonu, Hayat, Аурус, Air Liquide, Şişecam, Coşkunöz һ.б. кебек компанияләр бар.

2024 елның 1 гыйнварына «Алабуга» СҖТ МИЗ» акционер җәмгыятендә сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген 38 предприятие гамәлгә ашыра. Барлык чор өчен резидентлар тарафыннан гамәлгә ашырылган инвестицияләрнең күләме, бәяләүләр буенча, арта бара торган йомгак белән 168,6 млрд сум тәшкил итте, резидентлар тарафыннан 9 315 эш урыны булдырылды, еллык керем күләме, бәяләүләр буенча, 178,7 млрд сум күләмендә булды.

2023 елда «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ резидентлары статусы түбәндәгеләргә бирелде:

1) «Алабуга Эксим» ҖЧҖ – җитештерү-бүлү үзәге төзү;

2) «НОВАТЕКС» ҖЧҖ – елына 1 мең тоннага кадәр куәтле ясалма һәм синтетик җепселләрдән туку һәм трикотаж эрләү производствосы;

3) «ВАГНЕРМАЙЕР РУССЛАНД» ҖЧҖ – елына 2 100 берәмлек күләмендә куәтле тулы цикллы магистраль ярымприцеплар җитештерү;

4) «Альбатрос» ҖЧҖ – елына 1 мең данә күләмендә куәтле очкыч тибындагы пилотсыз оча торган аппаратлар җитештерү;

5) «Август-Полимер» ҖЧҖ – елына 5 мең тонна күләмендә бөртекле «җиңнәр» һәм елына 2,5 мең тонна күләмендә куәтле башка пленкалы материаллар җитештерү;

6) «МИМ технологияләр үзәге» ҖЧҖ – елына 60 тонна күләмендә гомуми куәтле порошок металлургиясе ысулы белән эшләнгән аз катнашмалы һәм тутыкмый торган корычлардан детальләр һәм комплектлау җайланмалары җитештерү;

7) «Сова Моторс Алабуга» ҖЧҖ – елына 4 мең машинага кадәр гомуми куәтле электр җиңел коммерция транспортын җыю производствосын оештыру;

8) «Татнефть-Пресскомпозит» ҖЧҖ – елына 2 970 тонна продукция күләмендә гомуми куәтле композитлы саклау савытлары һәм зур диаметрлы торбалар җитештерү;

9) «КАМАПЭК» ҖЧҖ – елына 400 мең эшләнмә күләмендә гомуми куәтле композит материаллардан төрү әйберләре җитештерү;

10) «ТЕХНО-КОМПАУНД» ҖЧҖ – елына 20 мең тонна күләмендә гомуми куәтле SMC технология өчен полимер-композит материал җитештерү.

«Иннополис» МИЗ составында 333 компания бар, шул исәптән 2023 елда аңа 56 яңа компания керде. Бәяләү мәгълүматлары буенча, барлык чор өчен «Иннополис» МИЗ компанияләренең инвестицияләр күләме арта бара торган йомгак белән 127,9 млрд сум тәшкил итте, 8 966 (шул исәптән 2023 елда – 1 616) яңа эш урыны булдырылды, еллык керем күләме 49,7 млрд сум тәшкил итте.

«Иннополис» МИЗ резидентлары һәм стартаплары тарафыннан 50дән артык мәсьәлә хәл ителде, алар FinTech, MedTech корпоратив системалары, болыт компьютингы, Smart City, интеллектуаль транспорт системалары өлкәсендә чит ил продуктларын алыштыру өчен тәкъдим ителгән чишелешләр исемлегенә кертелде. Күп кенә корпорацияләр «Иннополис» МИЗ резидентлары һәм стартаплары чишелешләренә күчеп бара инде.

Шул исәптән импортны алыштыра торган чишелешләр арасында IVA MCU видеоконференция элемтәсе платформасы, «МойОфис» офис чишелешләре, Astra Linux операцион системасы, Visiology мәгълүмат-аналитика системаларын төзү платформасы, «Дронопорт» пилотсыз оча торган аппаратлар базасының һәм аларга хезмәт күрсәтүнең автоматлаштырылган станцияләре, «Аврора» мобиль операцион системасы, Innostage комплекслы киберкуркынычсызлык проектлары.

«Иннополис» МИЗ эшчәнлегенең төп фокусы – сәнәгать мәйданчыкларын һәм югары технологияле җитештерүләрне үстерү. Иннополиста югары технологияләр өлкәсендәге «ИнноПарк» технопаркы файдалануга тапшырылды, биредә урыннар аз калды диярлек. Анда фәнни-техник, инновацион һәм югары технологияле җитештерү эшчәнлеге алып барыла торган индустриаль компанияләр урнаша.

«Лаеш» индустриаль паркы территориясен актив үстерү дәвам итә, аның гомуми мәйданы 116 га тәшкил итә. Төп платаларны өске ягыннан монтажлау буенча ICL заводын эшләтеп җибәрү бөтен индустриаль парк өчен инженерлык инфраструктурасын үстерүгә һәм магистраль челтәрләр үткәрүгә ярдәм итте һәм «Иннополис» МИЗ базасында микроэлектроника кластерын төзүгә беренче адым ясалды.

«Концерн Росэнергоатом» АҖ эгидасы белән мәгълүматны эшкәртү һәм саклау үзәгенең төзелеше төгәлләнеп килә. Бу Идел буенең мәгълүматларны эшкәртү һәм саклау буенча иң зур үзәге булачак, ул технологик җиһазландыруга карата куела торган югары таләпләргә җавап бирәчәк. Проектның мәсьәлә чишелешендә Tier III дәрәҗәле ышанычлылыгы югары булган 2000 гә кадәр терәк-урын карала.

Мәгълүматларны эшкәртү үзәге 23 мең кв. метрдан артык гомуми мәйданлы ике бинадан торачак, объектның куәте – 16 МВт, мәгълүматларны эшкәртү һәм саклау үзәгеннән файдалану мөмкинлеге дәрәҗәсе 99,982 % тәшкил итәчәк.

**Инфраструктураны финанслау механизмы**

Республикада Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясенә булган бюджет кредитлары бурычын түләү күләмен киметү нәтиҗәсендә янга кала торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасы инженерлык тикшеренүләрен башкаруга, проектлауга, проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга) җибәрелергә тиешле яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 1704 номерлы карарында билгеләнгән инфраструктураны үстерүнең яңа механизмы гамәлгә ашырыла.

Әлеге механизм, бер яктан, инвестиция проектларын кирәкле инфраструктура белән тәэмин итәргә, икенче яктан, республиканың Россия Федерациясенә булган бюджет кредитлары бурычын проектлардан җыелган федераль салымнар күләмендә исәптән чыгарырга мөмкинлек бирә.

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2023 елның 25 июнендәге 349 номерлы боерыгы белән (2023 елның 25 октябрендәге 749 номерлы боерыгы редакциясендә) яңа инвестиция проектларының җыелма исемлегенә 203 млрд сум гомуми инвестиция күләмендә 11 республика проекты кертелде.

**Үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрне үстерү**

2016 ел башыннан Татарстанда Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Зеленодольск һәм Менделеевск моношәһәрләре территорияләрендә үсеше алдан билгеләнә торган 5 территория төзелде.

2024 елның 1 гыйнварына 66,0 млрд сум күләмендә инвестицияләр, шул исәптән 55,1 млрд сум күләмендә капитал салулар (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) керткән 136 резидент теркәлде, 24 209 яңа эш урыны булдырылды.

2023 елда резидентлар тарафыннан 10,8 млрд сумнан артык инвестицияләр кертелде һәм 2 396 яңа эш урыны булдырылды, керем күләме 146,6 млрд сум тәшкил итте.

Үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентларына бирелә торган салым ташламалары моношәһәрләргә зур бизнес (Haier, OZON, Wildberries, КазаньЭкспресс һ.б.) вәкилләрен җәлеп итәргә мөмкинлек бирде, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итте.

Чаралар күрелгәнгә күрә, моношәһәрләр икътисады структурасын диверсификацияләү гамәлгә ашырыла, яңа тармаклар, кече һәм урта эшкуарлык үсә.

**Моношәһәрләрне үстерү**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 29 июлендәге б-1398 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы моношәһәрләре исемлегенә 7 моношәһәр – Зеленодольск, Чаллы, Менделеевск, Алабуга, Чистай, Түбән Кама шәһәрләре, Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы керә.

Республика халкының гомуми санында моношәһәрләр халкы санының өлеше 26,3 % (Чаллы шәһәре – 13,6 %, Түбән Кама шәһәре – 6,0 %, Зеленодольск шәһәре – 2,5 %, Алабуга шәһәре – 1,9 %, Чистай шәһәре – 1,5 %, Менделеевск шәһәре – 0,5 %, Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы – 0,3 %) тәшкил итә. Моношәһәрләр халкының гомуми санында эшче көч өлеше 51 % тәшкил итте.

2023 ел ахырына республика моношәһәрләрендә 44 019 эш урыны булдырылды, 43 035 кече һәм урта предприятие (микропредприятиеләрне кертеп) теркәлде.

2023 ел йомгаклары буенча моношәһәрләрнең салым һәм салым булмаган керемнәре суммасы 11,1 млрд сум тәшкил итте һәм 2022 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда 4,15 процентка артты.

2024 елның 1 гыйнварына моношәһәрләрдә теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе Чаллы шәһәрендә – 0,18 %, Түбән Кама шәһәрендә – 0,35 %, Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогында – 1,21 %, Менделеевск шәһәрендә – 0,13 %, Алабуга шәһәрендә – 0,16 %, Зеленодольск шәһәрендә – 0,12 %, Чистай шәһәрендә 0,1 % тәшкил итте. Моношәһәрләрдә уртача эшсезлек дәрәҗәсе – 0,23 %.

2024 елның 1 гыйнварына моношәһәрләрдә хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты уртача 1 вакансиягә 0,05 кеше тәшкил итте.

Моношәһәрләрне үстерү өчен яңа мөмкинлекләр «ВЭБ.РФ» дәүләт корпорациясе (алга таба – ВЭБ.РФ) ярдәмендә барлыкка килде.

ВЭБ.РФнең проектларны гамәлгә ашыруда катнашу максаты – моношәһәрләрнең икътисадын диверсификацияләү, эш урыннарын булдыру һәм моношәһәрләрне үстерүгә инвестицияләр җәлеп итү өчен кирәкле шартлар тудыру.

Татарстан Республикасы инфраструктура проектларына финанс ярдәменең гомуми суммасы – 6,6 млрд сумнан артык, шул исәптән ВЭБ.РФ акчасы исәбеннән 4 млрд сум күләмендә тәшкил итә. Инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында 2023 елга төзелгән инфраструктура нәтиҗәсендә 55 млрд сумнан артык инвестицияләр җәлеп ителде һәм якынча 18,6 мең эш урыны булдырылды.

2023 елның 28 декабрендә ВЭБ.РФ белән, Менделеевск моношәһәрендә инфраструктура төзү һәм (яисә) аны реконструкцияләү чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын финанслашу турында килешү төзелде. «Менделеевск 2.0» сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзү проекты кыйммәте – 874,8 млн сум, шул исәптән ВЭБ.РФ акчасы исәбеннән – 444,2 млн сум. Файдалануга тапшырырга планлаштырыла торган срок – 2025 ел. Менделеевск моношәһәрендә инфраструктура төзү һәм (яисә) аны реконструкцияләү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру тулаем алганда якынча 200 эш урыны булдырырга һәм 903,7 млн сум күләмендә инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Моннан тыш, 2023 елның 22 декабрендә ВЭБ.РФ га Чаллы моношәһәрендә «Үсеш» сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзүне (III чират) финанслашуга заявка җибәрелде. Проектның гомуми кыйммәте – 931,99 млн сум.

Инвестиция проектын гамәлгә ашыру 150 эш урыны булдырырга һәм 464,0 млн сум күләмендә инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Бер үк вакытта ВЭБ.РФнең заем акчасын җәлеп итү турында килешүләр гамәлгә ашырыла. Заем акчасының гомуми суммасы якынча 4,3 млрд сум тәшкил итте.

2023 елның октябрендә ВЭБ.РФ тарафыннан «Свияжск-Зернопродукт» ҖЧҖ белән бөртекле һәм майлы культураларны саклау һәм эшкәртү өчен заманча элеватор төзү буенча инвестиция проектын заем формасында финанслауда катнашу турында килешүгә кул куелды. ВЭБ.РФнең заемнар буенча йөкләмәләре 1 млрд сум тәшкил итә. Әлеге проектны гамәлгә ашыру 86 эш урыны булдырырга һәм 2 млрд сумнан артык инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

**Дәүләт партнерлыгы һәм хосусый партнерлык**

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан уздырыла торган рейтингта 2023 елда Татарстан Республикасы дәүләт партнерлыгын һәм хосусый партнерлыкны (алга таба – ДХП) үстерү дәрәҗәсе буенча – 6 урыннан 4 урынга, шул исәптән ДХП проектларын гамәлгә ашыру динамикасын бәяләү факторы буенча – 5 урыннан 4 урынга, ДХП проектларын гамәлгә ашырудан тупланган тәҗрибәне бәяләү факторы буенча – 35 урыннан 24 урынга һәм норматив-институциональ мохит торышын бәяләү факторы буенча 8 урыннан 3 урынга күтәрелде.

2024 елның 1 гыйнварына республикада 123 концессия килешүе һәм муниципаль-хосусый партнерлык турында 1 килешү гамәлдә, аларның күбесе коммуналь инфраструктура белән бәйле. Шулай ук сәламәтлек саклау, спорт, ял һәм мәдәният, транспорт өлкәсендә проектлар гамәлгә ашырыла.

2023 елда Чаллы шәһәрендә һәм Әлмәт шәһәрендә «ФИЗРА спорт үзәге» физкультура-сәламәтләндерү комплексы» спорт инфраструктурасы объектларын төзүгә һәм эксплуатацияләүгә карата 2 концессия килешүенә кул куелды, аларның гомуми инвестицияләр күләме 235,7 млн сум тәшкил итте.

2023 елның сентябрендә Казан шәһәрендә, Чаллы шәһәрендә һәм Арча муниципаль районының Түбән Мәтәскә авылында 3 гомуми белем бирү мәктәбе файдалануга тапшырылды, аларның гомуми инвестицияләр күләме 6,7 млрд сум тәшкил итте. Әлеге проектлар ДХП механизмын кулланып гамәлгә ашырылды.

**Конгресс-күргәзмә чаралары**

Конгресс-күргәзмә чараларын үткәрү инвестиция потенциалын күрсәтүдә иң мөһим юнәлеш булып тора.

2023 елның 18–19 маенда «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәге мәйданчыгында «Россия-Ислам дөньясы: KazanForum 2023» XIV Халыкара икътисадый форумы уздырылды. 2023 елда Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин указы нигезендә чарага федераль статус бирелде. 2023 елда форумның лейтмотивы – ул хәзерге чынбарлыкта икътисадый партнерлык, аның төп темалары – ислам финанслары, хәләл индустриясе, инвестицияләр, сәнәгать, логистика, туризм, технологияләр, халыкара хезмәттәшлек, дипломатия, бизнес-мөмкинлекләр һ.б.

Гомуми план 200 чарадан тора, шул исәптән эшлекле программа буенча төрле тематикаларга багышланган 148 сессия.

Форум кысаларында 8 ике яклы (шул исәптән «Россия – Төркия», «Россия – Мисыр», «Росси – Әзәрбайҗан», «Россия – Үзбәкстан», «Россия – Малайзия», «Россия – Иран») конференция, шулай ук ел саен уздырыла торган «Russia Halal Expo» халыкара инвестиция һәм инфраструктура проектлары күргәзмәсе уздырылды, ул бизнес-проектларны этәрү һәм анда катнашучылар арасында конструктив диалог төзү өчен уникаль киңлеккә әверелде. Күргәзмәдә 11 ил, шул исәптән Төркия, Үзбәкстан, Иран, Малайзия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Индонезия, Әзәрбайҗан, Һиндстан, Сенегал тәкъдим ителде.

«Россия-Ислам дөньясы: KazanForum 2023» XIV Халыкара икътисадый форумы эше барышында 130 килешү һәм меморандум төзелде.

2023 елның 27–28 ноябрендә Бәшир Рамиев исемендәге Казан ИТ-паркы мәйданчыгында дәүләт партнерлыгы һәм хосусый партнерлык буенча VI Дәүләтара тармак форумы уздырылды. Чарада Россиянең 36 төбәгеннән 600 дән артык вәкил катнашты. Форум эше барышында төрле тармакларда (социаль өлкәне (кампуслар, сәламәтлек саклау, спорт), ТКХ, офсет контрактларын гамәлгә ашыру мәсьәләләрен, ДХП өлкәсендә цифрлаштыруны, проектларны гамәлгә ашырганда салым рискларын кертеп) ДХП механизмын куллану тәҗрибәсе тәкъдим ителде. Форумның эшлекле программасы проблемаларга һәм аларны хәл итү юллары турында төрле тармакларга багышланган 11 эшлекле панельле дискуссиядән, бизнес һәм дәүләт хезмәттәшлеге механизмнарына ярдәм чаралары турында сессиядән, төбәкләрдә һәм төрле өлкәләрдә ДХП проектларын гамәлгә ашыру турында пленар утырыштан торды, шулай ук, үзәктән укытуга йомгаклар ясап, яңа заманча проектларның презентациясе белән беренче тапкыр Роуд-шоу үткәрелде. Форум ахырында 5 килешүгә кул куелды.

2023 елның ил тормышында иң зур вакыйгалардан берсе – ул Мәскәү шәһәрендә «Россия» халыкара күргәзмә-форумы эшли башлады. Анда кунаклар Россиянең алдынгы казанышлары һәм инновацияләре, илнең төрле почмакларындагы милли традицияләре, үз илебезнең фермерлары һәм предприятиеләре продукциясе һ.б. белән таныша ала. Республика көне 2023 елның 2 декабрендә үткәрелде. Стендны ачу вакытында күргәзмәгә килгән барлык кунаклар республика атмосферасын тоя алды: Казан шәһәренең тарихи үзәге буйлап йөри, татар йолаларын күрә, халык ашларын, ризыкларын татып карый алды.

**Партнерлык финанслары**

2023 елның 1 сентябреннән, «Россия Федерациясенең кайбер субъектларында партнерлык финанславы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, махсус җайга салуны билгеләү буенча эксперимент уздыру турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 417-ФЗ номерлы Федераль закон гамәлгә ашырыла, ул халыкның һәм бизнесның ислам финансларына өстәмә кызыксынуын арттыра. Эксперимент башланганнан бирле:

базарда катнашучыларның кайберләре биргән мәгълүмат буенча килешүләр саны 2022 елның тиешле чоры күрсәткечләреннән ике тапкырга артты;

республиканың бизнесны үстерү институтлары, банклары тарафыннан партнерлык финанславының факторинг, төзүчеләрне финанслау, поручительлек кебек яңа инструментлары кулланыла башлады: шулай ук кече бизнес өчен яңа ташламалы продуктлар әзерләнә;

илдә беренче хәләл биржа эшли башлады, берничә килешү төзелде;

«Россия Саклык банкы» ГАҖ белән берлектә, инвестиция проектларына ислам финанславын җәлеп итү эшләре алып барыла.

Республикада партнерлык финанславы өлкәсендә 12 оешма эшчәнлек алып бара.

Алар түбәндәге мөмкинлекләрне тудыра:

кулланучыларны һәм бизнесны финанслаудан файдалану;

өлешләп түләү шарты белән торак сатып алуны финанслау;

шәригать таләпләре нигезендә лизинг;

инвестиция шартнамәләре аша акча салу;

2 банк партнерлык финанслары принципларына туры килә торган дебет картасын тәкъдим итә.

8 яңа оешма бу базарга беренче тапкыр чыгарга планлаштыра.

Банк системасына яңа механизмнарны нәтиҗәле кертү, партнерлык (ислам) финанслары принципларын гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлегенең хокукый нигезләрен формалаштыру максатларында, әлеге секторны үстерү турында тәкъдимнәр әзерләнде һәм федераль дәрәҗәгә җибәрелде.

## ФӘННЕ ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ ҮСТЕРҮ

Татарстанның фәнни комплексы 129 оешмадан гыйбарәт, шул исәптән:

31 фәнни-тикшеренү учреждениесе;

40 югары белем бирү мәгариф оешмалары;

6 проект-конструкторлык бюросы;

25 корпоратив фәнни-тикшеренү институты һәм конструкторлык бюросы;

27 башка оешма.

Республикада «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге (алга таба – «РФА Казан фәнни үзәге» ФТҮ) эшли, ул 7 зур тикшеренү бүлекчәсен берләштерә торган интеграцион тикшеренү платформасы булып тора.

Иң зур төбәк фәнни учреждениесе булган Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе (алга таба – Фәннәр академиясе) республикадагы күпмилләтле халыкның мәдәни кодын һәм тарихи мирасын саклап калуга юнәлдерелгән эшчәнлекне дәвам итә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе составына җиде фәнни-тикшеренү институты һәм дүрт үзәк керә.

Эшчәнлекнең өстенлекле юнәлеше – аспирантурада яшь фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү. Фәннәр академиясендә 2 фән (тарих һәм филология) тармагында 5 фәнни белгечлек буенча ике диссертация советы эшли.

Фәннәр академиясе, цифрлы мәйданчыклар, электрон мәгълүматлар базасы, мәгълүмат-коммуникация технологияләрен эшләүгә басым ясап, планлы рәвештә фәнни-мәгариф һәм тикшеренү ресурс базасын үстерүне һәм киңәйтүне дәвам итә, бу фәннең һәм мәдәниятнең кайбер юнәлешләре буенча таләп ителә торган фәнни, фәнни-популяр проектларда чагылыш таба («Татарика 2.0» онлайн энциклопедиясе, «Татарстанның һәм татар халкының мәдәни мирасы» дәүләт мәгълүмат системасы, Tatzet татар теле сүзлекләренең электрон фонды, tatarstones.ru геопорталы һ.б.).

Дөньяның кырыктан артык иленнән һәм Россия Федерациясе төбәкләреннән фәнни учреждениеләр белән партнерлык мөнәсәбәтләре һәм уртак проектлар актив үсеш ала. Өстенлекле партнерлар арасында Россия фәннәр академиясе, шулай ук федераль үсеш институтлары бар.

Республика фәнни-белем бирү комплексының нигезе булып алдынгы югары белем бирү мәгариф оешмалары тора, алар арасында «Казан (Идел буе) федераль университеты (алга таба – К(И)ФУ) ЮББ ФДАМУ, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ» ЮББ ФДАМУ (алга таба – КМТТУ-КАИ), «Казан милли тикшеренү технология университеты» ЮББ ФДБМУ (алга таба – КМТТУ) аерым бер урын алып тора. Алар тикшеренүләрнең һәм эшләнмәләрнең төбәк секторын үстерүгә шактый өлеш кертә, аларга фәнни программаларны һәм проектларны фондка кертү өчен еллык җыелма чыгымнар күләменең якынча 30 проценты туры килә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 декабрь, 1429 нчы карары белән «Татарстан Республикасын фәнни-технологик үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы расланды, ул илнең технологик суверенитетын формалаштыруда төбәк тикшеренүләре һәм эшләнмәләре секторы ролен арттыруга юнәлдерелә.

Программада төбәк өчен традицион икътисад тармакларын технологик яңартуны тәэмин итү һәм тулаем төбәк продуктында яңа югары технологияле, фән казанышларына нигезләнгән һәм креатив тармаклар продукциясенең өлешен арттыру карала, шулай ук ул үз илебезнең технологияләрен һәм инновация продуктларын яңа базарларга чыгаруны тәэмин итәргә тиеш булып тора.

«Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» дәүләт программасы эреләтелгән җиде юнәлешне үз эченә ала, шул исәптән:

табигый-фәнни мәгарифне үстерү;

фәнни-мәгариф кластеры кадрларын үстерү;

конгресс-күргәзмә һәм аң-белем бирү чаралары комплексын үткәрү;

бердәм интеллектуаль фәнни-мәгариф киңлеген булдыру;

инновацион ваучерларны кертү;

яңа икътисад тармакларын үстерү;

уйлап табу эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү һәм стимул бирү.

**Инновацион үсеш**

Шулай ук инновация эшчәнлеген үстерүгә зур игътибар бирелә, чөнки инновацияләр икътисадның уңышлы үсеше өчен драйвер булып тора. Хуҗалык һәм фәнни эшчәнлекнең барлык инфраструктура элементлары диярлек булдырылды, алар эшчәнлек төрләре, башкарыла торган функцияләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең характеры һәм күләме, инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү алымнары белән аерылып тора.

Заманча инновация инфраструктурасы булу һәм дәүләт тарафыннан актив ярдәм күрсәтелү республикада инновация активлыгын үстерү өчен уңай шартлар тудырды. Төяп җибәрелгән инновация продукциясе күләме, технологик инновацияләрне гамәлгә ашыручы оешмалар өлеше, инновацияләргә чыгымнар һ.б. арту моңа дәлил булып тора.

2022 елда төяп җибәрелгән инновация товарлары, эшләр, хезмәт күрсәтүләр күләме 955,6 млрд сум тәшкил итте, бу 2021 елга (789,1 млрд сум) караганда 166,5 млрд сумга күбрәк. Әлеге күрсәткеч буенча Татарстан Республикасы Россия Федерациясе төбәкләре арасында икенче урынны алды (Мәскәү шәһәреннән кала – 989,9 млрд сум).

Төяп җибәрелгән инновация товарлары, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең гомуми күләмендә традицион рәвештә сәнәгать предприятиеләренең төяп җибәрелгән әйберләре төп өлешне алып тора. 2022 ел йомгаклары буенча сәнәгать предприятиеләренең инновация продукциясен төяп җибәрү 891,2 млрд сум (яисә төяп җибәрелгән инновация продукциясенең гомуми күләмендә 93 %) тәшкил итте.

2022 елда сәнәгать оешмаларында төяп җибәрелгән үз җитештерүендәге товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең гомуми күләмендә төяп җибәрелгән инновация продукциясе өлеше 21,5 % (2021 елга караганда 0,7 % пунктка күбрәк) тәшкил итте.

2022 елда 27 процентка инновация чыгымнары артты, ул 258,2 млрд сум (2021 елда – 203,1 млрд сум) күләмендә тәшкил итте.

2022 елда оешмаларның инновацион активлыгы дәрәҗәсе 32 % (2021 елда – 29 %) тәшкил итте.

Тикшерелгән оешмаларның гомуми санында технологик инновацияләрне гамәлгә ашыручы оешмаларның артуы дәвам итә, алар 2022 елда 46 % (2021 елда – 41,1 %) тәшкил итте.

**Кече инновация эшкуарлыгына ярдәм чаралары**

Татарстан икътисады үсеше резервларыннан берсе – ул кече һәм урта эшкуарлыкны (алга таба – КУЭ), шул исәптән югары технологияле эшкуарлыкны үстерү, аның эшчәнлеге нигезендә югары технологияле җитештерүләр булдыру, шулай ук яңа технологияләрне гамәлгә кертү һәм куллану ята, бу республика предприятиеләренең эчке һәм чит ил базарларында конкурентлык сәләтенә йогынты ясый, әлбәттә. Мондый бизнесны үстерү өчен яңа эшләнмәләрне апробацияләү һәм кертү өчен грант һәм заем акчасы рәвешендә өстәмә финанслау җәлеп итү зур ярдәм булып тора.

Кече инновация эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү һәм фәнни инновация проектларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы технологик компанияләрне үстерүгә һәм инновацияләрне коммерцияләштерү мәсьәләләрен хәл итүгә ярдәм итә торган программалар комплексын киң гамәлгә ашыра торган «Фәнни-техник өлкәдә предприятиеләрнең кече формаларын үстерүгә ярдәм фонды» ФДБУ (Инновацияләргә ярдәм фонды) белән хезмәттәшлек итә.

2023 ел йомгаклары буенча Инновацияләргә ярдәм фонды тарафыннан 364 республика инновация проектына ярдәм күрсәтелде, аларны гамәлгә ашыру өчен барлыгы 737,2 млн сум күләмендә федераль акча җәлеп ителде.

Талантлы яшьләрне фәнни-техник иҗатка һәм технологик эшкуарлыкка җәлеп итүгә зур игътибар бирелә. 2023 елда Инновацияләргә ярдәм фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган «Студентлар стартабы» конкурсының 3 һәм 4 нче чираты уздырылды, аларның йомгаклары буенча Татарстаннан 313 җиңүче билгеләнде, инновация проектларына 313 млн сум күләмендә гомуми суммага грант бирелде.

«Студентлар стартабы» программасында җиңгән проектлар, аларны алга таба гамәлгә ашыру максаты белән, тармак министрлыкларына (ведомстволарына), югары белем бирү мәгариф оешмаларына һәм республика предприятиеләренә беркетелде. Бу эшкә барлыгы 16 югары белем бирү мәгариф оешмасы, 15 министрлык, 180 предприятие җәлеп ителде.

Шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, кече һәм урта эшкуарлыкның югары технологияле, инновацион субъектларына ярдәм күрсәтү максатларында, «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорациясе» АҖ (алга таба – «КУЭ» корпорациясе» АҖ) белән үзара хезмәттәшлек итә.

Ярдәмнең бер төре – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 25 мартындагы 469 номерлы карары нигезендә Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан, «КУЭ» корпорациясе» АҖ һәм «МСП Банк» АҖ белән берлектә, гамәлгә ашырыла торган югары технологияле, инновацион компанияләргә ташламалы кредит бирү программасы. Кредитлар «МСП Банк» АҖ тарафыннан бер заем алучыга күләмдә елына 3 % ташлама бирә торган ставка белән 500 млн сумга кадәр акча бирелә. 16 юнәлешкә ярдәм күрсәтү өстенлеккә ия, әлеге юнәлешләр арасында ясалма интеллект, коммуникация технологияләре, әйберләр

интернеты, яңа җитештерү технологияләре, яңа материаллар һәм матдәләр технологияләре, генетик технологияләр, биотехнологияләр һәм фармацевтика бар.

2023 елда әлеге программада катнашу кысаларында барлыгы 8 Татарстан компаниясе 1,1 млрд сум гомуми суммага кредит шартнамәләре төзеде. Әлеге ярдәм күрсәтү чарасы технологик эшкуарларга финанслар алырга мөмкинлек бирә, бу бигрәк тә товарлар кайтартуның глобаль чылбыры үзгәрү һәм импортны алыштыруны тәэмин итү шартларында аеруча мөһим булып тора.

Шулай ук республика компанияләре технологик компанияләрне Россиянең эре корпорацияләре таләпләренә туры килә торган итеп «үстереп бетерү» буенча грант программасында (алга таба – «үстереп бетерү» программасы) актив катнаша, аның операторы – «Инжинирингка һәм инновацияләргә ярдәм үзәге» АКБО. «Үстереп бетерү» программасында читтән кертелә торган продукцияне һәм башка инновация продукциясен Россия корпорацияләренең билгеле бер бурычларына (техник таләпләренә) туры килә торган җитештерүне уйлап чыгару һәм булдыру (киңәйтү) буенча Россия технология компанияләре проектларына грант ярдәме күздә тотыла.

2023 елда 5 Татарстан компаниясе 750 млн сум гомуми суммага грант отты. Татарстан Республикасы, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән кала, «үстереп бетерү» программасында катнашу кысаларында ярдәм күрсәтелгән проектларны финанслау күләме буенча төбәкләр рейтингында 3 нче урынны алды.

**Инновация инфраструктурасын үстерү**

Татарстанда КУЭ үсешенә шулай ук республикада бизнеска ярдәм күрсәтү буенча булдырылган инфраструктура да ярдәм итә. Ээлеккечә, мәйданчыкларның белгечлеген исәпкә алып, инновацион компанияләрне үстерүгә ярдәм итә торган технопарк структуралары республиканың инновация инфраструктурасы чылбырында төп звенолар булып кала. Бу мәйданчыкларда республика үсешенең өстенлекле юнәлешләре буенча инновацияләр генерациясе бара.

2023 ел йомгаклары буенча «Идея» инновация-җитештерү технопаркында 111 компания-резидент эшләде, алар нигездә мәгълүмат технологияләре һәм автоматлаштыру, инжиниринг һәм метрология, консалтинг һәм мәгариф хезмәтләре, тренажер-симуляторлар җитештерү өлкәсендә эш алып бара.

Югары технологияләр өлкәсендә 4 технопарк мәйданчыгы булдырылды – бу мәгълүмат һәм коммуникация технологияләре тармагын үстерү өчен уникаль мәйданчыклар.

«Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» ДАУ (алга таба – «ИТ-парк» ДАУ) Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә урнаша һәм үз илебезнең программа тәэминатын эшләп чыгару белән шөгыльләнә. «ИТ-парк» ДАУ резидентлары – 673 компания (экстерриториаль резидентларны исәпкә алып).

2022 елда Казан шәһәрендә «ИТ-парк» ДАУнең яңа мәйданчыгы ачылды, аңа күренекле совет галиме, беренче совет электрон исәпләү машинасын уйлап табучы Б.И.Рамиев исеме бирелде. Яңа ИТ-паркның төп инфраструктурасына балалар ИТ-паркы, «Арена» киберпаркы, цифрлы китапханә (коворкинг), «Хаб» стартабы, конференц-сервис зоналары һәм сөйләшүләр бүлмәләре, криптополигон керә.

«ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесенең техник һәм бизнес инфраструктурасы, өзлексез камилләшеп һәм резидентлар өчен төрледән төрле сервислар тәкъдим итеп, стартап-проектларны һәм ИТ-компанияләрне барлык үсеш

стадияләрендә: югары технологияле продукт чыгару идеясеннән башлап аның соңгы продуктын базарга чыгарганга кадәр комплекслы үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен экосистема тудыра.

«Иннополис» МИЗ территориясендә югары технологияләр өлкәсендәге «ИнноПарк» технопаркы эшчәнлек алып бара. Технопарк 7 җитештерү бинаылары модулен һәм офис бүлмәләреннән торган төп административ-көнкүреш корпусын үз эченә ала. 2023 ел йомгаклары буенча «ИнноПарк» технопаркында 9 югары технологияле компания теркәлде.

**Интеллектуаль милек өлкәсен үстерү**

Интеллектуаль милек өлкәсен үстерүгә аерым игътибар бирелә, анда патент активлыгы хәл-торыш индикаторларының берсе булып тора.

Интеллектуаль милек федераль хезмәте мәгълүматлары буенча, 2023 елда республика предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан 1 382 заявка бирелде һәм интеллектуаль милек объектларына 1 081 патент алынды. Интеллектуаль милек объектларына алынган патентлардан 677 патент – уйлап табуга, 296 – файдалы модельгә, 108 сәнәгать үрнәгенә бирелде.

2023 елда «Татпатент» «Татарстан Республикасы интеллектуаль потенциалы» мәгълүматлар банкы» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасын (алга таба – «Татпатент» системасы) модернизацияләү эшләре алып барылды.

«Татпатент» системасы Татарстанның фәнни-технологик үсешенең инновация проектларын гамәлгә ашырганда инноваторларга һәм бизнеска ярдәм күрсәтү өчен цифрлы платформадан гыйбарәт. Платформа КУЭ предприятиеләре, индивидуаль эшкуарлар, уйлап табучылар өчен билгеләнде.

«Татпатент» системасын модернизацияләү кысаларында түбәндәге федераль системалар белән интеграция ясалды:

Интеллектуаль милек федераль хезмәтенең глобаль эзләү системасы (Роспатент) белән. Әлеге интеграция исәбенә «Татпатент» системасыннан файдаланучыларның патент эзләнүләрен һәм тикшеренүләрен үткәрү өчен интеллектуаль милек буенча Россия һәм халыкара мәгълүмат ресурсларыннан файдалану мөмкинлеге барлыкка килде;

Роспатентның патент заявкаларын автоматлаштырылган кабул итү системасы белән. «Татпатент» системасыннан файдаланучыларның бер процесс кысаларында патент белгече белән элемтәгә керү, онлайн режимда патент хезмәтләренең тулы исемлеген алу, патент пошлинасын 30 процентлы ташлама белән түләү һәм Роспатентка турыдан-туры рәсми патент заявкасын бирү мөмкинлеге хасил булды;

«Идарә карарларын кабул итү» дәүләт мәгълүмат системасы белән. «Татпатент» системасында интеллектуаль милек өлкәсендәге төп максатчан күрсәткечләр һәм социаль-икътисадый күрсәткечләр яктылыгында Татарстан Республикасы буенча берләштерелгән мәгълүмат, шулай ук республика хуҗалык субъектлары буенча заявкалар тапшыру, уйлап табуга һәм файдалы модельләргә патентлар бирү динамикасы барлыкка килде. Шулай ук, тулаем алганда, Россия буенча интеллектуаль милек өлкәсенең төп күрсәткечләре буенча берләштерелгән мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге бар;

Идентификация һәм аутентификация бердәм системасы аша идентификация белән. Урнашу урыны турындагы мәгълүматларны структуралаштыру өчен «ДаДата»

системасы белән өстәмә интеграция ясалды, бу файдаланучылар өчен уңайлыклар тудыра һәм аларның мәгълүматларны кертүгә вакытын киметә.

Үткәрелгән модернизация нәтиҗәсендә «Татпатент» системасыннан файдаланучыларга тулы мәгълүмат алу һәм патент эзләвен башкару, дәүләт ярдәме чараларын сайлап алу, «Татпатент» системасының проект офисында консультацияләр алу һәм патентларны тизләтеп рәсмиләштерү өчен шартлар тудырылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасында граждан билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен дәүләт исәбенә алу һәм саклау бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 ел, 12 март, 133 нче карары нигезендә граждан билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен дәүләт исәбенә алу һәм саклау эше дәвам итте, аларның финанс белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2006–2023 елларда Фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен дәүләт исәбенә алу һәм саклау бердәм системасында 2,2 млрд сум гомуми суммага 2 448 фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эш, шулардан 2023 елда 75,8 млн сум күләмендә 72 фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эш теркәлде

2023 елда фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне финанслау түбәндәге төп юнәлешләр буенча гамәлгә ашырылды:

«Мәгълүмат-телекоммуникация системалары һәм мәгълүматны саклау» (59 %);

«Татар халкының һәм Татарстан халыкларының тарихи-мәдәни мирасы» (13 %);

«Биотехнологияләр» (11 %);

«Архитектура һәм төзелеш, транспорт системалары» (6 %);

«Табигатьтән рациональ файдалану, экология һәм әйләнә-тирә мохитне саклау» (4 %);

«Авыл хуҗалыгы фәннәре һәм азык-төлек иминлеге» (3 %);

«Полимер, композицияле һәм энергиягә бай материаллар» (3 %);

«Фундаменталь һәм гамәли медицина, фармацевтика» (1 %).

2006 елдан 2023 елга кадәр дәүләт контрактлары кысаларында патентланган нәтиҗәләрнең гомуми саны 127 берәмлек тәшкил итә.

ТР Фәннәр академиясе (46,4 %), Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (23 %), Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (13 %) һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (7 %) тарафыннан башкарыла торган эшләр бик күп санда теркәлде һәм аларга патентлар бирелде.

**2023 елда «Фән һәм университетлар» илкүләм проектын һәм социаль-икътисадый үсешнең стратегик инициативаларын гамәлгә ашыру**

*«Приоритет-2030» стратегик академик лидерлыгы программасы*

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 13 маендагы 729 номерлы карары нигезендә 2021 елдан бирле гамәлгә ашырыла торган «Приоритет-2030»

стратегик академик лидерлык программасы университетларны үстерү программаларына ярдәм күрсәтүгә һәм 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешүдә Россия университетларының өлешен арттыруга, илнең балансланган пространстволы үсешенә, Россия Федерациясе субъектларында сыйфатлы югары белем алу мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлдерелде.

2023 елда республиканың 4 югары белем бирү мәгариф оешмасы – К(И)ФУ, КМТТУ-КАИ, КМТТУ, «Казан дәүләт энергетика университеты» ЮББ ФДБМУ (алга таба – КДЭУ) – программа грантының база өлешен гамәлгә ашыруда катнашты. Федераль ярдәмнең гомуми суммасы 400 млн сум тәшкил итте. К(И)ФУ шулай ук грантның махсус өлешен алды. Бу юнәлеш буенча финанслау күләме 830 млн сум тәшкил итте.

2023 елның 1 декабрендә Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасында катнашу өчен өстәмә сайлап алуны гамәлгә ашыру комиссиясе утырышы уздырылды.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының элек программада катнашу кандидаты статусына ия «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (алга таба – КДМУ) аның катнашучылар категориясенә күчерелде, ә КМТТУ грантның махсус өлешен алуга лаек булды.

*Фәнни тикшеренүләр һәм кадрлар әзерләү өчен инфраструктураны үстерү*

К(И)ФУ җитәкчелегендәге консорциум базасында илнең фәнни-технологик үсешенең өстенлекле юнәлешләренннән берсе (табигатьтән рациональ файдалану) буенча дөньякүләм дәрәҗәдәге «Планетаның сыек углеводородларын рациональ үзләштерү» фәнни үзәге эшләвен дәвам итте. 2023 елда үзәкне үстерү программасын гамәлгә ашыруга федераль ассигнованиеләр күләме 441,3 млн сум тәшкил итте, шулардан 246,9 млн сумы К(И)ФУна бүлеп бирелде.

2023 елда К(И)ФУның һәм КМТТУ-КАИның махсуслаштырылган укыту фәнни үзәкләре үсеш программаларын гамәлгә ашыруны дәвам итте. Үзәкләргә ярдәм күрсәтү өчен федераль ассигнованиеләр күләме шул ук эзлеклелектә 200 һәм 91,7 млн сум күләмендә тәшкил итте.

«Казан дәүләт мәдәният институты» ЮББ ФДБМУ базасында инжиниринг үзәге эшләве дәвам итте. Федераль бюджеттан җәлеп ителгән акча суммасы 33,1 млн сум тәшкил итте.

Моннан тыш, «РФА КазФҮ» ФТҮ базасында агросәнәгать комплексында фәнни һәм мәгариф оешмаларының үз эшләнмәләре нигезендә заманча технологияләр булдыруга һәм кулланышка кертүгә юнәлтелгән селекция-орлыкчылык үзәге эшчәнлеге дәвам итте. Федераль бюджет акчасыннан финанслау суммасы 30 млн сум тәшкил итте.

«РФА КазФҮ» ФТҮндә фәннең приборлар базасын яңарту, реконструкцияләү һәм техник яңадан җиһазландыру чаралары дәвам итте. 2023 елда әлеге максатлар өчен учреждение федераль бюджеттан 227 млн сум күләмендә акча алды.

2023 елда К(И)ФУ дөньякүләм танылган әйдәүче галимнәр, шул исәптән чит илләрдә яшәүче ватандашлар җитәкчелегендәге дөньякүләм дәрәҗәгә ия лаборатория төзүгә 60 млн сум күләмендә федераль грант алды.

Дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәге составына кергән өч оешма (К(И)ФУ, «РФА КазФҮ» ФТҮ һәм КДЭУ) базасында 7 яшь лабораториягә ярдәм

күрсәтелә, 2023 елда федераль бюджеттан финанслау күләме 100 млн сумнан артып китте.

КДМУда өч яшьләр лабораториясе эшләвен дәвам итте, 2023 елда аларны гомуми финанслау күләме 45 млн сум тәшкил итте.

*«Алдынгы инженерлык мәктәпләре» федераль проекты*

2023 елда «Алдынгы инженерлык мәктәпләре» проектында катнашучылар – машиналар төзү, химия технологияләре тармакларындагы һәм мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге югары технологияле компанияләре белән партнерлыкта булган К(И)ФУ, КМТТУ һәм «Иннополис» университеты.

Акча яңа фәнни-технологик һәм эксперименталь лабораторияләр; заманча югары технологияле җиһазлар һәм махсуслаштырылган гамәли программа тәэминаты белән җиһазландырылган тәҗрибә җитештерүләрен ачуга; алдынгы цифрлы технологияләрне белә торган инженерлык кадрларын алга китеп әзерләү буенча яңа программалар эшләүгә тотыла.

2023 елда һәр алдынгы инженерлык мәктәбен үстерү бюджеты федераль бюджеттан 348 шәр млн сум, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан 200шәр млн сум тәшкил итте.

Моннан тыш, 2023 елда өстәмә сайлап алу йомгаклары буенча программада «Әлмәт дәүләт нефть институты» ЮББ ДБМУ һәм КМТТУ-КАИ катнаша.

Катнашучыларның гомуми саны буенча Татарстан, Мәскәү шәһәреннән кала, Санкт-Петербург шәһәре белән икенче урында тора.

*«Университет технологик эшкуарлыгы платформасы» федераль проекты*

Югары уку йортларында белем алучыларның һәм профессор-мөгаллим составындагыларның эшкуарлык күнекмәләрен һәм компетенцияләрен алга китеп формалаштыру максатларында, «Университет технологик эшкуарлыгы платформасы» масштаблы проекты гамәлгә ашырыла.

Югары белем бирү мәгариф оешмалары консорциумы кысаларында К(И)ФУ җитәкчелегендәге стартап-студия эшли.

Аны үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен проектның федераль операторы – Инфраструктура һәм мәгариф программалары фонды тарафыннан тәкъдим ителәчәк грант күләме 100 млн сум тәшкил итте.

Шулай ук «КАМАЗ» ГАҖ һәм «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» КБО старт-студия партнерлары булып тора, алар үз ягыннан Инфраструктура һәм мәгариф программалары фонды бүлеп биргән күләмнәрдә финанслашуны тәэмин итте.

*Фәнни-мәгариф кампусларын төзү*

Әлмәт шәһәрендә В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ ярдәмендә Әлмәт дәүләт нефть институты базасында «Нефть югары мәктәбе» кампусы төзелә.

2023 елда аның территориясендә 708 урынга исәпләнгән 2 студентлар тулай торагы корпусы, 16 мең квадрат метрдан артык мәйданлы лаборатория-тикшеренү корпусы, спорт үзәге, җир асты парковкасы һәм хезмәткәрләр өчен 55 урынлык балалар бакчасы урнаша торган беренче торак йортлар төзелде.

Кампус территориясендә «Әлмәт дәүләт нефть институты» ЮББ ДБМУ, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖнең «ТатНИПИнефть» тармак институты урнашачак һәм алар бергәләп эшләячәк.

**КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫК**

2024 елның 1 гыйнварына республикада:

172,5 мең кече һәм урта эшкуарлык субъекты (алга таба – КУЭ) теркәлде, бу 2023 ел башына карата 7 100 субъектка (4,3 процентка) күбрәк;

КУЭ белән шөгыльләнүчеләр (индивидуаль эшкуарларны һәм үзмәшгульләрне кертеп) саны 597,7 мең кеше исәпләнә, бу 2023 ел башына карата 16,3 мең кешегә (2,8 процентка) күбрәк;

республика икътисадында эшләүчеләрнең гомуми санында КУЭ эшләүчеләр өлеше – 41,5 %, бу 2023 ел башына карата 2,9 процентка күбрәк;

үзмәшгульләр саны 306,2 мең граждан тәшкил итте, бу 2023 ел башына карата 71,9 мең кешегә (30,7 процентка) күбрәк;

КУЭ субъектларыннан салым кертемнәре күләме – 183,9 млрд сум, бу 2023 ел башына караганда 38,5 млрд сумга (26,5 процентка) күбрәк.

**Татарстан Республикасының КУЭ субъектларына ярдәм инфраструктурасы**

Татарстанда КУЭ субъектларына ярдәм инфраструктурасы оешмалары төзелде һәм эшли.

Алар санына «Татарстан Республикасының Эшкуарлыкка ярдәм фонды» микрокредит компаниясе коммерциячел булмаган оешмасы («Минем бизнес» үзәге, Эшкуарлыкка ярдәм үзәге, Социаль өлкә инновацияләре үзәге, Бизнес өчен күпфункцияле үзәк, Микрофинанслау үзәге, Экспортка ярдәм үзәге) (алга таба – Эшкуарлыкка ярдәм фонды), «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» КБО, «Татарстан Республикасының Төбәк лизинг компаниясе» АҖ, «Татарстан Республикасының Кластерлы үсеш һәм проект идарәсе үзәге» АКБО, «Татарстан Республикасында Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм программаларын гамәлгә ашыру үзәге» ДКУ керә.

Әлеге оешмалар тарафыннан, шул исәптән «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында КУЭ субъектларына финанс һәм финанс булмаган ярдәм чаралары комплексы күрсәтелә.

2023 елда мондый чаралардан якынча 30 мең КУЭ субъекты файдаланды, шулардан 4 меңнән артык субъектка якынча 87 млрд сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелде, шул исәптән:

*республика ярдәм чаралары:*

6,6 млрд сумга 1 131 (2022 елда – 3,7 млрд сумга 668) поручительлек бирелде;

2,0 млрд сумга 862 ташламалы микрозаем (2022 елда – 1,5 млрд сумга 777 ташламалы микрозаем) бирелде;

14 оешманың электр энергиясе чыгымнары 15,0 млн сумга (2022 елда 9 оешманың – 9,99 млн сумга) субсидияләнде;

92,3 млн сумга 217 грант (2022 елда – 47,0 млн сумга 119 грант) бирелде;

33 лизинг алучыга 152,0 млн сум күләмендә (2022 елда 14 алучыга – 87,2 млн сум күләмендә) финанслар бирелде.

*федераль ярдәм чаралары:*

70 КУЭ субъектына 1,1 млрд сумга кредит каникуллары бирелде;

«Инвестицияле» дигән кредит бирүне стимуллау программасы буенча ярдәм күрсәтүдән 7,5 млрд сумга 86 кеше файдаланды;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен ташламалы кредит бирүдән 26,6 млрд сумга 484 кеше файдаланды;

кредит бирүне субсидияләү – 24,4 млрд сумга 773 кредит;

2,5–4 % еллык ставка белән ташламалы кредит бирүдән 5,9 млрд сумга 34 кече һәм урта эшкуарлык субъекты файдаланды;

7,5 млрд сумга 566 кредит реструктурлаштырылды;

өстенлекле чит ил товарларын сатып алуга ташламалы кредит бирү – 3,3 млрд сумга 12 кредит;

IT-оешмаларга 3 проценттан югары булмаган ставка белән ташламалы кредит бирү – 1,1 млрд сумга 9 кредит;

3,5 % ставка белән сәнәгать ипотекасы – 0,7 млрд сумга 21 кредит.

**Мәгълүмат-консультация һәм белем бирү ярдәме, тарату, сертификация хезмәтләре, экспортка чыгару**

*«Минем бизнес» үзәге*

Эшкуарлыкка ярдәм фондының «Минем бизнес» үзәге:

28 меңнән артык КУЭ субъекты һәм үзмәшгуль гражданнар, физик затлар өчен 44 меңнән артык хезмәт күрсәтелде, 45 тән артык чара, шул исәптән Татарстан Республикасында Эшкуарлар көне, «Минем бизнес. E-com» форумы, үзмәшгуль гражданнар өчен «Мин Татарстан инде ул» дигән ярминкәләр һ.б. оештырылды;

«Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорация» АҖ тарафыннан эшләнгән 20 тренинг үткәрелде, аларда 1 600 дән артык кеше катнашты;

КУЭ субъектлары өчен белем бирү программалары үткәрелде һәм «Мәктәп бизнес-стартлы» проекты гамәлгә ашырылды, анда 5-7 нче сыйныфларның 11 меңнән артык укучысы катнашты;

4,5 меңнән артык үзмәшгуль гражданга мәгълүмат-консультация хезмәтләре күрсәтелде;

190 КУЭ субъектлары дип социаль предприятиеләр танылды;

53 социаль предприятие вәкиле социаль эшкуарлык өлкәсендә уку-укыту программасын узды;

социаль эшкуарлык мәсьәләләре, социаль һәм социаль-эшкуарлык проектларын үстерү буенча 3,5 меңнән артык консультация бирелде;

1 600 дән артык граждан социаль контракт буенча укуларда булды һәм сертификатлар алды;

социаль эшкуарлык өлкәсендәге һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның проектлары буенча «Минем игелекле бизнес» бөтенроссия конкурсының төбәк этабы уздырылды, аның кысаларында социаль предприятиеләрнең 9 проекты һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның 7 проекты җиңүче дип танылды;

күргәзмә-ярминкә чараларында катнашу, маркетплейсларга чыгу, үз продукциясен/хезмәтләрен тарату буенча 2 200 дән артык комплекслы хезмәт күрсәтелде.

*Экспортка ярдәм үзәге*

Эшкуарлыкка ярдәм фондының Экспортка ярдәм үзәге:

«Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында 3 119 КУЭ субъектына ярдәм чаралары күрсәтелде;

70тән артык КУЭ субъектына чит ил базарларына чыгуда ярдәм күрсәтелде;

29 халыкара күргәзмә-ярминкә чарасында 71 уникаль КУЭ субъектының катнашуы оештырылды;

халыкара электрон сәүдә мәйданчыкларында 2 КУЭ субъекты продукциясен урнаштыру оештырылды;

«Россия экспорт үзәге» АҖнең белем бирү семинарларында 74 КУЭ субъектының катнашуы оештырылды;

6 КУЭ субъектына үз продукциясенә сертификатлар алуда хезмәт күрсәтелде;

46 КУЭ субъектына экспорт контрактын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтелде;

17 КУЭ субъектына чит ил сатып алучысын эзләүдә һәм сайлап алуда ярдәм күрсәтелде;

уртак финанслау шартларында 2 КУЭ субъекты өчен индивидуаль маркетинг тикшеренүләре уздырылды;

4 түгәрәк өстәл, 150дән артык вебинар һәм семинар, 1 конференция үткәрелде.

**Интернет сәүдәне үстерү**

Татарстан эшкуарларына комплекслы ярдәм күрсәтү максатларында ,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 27 гыйнвар, б-138 нче боерыгы белән расланган 2023–2025 елларга Татарстан Республикасында интернет сәүдәне үстерү программасы (чаралар планы) эшләнде.

Чаралар планы берничә блоктан гыйбарәт:

Татарстан Республикасында интернет сәүдә инфраструктурасын үстерү (продукция кабул итү пунктларының географиясен киңәйтү, логистика компанияләре белән хезмәттәшлекне оештыру, логистика бүлү үзәкләрен төзегәндә ташламалар һәм чаралар бирү чаралары кертелде);

интернет мәйданчыкларга чыкканда эшкуарларны теркәү, аларга даими булышлык күрсәтеп тору һәм консультация бирү. Бу блокта финанс һәм финанс булмаган ярдәм чаралары комплексына аерым игътибар бирелә. Эшкуарлар өчен электрон сәүдә мәйданчыкларында урнаштыру һәм тарату хезмәтләре, шулай ук махсус кредит һәм микрофинанс продуктлары карала;

интернет сәүдәне тарату һәм популярлаштыру. Бу блок кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм үзмәшгуль гражданнар өчен логистика һәм электрон сәүдә буенча форумнар, конференцияләр, электрон сәүдә мәйданчыкларына чыгу буенча онлайн интенсивлар, шулай ук электрон сәүдәне популярлаштыру максатларында күчмә семинарлар үткәрү чараларын үз эченә ала;

тышкы икътисадый эшчәнлек. Блок эшкуарларның халыкара электрон мәйданчыклары һәм транспорт-логистика провайдерлары белән хезмәттәшлеген киңәйтүгә юнәлдерелде;

мәгариф. Әлеге блок кысаларында кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре, шулай ук «Демография» илкүләм проекты кысаларында өлкәннәр өчен укыту программалары тормышка ашырыла.

Экспортка ярдәм үзәге тарафыннан Alibaba, Epinduo, ЛеснойРесурс.рф, Topfranchise, Trendyol һәм Turkishexporter кебек халыкара маркетплейсларда эшкуарлар продукциясен урнаштыру хезмәтләре күрсәтелә.

2023 елда 2 КУЭ субъектының продукциясе Экспортка ярдәм үзәге тарафыннан TurkishExporter һәм Trendyol халыкара электрон сәүдә мәйданчыкларында урнаштырылды.

Маркетплейслар белән нәтиҗәле эшләү өчен Эшкуарлыкка ярдәм фонды, «Маркетплейс.Легко» электрон сәүдә үзәге автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән хезмәттәшлек итеп, маркетплейсларга чыгу буенча комплекслы хезмәт күрсәтә, шулай ук укыту программаларын, шул исәптән «аккаунт-менеджер» белгечлеге буенча КУЭ субъектлары вәкилләренең квалификациясен күтәрү / аларны яңадан әзерләү буенча үткәрә.

2023 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында интернет сәүдәне үстерү программасы (чаралар планы) чараларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан сатучылары саны 2022 елга карата 32,7 процентка артты һәм 60 279 берәмлеккә җитте.

**Сәнәгать паркларын үстерү**

Республиканың сәнәгать паркларында 1 645 тән артык резидент эшчәнлек алып бара, 65,3 меңнән артык эш урыны булдырыла.

Сәнәгать паркларын үстерү эш урыннарын булдыруга һәм модернизацияләүгә, салым өчен тотрыклы кучерелә торган түләүләргә, авылда кече бизнес белән шөгыльләнүнең альтернатив төрләрен, социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерүгә, хезмәткә карата мотивация формалаштыруга, бу өлкәгә квалификацияле хезмәткәрләр җәлеп итүгә юнәлдерелә.

Инфраструктураның төп звенолары:

«Химград» технополисы (2023 ел йомгаклары буенча: 10,5 мең гомуми эшчеләр саны белән 370 резидент, керем – 80,3 млрд сум);

«Мастер» Кама индустриаль паркы (2023 ел йомгаклары буенча: 12,6 мең гомуми эшчеләр саны белән 290 резидент, резидентларның кереме – 180,0 млрд сум);

муниципаль сәнәгать парклары (2023 ел йомгаклары буенча: 41,5 мең гомуми эшчеләр саны белән 742 резидент, резидентларның кереме – 234,2 млрд сум).

Сәнәгать паркларының нәтиҗәлелеген күтәрү, эш урыннары санын арттыру максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов тарафыннан авыл җирендә территорияләрне комплекслы үстерү өчен сәнәгать паркларының нәтиҗәлелеген күтәрү концепциясе килештерелде, аның кысаларында резидентларга һәм аккредитация узган сәнәгать паркларының идарәче компанияләренә төрле преференцияләрдән файдалану мөмкинлеге бирә торган закон чыгару инициативалары кабул ителде:

салым салуның гадиләштерелгән системасы буенча салым ставкаларын (керемнәр ставкасы – 1 %, чыгымнар тотып калынган керемнәр ставкасы – 5 %) киметергә;

транспорт салымы буенча салым ташламасы (0 %) алырга;

оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым ташламасы алырга (0 %).

Аккредитацияләнгән, эш урыннары биләнү дәрәҗәсе түбән булган сәнәгать парклары территорияләрендә эшчәнлек алып барган һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килешү төзегән идарәче компанияләр һәм резидентлар салым ташламаларыннан 10 елга кадәр файдаланырга мөмкин.

2024 елда сәнәгать парклары өчен түбәндәге дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру дәвам итәчәк: ташламалы микрозаемнар, электр энергиясе чыгымнарының бер өлешен субсидияләү, Гарантия фондының поручительлеге, «үстереп бетерү» программасы, җиһаз лизингы, кредит алу буенча ташлама бирә торган программалар, инженерлык инфраструктурасы төзелешен финанслау.

Республикада «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында «Кече һәм урта эшкуарлык корпорациясе» акционер җәмгыятенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын «үстерү» программасын тормышка ашыру дәвам итә. 2023 елда программада катнашу өчен республиканың 40 предприятиесе сайлап алынды, алар өчен «Кече һәм урта эшкуарлык корпорациясе» акционер җәмгыятенең цифрлы платформасында скоринг бәяләүләре уздырылды, предприятиеләр үсеше буенча индивидуаль карталар эшләнде һәм гамәлгә ашырыла. 2020–2023 еллар чорында «үстерү» чараларында катнашучыларга 6,5 млрд сумнан артык күләмдә финанс ярдәме күрсәтелде, шул исәптән Инновацияләргә булышлык фонды, Инжинирингка һәм инновацияләргә ярдәм үзәге һәм Технологик үсеш агентлыгы грантлары, Сәнәгатьне үстерү фонды заемнары, ташламалы кредит, ташламалы заемнар һ.б. бирелде. Моннан тыш, әлеге чор дәвамында 600 гә якын финанс булмаган ярдәм чарасы күрсәтелде (продукцияне популярлаштыру, сертификацияләү, патент тикшеренүләре, маркетинг тикшеренүләре, товар билгесен теркәү, техник-икътисадый нигезләүне эшләү, бизнес-миссия һ.б.).

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан барлыгы 86 сәнәгать паркы, шул исәптән 2023 елда 18 сәнәгать паркы аккредитацияләнде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 октябрендәге 1119 номерлы карары кысаларында индустриаль парклар, сәнәгать технопарклары һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын субсидияләү буенча 2023 елда федераль бюджеттан «Алабуга» МИЗ, «Алабуга-2. Нефть химиясе», «Лаеш» индустриальных парклары, югары технологияләр өлкәсендәге «ИнноПарк» технопаркы проектларын гамәлгә ашыруга 19,1 млрд сумнан артык акча җәлеп ителде.

КУЭ субъектларына һәм үзмәшгуль гражданнарга мөлкәти ярдәм күрсәтү өчен республикада дәүләт һәм муниципаль күчмә һәм күчемсез мөлкәт исемлекләре расланды, аларга ташламалы ставка белән арендага бирү өчен 1 226 дан артык объект керә.

**Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының сатып алулардан файдалану мөмкинлеге**

КУЭ субъектларыннан сатып алулар өлешен арттыру максатларында, вәкаләтле орган буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы «Юридик затларның кайбер төрләре товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында»

2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 223-ФЗ номерлы Федераль закон) кысаларында республиканың иң зур һәм кайбер заказчыларына карата, аларның КУЭ субъектларыннан планлаштырыла торган сатып алуларның еллык күләменнән кимендә 25 % күләмендә сатып алуларны гамәлгә ашыруын тикшереп, сатып алулар планнарын бәяли һәм мониторинглый.

2023 елда Татарстан Республикасында 223-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында 31 иң зур заказчы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 717-р номерлы боерыгы белән расланган исемлек нигезендә) һәм 83 аерым заказчы эшчәнлек алып барды.

2023 елда иң зур заказчылар тарафыннан КУЭ субъектларыннан сатып алулар 32,7 млрд сумга (72,8 млрд сумнан) якынча 45 процент гамәлгә ашырылды. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан иң зур заказчыларның 1,5 меңнән артык сатып алулар планы проекты карап тикшерелде һәм килештерелде.

Кече һәм урта эшкуарлыкның сату базарларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, шул исәптән бердәнбер сайлап алынган федераль дәрәҗәдәге ZakazRF төбәк мәйданчыгын (калган 7 мәйданчык Мәскәүдә) исәпкә алып, барлык кирәкле инструментлар да бар.

Шулай ук бизнесның электрон сатуларда катнашуын тәэмин итү максатларында, республика муниципаль берәмлекләре белән бергәләп эшләгән вакытта 2023 елда Республика маркетинг үзәге ресурсларында 4,5 меңнән артык Татарстан эшкуары – КУЭ субъекты 210,5 млрд сумнан артык күләмендә керем алды.

Моннан тыш, 223-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында республика оешмалары-заказчылары тарафыннан Республика маркетинг үзәгенең 223etp.zakazrf дигән мәйданчыгында КУЭ субъектларыннан конкурентлы ысул белән 26,5 меңнән артык сатып алу урнаштырылды. КУЭ субъектлары продукциясен сату базарын киңәйтү проекты кысаларында 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләмәүче предприятиеләр заявкалары буенча конкурентлы сатып алулар үткәрү хисабына, «АГЗСНАБ» ресурсыннан файдаланып, 2 меңнән артык сатып алу ясалды.

**Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге процессларын цифрлаштыру**

2023 елда контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге (алга таба – ККЭ) процессларын цифрлаштыру кысаларында Татарстан сынау төбәге буларак түбәндәгеләрне апробацияләүдә катнашуын дәвам итте:

дистанцион тикшерүләр үткәрү өлешендә «Инспектор» мобиль кушымтасын;

төзелеш күзәтчелеге органнарының цифрлы вертикален булдыру өлешендә «Төзелеш күзәтчелеге» модулен;

административ җаваплылыкка тарту тәҗрибәсен камилләштерү өлешендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт карары» дәүләт мәгълүмат системасының «Административ эш башкару» модулен (алга таба – Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасы).

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталында (алга таба – Портал) юридик затның цифрлы профилен булдыру буенча сынау проектында республиканың катнашуы кысаларында Контроль (күзәтчелек) чаралары бердәм реестрыннан (алга таба – Бердәм реестр) мәгълүматны юридик затның шәхси кабинетына күчереп кертүгә апробация ясалды, аның

ярдәмендә эшкуар башкарыла торган эшчәнлеккә карата үткәреләчәк тикшерүләр, профилактик чаралар турында мәгълүмат алырга мөмкин.

Бүгенге көндә республика эшкуарларының контроль (күзәтчелек) органнары (алга таба – контроль-күзәтчелек органнары) тарафыннан планлаштырыла торган һәм хәзерге вакытта уздырыла торган тикшерүләр һәм профилактик чаралар турында, Порталдагы шәхси кабинетка кереп, «Контроль һәм күзәтчелек» дигән махсус бүлектән белергә мөмкинлеге бар.

2023 елда республика сынау төбәге буларак Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасына яңа функцияләр һәм сервислар кертү проектына кертелде. Проектта 5 контроль-күзәтчелек органы (Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе (алга таба – Дәүләт алкоголь инспекциясе), Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты) катнаша.

Апробация йомгаклары буенча Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасында түбәндәге функционал гамәлгә ашырылачак:

Порталдан файдаланып, шәхси кабинет аша юридик затлар белән хезмәттәшлек итү мөмкинлеге (тикшерү йомгаклары турындагы карар Порталдагы шәхси кабинетка җибәрелә, нәтиҗәдә эшкуар хәбәр ителгән дип санала);

Порталдагы шәхси кабинет аша профилактик визитка һәм консультациягә язылу мөмкинлеге;

үз-үзеңне тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләргә туры килү турында үз-үзеңне декларацияләү механизмын кертү (үз-үзен тикшерү нәтиҗәләре буенча югары бәя алган юридик затларның Порталдагы шәхси кабинетына рәхмәт хатлары киләчәк).

Бүгенге көндә республикада Порталдагы шәхси кабинет аша профилактик визитка һәм консультациягә онлайн язылу мөмкинлеге апробацияләнде һәм гамәлгә ашырылды. Мәсәлән, Дәүләт алкоголь инспекциясе хезмәткәрләре тарафыннан Порталдагы шәхси кабинет аша юридик затларның онлайн язылуы буенча 26 профилактик чара (24 профилактик визит, 2 консультация) үткәрелде.

Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасының берничә функциональ мөмкинлекләре, шул исәптән Порталдагы шәхси кабинетлардан файдаланып, 2024 елда гамәлгә ашырылачак.

**Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге реформасы**

Эшкуарларга уңай шартлар тудыру һәм бизнеска административ киртәләрне киметү мәсьәләсе республиканың барлык дәрәҗәләрдәге хакимияте өчен бик мөһим эшчәнлек юнәлеше булып тора. Әлеге максатлар өчен бизнес-бергәлек һәм контроль-күзәтчелек органнары белән хезмәттәшлек итү җайга салынды.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан контроль-күзәтчелек органнары эшчәнлегенә тикшерү кәгазьләрен куллану, кисәтү бирү, профилактик визит ясау, «беренче җәза буларак – кисәтү» механизмын куллану аша яңа профилактика инструментларын кертү эшләре алып барыла.

План буенча тикшерүләр гамәлдән чыгарылганнан соң, 2023 елда контроль-күзәтчелек органнары тарафыннан алар урынына профилактик визитлар каралды. Аларны үткәрү нәтиҗәлелеге бизнестан кире элемтә аша алынган нәтиҗәләр белән раслана.

Гомумән алганда, 2023 елда 1 983 профилактик визит ясалды, бу 2022 елга караганда 2,3 тапкырга күбрәк, 11 717 кисәтү бирелде. Чараларның гомуми санында профилактик чаралар өлеше 79 % (2022 елда – 74 %) тәшкил итте.

Контрольдә тотылучы затларның хокукый белемен арттыру, законнар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү турында мәгълүмат бирү һәм эшкуарлар белән нәтиҗәле «кире элемтә» механизмнарын булдыру эшләре оештырылды. Аңлату эшләре барлык кулланыла торган каналлар (социаль челтәрләрне, мессенджерларны һ.б. кертеп) буенча даими нигездә үткәрелә.

Эшкуарлардан кире элемтә алуны стимуллау һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлеге өлкәсендә уңай мәгълүмат кырын булдыру өчен мәгълүмат кампанияләре уздырыла. 2023 елда 15,4 мең чара, 2022 елда 8,6 мең чара уздырылды.

Мораторий кертелүне исәпкә алып, 2023 елда тикшерүләрнең гомуми саны, 2019 ел (шартлы репрезентатив) белән чагыштырганда, 3,5 тапкырга кимеде (2023 елда – 3 595, 2022 елда – 3 874, 2019 елда – 12 888 тикшерү).

Бизнес өчен административ киртәләрне киметү мәсьәләсе квартал саен Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил катнашында Татарстан Республикасы Прокуроры рәислегендәге эшкуарлар хокукларын яклау буенча ведомствоара эш төркеме утырышларында тикшерелә.

Барлык контроль-күзәтчелек органнары белән профилактик чаралар санын һәм төрләрен арттыру исәбенә кылу ихтималы булган бозуларны кисәтү буенча хезмәттәшлек алып барыла. Тикшерүләрнең кайбер күрсәткечләре арту сәбәпләре анализлана, административ басымны киметү буенча тәкъдимнәр эшләнә.

Әлеге эшнең нәтиҗәсе Татарстан Республикасының Административ басым индексындагы позициясендә чагыла, ул Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Б.Ю. Титовның ел саен Россия Федерациясе Президентына ясала торган илнең кече һәм урта эшкуарлык торышы турындагы докладында бирелә. 2022 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы әлеге индекста 4 нче урыннан 2 нче урынга күтәрелде. 2023 ел мәгълүматлары 2024 елның маенда басылып чыгачак.

Бизнеска законнарның гамәлдәге таләпләре турында оператив мәгълүмат бирү максатларында, республикада «Тикшерелгән бизнес» интернет ресурсы эшли. Ресурсның функционалы эшкуарларның хокукый грамоталылыгын арттырудан, шулай ук бизнес белән контроль-күзәтчелек органнары арасында диалог төзүдән гыйбарәт.

provbiz.ru сайтында түбәндәгеләрне табарга мөмкин:

законнарга кертелә торган үзгәрешләр турында актуаль яңалыклар;

ККО тарафыннан үткәреләчәк, катнашу мөмкинлеге булачак чаралар анонслары;

бертип бозулар һәм аларны булдырмау ысуллары турында 1 350 белешмәлек;

тормыш хәлләренә бәйле сорауларга 1 300 җавап.

Электрон тикшерүләр журналы тулаем республика буенча да һәм һәр эшкуарга карата да бизнеска туры килә торган административ авырлыкның реаль өлешен динамикада күрергә мөмкинлек бирә.

Тикшерүгә әзерләнү өчен эшкуар алдан ук интерактив сораштыру узарга һәм инспекторлар тарафыннан ачыклана алган хаталарын тест ярдәмендә билгеләргә мөмкин.

Хәзерге вакытта «Тикшерелгән бизнес» интернет ресурсын алга таба үстерү мәсьәләләре җентекләп өйрәнелә.

## ЦИФРЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ

Татарстанның мәгълүмат технологияләре тармагында 3 200дән артык компания эшчәнлек алып бара.

Глобаль чит ил корпорацияләренең китүенә бәйле рәвештә, үсеш фокусы үз илебезнең чишелешләренә юнәлде, төбәк компанияләренең компетенцияләре һәм яңа ИТ-стартаплар саны артты.

2023 ел йомгаклары буенча Татарстанда 1 230 меңнән артык чыбыклы Интернет абоненты (2022 ел дәрәҗәсенә карата 105 %) исәпләнә.

«Таттелеком» гавами акционер җәмгыятенең элемтә операторы GPON оптик файдалану технологиясе буенча Интернетка киң полосалы керү челтәрләрен булдыру эшен башкара. 2023 елда республиканың 62 меңнән артык йорт хуҗалыгы оптик ысул белән тоташтыру технологиясенә күчү мөмкинлегенә ия булды.

Мобиль Интернет абонентлары саны 4 980 мең кеше (2022 ел дәрәҗәсенә карата 108 %) тәшкил итте.

2023 елда инфраструктура үсешенә мобиль элемтә операторлары инвестицияләре күләме 2 млрд сумнан артык тәшкил итте.

2023 елда 1 000 нән артык мобиль элемтә база станцияләре файдалануга тапшырылды һәм яңартылды. 2024 елда шулай ук 984 мобиль элемтә база станциясе урнаштырылачак һәм яңартылачак.

Бер ел эчендә мобиль Интернет трафигы – 11 процентка, чыбыклы Интернет трафигы 20,8 процентка артты.

2023 елда цифрлы тигезсезлекне бетерү буенча федераль программа кысаларында база станцияләре Татарстанның 77 торак пунктында урнаштырылды. 2024 елда база станцияләрен тагын 87 торак пунктта урнаштыру планлаштырыла.

### Мәгълүмат системалары

2023 елдан, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов йөкләмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мөлкәтен исәпкә алу һәм аның белән идарә итү бердәм мәгълүмат системасын (алга таба – «Мөлкәт» системасы) булдыру чараларын гамәлгә ашыра.

«Мөлкәт» системасын кулланышка кертү җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә мәгълүматны җыю, системага салу, саклау, эшкәртү барышларын электрон формага күчерергә һәм республиканың дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү чараларында катнашучы субъектлар арасында, шул исәптән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү кысаларында, электрон хезмәттәшлекне оештырырга мөмкинлек бирәчәк.

2023 елда «Мөлкәт» системасын эшләүнең беренче чиратына караган 1 нче этабы төгәлләнде. 2024 ел планнарында беренче чират кысаларында аны тәмамлап кую.

Шулай ук 2023 елның өстенлекле проектларыннан берсе – Татарстан Республикасы экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасын (алга таба – «Экология» платформасы) эшләү.

«Экология» платформасы республика милкендәге табигать ресурслары белән эш итүгә, аларның ярлылануын кисәтү максаты белән рациональ файдалануны тәэмин итүгә, җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнар таләпләрен үтәвенә, тенденцияләрне фаразлау максаты белән әйләнә-тирә мохитнең торышын контрольдә тотуга бәйле процессларны комплекслы мониторинглау һәм алар белән идарә итү өчен билгеләнә.

2023 ел йомгаклары буенча «Экология» платформасының 80 проценты ясалды. «Җир асты байлыклары» ярдәмче системасы эшләнде, «Картография» модуле OpenStreetMap картографик нигезен кулланып гамәлгә ашырылды. «Экология» платформасы Татарстан Республикасы бердәм цифрлы платформасына (алга таба – Бердәм платформа) тест формасында урнаштырылды, аны Бердәм платформаның продуктив куллану формасына күчерү гамәлгә ашырыла. 2024 ел планнарында – «Экология» платформасын файдалануга тапшыру.

Мәдәният тармагын цифрлы трансформацияләү проектларын гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы порталын – мәгълүмат системасын эшләү дәвам итә, ул бердәм платформаны республиканың мәдәният маршрутларына онлайн язылу ысулы белән, мәдәният өлкәсендәге объектлардан һәм чаралардан файдалану мөмкинлеге белән гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

2023 елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Бердәм мәгълүмат системасын сынау версиясе эшләнде. Бу система – мәдәният учреждениеләренә йөрүчеләр санын арттыру, халыкны Татарстан мәдәнияте белән таныштыру, мәдәният хезмәтләре өлкәсендә барлык катнашучыларга мөмкинлекләр эзләү өчен бердәм тәрәзә. Аның ярдәмендә барлык мәдәният учреждениеләре, гидлар, халык-сәнгать һөнәрләре осталары, бизнес вәкилләренең эшләре автоматлаштырылачак.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының мәгълүмат системаларын сынау версияләре проекты ясалды һәм эшләнде.

2022 елдан Татарстан дүрт сынау төбәгенең берсе буларак (Краснодар крае, Пермь крае, Иркутск өлкәсе белән беррәттән) «Киңлек мәгълүматлары илкүләм системасы» Россия Федерациясе дәүләт программасын (алга таба – Киңлек мәгълүматлары системасы) гамәлгә ашыруда катнаша.

Әлеге ресурсны булдыру идарә карарларын кабул итү өчен мәгълүматлар җыю барышларын гадиләштерәчәк, территориаль планлаштыру һәм пространствоны үстерү, объектларның проектын ясау һәм аларны төзү мәсьәләләренә тагы да комплекслы якын килергә мөмкинлек бирәчәк.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының мәгълүмат системаларын («Татарстан Республикасы экология картасы», «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасының Татарстан Республикасы киңлек мәгълүматлары буенча төбәк порталы, «Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы, Казан шәһәренең комплекслы муниципаль геомәгълүмат системасы) Киңлек мәгълүматлары системасы белән берләштерү чаралары үткәрелде. Аларны көйләп, тест үткәрү тәмамланганнан соң мәгълүматлар федераль системага автоматлаштырылган режимда тапшырылачак.

## ДӘҮЛӘТ БЕЛӘН ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ ИДАРӘ ИТҮ

2023 елда федераль хакимият органнарының электрон төрдә күрсәтелә торган хезмәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырылды, шул исәптән:

Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының аеруча таләп ителә торган 4 хезмәтен, шул исәптән ана (гаилә) капиталы акчасы (акчасының бер өлеше) белән эш итү турында гаризалар кабул итү, иминият пенсияләре, җыелып барыла торган пенсия һәм дәүләт пенсия тәэминаты буенча пенсияләр билгеләү һ.б. өстәмә көйләү һәм модернизацияләү белән тәэмин ителде;

Федераль салым хезмәтенең 7 хезмәте буенча Бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша хезмәттәшлек итү һәм экран формалары гамәлгә ашырылды (салым органы хәбәрнамәсен бирү турында гариза; физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым ташламасы бирелә торган һәм сайлап алынган салым салу объектлары турында хәбәрнамә; транспорт салымы, җир салымы, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым ташламасы бирү турында гариза һ.б.);

«Транспорт чарасы мәҗбүри алынуга бәйле рәвештә транспорт салымын исәпләүне туктату турында гариза кабул итү» хезмәте гамәлгә ашырылды;

«8 яшьтән 17 яшькә кадәр балага ай саен бирелә торган акчалата түләү» хезмәте буенча электрон форма гамәлгә ашырылды;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган документларның һәм мәгълүматның электрон дубликатларына бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2021 елның 25 октябрендәге 1818 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә (алга таба – Күпфункцияле үзәк) «Документларның электрон дубликатларын Дәүләт хезмәтләре бердәм порталының шәхси кабинетына тапшыру» хезмәте гамәлгә ашырылды;

республиканың «Бердәм биометрик система» системасында биометрик шәхси мәгълүматларны теркәү буенча сынау проектында катнашуын тәэмин итү максатларында, Күпфункцияле үзәктә «Физик затны идентификация һәм аутентификация бердәм системасында теркәү өчен кирәкле белешмәләрне урнаштыру һәм яңарту, биометрик шәхси мәгълүматларны эшкәртү (җыю һәм саклауны кертеп) тәэмин итәлә торган бердәм мәгълүмат системасында биометрик шәхси мәгълүматларны урнаштыру» хезмәте гамәлгә ашырылды;

277 хезмәт дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр гамәли платформасына виджетлар рәвешендә чыгарылды;

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат үзәге» мәгълүмат системасы элементларына техник ярдәм күрсәтелде һәм модернизация ясалды;

Бердәм цифрлы платформа үзәгенең 37 модуле эшләп бетерелде;

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Аттестация», «Мәдәни мирас» бүлекләре нәтиҗәле кулланыла торган формага чыгарылды, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе бүлеге булдырылды.

Республика башкарма хакимият органнары һәм республика җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә

ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру өчен автоматлаштырылган мәгълүмат системасын модернизацияләү гамәлгә ашырылды.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы төрле тормыш хәлләренә караган электрон хезмәтләрнең һәм сервисларның 468 төрен берләштерә.

Әлеге порталда хезмәтләр күрсәтү өчен муниципаль ведомстволардан алына торган тулы һәм актуаль мәгълүматлар бирелә, хезмәтләр күрсәтү срокларына һәм сыйфатына оператив мониторинг ясау, ярдәм ресурста кире элемтәне анализлау мөмкинлеге бирелә, гариза бирү ысулына карамастан, дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең бердәм принцибын формалаштыра, болар хисап төзү өчен сарыф ителә торган хезмәтне һәм вакытны киметүгә, шулай ук кәгазь документлар әйләнешенә һәм курьер хезмәте эшенә финанс чыгымнарын азайтуга китергә.

**Күпфункцияле үзәкләр**

Татарстанда Күпфункцияле үзәкнең 60 бүлеге эшли, алар тарафыннан 285 дәүләт хезмәтләре, муниципаль хезмәтләр һәм хезмәтләрнең башка төрләре күрсәтелә. Көн саен КФҮ офисларында 14 меңнән артык гражданга хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла. 2023 елда КФҮ офисларында 5 миллионнан артык хезмәт күрсәтелде.

Хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә кертү һәм актуальләштерү процессларын тизләтү, шулай ук гражданнарга күбрәк күләмдә мөмкинлекләр бирү өчен 2023 елда КФҮ яңа автоматлаштырылган мәгълүмат системасына күчте. Әлеге күчүгә бәйле рәвештә, КФҮ гариза бирүчеләр өчен берничә өстәмә сервисны гамәлгә ашыра алды.

Күпфункцияле үзәкнең яңа сайты (mfc.tatarstan.ru) эшләтеп җибәрелде, аннан гражданнар КФҮ офисларында кешенең һәм эшнең күп булу-булмавын онлайн режимда карый һәм анда бару өчен кешесе һәм эше азрак булган офисны сайлый ала.

Гражданнарга уңайлы булсын өчен тагын «Татарстан Республикасы КФҮ» мобиль кушымтасы ясалды. Бу – офисларга баручылар өчен мәгълүмат бирә торган тагын бер ярдәмче җайланма.

КФҮ һәм муниципаль органнар арасында документлар алмашу буенча электрон хезмәттәшлеккә тулысынча күчүгә бәйле рәвештә, 2023 елда КФҮ вазыйфаи затның шәхси имзасы белән раслау таләп ителми торган хезмәтләр буенча муниципаль хезмәтләрне, муниципаль органның урнашу урынына яки мөрәҗәгать итүченең кайда теркәлүенә карамастан, экстерриториаль форматта күрсәтә башлады.

2023 елда Татарстанның күпфункцияле үзәгендә гамәлгә ашырылган җирле үзидарә органнары белән электрон хезмәттәшлекне оештыру проекты ел саен уздырыла торган «Россиянең иң яхшы күпфункцияле үзәге» бөтенроссия конкурсының «Күпфункцияле үзәкнең иң яхшы проекты» номинациясендә җиңүче дип игълан ителде.

**«Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасы**

Татарстанда «Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасының 5 төбәк проекты гамәлгә ашырыла: «Мәгълүмати иминлек», «Цифрлы дәүләт идарәсе», «Цифрлы технологияләр», «Мәгълүмат инфраструктурасы», «Цифрлы икътисад өчен кадрлар».

«Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасының төп

максаты – тормышның барлык өлкәләрендә: икътисад, эшкуарлык, дәүләт идарәсе, социаль өлкә һәм шәһәр хуҗалыгында цифрлы технологияләрне системалы үстерүне һәм гамәлгә кертүне оештыру.

2023 елда «Россия Федерациясе цифрлы икътисады» илкүләм программасының төбәк проектларын гомуми финанслау күләме 54,7 млн сум (планнан 100 %) тәшкил итте.

Барлыгы 11 күрсәткеч теркәлде, 2023 елда аларның план буенча ирешү дәрәҗәләре 100 процент булды.

**Программа тәэминатында импортны алыштыру**

Татарстан Республикасында кәрәзле элемтә җиһазын җитештерү белән «В.И. Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ шөгыльләнә. Эш КМТТУ-КАИның фәнни-техник партнеры, «Таттелеком» ГАҖнең реверс инжиниринг технологиясе буенча инфраструктура партнеры белән берлектә алып барыла.

Цифрлы икътисад үсеше өчен мәгълүмат саклау үзәкләре күп санда таләп ителә. «Атомдата-Иннополис» компаниясе Идел буе федераль округында мәгълүматларны эшкәртү һәм саклау буенча иң зур үзәк төзү проектын гамәлгә ашыра, ул «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорацииясенең мәгълүматларны эшкәртү һәм саклау үзәкләренең геологик бүленгән һәлакәткә чыдамлы челтәренә керә. Мәгълүматларны эшкәртү һәм саклау үзәгендә 2 мең урын булуга исәпләнде.

«МВС Индата» ҖЧҖ («МТС» ГАҖнең бүленеп чыккан компаниясе) Мәгълүматларны эшкәртү модульле үзәген проектлый, 2024 елда аны төзи башларга планлаштырыла.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте һәм муниципаль хакимият органнары тарафыннан Россиянең уйлап табучылары эшләгән программа тәэминатын куллану өстенлекле бурыч итеп билгеләнде.

2023 елның сентябрендә Казан шәһәрендә үткәрелгән Kazan Digital Week халыкара форумы кысаларында Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Русбитех-Астра» ҖЧҖ компаниясе арасында хакимият органнарындагы һәм бюджет учреждениеләрендәге барлык эш урыннарын Astra Linux Россия операцион системасына күчерү турында килешү төзелде.

2023 елның 27 ноябрендә «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформациясе үзәге» ДКУ, Социаль программаларга ярдәм фонды һәм ICL компанияләр төркеме арасында өчьяклы шартнамәгә кул куелды. Шартнамәдә дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, шулай ук аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә «Astra Linux Special Edition» махсус билгеләнештәге операцион система лицензияләрен файдалану хокукларын тапшыру күздә тотыла.

Татарстан Республикасында импортны алыштыру проектларын уңышлы гамәлгә ашыру һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен «Русбитех-Астра» ҖЧҖ һәм ICL компанияләр төркеменең уртак компетенцияләр үзәге төзелде. Ул үз илебезнең операцион системаларын инсталляцияләү эшләрен башкара һәм файдаланучыларга техник ярдәм күрсәтә.

Үз илебездә җитештерелгән һәм уникаль Россия программа тәэминаты урнаштырылган «Атом» инновацион электромобилен эшләү проекты, алдынгы

автомобильләр төзү компанияләрендә һәм ИТ-юнәлештәге лидерларда эш тәҗрибәсе булган халыкара уйлап табучылар һәм инженерлар командасын җәлеп итеп, «КАМА» АҖ тарафыннан гамәлгә ашырыла. Штаб-фатиры Чаллы шәһәренең «ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесендә урнаша. Хәзерге вакытта үз илебезнең операцион системасы, электр автомобиленең иярчен сервислары һәм программа тәэминаты эшләнә, партнерлар белән эш алып бару тәртибе җайга салына.

2023 елның 13 ноябрендә «АйСиЭл-КПО ВС» АҖ тарафыннан Россиядә электрон басма платаларны өске ягыннан монтажлау һәм исәпләү техникасы җитештерү буенча иң зур заводларның берсе ачылды. Яңа җитештерү Лаеш муниципаль районында «Иннополис» МИЗ территориясендә урнаша. Заводның мәйданы 8 мең кв. метрдан артык тәшкил итә, ул үзенә басма платаларны өске ягыннан монтажлау цехын, исәпләү техникасы җитештерүнең конвейер линияләрен һәм яңа тест лабораториясен берләштерә. Предприятиедә исәпләү техникасының 200дән артык төре: серверлар, мәгълүматларны саклау системалары, шәхси компьютерлар, моноблоклар, ноутбуклар, планшетлар һәм башка продукция чыгарылачак.

**Мәгълүмат иминлеге**

2023 елда Татарстанның мәгълүмат инфраструктурасының тотрыклылыгын тәэмин итү һәм куркынычсызлыгын арттыру кысаларында түбәндәге эшләр башкарылды:

мәгълүмат системаларын саклау өчен сертификацияләнгән чаралар кертелде, 30 төп системаның DDoS-атакасыннан саклану тәэмин ителде;

«Kazan Digital Wek 2023» Халыкара форумы кысаларында, Innostage IT-компаниясе белән берлектә, «Яңа заман киберкуркынычсызлыгы» секциясенең өч көнлек программасы оештырылды. Россиянең мәгълүмат иминлеге буенча алдынгы компанияләре-интеграторларыннан 60тан артык спикер-белгеч җәлеп ителде;

Татарстан Республикасында Россия Федерациясендә программа тәэминатының һөҗүмгә бирелә алу сәләте турында мәгълүмат бирә торган беренче программа эшләтеп җибәрелде (Vulnerability Disclosure Policy);

дәүләт хакимияте һәм муниципаль хакимият органнары хезмәткәрләре өчен «Мәгълүмат иминлеге» программасы буенча квалификация күтәрү курслары оештырылды. Татарстанның дәүләт һәм муниципаль хакимияте органнарыннан 3,5 мең хезмәткәр әлеге укуга җәлеп ителде;

Россия Федерациясе субъектларының мәгълүмат ресурсларына компьютер һөҗүмнәре салган зыяннарны бетерү буенча төбәк киберукулар үткәрелде;

башкарма хакимият органнары белгечләренә мәгълүмат иминлеге өлкәсендә, белем бирү программаларына нигезләнеп, белем бирү процессында үз илебезнең мәгълүматны саклый торган югары технологияле комплексларыннан һәм чараларыннан файдаланып, яңадан әзерләү курслары уздырылды.

Шулай ук Татарстан дәүләт органнары челтәрләрендә һәм мәгълүмат системаларында мәгълүмат иминлеген тәэмин итү максатларында, «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» ДУП тарафыннан, Компьютер һөҗүмен билгеләү һәм булдырмау системасыннан файдаланып, Татарстан Республикасы телекоммуникацияләре дәүләт интеграцияләнгән системасының тышкы периметрына мониторинг ясала һәм контрольдә тотыла.

Татарстан Республикасының мәгълүматларны эшкәртү буенча хөкүмәт үзәгенең мәгълүмат системаларында 12 млн артык шикле челтәр активлыгы теркәлде һәм нейтральләштерелде. Дәүләт мәгълүмат системаларындагы 2,4 меңнән артык серверның һөҗүмгә бирелә алу-алмау мөмкинлеге сканерланды.

**ИТ-бизнес өчен инфраструктура**

Казан һәм Чаллы шәһәрләрендәге технопаркның техник, эшлекле һәм бизнес инфраструктурасы стартап-проектларның һәм ИТ-компанияләрнең барлык үсеш стадияләрендә: югары технологияле продукт эшләү идеясеннән алып соңгы продуктны гамәлгә керткәнгә кадәр аларны комплекслы үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтү платформасын булдыра.

2023 елда «ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесенең 3 мәйданчыгы 99 % биләнде, 50 дән артык яңа ИТ-компания җәлеп ителде.

Старт-бергәлекне үстерү – «ИТ-парк» дәүләт автоном учреждениесенең өстенлекле бурычларыннан берсе. Әлеге бурычны хәл итү белән Бәшир Рамиев исемендәге ИТ-паркның Стартап Хабы – мәгълүмат технологияләре өлкәсендә smart-офис форматында гамәлгә ашырыла торган стартап-проектларны үстерү мәйданчыгы (1,1 меңнән артык кв.м) шөгыльләнә.

2023 елда «ИТ-парк» ДАУ тарафыннан 300 чара, шул исәптән республика, федераль һәм халыкара масштабтагы чаралар уздырылды, аларда Россия Федерациясенең 50 дән артык төбәгеннән, Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләреннән һәм Ислам илләре хезмәттәшлеге оешмасыннан барлыгы 31 меңнән артык кунак катнашты.

**КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ТОРУ**

Коррупция икътисад үсешенә, дәүләт идарәсе процессларына, хакимият белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләргә тискәре йогынты ясый торган тотрыксызландыру факторы булып тора.

Коррупциягә каршы тору буенча системалы чаралар икътисад үсешенә, сәламәт конкуренция тәэмин итүгә һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга уңай шартлар тудыра.

Бу эшчәнлек юнәлешенең актуальлеге турында ел саен халык фикерен социологик тикшерү нәтиҗәләре раслый. Шулай итеп, 2 ел рәттән соңгы ел дәвамында коррупция вәзгыятенә эләккән гражданнар өлеше республиканың 3 мең сораштырылган халкы арасыннан 9,9 % тәшкил итә.

Гражданнар җир кишәрлекләре бирүче һәм төзелешкә рөхсәт бирүче вазыйфаи затлар, югары уку йортлары мөгаллимнәре, предприятие җитәкчеләренең эшчәнлеге коррупция хәленә аеруча дучар дип саныйлар.

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшчәнлеге хокук саклау, контроль-күзәтчелек органнары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, бизнес берлекләр, фәнни берләшмәләр, иҗтимагый һәм дини оешмалар һәм гражданнарның үзләре катнашында комплекслы рәвештә алып барыла.

Республиканың дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары (50 зат – дәүләт хакимияте органнарында һәм 171 зат – җирле үзидарә органнарында) эшли.

Коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау максатларында федераль дәрәҗәдә дә, республика дәрәҗәсендә дә системалы эш алып барыла, ул коррупциячел ситуацияләр барлыкка килүгә китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны минимальләштерүгә, коррупциячел хокук бозуларны кылудан салынган зыяннарны киметүгә юнәлдерелә, шул исәптән әлеге өлкәдә законнарны камилләштерү юлы белән алып барыла.

Шулай итеп, 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде, анда чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен дисциплинар җаваплылыктан азат итү шартлары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләр һәм бу затка бәйле булмаган хәлләр (чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу һәм бурычларны башкару турындагы таләпләрне үтәү мөмкинлеген юкка чыгара торган гадәттән тыш һәм туктатып булмый торган хәлләр) аркасында булган очракларда йөкләмәләрне үтәмәү аңлатыла.

2023 елның 20 июнендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелде, аларда дәүләт хезмәткәренең дәүләт корпорациясе оешмасы, дәүләт компаниясе яисә гавами-хокукый компания булган, 50 % акцияләре (өлешләре) дәүләт корпорациясе оешмасы, дәүләт компаниясе яисә гавами-хокукый компания милкендә булган коммерция оешмасы идарәсендә әлеге оешманың коллегиаль идарә органы әгъзасы буларак Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан

билгеләгән тәртиптә түләүсез катнашу хокукын (әгәр федераль конституция законнары яисә федераль законнар белән башкасы билгеләнмәгән булса) билгели.

Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан үтәлеше контрольдә тотыла торган чикләүләр һәм тыюлар коррупциягә каршы тору турында, дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт турында федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына йөкләнде.

Хезмәткәрләр тарафыннан билгеләнгән чикләүләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше буенча үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча хокук бозулар өчен дисциплинар җаваплылыкка 12 дәүләт граждан хезмәткәре тартылды.

Бу уңайдан дәүләт граждан хезмәткәрләренең коррупциягә каршы аң-белем бирү мәсьәләләренә аерым әһәмият бирелә.

Хезмәткәрләр тарафыннан чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне контрольдә тоту эшен башкару нәтиҗәлелеген арттыру, алар тарафыннан коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән йөкләмәләр үтәлү коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы вазыйфаи затларның хокукый белемнәрен актуальләштерергә ярдәм итә.

2023 елда, әлеге максатларны күздә тотып, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә югары мәктәбе базасында дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр квалификациясен күтәрү өчен дистанцион һәм турыдан-туры катнашу формасында «Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау бүлекчәләре функцияләре» һәм «Коррупцияне профилактикалау нигезләре» дигән 2 программа гамәлгә ашырылды. Программалар түбәндәге блокларны үз эченә ала: коррупциягә каршы законнарда билгеләнгән коррупцияне профилактикалау буенча чаралар, йөкләмәләр, чикләүләр, тыюлар, коррупциягә каршы үз-үзеңне тоту стандартлары, коррупциягә каршы тору системасының гомуми тасвирнамәсе, дәүләт хакимияте органнарында һәм җирле үзидарә органнарында коррупция рискларын бәяләүне уздыру, социологик тикшеренүләр, республика дәүләт хакимиятенең һәм җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә карата коррупциягә каршы мониторинг ясау, керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерендагы йөкләмәләр турында белешмә тапшыру.

2024 елга куелган бурычлар арасында дәүләт хезмәткәрләренә, дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә коррупциягә каршы белем бирү максатларында кайбер коррупцияне профилактикалау мәсьәләләренә багышланган тематик брошюралар, истәлекләр (керемнәр турында белешмәләр тапшыру, чикләүләрне һәм тыюларны үтәү, мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу, коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру) эшләү зарурлыгын билгеләп үтәргә кирәк.

Методик материаллар әзерләү эше Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында, Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының Баш ветеринария идарәсендә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә башланды.

Коррупцияне профилактикалауда башкарма хакимият органнарының иҗтимагый оешмалар һәм башка гражданлык җәмгыяте институтлары белән, шул исәптән хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре һәм коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссияләре эшчәнлеге кысаларында хезмәттәшлеге мөһим роль уйный. Әлеге комиссияләрдә 42 иҗтимагый оешма вәкиле катнаша.

Шулай ук гражданнарга хокукый һәм коррупциягә каршы аң-белем бирү максатларында, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр һәм фәнни-гамәли семинарлар уздыру кебек хезмәттәшлек итү формалары актуаль булып тора. 2023 елда дәүләт хакимияте органнарында иҗтимагый оешмалар катнашында 155 чара уздырылды. Бу юнәлештә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе актив эш алып бара.

Татарстанда «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кабул ителде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланды), аның нигезендә икътисад һәм социаль өлкә белән дәүләт идарә итүен камилләштерүгә, шулай ук гражданнарга хокукый белем бирүгә һәм аларда коррупциягә каршы караш формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырыла.

Аерым алганда, дәүләт программасында махсус агитация һәм иҗтимагый, мәгълүмат һәм аң-белем бирү акцияләре циклын гамәлгә ашыру карала, ул җәмгыять тормышында һәм үсешендә тулысынча катнашуга, гражданлык активлыгына әхлакый әзер булган яшьләр буынын тәрбияләүгә юнәлдерелә, бу озак сроклы перспективадан чыгып караганда коррупция барлыкка килү шартларын минимальләштерә.

2023 елның декабрендә Коррупциягә каршы республика форумы үткәрелде. 150дән артык катнашучыны бер мәйданчыкта берләштергән чараның төп максаты – җәмгыятькә коррупциянең куркыныч булуын аңлауны һәм законнарда каралган барлык спектрдагы инструментларны аңа каршы куярга кирәклеген күрсәтү. Форумга республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе, җирле үзидарә органнары, коррупцияне профилактикалау чараларын гамәлгә ашыруда катнашучы мәгариф, фәнни һәм эшкуарлык берләшмәләре, иҗтимагый һәм яшьләр оешмалары вәкилләре чакырылды һәм спикер буларак чыгыш ясады. Форум «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының рәсми сайтында һәм youtube.com сайтында трансляцияләнде.

Коррупцияне профилактикалау чараларына республиканың төрле оешмалары кушыла. Мәсәлән, башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә (якынча 5 мең оешмада) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау буенча чаралар гамәлгә кертелде. Республиканың зур предприятиеләре коррупциягә каршы сәясәтне һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында нигезләмәләр расланды. Хезмәткәрләрнең законга каршы килә торган гамәлләрен кисәтү буенча комплаенс-системаны гамәлгә кертү буенча актив эшләр

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «КАМАЗ» ГАҖ, «СИБУР Холдинг» ГАҖ һ.б. тарафыннан алып барыла.

Ачык профилактика эшенә игътибар бирелә. 2023 елның декабрендә «СИБУР Холдинг» ГАҖ тарафыннан дәүләт органнары, көч структуралары һәм сәнәгать компанияләре вәкилләре катнашында комплаенс-чара уздырылды, аның барышында предприятиеләрдә коррупциягә каршы комплаенс процедураларын куллану, шулай ук бизнес һәм дәүләт диалогы нәтиҗәлелеген арттыру буенча төп аспектлар каралды. Чарада турыдан-туры һәм читтән торып 400 дән артык кеше катнашты.

Коррупциягә каршы сәясәтне тәэмин итүнең төп чараларыннан берсе – коррупциягә каршы аң-белем бирүне һәм пропаганданы оештыру. Массакүләм мәгълүмат чаралары җәмгыятькә коррупциянең яшерен механизмнары турында мәгълүмат бирү мөмкинлеген тәэмин итә, шулай итеп аның таралуын туктата.

2023 елда мөстәкыйль рәвештә яисә дәүләт хакимияте органы ярдәмендә коррупциягә каршы торуга багышланган 5 200 материал – программалар, фильмнар, басмалар эшләнде.

Коррупциягә каршы тору законнарының таләпләрен исәпкә алып, коррупцияне профилактикалау өлкәсендә түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру дәвам итәчәк:

дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт белән эш иткәндә, шулай ук дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алулар барышында республика программалары нигезендә, шул исәптән илкүләм проектлары кычаларында бирелә торган бюджет чаралары белән эш иткәндә гражданнарның тормыш дәрәҗәсен начарлануга китерә торган коррупциячел рискларны мониторинглау;

коррупциячел хокук бозуларны кылу сәбәпләрен бетерү буенча чаралар эшләү;

коррупциягә каршы тору, республика дәүләт хезмәткәрләрендә һәм халкында хокукый аң-белем бирүне оештыру һәм коррупциягә каршы караш формалаштыру өчен җаваплы затларның һөнәри компетенциясен күтәрү;

дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр, дәүләт вазыйфаларын һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан коррупциягә каршы тору максаты белән законнарда билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен тәэмин итү;

дәүләтнеке булмаган секторда коррупциягә каршы тору буенча корпоратив чаралар эшләү һәм кабул итү буенча республика оешмаларының эшен көчәйтү.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КОМИТЕТЛАРЫННАН ҺӘМ ДЕПУТАТ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕННӘН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА СОРАУЛАР ИСЕМЛЕГЕ БУЕНЧА МӘГЪЛҮМАТ

Икътисад, бюджет

**1. Татарстан Республикасы сәнәгатенең машина төзү тармагында һәм аграр комплекста цифрлаштыру торышы турында.**

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы нигезендә цифрлы нигезгә күчү Россия Федерациясен үстерүнең иң мөһим илкүләм максатларыннан берсе дип танылды.

Татарстан Республикасының машина төзү тармагын цифрлы нигезгә күчерү.

«Икътисадның төп тармакларының, социаль өлкәнең, шул исәптән сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәләренең, шулай ук дәүләт идарәсенең «цифрлы өлгергәнлегенә» ирешү» максатчан күрсәткечен үтәү өчен Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте каршындагы Аналитика үзәге белән берлектә сәнәгать тармагының «цифрлы өлгергәнлегенә» ирешүне характерлаучы тармак индексын хисаплау методикасы (алга таба – методика) эшләнде.

Методика нигезендә Дәүләт сәнәгать мәгълүмат системасы (алга таба –ДСМС) порталында «Сәнәгать предприятиесенең цифрлы паспорты» модуле гамәлгә ашырылды (алга таба – цифрлы паспорт), анда эшләгәндә сәнәгать секторы субъектлары үз предприятиеләренең цифрлаштырылуы индексы, сәнәгать предприятиесенең технологик карарларында цифрлаштыру дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлтелгән дәүләт ярдәме турындагы мәгълүмат белән танышу мөмкинлеге алалар.

2024 елның 24 гыйнварына ДСМС платформасында республиканың 98 предприятиесе цифрлы паспорт тутырды, шуларның 46-сы машина төзү тармагына карый.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан эре һәм урта сәнәгать предприятиеләренә ДСМС платформасында цифрлы паспортлар тутыру кирәклеге турында мәгълүмат бирү дәвам итә.

Республикада цифрлы нигезгә күчүдә лидерлыкны «КАМАЗ» ГАҖ тота, аның цифрлаштырылу дәрәҗәсе 82,75 % тәшкил итә. Алдынгылар унлыгына шулай ук түбәндәгеләр керә: «Преттль-НК» ҖЧҖ (71,82 %), «Түбән Кама механика заводы» ҖЧҖ (71,7 %), «Казан вертолет заводы» АҖ (59,21 %), «Римера-Алнас» ҖЧҖ (58,93 %), «Инженерлык-җитештерү үзәге» ҖЧҖ (57,63 %), «РУ-ИНЖИНИРИНГ» ФҖП ҖЧҖ (57,0 %), «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» АҖ (56,21 %), «РИАТ» ААҖ (54,3 %).

2023 елның икенче ярты еллыгында лидерлар төркемендә иң яхшы үсеш динамикасы «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыятендә һәм «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыятендә күзәтелде.

Цифрлы паспорт тутыруга кушылган предприятиеләр арасында алдынгылар сафында: «Түбән Кама механика заводы» ҖЧЖ, «Преттль-НК» ҖЧЖ, «Элекон» заводы АҖ, «Раритек-Технологии» ҖЧЖ, «Расплав» ҖЧЖ.

ДСМС мәгълүматларына караганда, машина төзү тармагы предприятиеләре түбәндәгеләрне кулланышка кертү буенча проектларны гамәлгә ашыра: җитештерүне технологик әзерләү системалары, ЧПУ җиһазлары белән идарә итү системалары, эшләнмәнең җитештерү циклы белән идарә итү, предприятие ресурслары белән идарә итү системалары, предприятие активлары белән идарә итү, эшләнмә турындагы мәгълүмат белән идарә итү һ.б. Шулай ук предприятие эшчәнлегенең ярдәмче процессларын бизнес-анализлау системасы – матди-техник тәэминат идарәсе, юридик идарә, финанслар, сату, логистика, персонал һәм мәгълүмат технологияләре белән идарә системалары кертелә.

Мәсәлән, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятендә җитештерүне әзерләү системасы, предприятие белән идарә итү системасы, җитештерү белән идарә итү системасы кертелде. Заводлар тарафыннан һәм «КАМАЗ»ның продукция китерүчеләре тарафыннан җитештерүне әзерләүгә идарә итү процессын автоматлаштыру җитештерүнең әзерлеге турында мәгълүматны онлайн режимда алырга мөмкинлек бирә, электрон технологик процесслар эшләнә һәм аларны цифрлы инструментлар ярдәмендә имитацияләп модельләштерү, технологик мәгълүматны электрон рәвештә җитештерү белән идарә итү системасына тапшыру башкарыла.

«Казан вертолет заводы» гавами акционер җәмгыятендә 2009 елдан эшләнмәләрне уйлап табу һәм җитештерүне конструкторлык-технологик әзерләү өчен файдаланыла торган система кертелде. Конструкторлык-технологик мәгълүмат белән идарә итүне тәэмин итү максатларында эшләнмә турында мәгълүматтан, шулай ук предприятиенең ИТ-хезмәтенең үзе уйлап тапкан кушымталарыннан торган ИТ-ландшафт булдырылды.

«Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыятендә Цифрлаштыру бурычларын үтәү өчен куркынычсызлык саклауның барлык заманча таләпләренә җавап бирүче заманча мәгълүмат системасы булдырылды. Хәзерге вакытта җитештерү белән оператив идарә итү функционалын файдалануга кертү, электрон архив һәм заказларның үз челтәр графигын төзү гамәлгә ашырыла.

«Элекон» заводы акционер җәмгыятендә эшләнмә турында мәгълүмат белән идарә итү һәм предприятие ресурсларын планлаштыру системалары гамәлгә кертелде.

«Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводында автоматлаштырылган проектлау системасы, ЧПУ станокларын программалаштыру системасы, инженерлык анализы системасы, җитештерүне автоматлаштырылган технологик әзерләү һәм эшләнмәләр турында мәгълүматлар белән идарә итү системасы кертелде.

Татарстан Республикасының аграр комплексында цифрлаштыру

Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы цифрлы нигезгә күчү буенча төбәкләрнең икътисадый рейтингында 1 нче урында тора. Республика бу урынны Мәскәү өлкәсе һәм Ямал-Ненец автоном өлкәсе белән бүлешә.

Цифрлы технологияләрне үстерү максатларында авыл хуҗалыгы тармагында Татарстан Республикасында 2022 елдан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының агросәнәгать комплексы дәүләт мәгълүмат

системасы – агросәнәгать комплексында катнашучылар өчен бердәм мәгълүмат платформасы эшли, ул «бер тәрәзә» принцибы буенча цифрлы, аналитик һәм финанс карарларын берләштерә.

Системага 9 модуль керә: «Шәхси кабинет», «Мәгълүмат җыю», «Үтәли аналитика», «Геомәгълүмати система», «Авыл хуҗалыгы җирләрен мониторинглау», «Файдаланылмый торган җирләрне мониторинглау», «Известьлашуны мониторинглау», «Терлекнең цифрлы паспорты».

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының агросәнәгать комплексы дәүләт мәгълүмат системасын гамәлгә кертү нәтиҗәсендә түбәндәгеләргә ирешелде:

республиканың авыл хуҗалыгы җирләрен паспортлаштыру төгәллеген 1,8 тапкырга арттыруга һәм 125 мең гектардан артык җирне әйләнешкә кертүгә;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне әйләнешкә кертү нәтиҗәсендә үсемлекчелек тармагыннан алынган керемне 3,5 млрд сумга арттыруга;

609,8 мең баш мөгезле эре терлекне идентификацияләргә;

анализлау һәм идарә өчен кирәкле мәгълүматның төгәллеген 2,5 тапкырга яхшыртуга;

66 хисапның эшләнү вакытын 17 көнгә азайтырга;

Шулай ук «Геомәгълүмат системасы» кертү нәтиҗәсендә кырлардан алынган мәгълүматны җыю һәм анализлау өчен сарыф ителгән вакытны киметүгә (80 процент), уңыш җыеп алу күләмен 5 процентка арттыруга, ашламаларга һәм үсемлекләрне саклауга тотыла торган чыгымнарны 10 процентка киметүгә ирешелде.

Республиканың цифрлы өлкәдә мәгълүмат алу ягыннан җитлеккәнлеген арттыру өчен «Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге» АҖ предприятиеләр җитәкчеләре өчен «АПКны цифрлы нигезгә күчерү» курсы эшләнде. Курс программасына АПКны цифрлы нигезгә күчерү нигезләре, хуҗалыкта цифрлы нигездә хисап алып бару үзенчәлекләре, җитештерү процессларын цифрлы нигезгә күчерү керә. Бүгенге көндә 244 предприятиедән 488 белгеч өйрәтелде.

Шулай ук авыл товар җитештерүчеләренең хезмәтен автоматлаштырып җиңеләйтүгә юнәлтелгән программа эшли. Ул авыл хуҗалыгында товар җитештерүчеләрнең илдә эшләнгән программа-аппарат комплексларын сатып алу, файдалануга кертү эшләрен бергәләп финанслауга юнәлтелгән.

## 2. Татарстан Республикасында технологик техник чаралар булдыру, җитештерү өлкәсен автоматлаштыру, роботлаштыру, интеллектуальләштерү максатларында цифрлы технологияләр кертү.

Цифрлаштыруны үстерү икътисадның барлык тармаклары өчен өстенлекле мәсьәлә булып тора. Предприятиеләр илдәге программа тәэминатын кулланууга кертү буенча эш алып бара.

Татарстан Республикасында бу юнәлештә берничә инвестиция проекты гамәлгә ашырыла.

2023 елда «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятендә 231 робот эшкә җигелде. Җитештерүне роботлаштыру стратегиясе нигезендә 2030 елда җитештерүдә 900 роботтан файдалана башлау планлаштырыла (роботлаштыру дәрәҗәсе – 10 мең кешегә якынча 280 робот). Бу эретеп ябыштыру эшләрендә роботлаштыруны 95 процентка, корпус эчендә һәм заводлар арасында транспорт логистикасын

комплекслы роботлаштырырга; эшләнмәләр әзерләү производствосын комплекслы роботлаштырырга (кендекләр, коелмалар, чүкеп, калыплап ясалган детальләр), җыю эшләрен  һәм ярдәмче операцияләрне роботлаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятендә төрле кулланыштагы пилотсыз йөк транспорты линейкасы эшләнде. Бу техниканың бер өлеше ябык территорияләрдә реаль шартларда эшләтеп сыналды. М-11 «Нева» трассасында эксперименталь-хокукый режим кертелү һәм КАМАЗның магистральләрдә кулланыла торган пилотсыз тарту җайланмалары гомум кулланылыштагы юлларда пилотсыз йөк транспорты өлкәсендә эшләнмәләрне, шулай ук чынлыктагы хәрәкәт шартларында пилотсыз йөк машиналары технологияләрен коммерциячел нигездә куллануны сынап карарга мөмкинлек бирә.

Якын киләчәктә компания, югары дәрәҗәдә  автоматлаштырылган транспорт чаралары «берлегенә» гражданнарга хезмәт күрсәтүнең һәркемгә яхшы таныш булган пассажирлар йөртү, йөк ташу кебек юнәлешләр белән бергә тар махсус техник чишелешләрне дә кертеп,  үзенең клиентлар базасын киңәйтәчәк.

«СОЛЛЕРС Алабуга» ҖЧҖ  тарафыннан перспектив проектлар гамәлгә ашырыла:

– автомобильләрнең электрон архитектурасы һәм транспорт өчен цифрлы идарә технологияләре өлкәсендә компетенцияләрне үстерү (тематик системалар, машина йөртүчегә ярдәм итү системасы, операция системасы өчен мультимедия җиһазлары, киберкуркынычсызлык, V2X технологияләре (Vehicle-to-Everytning – һәр нәрсәгә тулысынча тоташтырылган автомобиль);

– җиңел коммерция автомобильләренең электр модельләре өчен бердәй карарлар эшләү (тупланган бердәй модульләр, универсаль идарә ПО; зарядкага сарыф ителгән вакытны киметү өчен «алмаш» батареялар концепциясе);

– автоматлаштырылган проектлауның илдәге системаларына күчү.

Алга таба цифрлы «игезәк» технологияләре, автомобильгә хезмәт күрсәтү һәм клиентлар белән хезмәттәшлек процессларына идарә технологияләре (предикатив хезмәт күрсәтү, төзексезлек турында мәгълүмат бирү, запас частьләргә заказ бирү, хезмәт күрсәтүгә язу һ.б.), шулай ук «язылу буенча» автомобильнең төрле функцияләрен күрсәтү технологияләре кертеләчәк.

2023 елның маенда бортында илдә җитештерелгән, «КАМА» АҖ тарафыннан эшләнгән программа тәэминаты булган «АТОМ» перспективалы автомобиле проекты тәкъдим ителде. Татарстанның технологик стартапына «КАМАЗ» ГАҖ һәм «Росатом» атом энергиясе буенча  дәүләт корпорациясе ярдәм күрсәтте.

«АТОМ» – шәһәр электромобиле – универсаль платформага ия, гаилә өчен база версиясе 5 пассажирга исәпләнгән, такси, каршеринг һәм товарлар китерү хезмәтләре өчен модельләре каралган. Күпләп җитештерә башлау 2025 елга планлаштырылган. Шулай ук Чаллы шәһәрендә ИТ паркның    төп резиденты «КАМА» АҖ булачак яңа корпусын төзү каралган.

Нефть чыгару тармагында Цифрлы технологияләр кертү буенча алдынгылыкны «В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ тота. 2020 елның февралендә мәгълүмат технологияләре блогы белән идарә итүне камилләштерү һәм цифрлы инструментлардан киң файдаланып бизнес-процессларның нәтиҗәлелеген арттыру өчен «Татнефть – Цифрлы үсеш» структур бүлекчәсе булдырылды. Компанияне

цифрлы нигездә үстерүнең төп максаты – чыгымнарны киметү, конкурентлыкка сәләтне һәм инвестицияләрнең нәтиҗәлелеген үстерү.

Нефть химиясе тармагын цифрлаштыруда алдынгылар арасында – «СИБУР Холдинг» ГАҖ структурасына керүче предприятиеләр – «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ, «Казан органик синтез» ГАҖ, аларда Цифрлы нигезгә күчү программасы 2022 елда эшли башлады.

Цифрлы нигезгә күчүне гамәлгә ашыру өчен аерым бүлекчәләр – цифрлы офислар төзелде, аларның бурычы – эшчәнлекнең тәгаен структуралаштырылган берничә юнәлеше буенча цифрлы инструментларны куллануны кертү.

«СИБУР Холдинг» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан предприятиеләре производствосында төрле технологик өлкәләрнең цифрлы инструментлары кулланылышка уңышлы кертелә: алдынгы аналитика, процессларны цифрлаштыру, шулай ук Индустрия 4.0 өлкәсе инструментлары җыелмасы. Цифрлаштыру чыгымнарны, югалтуларны киметүгә, ахыргы продуктның ышанычлылыгын арттыру һәм сыйфатын яхшыртуга, шулай ук җитештерү процессларының куркынычсызлыгын һәм экологик чисталыгын тәэмин итүгә юнәлтелгән. Белгечләрнең хисаплаулары буенча, цифрлы инструментлардан файдалану «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционер җәмгыятенә 2026 елда 2,5 млрд сум тирәсе күләмдә икътисадый нәтиҗәлелеккә ирешергә мөмкинлек бирәчәк.

**3. Татарстан Республикасында энергетика тармагының торышы һәм аны яңартып кору мөмкинлекләре.**

Республиканың энергетика комплексы республиканың электр һәм җылылык энергиясе өлкәсендә ихтыяҗларын җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итә, сәнәгатьнең республикада урнашкан нефть чыгару, нефть эшкәртү, нефть химиясе һәм машина төзү тармаклары эре предприятиеләре өчен энергетика базасы булып тора.

Татарстанның энергосистемасында электр системасын җитештерүче өч эре оешма бар: «Татэнерго» АҖ, «ТГК-16» АҖ, «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ. Энергосистеманың гомуми электр энергиясе куәте, кече генерация объектларын исәпкә алып, 8,589 ГВт тәшкил итә, шул исәптән ЯЭС – 6,636 ГВт, ГЭС – 1,205 ГВт, бүленеш генерациясе – 767,506 МВт, җылылык куәте – 15 341 Гкал/ч.

«Челтәр компаниясе» АҖ республикада эре электр челтәрләре оешмасы булып тора. 2024 елның 1 гыйнварына 18 территориаль челтәр оешмасы эшли. «Татэнергосбыт» АҖ электр энергиясе белән гарантияле төстә тәэмин итүче булып тора.

2023 елда республиканың энергетика системасы кулланучыларны ышанычлы һәм куркынычсыз рәвештә электр энергиясе белән тәэмин итте. Бүленгән генерация объектларын исәпкә алып 28,2 млрд кВтч күләмдә электр энергиясе җитештерелде (2022 ел дәрәҗәсенә 100,4 %). Куллану күләме 33,4 млрд кВтч тәшкил итте (2022 ел дәрәҗәсенә 101,1 %). Республикада конкурентлыкка сәләтле электр энергиясенә кытлык саклана, ул Россиянең Бердәм илкүләм энергетика системасыннан күчерүләр хисабына каплана.

Барлык кулланучыларны ышанычлы төстә электр һәм җылылык энергиясе белән тәэмин итү өчен, энергетика тармагының конкурентлыкка сәләтле булуын арттыру һәм тотрыклы үсешен тәэмин итү өчен энергетика системасы производство

объектларын яңартып кору һәм яңа җитештерү объектларын эшләтеп җибәрү беренчел әһәмияткә ия.

2014 – 2018 елларда Татарстанда 4 эре энергетика станциясе яңартып корылды:

Казан ҖЭҮ-1 (246 МВт) һәм ҖЭҮ-2 (220 МВт) («Татэнерго» АҖ);

Казан ҖЭҮ-3 (394,4 МВт) («ТГК-16» АҖ);

«Түбән Кама ҖЭҮ» (350 МВт) («Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ).

Бу энергетика системасының куәтен 1,2 ГВт күләмендә арттырырга мөмкинлек бирде.

Түбән Кама ҖЭҮ (ПТК-2) («Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ) базасында җитештерү куәте 155 МВт газ-турбина җайланмасын төзү планлаштырыла.

Шулай ук түбәндәге кайбер проектларны гамәлгә ашыру каралган:

Казан ҖЭҮ-2 («Татэнерго» АҖ) пар казанын яңарту буенча (65 МВт, 2025 елда);

Түбән Кама ҖЭҮ-1 - дә гомуми куәте 467 МВт (2025-2027 елларда) һәм «ТГК-16» акционер җәмгыятенең Казан-ҖЭҮ-3 оешмасында җитештерү куәте 50 МВт (2025 елда) булган пар турбиналарын яңарту;

каты коммуналь калдыкларны термик зарарсызландыру заводының җитештерү куәте 55 МВт булган «АГК-2» ҖЧҖ төзү.

«Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте электр челтәрләре хуҗалыгын яңартып кору буенча эшләр дәвам итә. 2023 елда «Челтәр компаниясе» АҖ тарафыннан реконструкцияләнгәннән соң «Бөгелмә» 500 квалификация ярдәмче станциясендә 220 кВ ачык бүленеш җиһазлары, Казанда «Азино» 110кВ, Лаеш муниципаль районында «Каипы» ПС 35 кВ файдалануга тапшырылды.

Гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектлары арасында:

110 кВ «Су алу урыны» ярдәмче станциясен реконструкцияләү һәм «Сокуры» 110кВ подстанциясен төзү.

Өстенлекле юнәлешләрдән – углеродсыз энергетиканы, шул исәптән, җил энергетикасын үстерү. 2023 елда проектларны конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча Татарстан Республикасы территориясендә «Уралэнергосбыт» ҖЧҖ тарафыннан гомуми куәте 349 МВт тәшкил иткән җил электр станциясе төзү планлаштырыла (2028 елда кулланылышка тапшыру планлаштырыла).

2021-2022 елларда «Татэнерго» акционер җәмгыятенең Зәй ГРЭС-да җитештерү куәте 850 МВт булган пар-газ җайланмасын төзү проекты кысаларында эш алып барыла. Хәзерге вакытта әлеге проект буенча санкцияләргә бәйле рәвештә Россиягә җиһазларны төяп озатуда кыенлыклар туу сәбәпле төзелеш мәйданчыгын Түбән Кама ҖЭҮ-га күчерү мөмкинлеге карала (General Electric компаниясе инде акчасы түләнгән һәм төяп озатырга әзерләнгән җиһазларны Россиягә китертүдән баш тартты, бу исә Зәй ГРЭСын яңартып кору проектын тәмамларга мөмкинлек бирми). «Татэнерго» акционер җәмгыяте милкендә җитештерү куәте 236 МВт тәшкил иткән җиһаз булуы Чаллы ҖЭҮен яңарту проектын башлап җибәрергә мөмкинлек бирәчәк (2026 елда кулланышка кертү каралган). Әлеге мәсьәлә хәзерге вакытта федераль хакимият органнары белән бергәләп тикшерелә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Зәй ГРЭСын яңартып кору проектын Чаллы ҖЭҮгә күчерү күздә тотылган тиешле боерыгы булырга тиеш).

**4. Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан республика икътисадында кадрларга кытлыкның артуы сәбәпле күрелә торган чаралар турында.**

2023 елда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 18 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) үз эшен дәвам итте. Эш төркеме утырышлары кысаларында Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү чараларының үтәлүенә оператив мониторинг ясала, алар контрольдә тотыла, тиешле, шул исәптән халыкны эш белән тәэмин итү буенча чаралар күрелә.

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый тотрыклылыгын тәэмин итү буенча оператив штаб (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы белән расланды) тарафыннан социаль-икътисадый тотрыклылыкны саклауны һәм икътисадны үстерүне, аларның ярдәм чараларында катнашуын тәэмин итү буенча предприятиеләр белән килештерелгән эш оештырылды.

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Т.А. Голикова рәислегендә Хезмәт базарын торгызу мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме йөкләмәсен үтәү кысаларында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә оборона-сәнәгать предприятиеләрен (алга таба – ОПК) эшче кадрлар белән тәэмин итү буенча системалы чаралар гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы ОПК оешмаларында эшчеләргә ихтыяҗны мониторинглауны атна саен алып бару оештырылды. Мониторинг кирәкле компетенцияләргә һәм квалификацияләргә ия булган хезмәткәрләргә ихтыяҗны исәпкә ала.

ОПК предприятиеләренең кадрларга ихтыяҗын тәэмин итү буенча индивидуаль планнар төзелде, аларга эш белән тәэмин итү үзәгеннән куратор билгеләү, консультация һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү, вакансияләр ярминкәләре, эш бирүче көннәре уздыру, «Һәркем өчен эш урыннары» телеграм-каналында, Интернет челтәре сайтларында, һ.б. ОПК предприятиеләрен презентацияләү керә.

2022 елның сентябреннән «Россиядә эш урыннары» порталында предприятиеләрнең кадрларга ихтыяҗы турында мәгълүматны актуальләштерү өлешендә ОПК предприятиеләре белән эш алып барыла.

Вакансияләрне биләүне оештыру өчен Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе учреждениеләре ресурслары, һөнәри мәгариф оешмалары студентлары, шулай ук студентларның хезмәт отрядлары файдаланыла. Моннан тыш, сәнәгать предприятиеләренең вакансияләр ярминкәсенең төбәк һәм бөтенроссия этапларында катнашуы тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән ел саен республика икътисадының өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлеге раслана. Әлеге исемлек нигезендә Татарстан Республикасының 7 елга югары һәм урта һөнәри белемле кадрларны әзерләүгә дәүләт заказы һәм киләсе елга эшчеләргә һөнәри әзерлек һәм яңадан әзерлек бирү программалары эшләнә.

Республикада урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә дәүләт заказын формалаштыруга системалы караш икътисад тармаклары ихтыяҗына карап эшкә алуның контроль саннарын билгеләргә мөмкинлек бирә.

Республика предприятиеләренең фаразланган ихтыяҗларын исәпкә алып, ел саен һөнәри мәгариф оешмалары тарафыннан эшче профессияләр буенча һөнәри әзерлек һәм яңадан әзерлек бирү программалары буенча кадрлар әзерләү ихтыяҗы формалаштырыла. Бу эш халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, кадрларга заказ биргән предприятиеләр, шулай ук муниципаль берәмлекләр белән бергәләп башкарыла. Әзерлекнең күләме һәм юнәлешләре мәгариф оешмалары тарафыннан аз вакыт эчендә заказчыларның (предприятиеләр, эш белән тәэмин итү үзәкләре һ.б.) актуаль ихтыяҗларын исәпкә алып төзәтелергә мөмкин. Шул рәвешчә, 2023/2024 уку елына республиканың 15 көллиятендә һәм техникумында 13 һөнәр буенча кадрларга тизләтелгән әзерлек бирү буенча 550 бюджет урыны буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләме расланды.

Студентларны һәм укучы яшьләрне вакытлы, сезонлы һәм даими эш урыннарына урнаштыруны тәэмин итү, аларга Татарстан Республикасының хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган һөнәр үзләштерү мөмкинлеге бирү өчен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан ел саен студентларны әзерләү территорияләрен, һөнәрләр исемлеген һәм күләмнәрен билгели, шулай ук студентларны һөнәри белем алуга юллауны тәэмин итә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 мартындагы 436-р номерлы боерыгы).

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә студентларны эшче һөнәрләр буенча укыту өчен мәгариф оешмаларын сайлап алуны уздыралар һәм алар белән дәүләт контрактлары төзиләр.

2023 елда студент хезмәт отрядларында катнашкан 548 студент (Казан, Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск, Бөгелмә, Чаллы шәһәрләре) түбәндәге эшче һөнәрләре буенча укытылды. 2024 елда Казан, Әлмәт, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрендә студент хезмәт отрядларында катнашкан 700 дән дә ким булмаган студентны эшче һөнәрләр буенча укыту күздә тотыла.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Демография» илкүләм проектының «Эш белән тәэмин итүгә булышлык» федераль проекты кысаларында гражданнарның аерым категорияләрен һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын гамәлгә ашыруга коммерциячел булмаган оешмаларга федераль бюджеттан субсидияләр формасында грантлар бирү турында» 2021 елның 13 мартындагы 369 номерлы карары нигезендә яшәү урыны буенча эшкә урнаштыру үзәкләренә мөрәҗәгать иткән, ала торган һөнәрләре белемнәре буенча (белгечлекләре буенча) яраклы эш булмаган, урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф программалары буенча белем алуларын тәмамлаучы, 35 яшькә кадәр яшьләр арасыннан булган гражданнар укытыла.

2023 елда 8 276 кеше укып чыкты, шул исәптән хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган мәгариф программалары буенча 35 яше тулган 137 кеше.

2024 елда федераль бюджет хисабыннан Татарстан Республикасында аерым категория гражданнарны, шул исәптән 35 яшькәчә яшьләрнең аерым категорияләрен укытуны оештыру дәвам итә.

Укытуны федераль өч оператор башкара:

«Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия Халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе;

«Томск илкүләм тикшеренү дәүләт университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе;

«Һөнәри белем бирүне үстерү институты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе.

Уку курсын узарга теләгән гражданнар «Россиядә эш урыннары» эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә цифрлы нигезгә корылган бердәм платформа аша һөнәри белем яисә өстәмә һөнәри белем алырга теләүләре турында гариза бирәләр, анда алар катнашу категориясен, уку программасын һәм мәгариф оешмасын сайлыйлар.

Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү оешмаларында яшьләр белән эшләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары нигезендә расланган «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында башкарыла. Яшьләрне, шул исәптән һөнәри мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү максатында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыруга юнәлтелгән чаралар кысаларында аларны булган, резервка калдырылган эш урыннарына урнаштыруны оештыра.

2023 елда халыкны эшкә урнаштыру үзәкләренә 13,4 мең яшь граждан мөрәҗәгать итте, шуларның 10,1 меңе (мөрәҗәгать итүчеләрнең 75,4 проценты) эшкә урнаштырылды.

«Социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган гражданнарны һәм инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә урта һөнәри яисә югары белеме булган һәм эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны эшкә урнаштыру өчен, алар белеме һәм квалификациясе турында документлар тапшырган көннән бер ел эчендә, эш урыннарын резервлау башкарыла.

2023 елда әлеге категория гражданнар өчен 93 эш урыны резервланды, аларга 22 кеше эшкә урнаштырылды.

Яшьләрне эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү юнәлешләреннән берсе – эшсез гражданнарга, шул исәптән яшьләргә эшкуарлык эшчәнлеге башлау өчен дәүләт хезмәте күрсәтү. Бу юнәлештә 2023 елда 18 – 29 яшьтәге 161 гражданга дәүләт хезмәте күрсәтелде, 18–29 яшьтәге 57 граждан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге ярдәме белән эшкуарлык эшчәнлеген теркәде, аларга әлеге дәүләт теркәвен башкарган очракта бер тапкыр 145,1 мең сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелде.

Республиканың әйдәүче эш бирүчеләре белән бергәләп һөнәри белем бирү учреждениесе базасында кадрлар әзерләүнең резерв үзәкләре булдыру эше алып барыла, аларда җитештерү өлкәсенең ихтыяҗлары белән бәйле рәвештә

квалификацияле эшче кадрлар әзерләү билгеләнешендәге иң яхшы укыту-методика, кадрлар һәм матди-техник ресурслар тупланган.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2023 елда аерым категориядәге гражданнарны эш белән тәэмин итүне стимуллаштыру максатларында юридик затларга, коммерциячел булмаган оешмаларны кертеп, шәхси эшкуарларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2021 елның 13 мартындагы 362 номерлы карары нигезендә 2023 елда Татарстан Республикасында 30 яшькәчә 1,8 мең яшь граждан эшкә урнаштырылды. Гражданнарның аерым категорияләрен эшкә алуга субсидияләр программасы кысаларында дәүләт ярдәме эш бирүчеләргә эш тәҗрибәсе булмаган яшь гражданнарны, шул исәптән көллиятләрне һәм югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны эшкә алуга яхшы этәргеч бирде.

Эш бирүчеләр һәм Татарстан Республикасы һөнәри мәгариф оешмалары арасындагы тыгыз бәйләнеш эш урынын алдан билгеләп белем бирү турында килешүләр төзү тәҗрибәсен ел саен киңәйтергә мөмкинлек бирә. 2023 елда мондый килешүләр 1 194 кеше белән төзелгән.

Моннан тыш, 2023 елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри мәгариф оешмаларының беренче курсына кергән 365 кеше мондый килешүне машина төзү комплексы предприятиеләре («КАМАЗ» ГАҖ, «Туполев» АҖ филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы) белән төзеде.

Эш урынын алдан билгеләп белем бирү турында килешүләр төзү кысаларында ярдәм чаралары буларак эш бирүче-предприятиеләр тарафыннан студентларның укуы өчен түләнә, стипендия түләнә, практика узу вакытында хезмәт хакы бирелә, укуларын тәмамлаучылар эшкә урнаштырыла.

Мәгариф һәм сәнәгатьне нәтиҗәле берләштерү өчен Татарстан Республикасында предприятиеләрдә югары уку йортларының 122 база кафедралары эшләп килә, аларның төп өлеше сәламәтлек саклау һәм авыл хуҗалыгы өлкәләренә туры килә.

«Мәгариф һәм педагогика фәннәре» белгечлеге һәм юнәлешләре буенча югары белем бирү мәгариф программалары буенча укый торган һәм ким дигәндә 3 ел уку елы өчен арадаш аттестацияне уңышлы узган студентлар, шулай ук өстәмә гомуми белем бирү программалары юнәлешләренә туры килгән белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча югары белем бирү программалары буенча укый торган һәм арадаш аттестацияне уңышлы узган студентлар кимендә 2 ел укыганнан соң гомуми белем бирү оешмаларында эшләргә хокуклы.

Республиканың мәктәпләрендә һәм балалар бакчаларында 800 дән артык студент эшли (2022/2023 еллар уку елында – 445 студент). 2023 елның 1 сентябреннән көллиятләрнең чыгарылыш курслары студентларына шулай ук мәктәпләрдә эшләү рөхсәт ителә.

«Яшь һөнәр ияләре» һәм «Цифрлы нигездә белем бирү» федераль проектлары кысаларында 64 остаханә заманча җиһазландырылды.

Алдынгы һөнәри әзерлек үзәге һәм «ИТ-клуб» балалар өчен цифрлы нигездә белем бирү буенча 3 үзәк ачылды.

«Профессионалитет» федераль проектында республиканың 14 оешмасы җиңүче дип табылды. 7 укыту-производство һәм мәгариф кластеры булдырылды, 2024 елда тагын 7се ачылачак.

Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Премьер министры урынбасары Л.Р. Фазлыева тарафыннан 2023 елда республиканың эш бирүчеләре һәм мәгариф оешмалары вәкилләре белән Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы утырышларында кабул ителгән карарларны үтәү һәм кадрлар әзерләү өлкәсендә уртак эшне камилләштерү буенча киңәшмәләр уздырылды.

Республика предприятиеләрендә чит ил эшчеләрен эшкә җәлеп итү буенча уңай тәҗрибә тупланды. «КАМАЗ» ГАҖ  2021 елдан башлап Үзбәкстан гражданнарын эшкә ала. Чит ил эшчеләренә предприятие хезмәт урынында җайлашуда булышлык күрсәтә. Аларны өйрәтү, Торак урыннарга урнаштыру (тулай тораклар), социаль-көнкүреш шартларын бозмауларын күзәтеп тору һәм башка чаралар оештырылды.

2023 елның 18 декабрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Рәисеннән чит ил гражданнарын эшкә алуның нәтиҗәлелеген арттыру буенча Татарстан Республикасы предприятиеләре белән бергә эшләнгән тәкъдимнәр юлланды.

Мөрәҗәгать йомгаклары буенча бүгенге көндә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын оешкан төстә эшкә чакыру эшен киңәйтү кысаларында чит ил гражданнарының Россия Федерациясендә аерым бер эш бирүчедә оештырылган (максатчан) чакыру буенча эшкә алынуга хокукын раслый торган документның аерым бер формасын гамәлгә кертү механизмы эшләнә.

**5. Чит ил товарларын кертүне алмаштыру нәтиҗәләре һәм аларның республика икътисадына йогынтысы.**

Республикада читтән кертелгән продукцияне илдә җитештерелгән аналоглары, дустанә мөнәсәбәттәге илләр территориясендә җитештерелгән товарлар белән алмаштыру мөмкинлекләрен ачу, шулай ук яңа җитештерү объектлары оештыру, альтернатив логистика схемаларын төзү өчен системалы эш алып барыла.

Заказчы эре предприятиеләр белән республика җитештерүчеләренең хезмәттәшлеген җайга салу өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «СИБУР Холдинг» ГАҖ, «КАМАЗ» ГАҖ, «Ростсельмаш» ДК һәм башка компанияләр вәкилләре белән Товар китерүче көннәре,  түгәрәк өстәлләр даими төстә уздырыла.

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ТАНЕКО»  акционер җәмгыятендә яңа җиһазлар куюны дәвам иттерә. 2023 елның 22 декабрендә монда ачы газлардан чистарту катнаш җайланмасы, 4 нче су блогы, азот һәм һава компрессор станциясе эшләтеп җибәрелде.

«СИБУР Холдинг» ГАҖ тарафыннан катализаторлар, урта һәм аз тоннажлы проектларны эшләү алып барыла.

«Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционер җәмгыятендә «А» маркалы пропиленглеколь чыгару җайга салынды. Продуктның тәҗрибә-сәнәгать партиясе чыгарылды, фармацевтика сәнәгатендә, төзелеш, косметика һәм азык-төлек тармакларында  аңа ихтыяҗ зур.

«Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционер җәмгыяте үсешенең 2025 елга кадәр стратегик программасы билгеләнде, аның төп проектларыннан берсе – полимерлар җитештерелә торган ЭП-600 яңа олефин (этилен) комплексы (аны 2025 елда файдалануга тапшыру планлаштырылган).

2023 елның 17 декабрендә компанияне үстерүнең стратегик программасы кысаларында «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционер җәмгыятендә галобутил каучуклар җитештерү заводын, җитештерү куәтен елына 150дән 200 мең тоннага җиткереп, яңартып кору тәмамланды. Бу проектка 8 млрд сумлык инвестиция кертелде, 16 җайланма яңартып корылды һәм 6 җитештерү җайланмасы төзелде.

«Казан органик синтез» гавами акционер җәмгыятендә түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм эшкәртү заводында «В» реакторын, җитештерү куәтен елына 220 мең тоннага җиткереп, яңартып кору эше дәвам иттерелә (2025 елда тәмамлау каралган). 2023 елда түбәндәгеләрне яңартып кору буенча проектлар тәмамланды:

пропан чималын эшкәртү мөмкинлеген булдыру өчен этилен заводы цехлары;

җитештерү куәтен елына 100 мең тоннага җиткерү өчен поликарбонат заводын;

2023 елның 28 августында «Казан органик синтез» гавами акционер җәмгыятендә изопропилбензол җитештерү җайланмасын сафка бастыру тантанасы булды. Предприятиенең үзендә җитештерелә торган әлеге чимал поликарбонат эшләгәндә үзгәртеп корулар чылбырында беренче ярымпродукт булып тора.

2023 елда «Нәфис Косметикс» акционер җәмгыятендә «Көнкүреш химиясе һәм техник продукция җитештерүне киңәйтү һәм техник яңадан җиһазлау», «Татарстан Республикасының Зеленодольск районында склад комплексын төзү» проектларын гамәлгә ашыру дәвам итте.

KAMA TYRES компаниясендә җитештерүне яңартып кору, продукцияне төрләндерү эшләрен башкарыла, квадрацикллар өчен шиннар җитештерелә башлады.

2023 елның ноябрендә чит ил машиналарын алыштыра алырлык беренче К5 самосвалы җыелды. «КАМАЗ» ГАҖ, санкцияләргә каршы тотрыклы компонентлар базасына корып, характеристикалары яхшыртылган К5 автомобильләре модель рәтен киңәйтүне планлаштыра. 2023 ел башында яңартылган КАМАЗ-54901 тарту җайланмасы җыелды.

Предприятиенең фәнни-техник үзәге конструкторлары «Юпитер 30» дип аталган КАМАЗ-6559 самосвалын эшләделәр, бу – карьердагы эшләрне (вакланган тау токымнарын яисә мәгъдән ташу өчен) башкару өчен пилотсыз машина.

«КАМАЗ» ГАҖ кече тоннажлы йөк машиналары җитештерү буенча «Компас» проектын гамәлгә ашыра. Ул ике модельдән башланды: 9,5 тонналы «Компас-9» һәм 12,0 тонналы «Компас-12». Киләчәктә 5,5 тонналы, җыйнаграк һәм җиңелрәк «Компас-5» һәм 6 тонна массалы «Компас-6» модельләрен базарга чыгару планлаштырыла. Бу яңа төр машиналар арасында 3 тонналы «Компас-3» иң җиңеле булачак.

«Соллерс» компаниясе коммерциячел җиңел автомобильләр чыгара. 2023 елдан «Соллерс Алабуга» ҖЧҖ яңа линейканы туплау буенча масштаблы программа башлап җибәрде, аңа, детальләрне кою һәм механик эшкәртүне дә кертеп, 2 һәм 2,7 литрлы дизель двигательләре җитештерү, калыплау производствосы, электрон компонентлар, шасси элементлары, пластик эшләнмәләр җитештерүне туплау керә.

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасының «Соллерс» заводында 2023 елның 10 июлендә Иннопром-2023 сәнәгать күргәзмәсе кысаларында дизель двигательләрен серияле җитештерү башланды.

2023 елның 13 ноябрендә Лаеш муниципаль районындагы «Иннополис» махсус икътисадый зонасы территориясендә өстәл, мобиль һәм сервер системалары өчен күпкатлаулы төп платалар җитештерү буенча ICL компанияләр төркеме заводын ачу тантанасы булды.

«ЕлАЗ җитештерү берләшмәсе» АҖ ППС-5 платформасында скважиналар ремонтлау һәм бораулау өчен яңа модефикацияле АПР-80С агрегатын серияле җитештерә башлады, шассидагы өслек җиһазларын җыю һәм сүтү мобиль системалы АПРС-50С4 күтәрү агрегатын эшләде һәм җитештерде. Чит илләрдән кертелә торган товарларны алмаштыру һәм Россия җитештерүчесе дигән статус алу өчен, ЯМЗ-534 двигателен 880 моделендәге ELAZ-BL экскаватор-төягечләргә «бәйләү» эшләре башкарылды. Серияле җитештерү башланды.

«ХАИР» ААҖ 30 мең кв.метр мәйданда электр суҗылыткычлары җитештерү буенча завод төзү проектын (планлаштырылган туплану дәрәҗәсе – 60 проценттан артыграк) гамәлгә ашыра, 2024 ел ахырына кадәр файдалануга тапшыру планлаштырыла.

«Казан вертолет заводы» акционер җәмгыятендә Ансат вертолетын яңартып кору дәвам итә, илдә җитештерелгән ВК-650В яңа двигатель куелган вертолетның сынау өчен берәмлеге ясала һәм аны сынауга әзерлек бара.

«Туполев» АҖ филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводында Ту-214 очкычларын җитештерүне киңәйтү буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырыла, очкычларны цифрлы технологияләр кулланып җитештерүгә күчү, шулай ук сатылганнан соң эксплуатацияләүгә ярдәм күрсәтү заманча системасын булдыру башкарыла. Әлеге чаралар кысаларында җиһазларны яңарту һәм яңаларын сатып алу башкарыла, конструкторлык документларын цифрлаштыру һәм чит ил товарларын алыштыру буенча тәҗрибә-конструкторлык эшләре алып барыла.

«КМПО» АҖ газ-турбина двигателенең цифрлы «игезәген» булдыру программасын гамәлгә ашыра һәм аның беренче этабын – яну камерасын двигательнең кыш көннәрендә эш нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирерлек итеп яңартып коруны тәмамлады.

«Серго исемендәге завод» ПБ» АҖ лазер белән эретеп ябыштыру аппаратының яңа төрен файдалануга тапшырды. Ул төгәл үлчәмле югарырак сыйфатлы металл конструкцияләр ясарга һәм технологик катлаулы продукция җитештерүне сизелерлек гадиләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

Эшкуарларга ярдәм итү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм продукция сату базарларын киңәйтү максатында 2019 елның маеннан Республика маркетинг үзәге эшли, аның базасында чит ил товарларын алыштыру өчен мәгълүмати ресурс булдырылды. Анда ил күләмендә заказчылар кирәкле продукциянең аналогларын ил җитештерүчеләрендә яисә дустанә илләр җитештерүчеләрендә таба алачак.

Ресурсның функциональ 2 блогы бар, аларның базасына даими рәвештә мәгълүмат өстәлеп тора:

элегрәк сатып алына торган чит ил продукциясе исемлеге – элегрәк республика заказчылары санкцияләр керткән илләрдә сатып ала торган продукциянең 162,9 мең позициясе кертелгән;

алыштыру буенча тәкъдимнәр – Россия җитештерүчеләре бирә алачак продукциянең 255,6 мең позициясе кертелгән.

**6. Татарстан Республикасының «Автоматлаштырылган гадиләштерелгән салым салу системасы» һәм «Һөнәри эшчәнлек нәтиҗәсендә алынган керемгә салым» махсус салым режимнарын кертү буенча экспериментларда катнашуы йомгаклары турында**

Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең, Мәскәү, Мәскәү һәм Калуга өлкәләре белән беррәттән, махсус салым режимнарын урнаштыру буенча сынаулар уздыру өчен пилот төбәкләрнең берсе булып тора.

«Һөнәри эшчәнлек нәтиҗәсендә алынган керемгә салым» махсус салым режимын кертүне сынау Татарстан Республикасы территориясендә 2019 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр уздырыла («Һөнәри эшчәнлек нәтиҗәсендә алынган керемгә салым» махсус салым режимы кертү буенча сынауны уздыру турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон).

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һөнәри керемгә салым буенча керем салымы норматив буенча 63 % салынырга тиеш (37 % Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе федераль фонды бюджетына кертелә).

Татарстан Республикасының тупланган бюджетына әлеге салым 2019 елда 69,0 млн сум, 2020 елда – 169,7 млн сум, 2021 елда – 605,2 млн сум, 2022 елда – 942,8 млн сум, 2023 елда – 1 425,7 млн сум күләмендә тапшырылды.

Салымның күләме артуы нигездә салым түләүчеләрнең күбәюенә бәйле. Эшчәнлек алып бару өчен төбәк сыйфатында Татарстан Республикасында 2024 ел башында бу салымны түләүче 306 мең кеше эшчәнлек алып бара.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү турында» 2019 елның 28 мартындагы 233 номерлы карары белән расланган тәртип нигезендә акча җирле бюджетларга күчерелә (салым түләүчеләренең салым буенча бурычы булмаган җирлекләргә һәм шәһәр округларына).

2023 елда республикада «Һөнәри эшчәнлек нәтиҗәсендә алынган керемгә салым» махсус салым режимы кертү буенча сынауны уздыру турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законның төп нигезләмәләрен гражданнарга җиткерү буенча мәгълүмати кампания дәвам иттерелде.

2022 елның 1 июленнән 2027 елның 31 декабренә кадәр «Һөнәри эшчәнлек нәтиҗәсендә алынган керемгә салым» махсус салым режимы кертү буенча сынауны уздыру турында» 2022 елның 25 февралендәге 17-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Мәскәүдә, Мәскәү һәм Калуга өлкәләрендә, шулай ук Татарстан Республикасында «Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» (алга таба – САГС) махсус салым системасын кертүне сынау уздырыла.

2024 елның 11 гыйнварына республикада САГСтан файдаланучы 2 551 салым түләүче теркәлгән (Мәскәүдә – 7 478, Мәскәү өлкәсендә – 4 659, Калуга өлкәсендә – 522).

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына САГС буенча 54 % норматив буенча салым кертелергә тиеш (46 проценты – федераль бюджетка).

2022 ел өчен тупланган бюджетка 2,7 млн сумлык, 2023 елда 77,2 млн сумлык салым кертелде.

2023 елда САГС яңа махсус салым режимының өстенлекләрен бизнеска җиткерү буенча мәгълүмати эш алып барылды.

Махсус салымнар режимының өстенлеге һәм аларны куллануның үзенчәлекләре турында мәгълүмат ausn.nalog.gov.ru махсус сайтында урнаштырылган салым органнарына тарафыннан актуальләштереп торыла.

**7. Татарстан Республикасында 2024 елда Фәнни-технологик үсеш елын уздыру планында каралган чараларны гамәлгә ашыру барышы турында.**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 декабрендәге 1429 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» дәүләт программасы расланды. 2024 елда дәүләт программасын үтәүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан 1 581,6 млн сум каралган.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 30 декабрендәге 3268-р номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын уздыру планын гамәлгә ашыру кысаларында, 2024 елның 9 февралендә Россия фәне көнен бәйрәм итү һәм Татарстан Республикасы Фәнни-технологик үсеш елын ачуга багышланган тантаналы чара узды. Чарада Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министры В.Н. Фальков, Татарстан Республикасы Хөкүмәте, фәнни-педагогик, эксперт һәм эшмәкәрләр җәмгыятьләре вәкилләре катнашты.

2024 елның 17 февралендә «Россия» халыкара күргәзмә-форумы мәйданында «Фән һәм университетлар» тематик көне узды, аның эшлекле программасында Татарстан Республикасының фәнни-мәгариф комплексының вәкилләре катнашты. Республика стендында төбәкнең фәнни-технологик үсешенең төп йомгакларына багышланган берничә презентация тәкъдим ителде.

Моннан тыш, халыкта фәнне популярлаштыруга багышланган телевизион программалар һәм яшь буынга аталган фәнни-популяр тапшырулар әзерләнә.

Халыкара масштабта зур конгресс-күргәзмә чаралары әзерләнә: Россия венчур форумы һәм «Россия – ислам дөньясы» икътисадый форумы.

Параллель рәвештә республикада Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 30 декабрендәге 3227-р номерлы боерыгы нигезендә расланган Фән һәм технологияләр унъеллыгын уздыру буенча тематик план гамәлгә ашырыла. Анда фәнни тикшеренүләрне популярлаштыруга һәм яшь буынны тикшеренүләр процессына җәлеп итүгә юнәлтелгән байтак конгресс-күргәзмә һәм иҗтимагый-мәгърифәти чаралар каралган.

Республика шулай ук «Фән янәшә», «Галимнәр – мәктәпкә!», «Яле, фән», «Беләсеңме? Өйрәт!», «Фәннең көн кадагында», «Фәнни-техник эшчәнлектә катнашучы укучылар», «Фәнни-популяр туристлык» кебек Унъеллыкның федераль планына кертелгән башлангычларда һәм проектларда актив катнаша.

Фәнни-технологик үсеш елында тикшеренүләр һәм уйлап табулар үзәкләренең матди-техник базаларын ныгыту, Татарстан галимнәренең казанышларын популярлаштыру, шул исәптән моны «Приоритет-2030» стратегик академик

лидерлык программасында катнашучы республика югары уку йортларына мәгълүмати-методик һәм финанс ярдәме күрсәтү юлы белән башкару.

Республиканың биш югары уку йорты «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасында катнаша:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе;

«А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе;

«Казан милли тикшеренү технология университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;

«Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина академиясе» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе.

Татарстанда технологик эшкуарлык университет платформасын булдыру проекты гамәлгә ашырыла. Әйтик, Казан федераль университетында стартапларга комплекслы ярдәм күрсәтү өчен стартап-студия булдырылды. Программага һәм аны үстерүгә ярдәм итү өчен проектның федераль операторы – Инфраструктура һәм мәгариф программалары фонды тарафыннан бирелгән грантның күләме 3 ел дәвамында ел саен 100 млн сум тәшкил итәчәк.

Стартап-студиянең партнерлары – «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте, «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы, алар үз чиратларында Инфраструктур һәм мәгариф программалары фонды бүлеп бирә торган күләмдә бергәләп финанслауны тәэмин итәчәкләр.

Талантлы яшьләрне фәнни-техник иҗатка һәм технологик эшкуарлыкка җәлеп итүгә зур игътибар бирелә. 2023 елда Инновацияләргә ярдәм итү фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган «Студентлар стартабы» конкурсының 3 һәм 4 этаплары булды, аларның йомгаклары буенча Татарстан Республикасыннан 313 җиңүче билгеләнде, аларның инновация проектлары барлыгы 313 млн сумлык грант алды.

«Студентлар стартабы» конкурсында җиңү яулаган проектлар Татарстан Республикасы тармак министрлыклары (ведомстволары), югары уку йортлары һәм предприятиеләренә аларны киләчәктә гамәлгә ашыру өчен беркетелде. Барлыгы бу эштә республиканың 16 югары белем бирү мәгариф оешмасы, 15 министрлык, 180 предприятие катнаша.

Шулай ук югары технологияле, инновацияле урта һәм кече эшкуарлык субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы «Кече һәм урта эшкуарлык федераль корпорациясе» акционерлык җәмгыяте белән хезмәттәшлек итә (алга таба – «КУЭ» корпорациясе»).

Югары технологияле, инновацияле компанияләргә ташламалы кредитлар бирү программасы – ярдәм төрләренең тагын берсе. Ул Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан «КУЭ» корпорациясе», «КУЭ Банк» акционер җәмгыяте белән берлектә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урта һәм кече эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү Россия Банкы» акционер җәмгыятенә федераль бюджеттан югары технологияле, инновацияле кече һәм урта эшкуарлык субъектларына 2022–2024 елларда ташламалы ставка белән бирелгән кредитлар

буенча алынмый калган керемнәрен каплау өчен субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 25 мартындагы 469 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кредитларны «КУЭ Банк» акционер җәмгыяте еллык 3 процент ташламалы ставка белән бер заемчыга 500 млн. сум күләмендә бирә. 16 юнәлешкә ярдәм күрсәтү өстенлекле дип табылды. Алар арасында ясалма интеллект, аралашу технологияләре, әйберләр интернеты, яңа производство технологияләре, яңа материаллар һәм әйберләр технологияләре, генетика технологияләре, биотехнологияләр һәм фармацевтика юнәлешләре бар.

2023 елда әлеге программада катнашу кысаларында 8 республика компаниясе гомуми суммасы 1,1 млрд сумга кредит килешүләре төзеде. Татарстан Республикасы компанияләре шулай ук технологик компанияләрне Россиянең эре корпорацияләре таләпләренә туры килерлек итеп «үстерү» грант программасында актив катнаша. Аның операторы – «Инжиринг һәм инновациягә ярдәм үзәге» акционер коммерциячел булмаган җәмгыяте. «Үстерү» программасы Россия технологик компанияләренең Россия корпорацияләренең конкрет бурычларына (техник таләпләргә) туры китереп, чит ил товарларын алмаштыру һәм башка төрле инновацияле продукция җитештерүне эшләү һәм булдыру (киңәйтү) проектларына ярдәм итүне күздә тота.

2023 елда Татарстанның 5 компаниясе гомуми күләме 750 млн сумлык грант отты. Татарстан Республикасы, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән кала, «үстерү» программасында катнашу кысаларында ярдәм күрсәтелгән проектларны финанслау күләме буенча төбәкләр рейтингында 3 урынны алды.

**8. Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык тармагында мәгълүмат технологияләрен киңәйтү мөмкинлекләре турында.**

Рөхсәт бирү документларын алу процессын җиңеләйтү максатларында капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэминат челтәрләренә технологик тоташтыру кысаларында Бердәм килештерү кабинеты функционалы эшләнде. Бу исә челтәрләр уздыру проектларын килештерү вакытын киметергә, документларга электрон имза куярга, файллар тутырырга һәм җибәрергә, шулай ук килешү процессында хаталарны күрсәтергә мөмкинлек бирәчәк. Әлеге функционалны гамәлгә ашыру челтәрләр уздыруның бәясен санауда хаталар җибәрүне булдырмаска, дәүләт муниципаль хезмәтләр күрсәтү вакытын киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Бердәм килештерү кабинетында ресурслар белән тәэмин итүне килештерүче оешмалар түбәндәге җаваплар бирә алачак: трасса сузарга ярый/ярамый, яисә комментарий бирергә, шулай ук документка электрон имза куярга һ.б. Дәүләт хакимият органнары шулай ук «кызыл» сызыклар һәм генераль планнар турында кирәкле мәгълүматны бирә алачак.

Бердәм килештерүләр кабинетны эшләтеп җибәрү рөхсәт бирү документларын килештерүне электрон рәвешкә күчерергә мөмкинлек бирәчәк, шуның нәтиҗәсендә килештерүләргә азрак вакыт сарыф итү мөмкин булачак.

Шулай ук соратулар функционалы ярдәмендә проектлау алдыннан ресурслар белән тәэмин итүче башка оешмалардан челтәрләрнең булуы турында җавап алырга мөмкин булачак. Бу исә планлаштырылган чыгымнарны төгәлрәк исәпләргә һәм икътисадый куркынычларны киметергә мөмкинлек бирәчәк, ә трассаны башкарма

комитетлар белән килештерү функционалы дәүләт хакимияте органыннан ризалык алу вакытын киметәчәк.

Быел Бердәм килештерүләр кабинетын инженерлык-техник тәэминат челтәрләренә технологик кушылуга гаризалар бирү өчен ресурсны эшләү һәм эшләтеп җибәрү юнәлешен кертү планлаштырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 13 ноябрендәге 2882-р номерлы боерыгы нигезендә «Акыллы шәһәр» Татарстан Республикасы шәһәр хуҗалыгын цифрлаштыру буенча ведомство проекты паспорты расланды. Аның кураторы – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, катнашучылар – Әлмәт, Алабуга, Казан, Чаллы, Түбән Кама, Зеленодольск, Иннополис шәһәрләре башкарма комитетлары.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 4 августындагы 758 номерлы карары нигезендә «Locolo» дәүләт мәгълүмат системасы – торак мәсьәләләрен хәл итү, торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләреннән файдалану бердәм сервисы, шулай ук күршеләрнең социаль челтәре уңышлы эшләп килә.

Система республика халкының торак-коммуналь хуҗалык оешмалары, дәүләт хакимияте органнары һәм бизнес вәкилләре белән хезмәттәшлеге мөмкинлекләрен киңәйтү максатында эшләнде. Республикада яшәүчеләр «Локоло» дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә ТКХ һәм газ тәэминаты өчен комиссиясез түләү, үз Идарә компанияләренә һәм торак милекчеләре ширкәтенә цифрлы нигездә коммуналь ресурсларны санау приборлары күрсәткечләрен тапшыру, күпфатирлы йортлар милекчеләренең легитим гомуми җыелышларын электрон рәвештә уздыру мөмкинлеге ала.

Хәзерге вакытта «Локоло» дәүләт мәгълүмат системасына 314 идарәче оешма тоташтырылган. Быел «Локоло» дәүләт мәгълүмат системасын үстерү кысаларында түбәндәгеләр планлаштырыла:

күчемсез милекне арадашчыларсыз арендага бирү һәм сату уникаль сервисын эшләтеп җибәрү;

дәүләт торак-коммуналь хуҗалык мәгълүмат системасы белән кушылу (заявкалар, түләүләрне исәпләү, хисап приборлары күрсәткечләре);

«Локоло» дәүләт мәгълүмат системасы базасында дәүләт хезмәтләрен эшләтеп җибәрү (торак-коммуналь хуҗалык өчен түләүне каплау хезмәте).

**9. «Стратегия-2030» да каралган агломерацияләрне (Казан, Кама, Әлмәт) Пространствоны планлаштыру институты төзелү белән бәйле үстерү өчен күрелә торган чаралар турында.**

Казан агломерациясенең озак вакытка исәпләнгән тотрыклы пространство һәм социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү, агломерация составындагы территорияләрне пространство һәм социаль-икътисадый яктан үстерү өстенлекләрен һәм максатчан юнәлешләрен билгеләү максатларында 2023 елда «Татарстан Республикасы Пространствоны планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждение тарафыннан әлеге агломерацияне социаль-икътисадый һәм пространство ягыннан үстерү мастер-планы эшләнде, анда торак төзелеше барышында таләпләр һәм чикләүләр кертү күздә тотыла.

Әйтик, яңа төзелеш территориянең транспорт, инженерлык һәм социаль инфраструктура белән тәэмин ителгән булуы шартларында, күпфатирлы торак йорт төзелеше бары республиканың муниципаль районнары административ үзәкләрендә һәм транспорт һәм шәһәр төзелеше (баланс) модельләштерүенә нигезләнгән аерым үсеш нокталарында гына мөмкин була.

Әлеге мастер-планга нигезләнеп Казан агломерациясе составына кергән муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштырылуы һәм шәһәр төзелешенең зоналарга бүленүе документларына төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

Быел Кама агломерациясенең мастер-планын эшләү башкарыла. Әлмәт агломерациясенең мастер-планын эшләү 2025 елга планлаштырыла.

**10. Хәзерге заман шартларында республиканың тармак ресурс үзәкләренең эше, аларның укыту-методика базасын яңарту һәм аларны югары технологияле җиһазлар белән җиһазлау.**

Ресурс үзәкләрен булдыруның төп максаты – эш бирүчеләрнең хезмәт базарында конкурентлыкка сәләтле югары квалификацияле белгечләргә ихтыяҗын канәгатьләндерү.

Төбәк программалары кысаларында кадрларга заказ биргән предприятиеләрнең турыдан-туры катнашуында, республикада һөнәри мәгариф оешмасы базасында ресурс үзәкләре төзелә. Ул эш барышында биналарда капиталь ремонт ясала, өр-яңа укыту-лаборатория җиһазлары белән җиһазлау башкарыла.

Бүгенге көндә 47 ресурс үзәге эшли. Программа гамәлгә ашырылган нибары 9 ел эчендә аңа 8,2 млрд сум акча тотылды, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан 7,5 млрд сум бүлеп бирелде (уку биналарын һәм остаханәләрне, тулай торак биналарын төзекләндерүгә, җиһаз сатып алуга).

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен исәпкә алып, 2030 елга кадәр төзелә торган ресурс үзәкләрен 3 икътисадый зона: Казан, Кама һәм Әлмәт зоналарына бүлү планлаштырыла.

Казан икътисадый зонасында 23 ресурс үзәге бар, алар 14 юнәлеш буенча кадрлар әзерләү өчен төзелгән (ИТ-технологияләр, халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау, мәдәният, җиңел сәнәгать, машина төзү, педагогика, авыл хуҗалыгы, хезмәт күрсәтү, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык, транспорт, энергетика, нефть химиясе, электроника, радиотехника).

Кама икътисадый зонасында 8 юнәлеш буенча 14 ресурс үзәге эшли (машина төзү, нефть химиясе, педагогика, сәнәгать, авыл хуҗалыгы, хезмәт күрсәтү, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы, энергетика).

Әлмәт икътисадый зонасында 5 юнәлеш буенча 10 ресурс үзәге төзелде (машина төзү, нефть чыгару, сәнәгать, авыл хуҗалыгы, нефть һәм нефть продуктларын ташу).

## Социаль сәясәт

**11. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларының хокукларын, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучыларның кайда булуы һәм статусы (яраланган, һәлак булган, хәбәрсез югалган) турында үз**

**вакытында дөрес мәгълүмат алуга хокукларын тормышка ашыру өлешендә башкарыла торган чаралар турында.**

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатында хәбәргә чыкмаган (хәбәрсез югалган) хәрби хезмәткәрләрне һәм әсирлеккә эләккән хәрби хезмәткәрләрне исәпкә алу эше оештырылган.

Үзәк хәрби округы гаскәрләре командующие күрсәтмәләре нигезендә элемтәгә чыкмаучы һәм кайда икәнлеге билгеле булмаган махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары белән килеп туган хәл буенча аңлату эшләре алып барыла.

Әлеге мәсьәләне Үзәк хәрби округының иң югары җитәкчеләре һәм командование үз контроленә алды, хәрби хезмәткәрләрне эзләү мәсьәләсен хәл итү буенча барлык тиешле эшләр алып барыла.

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы җитәкчелегендә хәбәргә чыкмаучы хәрби хезмәткәрләрнең кайдалыгын мониторинглау һәм аларны эзләү буенча үзәкләр оештырылган.

Хәрби частьләр командованиесе хәрби хезмәткәрләрнең хәбәргә чыкмау очракларының барысы буенча да тикшерү эшләре алып бара, хәрби частьләрдә эзләүгә бәйле рәвештә документлар тупланмасы формалаштырыла, хәбәрсез югалучыларның карточкалары рәсмиләштерелә. Карточкаларга хәрби хезмәткәрне эзләү өчен кирәк булган төп мәгълүмат кертелә. Бер ай узганнан соң муниципаль берәмлек хәрби комиссариатына хәбәргә чыкмаган хәрби хезмәткәр турында хәбәрнамә килә. Хәбәрсез югалган хәрби хезмәткәрнең туганнарына хәрби хезмәт өчен түләнә торган хезмәт хакы күләмендә акчалата түләү бирүгә документлар әзерләнә һәм хәрби частькә җибәрелә.

**12. Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча алып барылган эш турында.**

2023 елда Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан 78 547 граждан мөрәҗәгате карап тикшерелде (2022 елда – 81 558 мөрәҗәгать), 61 545 мөрәҗәгать контрольгә алынды. 1 717 мөрәҗәгать урыннарга барып тикшерелде. Интернет-кабул итү бүлмәсе ярдәмендә электрон рәвештә 21 943 мөрәҗәгать килде, гражданнардан килгән 2 180 мөрәҗәгать урыннарга барып тикшерелде. 8 360 кеше шәхсән кабул ителде, шулардан 1 106 кеше – шәхсән министрлык һәм ведомство җитәкчеләре тарафыннан кабул ителде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү максатларында 2023 елда министрлыклар һәм ведомстволар видеоконференция системасы ярдәмендә саклана торган каналлар буенча гражданнарны кабул итүне оештыру мөмкинлегеннән файдалануны дәвам итте. Ел дәвамында 141 видео-кабул итү оештырылды.

Республика дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләре тарафыннан гражданнарны кабул итүнең бердәм көне билгеләнде – һәр сишәмбе көнне 14 сәгатьтән соң. Бу көнне министрлык һәм ведомстволарга 2 257 кеше мөрәҗәгать итте, шулардан 824 – җитәкчеләр тарафыннан кабул ителде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре социаль өлкәдәге вазгыятьнең билгесе буларак халык активлыгының төп сәбәпләрен күрсәтүче мөһим мәгълүмат чыганагы булып

тора. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшне нәтиҗәле оештыру халык мәнфәгатьләрен канәгатьләндерергә, социаль өлкәдә киеренкелекне киметергә һәм хакимият органнарының абруен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Дәүләт органнары Интернет челтәрендәге рәсми сайтларында гражданнардан кабул ителгән мөрәҗәгатьләрне анализлый, шулай ук билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы аеруча актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә.

Граждан мөрәҗәгатьләре белән эшләүне оештыруга контрольне көчәйтү һәм аларны шәхсән Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе тарафыннан кабул итүне оештыру максатларында ел саен урыннарга барып республика башкарма хакимияте органнарының «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль законнар, шулай ук «Татарстан Республикасында граждан мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәүгә кагылышлы эшчәнлеген бәяләү буенча чаралар уздырыла, аларның нәтиҗәләре урыннардагы җитәкчеләргә, ә хокук бозу очраклары булганда – аларны бетерү буенча тәкъдимнәр белән бергә җибәрелә.

**13. Чит ил студентларының һәм чит илдән күчеп килүчеләрнең балаларының иҗтимагый мохиткә социаль һәм мәдәни яраклашуы максатларында алып барыла торган эш турында.**

2023/24 уку елында Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында ерак һәм якын чит илләрдән, аерым алганда Таҗикстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан һәм Әрмәнстаннан 3 300 бала белем ала. Казан һәм Чаллы шәһәрләрендәге белем бирү оешмаларында чит илдән күчеп килгән балалар саны аеруча күп ( 1 550 кеше).

Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында балигъ булмаган чит ил гражданнарының социаль мохиткә җайлашуын һәм психологик яраклашуын тәэмин итү буенча эш Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 20 декабрендәге 3718-р номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру буенча 2022–2025 елларга чаралар планы һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык тарафыннан 2022 елның апрелендә расланган 2025 елга кадәрге чорда мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомуми белем бирү, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү, урта һөнәри белем бирү, югары белем бирү программалары буенча белем алачак балигъ булмаган чит ил гражданнарының социаль мохиткә җайлашуы һәм психологик яраклашуы буенча чаралар комплексы нигезендә тормышка ашырыла.

2023 елның ноябрендә рус телен начар белүче чит илдән күчеп килгән балалар саны аеруча күп булган сыйныфларны билгеләү максатында мониторинг уздырылды.

Аның йомгаклары буенча чит илдән күчеп килгән балаларның 10 проценты рус телен бик начар һәм канәгатьләнерлек дәрәҗәдә белүе һәм шуның нәтиҗәсендә аларга мәгариф программасын өйрәнү зур авырлык белән бирелүе ачыкланды.

2023 елның 28 ноябрендә Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р. Фазлыева, чит илдән күчеп килгән балалар саны аеруча күп булган

мәктәп директорлары һәм сыйныф җитәкчеләре катнашында киңәшмә уздырылды. Өлгерешнең түбән булуының төп сәбәпләре булып элек Россия Федерациясеннән читтә белем алган мәктәп укучыларының иң баштан ук уку-укыту планының төп предметлары буенча белемнәренең түбән булуы, яхшы укуга һәм өстәмә белем алуга кызыксынулары булмавы тора.

Гомуми белем бирү оешмаларында белгечләр тарафыннан чит илдән күчеп килгән балалар белән балаларга һәм аларның әти-әниләренә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү, социаль мохиткә җайлашуда булышлык итүгә юнәлтелгән эш алып барыла.

Уку елы дәвамында рус телен, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм йолаларын өйрәнү буенча индивидуаль эш алып барыла, балалар актив рәвештә мәктәптә уздырыла торган чараларда (осталык дәресләре, тематика күргәзмәләр, спорт һәм мәдәни бәйрәмнәре һ.б.) катнашуга җәлеп ителә.

Мәгариф оешмаларында чит илдән күчеп килгән балаларга спорт клубларына һәм мәктәп театрларына йөрү, шулай ук балаларга өстәмә белем бирү программалары буенча укырга тәкъдим ителә.

Мәгариф оешмалары педагоглары тарафыннан ата-аналар белән эш алып барыла, аңа баланың үсеше һәм тәрбияләүгә, һөнәр сайлавы, социаль мохиткә җайлашуы, мәктәптән тыш чараларда катнашуы, баланың мөстәкыйль рәвештә уку программасын үзләштерүе мәсьәләләренә кагылышлы шәхси консультацияләр уздыру, социаль-хокук мәсьәләләре буенча консультацияләр бирү һәм башка эшләр керә.

2023 елның 14 декабрендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Алгоритм» технологик лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмасы базасында чит илдән күчеп килгән балаларның ата-аналары өчен түгәрәк өстәл уздырылды. Ел дәвамында хокук саклау органнары, республика башкарма хакимияте органнары, милли-мәдәни мохтариятләр, дини оешмалар катнашында миграция сәясәтен гамәлгә ашыру, чит илдән күчеп килүчеләр арасында хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәл утырышлары үткәрелде.

2023 елның 20 декабрендә Чаллы дәүләт педагогика университеты базасында «Мәгариф һәм мәдәниятара бәйләнешләр: гореф-гадәтләр һәм хәзерге заман» дип аталган бөтенроссия фәнни-гамәли конференция уздырылды. Анда секцияләр эше кысаларында мәгариф оешмалары укытучылары һәм педагоглары осталык дәресләре үткәрелде, алар заманча мәгариф киңлекләрендә балаларның мультилингваль үсеше өлкәсенә, Россия мәктәпләрендә чит илдән күчеп килгән балаларны укытуга, мәдәниятләр һәм сәнгатьләр бәйләнешләре аша баланың гармонияле шәхес булып формалашуы мәсьәләләренә кагылды.

2023 елның 25 декабрендә «Балигъ булмаган чит ил гражданнарының мәгариф өлкәсенә җайлашуы һәм яраклашуы: проблемалар, тенденцияләр, үсеш перспективалары» темасына психологик-педагогик, медицина һәм социаль хезмәтләр оешмалары җитәкчеләре өчен республика семинар-практикумы уздырылды.

Мәгариф оешмалары чит илдән килгән балалар белән эшләгәндә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының методик тәкъдимнәренә таяна:

чит ил гражданнары булган балаларның психологик яктан куркынычсызлыгы, социаль күнекмәләр алуы һәм мәдәни өлкәгә яраклашуы ягыннан белемгә булган аерым ихтыяҗларын бәяләү программасы;

чит ил гражданнары балаларына белем бирү, аларга социаль һәм мәдәни мохиткә җайлашу, тел өйрәнү процессларында психологик-педагогик ярдәм программаларын үтәү буенча методик тәкъдимнәр;

чит ил гражданнары балаларына белем бирү, аларга социаль һәм мәдәни мохиткә җайлашу, тел өйрәнү процессларында психологик-педагогик ярдәм программалары инструментлары пакеты.

Педагог-психологлар уен терапиясе, арт-терапия ысулларын кулланып, стресс хәлен, дулкынлану һәм курку хисләрен бетерүгә юнәлтелгән шәхси консультацияләр һәм төркем дәресләре уздыралар.

Балигъ булмаган чит ил гражданнарына «Инофон-балаларның тел ягыннан һәм социаль-мәдәни җайлашуы», «Минем дөньям – ул...» мәгариф-мәдәният учреждениеләре кысаларында чит илгә күченеп килергә мәҗбүр булган 6–15 яшьлек мигрант балаларга психологик ярдәм күрсәтү» программалары буенча психологик-педагогик ярдәм чаралары күрсәтелә.

Мәгариф оешмалары тарафыннан социаль-мәдәни өлкәдә белемнәр алу, чит ил мәдәниятен өйрәнү, конструктив аралашу тәҗрибәсен формалаштыру тәэмин ителү гомуми һәм шәхси характердагы профилактика чараларының нигезен тәшкил итә, алар дәресләр вакытында (уку предметлары программалары, курслар, дисциплиналар (модульләр), башка компонентлар (рус теле, әдәбияты, тарих, география һәм башкалар) һәм дәрестән тыш эшчәнлек программалары кысаларында тормышка ашырыла:

спорт юнәлеше (футбол, волейбол, баскетбол, шахмат, өстәл теннисы);

сәнгать юнәлеше («Тылсымчы», «Оригами», «Вокал», «Дөнья халыклары биюләре», «Илһам» театр түгәрәге);

социаль юнәлеш («Күңелле инглиз теле», «Экос», «Мөһим әйберләр турында сөйләшү», «Һөнәрләр дөньясы», «Проект эшчәнлеге», «Функциональ белемнәр», «Әйләнә-тирә дөнья», «Толерантлык дөньясы», «Мәктәптә толерантлык атналыгы», сәламәт яшәү рәвеше формалаштыруга юнәлтелгән мөһим рухи кыйммәтләрне һәм социаль юнәлешләрне үстерү буенча дәресләр);

«Әдәплелек әлифбасы» дигән рухи-әхлакый юнәлеш;

«Кызыклы грамматика», «Информатика дөньясы», «Робототехника», «Инглизчә сөйләшәбез», «Лингво-инженерлык белеме» дигән фәнни-белем бирү юнәлеше.

2024 елның 1 февраленә Татарстан Республикасында югары белем бирү мәгариф программалары буенча 15 якын чит илдән һәм 109 ерак чит илдән 22 074 чит ил гражданы белем ала.

Чит ил студентларының республиканың иҗтимагый мохитенә җайлашуын, аларның социаль һәм мәдәни яраклашуын тәэмин итү, яшьләр арасында мәдәниятара бәйләнешләрне үстерү, чит ил студентлары белән профилактика һәм тәрбия эшен алып бару максатларында «2017 – 2025 елларга Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы чит ил студентларының иҗтимагый һәм социаль мохиткә җайлашуын тәэмин итү буенча чаралар планы (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2017 елның 28 февралендәге 340-р номерлы боерыгы) (алга таба – План) эшләнде.

Планда чит ил студентлары белән эшләүнең 5 юнәлеше каралган: чит ил студентлары контингенты хәрәкәтен исәпкә алу, белем алучылар белән мәгълүмати-аңлатма эшләре алып баруны оештыру, чит ил студентларына кураторлык хезмәтен булдыру, чит ил студентларының мәдәни-массакүләм, спорт, мәгариф һәм башка чараларда катнашуы, чит ил студентларының студент клублары эшчәнлеге мәсьәләләре.

Көн саен югары уку йортларында профильле структур бүлекчәләр чит ил студентлары белән эшли, алар чит ил студентларының исәбен алып бара, аларга чит илгә күчү һәм белем алу белән бәйле сорауларда ярдәм күрсәтә. Мәгариф оешмаларында чит ил студентларын студентлар мохитенә җайлаштыру буенча эшне чит ил студентлары белән эшләү бүлекләре башкара, алар чит ил гражданнарына тел өйрәнергә булыша һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтә. Студентлар үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (чит ил студентлары һәм аспирантлары берлекләре, чит ил студентлары ассоциациясе) эшли.

Чит ил студентлары белән даими элемтә тоту максатларында россияле һәм чит илдән килеп укучы 3–5 курс студентлары арасыннан җаваплы кураторлар билгеләнде. Кураторларның төп эше – чит ил студентларына белем алу процессына җайлашуда ярдәм итү, аларның яшәү шартларын контрольдә тоту, системалы рәвештә аларның уку һәм көнкүреш шартларын мониторинглау. Ел саен чит ил студентлары кураторлары белән мәгълүмати эш кысаларында югары уку йортларында иҗтимагый берләшмәләр, милли-мәдәни берләшмәләр, кызыксынган министрлыклар һәм ведомстволар катнашында 50 гә якын мәгълүмати очрашу булып узды.

Ел саен чит ил студентлары белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару кысаларында 7 меңгә якын чит ил студенты катнашында 300 лекция уздырылды. Утырышларга Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе вәкилләре, психологик үзәкләр хезмәткәрләре, министрлык һәм ведомство, дини һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре чакырыла.

Чит ил студентлары өчен план кысаларында ел саен 20 гә якын республикакүләм мәдәни, мәгариф һәм спорт чарасы, мәсәлән, төрки яшьләр фестивале, чит ил студентлары арасында рус теле буенча республика олимпиадасы, «Халыклар дуслыгы» чит ил студентлары өчен спартакиада, «Чит ил студенты көне» югары уку йортлары арасындагы фестиваль, «Татарстанның мәдәни күптөрлелеге» республика яшьләр фестивале һәм башкалар уздырыла.

Чит ил студентлары белән чаралар шулай ук республиканың яшьләр белән эшләү оешмалары белән берлектә уздырыла. Системалы рәвештә уздырыла торган чараларның оештыручысы булып «Татарстан Республикасының Студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы (алга таба – Студентлар лигасы), «Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы тора.

Студентлар лигасы базасында республика территориясендә белем алучы чит ил студентларын социаль мохиткә җайлаштыру буенча эшне Чит ил студентлары белән эшләү комитеты (алга таба – Комитет) алып бара. Комитет мәгариф оешмаларының чит ил студентлары ассоциациясе белән берлектә эшли, шулай ук Татарстан Республикасының чит ил студентлары ассоциациясе җитәкчеләре советы

(Студентлар лигасы каршындагы коллегиаль орган 2022 елда төзелә) кысаларында аларның эшчәнлеген координацияли.

2023 елда Комитет чит телләрне һәм мәдәниятләрне өйрәнү буенча тел өйрәтү курслары, «Чит ил студентлары берлеге лидерлары» дигән мәгариф программасы, «Халыклар дуслыгы» дип аталган чит ил студентлары спартакиадасы кебек чаралар уздырды. 2024 елда Комитет «ГЛОБАЛ ФЕСТ» дигән чит ил мәдәниятләре фестивален оештырды, шулай ук Татарстан Республикасының чит ил студентлары беренче конференциясен уздыру планлаштырыла. Комитет вәкилләре Яшьләр эшләре буенча федераль агентлыкның (Росмолодежь) грант конкурсларында актив катнаша, нәтиҗәдә берничә проектка грант ярдәме күрсәтелде.

Шулай ук чит ил студентлары төбәк проектларында катнашуга да җәлеп ителә. Шулай итеп, 2023 елда алар «Елның иң яхшы чит ил студенты» номинациясендә «Татарстан Республикасының ел студенты» Татарстан Республикасының ел саен үткәрелә торган студентлар премиясендә катнашты. 2024 елда әлеге номинациядә катнашуга 19 кешедән гариза килде.

2024 елның февралендә «Форумнар Лигасы» студентлар мәгариф форумы кысаларында чит ил студентлары барлык сменаларда да («Мөмкинлекләр лигасы»ның беренче сменасы, «Берләшмәләр лигасы»ның икенче сменасы, «Үзгәрешләр лигасы»ның өченче сменасы) актив катнашты. Икенче смена кысаларында чит ил студентлары өчен «Аралашуга чикләр юк» дип исемләнгән махсус трек булдырылды, анда 100 дән артык гариза биргән студентның 50се катнашты. Алар арасында чит ил гражданнары, халыкара оешмалар җитәкчеләре, милли мохтариятләр кураторлары һәм башкалар бар.

«Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы һәм «Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы тарафыннан зур эш алып барыла.

Татарстанның Халыклар дуслыгы йортында һәм Казан шәһәре югары уку йортларында даими нигездә чит ил студентлары белән чит ил студентларының социаль-мәдәни мохиткә җайлашуы, аларның Россия Федерациясе законнарын үтәве мәсьәләләренә кагылышлы очрашулар булып тора. Әлеге очрашулар кысаларында Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясе вәкилләре чит ил студентларына Россия Федерациясендә экстремистлык һәм террорчылык эшчәнлегенә каршы көрәшү өлкәсендә хокукый мәгълүмат бирә.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының экстремистлыкка каршы көрәшү үзәге вәкилләре студентларның игътибарын тагын бер кат яшәү һәм эшләү урыннарында хокук тәртибен саклауның мөһимлегенә, санкцияләнмәгән гавами чараларда катнашуның катгый тыелуына юнәлтә, шулай ук әлеге хокук бозулар ачыкланган очракта, административ җаваплылыкка тарту, Россия Федерациясе территориясендә керү тыелган хәлдә, илдән куую мөмкинлеге турында кисәтә.

Татарстанның муниципаль районнарында яшьләр арасында милләтара дуслыкны һәм татулыкны ныгыту, яшьләр даирәсендә милләтчелекне һәм экстремистлыкны кисәтү максатларында 2023 елның 27 сентябреннән 29 сентябренә кадәр Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясенең Татарстан Республикасы

муниципаль районнарындагы вәкиллекләре активистлары һәм милли-мәдәни мохтариятләрнең яшьләр хәрәкәтләре вәкилләре катнашында республика слеты булып узды. Слет кысаларында социаль проектлар буенча укулар, ксенофобия һәм милләтара каршылыкларны профилактикалау өлкәсендә компетенцияләрне үстерү, социаль профилактика проектларын эшләү кебек чаралар үткәрелде. Яшьләр арасында радикаль карашларны профилактикалауга, шулай ук яшьләр даирәсендә милләтләр арасында дуслыкны һәм татулыкны ныгытуга юнәлдерелгән тәкъдим ителгән проектларны сайлап алу нәтиҗәләре буенча Нурлат, Алабуга һәм Әлмәт муниципаль районнары, Чаллы шәһәре җиңү яулады. Аларда 9 профилактика чарасы уздырылды.

Татарстан Республикасында чит илдән килүчеләрне социаль мохиткә җайлаштыру һәм яраклаштыру өчен өстәмә шартлар булдыру өчен 2023 елдан Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты тарафыннан «Татарстан – яңа юл» чит илдән килүчеләр белән үзара эшчәнлек алып баруның коммуникация каналы булдыру белән бәйле проект гамәлгә ашырыла башлады. Әлеге проектны гамәлгә ашыру кысаларында «ВКонтакте» һәм «Telegram» социаль челтәрләрендә алты телдә алып барыла торган берләшмәләрнең уртак челтәрен формалаштыру эше башланды. Проектның төп максаты – төрле телләрдә актуаль контент кертеп, социаль челтәрләрдән актив файдалану, чит ил гражданнарына эш вакансияләре, этномәдәни чаралар турында файдалы мәгълүмат бирү, миграция законнары буенча аңлату эшләре алып бару, республика техникумнарына, көллиятләренә, югары уку йортларына укырга керү, медицина хезмәте күрсәтү мөмкинлеге турында һәм Россиядә яшәү өчен кирәкле булган башка файдалы мәгълүмат бирү. Проект мәгълүмат ресурсларына, платформаларга максатчан аудитория җәлеп итү, чит илдән килгән гражданнарга бер-берсе белән аралашу һәм хезмәттәшлек итү, шулай ук чит илдән килгән гражданнарның социаль кәефен мониторинглау, потенциаль куркыныч моментларны ачыклау, килеп туган мәсьәләләрне хәл итү алымнарын табу мөмкинлеге бирәчәк.

## 14. Татарстан Республикасында яшьләрнең һөнәри, хезмәт һәм эшкуарлык өлкәләрендә мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар булдыру турында.

Республикада яшьләр арасында эшкуарлык башлангычларын үстерүгә, остазлык системасын популярлаштыруга, яшь эшкуарлар берләшмәсен үстерүгә юнәлтелгән төрле чаралар тормышка ашырыла.

«Беренчеләр хәрәкәте» балаларның һәм яшьләрнең гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсенең төп проектларының берсе булып «Үз һөнәрләрендә иң беренчеләр» бөтенроссия проекты тора, аның кысаларында катнашучылар предприятиеләргә барып, эш бирүчеләр белән очраша, төрле һөнәрләр һәм төрле тармакларда эшләүчеләрнең һөнәри эшчәнлеге турында мәгълүмат ала.

Ай саен «Беренчеләр хәрәкәте»ндә катнашучылар төрле һөнәр ияләре һәм эшкуарлар белән очрашулар уздыра. «Галимдә кунакта» проекты кысаларында укучылар Татарстан Республикасының фән өлкәсендәге мөмкинлекләре белән генә танышып калмыйча, югары уку йортларына, көллиятләргә барып, анда уку

юнәлешләре, укырга керү тәртибе һәм киләчәктә эшкә урнашу мөмкинлекләре белән таныша.

Яшь фермерлар, авылларда бизнес проектларын тормышка ашыручы эшкуарлар белән эш «Татарстан Республикасының аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы тарафыннан алып барыла.

2023 елда түбәндәге проектлар тормышка ашырылды:

«Авылларда яшь эшкуарлар акселераторы», анда республиканың 32 муниципаль районыннан 80 яшь эшкуар катнашты;

«Фермер мәктәбе» мәгариф проекты, аны тәмамлап чыккан 40 кеше һөнәри яктан яңадан әзерләү узу турында дәүләт үрнәгендәге диплом алды.

2023 елда Татарстан Республикасы Яшь эшкуарларны үстерү бөтенроссия программасында катнашучы биш пилот төбәк исемлегенә керде. «Россия» халыкара күргәзмә-форумы кысаларында җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы узды.

Татарстан Республикасында «Кече һәм урта эшкуарлык һәм эшкуарлык башлангычларына ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты кысаларында социаль эшкуарларга һәм 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) яшь эшкуарларга грант ярдәме күрсәтү программасы тормышка ашырыла. 2023 елда программаны финанслауның гомуми суммасы 92,3 млн сум тәшкил итте. 148 яшь эшкуар грантка ия булды, грантның суммасы 64,4 млн сум тәшкил итте.

2023 елның августында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы «Татарстан Республикасында эшкуарлыкка ярдәм фонды»ның «Минем бизнес» үзәге белән берлектә Студентлар лигасы базасында яшь эшкуарлар клубы оештырды, анда бизнес-очрашулар, тәҗрибәле эшкуарлар катнашында лекцияләр, маркетплейсларда эшләү буенча түләүсез укулар, эшкуарлык дәресләре уздырыла.

Яшь эшкуарлар клубының эшчәнлеге бизнес-проектларны үстерүгә, бизнес-идеяләрне тормышка ашыруга инвестицияләр җәлеп итү мөмкинлеген тәэмин итүгә, Россия Федерациясе территориясендә эшкуарлык эшчәнлеге алып баруга кызыксынулары булган яшь эшкуарларның һәм яшьләрнең шәхси үсеше һәм аларга һөнәри яктан үз-үзен таныту өчен шартлар булдыруга, аларны «Россия яшьләре.Бизнес» трегының төп проектларына җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

2024 елда Татарстанның югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм муниципаль берәмлекләре базасында яшь эшкуарлар клубларын төзү планлаштырыла.

«Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында «Киләчәккә билет» проектлары уңышлы гына эшләп килә. Аның максаты – 6–11 сыйныф укучыларын һөнәр сайлауга әзерләү. 2023 елда проектта 29 138 мәктәп укучысы катнашты.

2023 елның 16 мартыннан 30 ноябренә кадәр «Татарстан Республикасы яшь рационализаторы һәм уйлап табучысы» республика конкурсында 97 кеше катнашты.

2023 елның 27 апреленнән 30 апреленә кадәр «Татарстан Республикасы яшь рационализаторы һәм уйлап табучыларының мәгариф форумы уздырылды. Форум «Идел» яшьләр үзәге дәүләт автоном учреждениесе базасында үткәрелде, анда Татарстан Республикасының 16 предприятиесеннән 50 кеше катнашты. Форумда катнашу нәтиҗәсендә яшьләр үз квалификацияләрен күтәреп, «Интеллектуаль милек объектларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану» программасы буенча сертификат алды.

2023 елның 28 мартыннан 5 декабренә кадәр яшьләр белән эш иң яхшы оештырылган Татарстан Республикасы предприятиеләрен һәм оешмаларын ачыклау йөзеннән «Республика потенциалы» республика конкурсы уздырылды, аның максаты – Татарстан Республикасы предприятиеләрендә һәм оешмаларында дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруга ярдәм итү. Конкурста 31 оешма катнашты.

2023 елда унберенче тапкыр эшче яшьләр иҗатының «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион фестивале үткәрелде. Анда Татарстан Республикасының 42 муниципаль берәмлегеннән 185 предприятие катнашты, 1,6 меңнән артык катнашучы үзенең сәләтләрен күрсәтте.

2020 елдан «Студентларның хезмәт отрядлары республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе студентлар өчен укудан һәм эштән буш вакытларда вакытлыча, сезонлы һәм төп эш урыныннан тыш өстәмә эш урыннары белән тәэмин итә. Әлеге вакыт эчендә 15 меңнән артык кеше эшкә урнашты.

Яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү һәм аларны эшкә урнаштыру өчен республика территориясендә студентлар хезмәт отрядларының 22 муниципаль штабы эшләп килә: сервис хезмәте, педагогик, махсуслаштырылган, төзелеш, җитештерү, авыл хуҗалыгы, медицина, балык тоту һәм эшкәртү, проводниклар отрядлары. Студентлар хезмәт отрядлары 24 югары белем бирү һәм 33 урта махсус белем бирү оешмалары базасында эшли, алар ел әйләнәсе эш эзләүче  студентларны эш урыннары белән тәэмин итә.

2023 елда студентлар отрядларының 2 зона штабы ачылды: көньяк-көнчыгыш зонада – Әлмәт шәһәрендә һәм Идел аръягы зонасында – Буа шәһәрендә. Әлеге шәһәрләрдә студентлар отрядларының «СО.Здание», мультиформат мәйданчыклары булдырылды, алар студентларга һәм яшүсмерләргә һөнәри белем алу һәм кирәкле хезмәт тәҗрибәсе туплау һәм белгечлек буенча эшләү мөмкинлеге бирәчәк.

2023 елда 36 мәгариф оешмасы базасында 46 эшче белгечлеге буенча 2 466 кеше бушлай һөнәри белем алды.

Хезмәт отрядлары зур хезмәт проектларын тормышка ашыруда катнаша: «АльМедик» бөтенроссия студентлар медицина отрядлары (Әлмәт шәһәре) һәм «Сәләт» (Лениногорск шәһәре), алар төбәк һәм бөтенроссия проектларында эшли. 15 федераль компания студентлар хезмәт отрядларына эш бирүчеләр булып тора. Алар арасында – «Газпром» гавами акционер җәмгыяте, «Росатом» гавами акционер җәмгыяте, «Россети» гавами акционер җәмгыяте, «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте, «ФПК» акционер җәмгыяте һәм башкалар.

Татарстан Республикасы территориясендә хезмәт отрядлары  50 предприятие, шул исәптән «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, «АК Барс» холдинг компаниясе акционер җәмгыяте, «Ремдизель» һәм башкалар белән хезмәттәшлек итә.

2023 елның 8 ноябреннән 12 ноябренә кадәр Казан шәһәрендә Студентлар отрядларының бөтенроссия слеты булып узды. Слет йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең 81 төбәге арасыннан Россия студентлар отрядларының иң яхшы төбәк бүлекчәсе дип танылды һәм комиссарлар эшчәнлеген оештыру буенча төбәк бүлекчәләре рейтингында икенче урынны алды.

**15. Авылларда квалификацияле яшь кадрларга кытлыкны бетерү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан планлаштырылган чаралар турында.**

Квалификацияле яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында һәм Татарстан Республикасында авылларда кадрларга кытлыкны бетерү максатларында түбәндәге эшләр башкарыла:

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә.

Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт яисә муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына эшкә кергән белгечләргә түбәндәге күләмдә бер тапкыр бирелә торган пособие түләнә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 20 декабрендәге 1199 номерлы карары):

50 мең – һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаган белгечләргә;

100 мең сум – югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлаган белгечләргә.

Пособиеләр укуларын тәмамлаган елны квалификациясе турында документ нигезендә эшкә урнашкан 35 яшькәчә (35 яшьне дә кертеп) белгечләргә түләнә.

Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге максатларга 2023 елда 450,0 мең сум бүлеп бирелде. 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетында әлеге бер тапкыр бирелә торган түләүләргә 1, 35 млн сум каралган.

Мәгариф өлкәсендә.

Педагогик хезмәткәрләргә 2 510 сум күләмендә кызыксындыру рәвешендә айлык өстәмә – яшь белгечләргә дәресләр санын, эшләнгән елларын исәпкә алып, педагог вазыйфасында өзлексез эшләвенең беренче 3 елында түләнә.

Түбәндәге оешмаларда эшләүче яшь белгечләргә кызыксындыру рәвешендә айлык өстәмә алуга хокукы бирелә: мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, гомуми белем бирү оешмаларында, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында, өстәмә белем бирү оешмаларында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карары).

Әлеге максатларга 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан 104,705 млн сум күләмендә акча каралган, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирүгә – 101,036 млн сум.

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында 2023 елның 23 декабрендә төзелгән 073-09-2024-527 номерлы килешү нигезендә 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетында авыл торак пунктларына яисә эшче поселокларга яки шәһәр тибындагы поселокларга яисә 50 меңнән кимрәк кеше яшәүче шәһәрләргә эшкә килгән (күчеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен башкаруга чыгым йөкләмәләрен уртак финанслауга 3,0 млн сум күләмендә акча бүлеп бирелде, шулардан 1,8 млн сум – федераль бюджеттан субсидия, 1,2 млн сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары.

Спорт өлкәсендә.

Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне тормышка ашыручы дәүләт һәм муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә түбәндәге түләүләр каралган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карары):

эшләгән елларына туры китереп 2 510 сум күләмендә кызыксындыру рәвешендә айлык өстәмә;

20 мең сум күләмендә хуҗалык кирәк-яраклары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2023 елда 3,368 млн сум акча бүлеп бирелде, 2024 елга 3,389 млн сум каралган.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов карары нигезендә 2024 елда хуҗалык кирәк-яраклары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүнең күләме 100 мең сумга кадәр арттырылды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 7 мартындагы 127 номерлы карары).

Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә.

Педагогик хезмәткәрләргә – Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләр билгеләнде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 16 ноябрендәге 857 номерлы карары):

өзлексез эшләвенең беренче 2 елы дәверендә 2 510 сум күләмендә айлык өстәмә түләү;

20 мең сум күләмендә хуҗалык кирәк-яраклары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү.

2023 елда әлеге түләүләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан 38,0 мең сум акча бүлеп бирелде, 2024 елга 325,1 мең сум каралган.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгыннан максатчан билгеләнеш буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарында урнашкан дәүләт автоном (бюджет) сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә урнашкан яшь белгеч – табибларга түбәндәге акчалата түләү билгеләнде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 9 сентябрендәге 501 номерлы карары):

өзлексез эшләвенең беренче 3 елы дәверендә 2 510 сум күләмендә айлык өстәмә түләү;

21 534 мең сум күләмендә хуҗалык кирәк-яраклары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2023 елда 13,376 млн сум акча бүлеп бирелде, 2024 елга 13,805 млн сум каралган.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә.

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә түбәндәге дәүләт ярдәме чаралары каралган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 ноябрендәге 893 номерлы карары):

мәгариф оешмасын тәмамлаган елны эшкә кергән югары белемле яисә урта һөнәри белемле, кимендә 3 ел авыл хуҗалыгы оешмаларында яки кулланучылар кооперациясе оешмаларында эшләү йөкләмәсе алган яшь белгечләргә түбәндәгеләр түләнә:

югары белеме булган белгечләргә 300 мең сум күләмендә, урта һөнәри белемгә ия белгечләргә 150 мең сум күләмендә акчалата түләү;

эшкә урнашкан көннән 12 ай дәвамында 7,5 мең сум күләмендә айлык акчалата түләү;

көндезге уку бүлекләрендә федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә Татарстан Республикасы югары белем бирү мәгариф оешмаларында югары белем алучы студентларга шәхси стипендияләр билгеләнде – «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе һәм «Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе студентларына ел дәвамында ай саен 2 мең сум күләмендә 50 стипендия;

көндезге уку бүлекләрендә федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы юнәлеше буенча һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф оешмаларында һөнәри белем алучы студентларга шәхси стипендияләр билгеләнде – авыл хуҗалыгы юнәлеше буенча һөнәри белем бирү оешмалары студентларына ел дәвамында ай саен 1 мең сум күләмендә 50 стипендия;

«Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе һәм «Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең 3, 4 һәм 5 курслар студентларына Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендә авыл хуҗалыгы оешмаларында производство практикасы уку чорында ике ай дәвамында 1 мең сум күләмендә стипендия;

Татарстан Республикасы аграр юнәлештәге фәнни оешмаларда һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан расланган тематика планнар нигезендә фәнни-тикшеренү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче 30 яшькә кадәрле кече фәнни хезмәткәрләргә 5 мең сум күләмендә айлык стипендия.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2023 елда 70,823 млн сум акча бүлеп бирелде, 2024 елга 85 млн сум каралган.

«Авыл халкын эш белән тәэмин итү» төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыруга 2024 елда 21,448 млн сум күләмендә ассигнованиеләр бүлеп бирелде, шулардан:

авыл территорияләрендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү белән шөгыльләнүче оешмалар өчен белгечләрне укытуга – 14,311 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан – 11,592 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 2,719 млн сум;

авыл территорияләрендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү белән шөгыльләнүче оешмаларның студентларны практика узуга һәм хезмәт практикасы узуга җәлеп итү белән бәйле чыгымнарын каплауга – 7,138 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан – 5,782 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1,356 млн сум.

**16. Сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәләрендә кадрларга кытлыкны бетерү чаралары турында.**

Татарстан Республикасында кадрларга кытлыкны бетерү максатларында «Сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проекты эшләнде һәм расланды. Аны гамәлгә ашыру кысаларында медицина оешмаларын кадрлар белән тәэмин итү һәм беренчел

медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кадрларга кытлыкны бетерү буенча берничә этапка бүленгән эш алып барыла.

Кадрларга кытлык мәсьәләсен хәл итүнең бер юлы булып югары белем бирү мәгариф оешмаларында укуга максатчан кабул итү квоталары буенча белгечләрне максатчан укыту тора. 2023 елда югары медицина белеме бирү мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасының максатчан кабул итү квотасы буенча укып чыккан белгечләр саны 375 кеше тәшкил итте, шулардан 132 кеше белгечлек программасы буенча, ординатура программасы буенча – 243 кеше тәмамлады.

Барлык ведомство карамагындагы медицина оешмаларында яшь белгечләрне (табиблар, шәфкать туташлары) эшләү чорының беренче ике елында медицина этикасына һәм деонтология нормаларына, үз-үзен тоту кагыйдәләренә өйрәтергә, аларны җәмгыять тормышында катнашуга җәлеп итү максатында «Медицина өлкәсендә остазлык» дип аталган программа гамәлгә кертелде.

Урта медицина персоналын әзерләү кысаларында 10 дәүләт автоном һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларында 2023 елда белгечләрне максатчан билгеләнеш буенча һәм укуларын тәмамлаганнан соң эш белән тәэмин итү турында 1 337 шартнамә төзелде. 1 338 кеше укуларын тәмамлап чыкты, шулардан 1 090 кеше дәүләт медицина оешмаларына эшкә урнашты (укуларын тәмамлаучыларның 81,5 проценты).

2023 ел йомгаклары буенча фельдшерлык-акушерлык пунктларының кадрлар белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе 100 процент тәшкил итте (берьюлы ике урында эшләүче физик затлар 93 процент). Республикада барлыгы 1 673 фельдшерлык-акушерлык пункты бар, шулардан фельдшерлык-акушерлык пунктында берьюлы ике урында эшләүчеләр хезмәт итә.

Өзлексез медицина белеме бирү кысаларында медицина хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү эше дәвам иттерелә. Өзлексез медицина белеме бирү системасында барлыгы 49 571 белгеч теркәлгән.

2023 ел йомгаклары буенча 22 385 табиб һәм гомуми камилләштерү курсларында 12 994 урта медицина хезмәткәре белем алды, һөнәри яктан яңадан әзерләү циклларында 452 табиб һәм 1 347 урта медицина хезмәткәре укып чыкты.

Табиблар һәм урта медицина персоналының һөнәри белемнәрен үстерү курслары 3 аккредитация-симуляция үзәкләрендә (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Фундаменталь медицина һәм биология институты, «Югары медицина технологияләре мәгариф үзәге» өстәмә һөнәри белем бирү академиясе) уза.

Ел саен медицина хезмәткәрләре симуляция аппаратларында медицина ярдәме күрсәтү күнекмәләренә (эндоскопия симуляторы, йөрәк-үпкә реанимациясе комплексы өчен симулятор, ангиографик симуляция җиһазлары, лапароскопия симуляторы, ультратавыш диагностикасы симуляторы) өйрәнә, бу исә медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын арттыру мөмкинлеге бирә. 2023 ел йомгаклары буенча симуляция үзәкләрендә 619 медицина белгече укып чыкты.

2023 елда түбәндәге проектлар гамәлгә ашырылды:

– Татарстан Республикасының 6 югары технологияле үзәгендә симуляция җиһазларында эшләргә өйрәтү сыйныфлары ачылды, шуларның 6 сы 2024 елда

җиһазландырылачак («Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Әлмәт районара күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе);

Симуляция җиһазларында эшләргә өйрәтү буенча беренче белем бирү сыйныфы Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында эшли башлады. Белгечләр симуляция-тренинг һөнәри медицина белеме бирү программалары буенча түбәндәге медицина симуляторларында: эндоскопия симуляторы, йөрәк-үпкә реанимациясе комплексы өчен симулятор, ангиографик симуляция җиһазлары, лапароскопия симуляторы, ультратавыш диагностикасы симуляторы өйрәнә.

«Фельдшер ярдәмчесе» проектының максаты булып авыл халкына медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен хәл итү тора. Проект буенча республиканың 43 муниципаль берәмлегеннән 1 046 кеше укып чыкты.

«Һөнәри осталык. 2023» һөнәри осталык чемпионаты. Сайлап алу туры йомгаклары буенча медицина оешмалары вәкилләре өч компетенция – «Лаборатор һәм медицина анализы», «Дәвалау эшчәнлеге», «Фармацевтика» компетенцияләре буенча 1 урын алды. Илкүләм чемпионатның финалында «Медицина һәм социаль хезмәт күрсәтү» компетенциясендә «Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе җиңү яулады. «Һөнәри осталык» һөнәри осталык чемпионатының финал этабында «Медицина һәм социаль хезмәт күрсәтү» компетенциясенең «корпоратив катнашучы» категориясендә Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе шәфкать туташы Гарипова Айгөл 1 урын яулады.

Социаль ярдәм чаралары буларак түбәндәгеләр тормышка ашырыла:

табибларга социаль ярдәм чараларын финанслар белән тәэмин итү – хуҗалык кирәк-яраклары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү һәм өзлексез эшләү чорының беренче 3 елында түләнә торган айлык өстәмә. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгыннан максатчан билгеләнеш нигездә республиканың дәүләт (автоном) сәламәтлек саклау учреждениесенә эшкә кабул ителгән 373 яшь белгечкә (табибка) дәүләт ярдәме күрсәтелде, шулардан 170 белгечкә 21 534,0 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде һәм беренче тапкыр 2 510,0 сум күләмендә айлык өстәмә билгеләнде. Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2023 елда 13 375,6 мең сум күләмендә акча бүлеп бирелде;

Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган табибларга – белгечләргә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына дәүләт ярдәме чараларын финанслар белән тәэмин итү. Бер белгечкә грантның суммасы 800,0 мең сум тәшкил итә. 2023 елда гомуми суммасы 100,0 млн сумга 125 грант бирелде.

Өстәмә рәвештә «Авыл докторы» һәм «Авыл фельдшеры» программалары эшләп килә. Бер табибка бер тапкыр бирелә торган түләүнең күләме 1 млн сумнан 1,5 млн сумга кадәр, фельдшерга – 500,0 мең сумнан 750,0 мең сумга кадәр.

2023 елда бер тапкыр бирелә торган компенсация 127 медицина хезмәткәренә, урта медицина персоналыннан булган 95 табибны һәм 32 хезмәткәрне кертеп, түләнде. Татарстан Республикасы бюджетында 2023 елга әлеге максатларда 142,0 млн сум бүлеп бирелде, шул исәптән федераль бюджеттан – 85,2 млн сум (60 процент), Татарстан Республикасы бюджетыннан – 56,8 млн сум (40 процент).

2020 елдан Татарстан Республикасы Сәламәтлек министрлыгы тарафыннан республиканың дәүләт медицина оешмаларында эшләүче медицина хезмәткәрләре өчен социаль ипотека программасы буенча торак алуга квота бирелә. 2023 елда медицина хезмәткәрләренә 142 фатир бирелде.

Мәгариф өлкәсендә кадрларга кытлыкны бетерү өчен шулай ук мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә социаль ярдәм чаралары булдырылды, алар республикага педагогик кадрлар җәлеп итүгә һәм аларны биредә эшкә калдыруга юнәлтелгән.

2020 елдан республикада «Авыл укытучысы» программасы эшләп килә, аның нигезендә авыл торак пунктларына, шулай ук шәһәр тибындагы поселокларга яисә 50 меңнән кимрәк кеше яшәүче шәһәрләргә эшкә килгән (күчеп килгән) укытучыларга 1 млн сум күләмендә компенсация түләнә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 26 февралендәге 149 номерлы карары). Әлеге акча төрле максатларга тотылырга мөмкин (торак, автомобиль, дача сатып алуга һ.б.). 2020–2023 елларда әлеге түләүне Россия Федерациясенең башка төбәкләреннән авыл торак пунктларына яисә эшче поселокларга яки шәһәр тибындагы поселокларга яисә 50 меңнән кимрәк кеше яшәүче шәһәрләргә эшкә килгән (күчеп килгән) 51 укытучы алды.

Яшь укытучыларга эшкә урнашканда аерым муниципаль районнарда җирле бюджет акчалары хисабыннан бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү (Лаеш районы – 120,0 мең сум, Азнакай районы – 50,0 мең сум, Сарман районы – 25,0 мең сум, Лениногорск, Түбән Кама районнары –10,0 әр мең сум, Әгерҗе районы – 8,0 мең сум), шулай ук хезмәт (аренда) торагы (Азнакай, Әлмәт, Апас, Бөгелмә, Алабуга, Яңа Чишмә, Саба, Чирмешән, Чистай) бирелә.

Шулай ук 2023 елда «Безнең яңа укытучыбыз» гранты яңадан эшли башлады, аның кысаларында 200 яшь укытучы 3 ел дәвамында ай саен хезмәт хакына өстәп, 10 мең сум күләмендә өстәмә ала.

Моннан тыш, «Социаль ипотека» һәм «Яшь гаилә» программалары кысаларында педагогик хезмәткәрләрнең торак шартларын яхшырту чаралары тормышка ашырыла.

Укытучы һәм остаз елында Татарстан Республикасы Рәисе карары нигезендә 70 педагогик хезмәткәр фатир ачкычлары алды.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә авыл торак пунктларында, эшче поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче һәм эшләүче педагогик хезмәткәрләр, мәгариф оешмалары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, мәгариф оешмалары структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары коммуналь хезмәтләр өчен түләү нормативларын исәпкә алып, торак йортлар өчен, торак мәйданының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормалары буенча бернинди чикләүләрсез 100 процент

күләмендә җылылык һәм яктылык өчен түләүгә чыгымнарны каплауга компенсация алуга хокуклы.

Яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм педагогик кадрларны эш урыннарында беркетү максатларында яшь педагогларга дәресләр санын, эшләнгән елларын исәпкә алып, педагог вазыйфасында өзлексез эшләвенең беренче 3 елында 2 510 сум күләмендә кызыксындыру рәвешендә айлык өстәмә түләнә. Түбәндәге оешмаларда эшләүче яшь белгечләргә кызыксындыру рәвешендә айлык өстәмә алуга хокук бирелә: мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, гомуми белем бирү оешмаларында, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда, өстәмә белем бирү оешмаларында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карары). 2024 елның 1 гыйнварына кызыксындыру рәвешендә айлык өстәмәне 2 898 педагогик хезмәткәр – яшь белгеч алды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карары нигезендә авыл җирендә эшләүче белгечләргә түләнә торган өстәмә түбәндәге хезмәткәрләргә бирелә: педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркеме вазыйфаларына керүче хезмәткәрләргә һәм һөнәри квалификация төркеменә керүче мәдәният хезмәткәрләренә, урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар һөнәри квалификация төркеменә керүче медицина хезмәткәрләренә. Авыл җирендә эшләүче белгечләргә түләүнең күләме 1 388 сум тәшкил итә.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы бүләге булган очракта, өстәмәнең күләме гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәренең вазыйфаи окладының 4 процентын, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы бүләге булганда – вазыйфаи окладының 2 процентын тәшкил итә.

Укытучы һәм остаз елында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2023 елда яңа 3 төр ведомство бүләге гамәлгә куелды: «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерымлык билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, гореф-гадәтләрне саклау һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясы 1.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары составына кергән шәһәр һәм авыл җирлекләрендә төп эш урынында эшләүче гражданнарга бер тапкыр шәхси торак төзүгә яисә шәхси хуҗалык алып баруга дәүләт һәм муниципаль милектә булган җир кишәрлекләре бушлай файдалануга бирелә, әлеге җир кишәрлекләреннән 6 ел файдаланырга була. Хәзерге вакытта муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү турында 254 гамәлдәге шартнамә төзелде.

**17. Опекуннарга һәм попечительләргә Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясында билгеләнгән акчалата түләүнең күләмен арттыруның максатка ярашлыгы турында.**

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләр дәүләт банкында исәпкә торучы балалар саны тотрыклы рәвештә югары кала бирә. Ул

2023 елда 586 кеше тәшкил итә, аларның күбесе 10 яшьтән өлкәнрәк булган яшүсмерләр (384 кеше), сиблинглар (308 кеше).

2009 елның 31 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексында үз вазыйфаларын түләүсез нигездә башкарган опекуннар һәм попечительләргә акчалата түләү билгеләнде. Бер бала тәрбияләгән өчен түләү 3 мең сум тәшкил итә.

Җирле үзидарә органнары җирле бюджет акчалары хисабыннан опекуннар һәм попечительләргә өстәмә түләү билгеләргә хокуклы.

Казан шәһәрендә бер бала тәрбияләү өчен акчалата түләү 5 мең сум тәшкил итә, шулардан 2 мең сум Казан шәһәре муниципаль берәмлеге акчалары хисабыннан.

Моннан тыш, үз вазыйфаларын түләүсез нигездә башкарган опекуннар һәм попечительләргә (шул исәптән тәрбиягә бала алган ата-аналарга), түбәндәге өстәмә түләүләр билгеләнде:

педагогик һәм медицина белеме булган тәрбиягә бала алган ата-аналарга федераль законнарда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән 50 проценты (8 121 сум, 2024 елга – 9 621 сум);

өч яше тулмаган баланы тәрбиягә алган яисә инвалид бала яки психик яки физик үсешендә тайпылышлары булган баланы яисә девиант тәртипле бала тәрбияләгән өчен акчалата түләүнең 30 проценты (900 сум).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга өстәмә рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2017 елның 13 июлендәге 493 номерлы карары нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алган гражданнарга 200 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләнде.

Шулай ук федераль бюджеттан 22 909 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү баланы гаиләгә тапшырганда бирелә, ә инвалид баланы, 7 яшьтән өлкәнрәк булган баланы, абыйлы-энеле яисә апалы-сеңелле туганнарны гаиләгә тәрбиягә алганда 175 043 сум күләмендә пособие түләнә.

## 18. Гаилә кыйммәтләрен формалаштыру, яшьләрдә әти-әни булуга җаваплы караш тәрбияләү буенча эш.

<u>Гаилә кыйммәтләрен формалаштыру.</u>

Гаиләнең социаль статусын арттыру, традицион гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру максатларында 2023 елда республиканың гражданлык хәле актларын теркәү идарәләре тарафыннан 17,5 меңнән артык гаилә теркәү тантаналары уздырылды, шулай ук 3 171 гаилә гаилә коруның юбилей даталарын билгеләп үтте.

Республиканың мәгариф оешмаларында «Гаилә фәне» проекты тормышка ашырыла, аның максаты – укучыларны гаилә тормышына әзерләү, гаилә әгъзасы формалаштыру, туган йорт, гаилә, әти-әни булу, туганнар белән мөнәсәбәт, нык гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык кебек традицион гаилә кыйммәтләренә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

«Гаилә фәне» проекты мәгариф системасына электив, факультатив дәресләр яисә мәгариф оешмаларында тәрбия эше кысаларында сыйныф сәгатьләре сыйфатында кертелә.

2024 елның 25–26 гыйнварында республикада «Гаилә фәне» проектын гамәлгә кертү буенча инновация мәйданчыгы булып торган Түбән Кама муниципаль районында Гаилә елына багышланган «Гаилә: минем өемдәге урыным» дип аталган укыту-методик семинары уздырылды, анда «Гаилә фәне» проектын алып баручы тәрбия буенча директор урынбасарлары һәм директор киңәшчеләре, укытучылар катнашты.

Казан шәһәре Яңа Савин районының «146 номерлы «Ресурс» лицее» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе федераль дәрәҗәдә Татарстанда гаилә фәне буенча укыту-методик структура педагоглары уздырган осталык дәресләре саны буенча «Россиянең иң яхшы мәктәбе» дип танылды.

2024 елның 27 февралендә Казан шәһәрендә «ТИСБИ» идарә университеты базасында «Әтиләр һәм хәзерге заман җәмгыять тормышында этиләрнең урыны: «Гаилә фәне» программасы аша караш» республика фәнни-гамәли конференциясе булып узды.

Моннан тыш, гаилә кыйммәтләре формалаштыру, милли мәдәниятнең рухи хәзинәләрен һәм гореф-гадәтләрне өйрәтү максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2023 елда Казан шәһәре Совет районының «М.И. Мәхмүтов исемендәге 184 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе базасында «Шәҗәрәләр – нәсел агачы» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе уздырылды. Конференциядә Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе субъектлары территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларыннан 7–11 сыйныфта укучы 350 мәктәп укучысы катнашты.

2023 елда республикада яшьләр сәясәте учреждениеләре базасында 80 меңнән артык кеше катнашында 764 гаилә чарасы булып узды. «Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге тарафыннан түбәндәге чаралар үткәрелде:

«Гаилә учагы» балалар һәм ата-аналар арасында мөнәсәбәтләрне җайга салу һәм үзгәрешләр кертү буенча гаилә клубы (22 чара);

яшь гаиләләр клубы (50 чара);

сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларның ата-аналары өчен онлайн һәм офлайн-форматта гаилә клубы (18 чара);

тормышның төрле өлкәләрен үз эченә алып, балалы гаиләләрнең уңай тәҗрибәсен пропагандалаучы «җаваплы ата-ана мәктәбе» дәресләре (булачак яшь гаиләләр белән 87 мәгълүмати-мәгърифәти дәрес).

2023 елда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында республикада традицион гаилә кыйммәтләрен ныгыту һәм популярлаштыру максатларында Халыкара гаилә елына багышланган «Минем гаиләм – минем байлыгым» дип аталган республика рәсем конкурсы оештырылды.

2023 елның 25 августында Татарстан Республикасы Көннәре алдыннан Казан Кремлендә республиканың иң яхшы гаиләләре хөрмәтенә ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов һәм аның тормыш иптәше Г.Ә. Миңнеханова исеменнән тантаналы кабул итү мәҗлесе булып узды. Әлеге чара 2023 елда унынчы тапкыр үткәрелде. 10 ел дәверендә әлеге чарада Татарстаннан барлыгы 500 гаилә катнашты.

Республикада ел саен «Нечкәбил» әниләр өчен республика матурлык конкурсы уздырыла.

2023 елның 12 ноябрендә «Мега» сәүдә үзәгендә Татарстан Республикасының яшь гаиләләре фестивале узды, анда гаилә бюджетын нәтиҗәле файдалану һәм хуҗалык алып бару турында лекцияләр, фикер алышулар форматында гавами дискуссияләр, гаилә квизлары, «Кыска вакыт эчендә танышу» проекты, конкурслар һәм башка чаралар үткәрелде. Әлеге чарада 1,5 меңнән артык кеше катнашты.

2023 елның 1 декабрендә «Киләчәк гаиләсе. Киләчәк сәламәтлеге» Яшьләр республика конференциясе үткәрелде, ул идеяләр һәм тәҗрибә алмашу, үзара элемтәләр урнаштыру, яшьләр белән эшләүнең яңа формаларын тәкъдим итү буенча төп мәйданчык булып тора. Конференциядә Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте учреждениеләрендә эшләүче 200 хезмәткәр катнашты.

Республиканың 43 муниципаль берәмлегендә (Аксубай һәм Арча муниципаль районнарыннан тыш) яшьләр үзәкләре һәм яшьләр яшүсмерләр клублары базасында 50 яшь гаилә клубы эшләп килә, аларның максаты булып гаилә әгъзаларын уртак мәдәни-ял итү чараларына җәлеп итү аша яшь гаиләләр институтын ныгыту тора. Аларда гаилә төзү, гаиләне һәм гаилә кыйммәтләрен саклап калу буенча әңгәмәләр; гаилә кору һәм гаилә мөнәсәбәтләре төзү күнекмәләренә өйрәтү чаралары; мәдәни һәм спорт чаралары, тренинглар һәм осталык дәресләре форматында эш алып барыла; психологик һәм мәгълүмат ярдәм күрсәтелә. Хәзерге вакытта Аксубай һәм Арча муниципаль районнарында мәдәният учреждениеләре базасында яшь гаилә клублары ачу мәсьәләсе карала.

2023 елның 2 декабрендә Мәскәү шәһәрендә «Россия» халыкара күргәзмә-форумы мәйданчыгында Татарстан Республикасы Көннәрендә Балтач муниципаль районыннан яшь гаилә милли гореф-гадәтләр үрнәгендә гаиләләрен дәүләт теркәве тантанасын уздырды.

Бөтенроссия гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнен бәйрәм итү кысаларында 2023 елда 8 июлендә республиканың барлык муниципаль районнарында төрле массакүләм чаралар уздырылды, аларда 70 комплект «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медале тапшырылды. 2008 елдан Татарстаннан 1 050 гаилә Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медаленә лаек булды.

Республика музейларында музей-белем бирү интерактив программалары, музей дәресләре, экскурсияләр, музыкаль фестивальләр, гаиләләр катнашында уен чаралары, гаилә коруның юбилей даталарын билгеләп үтүче гаилә парлары белән очрашулар, республика территориясендә яшәүче халыкларның гаилә традицияләре һәм йолалары турында күчмә дәресләр, уен арт-мәйданчыклары һәм башка чаралар оештырылды.

Республика гражданнары һәр айның беренче сишәмбесендә Татарстанның дәүләт музейларына, музей-тыюлыкларына, муниципаль музейларга бушлай керә ала.

18 яше тулмаган затларга, шулай ук төп һөнәри белем бирү программалары буенча укучыларга тиешле документ күрсәткән һәм аларга бирелгән бушлай билетлар нигезендә республиканың барлык музейларына һәм музей-тыюлыкларына бушлай керү хокукы (экскурсияләр керми) бирелә.

Театрларда һәм концерт учреждениеләрендә гаилә абонементлары системасы кертелде, күпбалалы гаиләләргә, ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган

балаларга ташламалы билетлар алу һәм бушлай спектакльләр һәм концертлар карау мөмкинлеге бирелә.

Дәүләт һәм муниципаль китапханәләр яшьләрнең игътибарын гаилә традицияләренә саклауга җәлеп итү максатында кызыклы мәдәни-массакүләм чаралар (тематик акцияләр, фестивальләр, ачык һавада уку заллары, китап күргәзмәләре, конкурс-уен программалары, танып-белү сәгатьләре, түгәрәк өстәлләр, викториналар, фотокүргәзмәләр, балалар рәсемнәре конкурслары) уздыру ярдәмендә актив рәвештә гаилә кыйммәтләрен пропагандалый.

Гаилә ялын оештыруның бер төре – ул ел саен уздырыла торган халык бәйрәмнәренә бару, алар арасында иң киң таралганнары: «Сабантуй» татар халык бәйрәме, «Каравон» рус  милли бәйрәме, «Уяв» чуваш мәдәнияте, «Гырон быдтон» удмурт мәдәнияте, «Валда шинясь» мордва мәдәнияте, «Иван Купала» славян мәдәнияте, «Семык» мари мәдәнияте, «Питрау» керәшен мәдәнияте, «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивале бәйрәмнәре, алар хәзерге заман шартларында матди булмаган мәдәни мирасны актуальләштерергә ярдәм итә.

Спорт мәктәпләрендә эш дәүләт һәм муниципаль заданиеләре нигезендә алып барыла, балалар бушлай шөгыльләнә ала, шулай ук яңа язылучылар өчен бюджеттан тыш төркемнәр дә эшләп килә.

Моннан тыш, спорт учреждениеләре локаль-норматив актлар нигезендә ташламалы шартларда хезмәт күрсәтергә хокуклы.

Хәзерге вакытта махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына, пенсионерларга һәм башка категория затларга спорт объектларында шөгыльләнүгә ташламалар каралган.

2024 елда республикада Гаилә елын уздыру максатларында Төп чаралар планы расланды, ул  6 бүлектән һәм 127 чарадан тора:

Гаилә елын уздыру буенча төп чаралар;

сәламәтлекне ныгыту максатларында чаралар;

гаиләләргә ярдәм итүнең төрле формаларын камилләштерүгә юнәлтелгән чаралар;

фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, конференцияләр, форумнар, осталык дәресләре, ярышлар;

гаилә институтын һәм гаилә кыйммәтләрен ныгытуга юнәлтелгән чаралар;

уздырыла торган чараларны һәм басылган мәкаләләрне мәгълүмати тәэмин итү.

Мисал өчен, Казан шәһәрендә берничә чара уздырылачак: «Эшчеләр династиясе» («Казанга курс» гаилә квестын үз эченә ала) проекты, гаилә кыйммәтләре турында медиа проект, интеллектуаль күңел ачу уеннары; «Балаларны яклау көне» бәйрәмендә «Крылья Советов» паркында интерактив мәйданчыклар һәм халык өчен күңел ачу тамашалары оештыру; Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көненә, Әтиләр һәм әниләр көненә багышланган чаралар; ачык дәресләр; Гаилә көненә багышланган гамәли сәнгать күргәзмәсе; «Гаилә» дип аталган гаилә фестивале һәм башкалар.

<u>Әти-әни булуга җаваплы караш формалаштыру.</u>

Татарстан Республикасында йөкле, бала табучы, бала тапкан хатын-кызларга һәм яңа туган сабыйларга акушерлык һәм экстрагениталь патология куркынычы дәрәҗәсен исәпкә алып, медицина хезмәт күрсәтүнең өчбуынлы системасы формалаштырылды:

беренче буын медицина ярдәме (акушерлык һәм экстрагениталь патология куркынычы түбән булган, өзлегүләрсез бала тапкан хатын-кызларга) 37 үзәк район хастаханәсендә күрсәтелә;

икенче буын медицина ярдәме муниципальара үзәкләр һәм Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Лениногорск, Чистай, Зеленодольск шәһәрендәге бала тудыру йортларында күрсәтелә;

өченче буын медицина ярдәме – акушерлык һәм экстрагениталь патология куркынычы дәрәҗәсе югары булган йөкле хатын-кызларга медицина ярдәме күрсәтү тәэмин ителә торган «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 195 ятакка исәпләнгән һәм Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 120 ятакка исәпләнгән перинаталь үзәкләрендә күрсәтелә.

Татарстан Республикасында бала төшерүчеләр саны 2019–2022 елларга 19 процентка кимеде, 2023 елда йөклелеген туктатучыларның гомуми саны 9 094 иде. 2019–2022 елларга бала төшерү очракларының таралышы күрсәткече 18 процентка кимеде, 2023 елда 1 мең бала табу чорындагы хатын-кызга карата 10,1 тәшкил итте.

2023 елга Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы медицина оешмаларына йөклелеген туктату теләге белән 5 440 хатын-кыз мөрәҗәгать итте, шулардан 5 437енә (99,9 %) хатын-кызларга психологик һәм медицина-социаль ярдәме күрсәтү кабинетларында (үзәкләрендә) консультация бирелде. 2023 елда консультация алган йөкле хатын-кызларның 34,6 % ы – 1 876 кешедә йөклелек срогының дөрес куелмавы очраклары күзәтелде (2022 елда 15 %).

2023 елның 30 июнендә репродуктив сайлау алдында торган хатын-кызларга кызыксындыру чарасы буларак анкета сораштыруы уздыру дәүләт милке рәвешендәге 62 медицина оешмасында һәм хосусый милек рәвешендәге 27 учреждениесендә гамәлгә кертелде. Кызыксындыру чарасы буларак анкета сораштыруы кертелгән вакыттан репродуктив сайлау алдында торган 2 953 хатын-кыз анкета сораштыруы узды, бу исә медицина оешмаларына йөклелеген туктату теләге белән мөрәҗәгать иткән хатын-кызларның 97,7 процентын тәшкил итә.

2023 елның августыннан Казан шәһәрендә «Медицина университеты клиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә йөклелеген туктатуга хәтле консультация алуның 2 нче этабы проекты тормышка ашырыла, анда хатын-кызлар консультацияләреннән репродуктив сайлау алдында торган хатын-кызлар җибәрелә, йөклелеген саклап калучылар 43 процентны тәшкил итте (218 хатын-кыз йөклелеген туктатуга хәтле консультация алган, 94е йөклелеген саклап калу турында карар кабул итте).

2023 елга экстракорпораль аталандыру процедурасы ясалды, аларның 38,7 проценты уңышлы узды.

2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан экстракорпораль аталандыру процедурасына 20,2 млн сум күләмендә өстәмә финанс ассигнованиесе бүлеп бирелде.

Яңа туган сабыйларда авыруларны иртә диагностикалау максатында карындагы баланың һәм яңа туган сабыйның үсешендә булган кимчелекләрне пренаталь (карында килеш) диагностикалау уздырыла. Бүгенге көндә республикада

6 карындагы сабыйны антенаталь саклау муниципальара үзәге эшләп килә. 2023 елда 30 437 йөкле хатын тикшерү узды; йөклелек буенча исәпкә баскан хатын-кызларның гомуми саныннан медицина тикшерүе узучылар 95,1 процент тәшкил итә. 181 карындагы балада хромосома патологиясе, 543 балада тумыштан килгән үсеш тоткарлану очрагы ачыкланды.

2023 ел йомгаклары буенча неонаталь скрининг уздыру кысаларында 36 560 фенилкетонурия, тумыштан килгән гипотиреоз, адреногениталь синдромы, галактоземия, муковисцидоз тикшеренүләре уздырылды. 33 авыру очрагы ачыкланды.

2023 елның 1 гыйнварыннан республикада тумыштан һәм нәселдән килгән авыруларның 36 төрен очракларын ачыклау максатыннан яңа туган сабыйларга киңәйтелгән неонаталь скрининг уздырыла башлады. 2023 елда 35 887 яңа туган сабый тикшеренү узды.

2020 елдан Татарстан Республикасында «Яңа туган сабыйга бүләк» акциясе гамәлгә ашырып килә. Әлеге акция кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, кеше башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артык булмаган яңа туган балалары булган гаиләләргә бала кирәк-яраклары белән бүләк комплектлар бирү каралган.

Татарстан Республикасында ясалма һәм катнаш тукланууда булган, кеше башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артык булмаган 3 яшькә хәтле балалары булган гаиләләргә, хроник авырулары булган (анемия, аксым җитмәүнең уртача һәм катлаулы дәрәҗәсе) балаларга, ВИЧ инфекцияле, ВИЧ инфекциясе булган аналардан туган, туберкулез йогышлы авыруы булган, туберкулез йогышлы авыруы чыганагы булган урыннарда яшәүче балаларга бушлай сөт продуктлары бирелә. 2023 елда 3 яшь кадәрле 36 108 бала табиб рецепты буенча балалар туклануы продуктлары белән тәэмин ителде.

Республиканың барлык поликлиникаларында сәламәт бала кабинетлары оештырылды. Хатын-кыз консультацияләрендә исәптә торучы барлык йөкле хатын-кызлар сәламәт бала кабинетына җибәрелә, анда «Буларак аналар мәктәбе» эшли. Моннан тыш, әлеге мәктәпләрдә йөкле хатын-кызларны бала табуга, баланы карап-тәрбияләүгә әзерләү буенча лекцияләр уздырыла.

Яшь гаиләләргә һәрьяклы ярдәм күрсәтү, уңай гаилә кыйммәтләре формалаштыру, гаилә потенциалын үстерү өчен шартлар булдыру Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы алдында торган өстенлекле бурычларның берсе булып тора.

Бүгенге көндә Татарстанда 35 яшьләр үзәге, 225 тору урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары, 7 балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге базасында гаилә институтын ныгытуга, яшьләр арасында рухи-әхлакый хәзинәләрне һәм гореф-гадәтләрне саклауга юнәлтелгән киң колачлы чаралар уздырыла. 2023 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында алар базасында 80 мең кеше катнашында 764 гаилә чарасы үткәрелде.

Яшьләр, шул исәптән яшь гаиләләр белән актив хезмәттәшлек итү һәм алар белән бәйләнышлар урнаштыру максатында ата-аналарга актуаль темалар буенча «Олыларда һәм балаларда депрессия чагылышлары һәм ярдәм итү ысуллары»,

«Конструктив булмаган берләшмә әгъзасы портреты», «Гаиләдә шәхси чикләр» һ.б.) психологик ярдәм итүгә юнәлдерелгән медиа-чаралар оештырылды, алар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау республика комиссиясе тарафыннан уздырыла торган туры эфирлар рәвешендә үткәрелә. 2021 елдан 41 эфир уздырылды, эфирларның язмалары «Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте» youtube-каналында куела һәм бүгенге көндә аларны 57 меңнән артык кеше карады.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство карамагындагы учреждениесе – «Новигатор» яшьләр, инновация һәм профилактика программалары республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан балалар һәм гаилә психологиясенең актуаль психологик аспектлары буенча онлайн-вебинарлар сериясе оештырылды. Вебинарларны Казан шәһәренең яшьләргә кагылышлы проблемалар белән эшләүче гамәли психологлары алып бара. Вебинарлар барышында һәр кешенең үзен кызыксындырган сорауларын бирү һәм консультация алу мөмкинлеге бар. 2023 елда 1 839 кеше катнашында 7 онлайн-вебинар уздырылды.

**19. Татарстан Республикасында балаларның җәйге ялын һәм сәламәтлеген ныгыту программаларын әзерләү һәм оештыру, балаларны эш белән тәэмин итү .**

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру» ярдәмче программасын гамәлгә ашыруга 2023 елда 2 156,65 млн сум акча бүлеп бирелде.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары нигезендә 2023 елда түбәндәгеләр белән бәйле чыгымнарны каплауга акча бүленде:

балаларның сәламәтлеген ныгыту лагерьларын саклауга – 28,650 млн сум;

Россия Федерациясенең башка субъектларыннан балаларның ялын оештыруга (Россия Федерациясенең яңа субъектларыннан эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең 40 баласы һәм аларны озатып баручы 6 кеше, Луганск Халык Республикасыннан 200 бала һәм аларны озатып баручы 13 кеше) – 11,587 млн сум.

Татарстан Республикасы бюджетында 2024 елга «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру» төбәк проектын гамәлгә ашыруга чыгымнарны каплауга 2 294,04 млн сум бүлеп бирелде.

Шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан балаларның сәламәтлеген ныгыту лагерьларын саклауга 654 млн сум күләмендә өстәмә акча бүлеп бирелде, шул исәптән дәүләт лагерьларын саклауга – 323 млн сум, муниципаль лагерьларны саклауга – 331 млн сум.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов карары нигезендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучылар гаиләләреннән 3 644 баланың ялын оештыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024 елда 712 млн сум акча бүлеп бирелде.

«Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру» төбәк проекты кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024 елда 43 415 юллама (2023 елда – 43 191 юллама) тулы күләмдә финансланылачак, шулардан:

11 081 – авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен;

4 700 – балалар өчен санаторий-курорт оешмаларында «Балалар» һәм «Ана һәм бала» юлламасы буенча тернәкләндерү-дәвалауга мохтаҗ, шулай ук хроник авырулары булган балалар өчен;

3 000 – гражданлык-ватанпәрвәрлек юнәлешендәге палата тибындагы лагерьларында ял итү өчен хәрби хезмәткә чакырылу яшенә җитәчәк яшүсмерләр өчен;

5 000 – югары белем бирү оешмалары студентларына физкультура-сәламәтләндерү чараларын оештыруга;

11 315 – мәктәпләрдәге көндезге лагерьлар кысаларында хезмәт һәм ял лагерьларында ял итү өчен мәктәп укучыларына;

8 319 – сәләтле балаларга (фән олимпиадаларында җиңүчеләргә, призерларга, иҗат конкурслары лауреатларына, спорт ярышлары призерларына) шәһәр яны лагерьларындагы профильле сменаларда ял итүгә, шул исәптән Кара диңгез яр буенда ял итүгә 1 224 юллама һәм «Сәләт» форумында катнашучылар өчен 2 200 юллама.

Ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары нигезендә расланган «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан җәйге каникулларда һәм укудан буш вакытта 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрле балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру буенча эш алып барыла.

Яшүсмерләрне укудан буш вакытта эш белән тәэмин итү ата-ана контроленнән читтә калган балаларын санын киметү, балигъ булмаганнар арасында наркомания, алкоголь һәм спиртлы эчемлекләр куллану очракларын профилактикалау чарасы булып тора.

Республиканың халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре ярдәме белән яшүсмерләрнең 40 проценты хезмәт өчен түләү мөмкинлеге булмаган бюджет оешмаларына (мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт, мәгариф һәм башкалар) эшкә урнаша. Бу очракта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан яшүсмерләрнең хезмәте өчен түләүгә муниципаль берәмлекләр бюджетыннан акча бүлеп бирү мәсьәләсе карап тикшерелә.

Яшүсмерләрне эш белән тәэмин итү мәсьәләсенең актуальлеген исәпкә алып, ел саен муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары тарафыннан балигъ булмаган гражданнарны муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан бюджет учреждениеләрендә вакытлыча эшләгән өчен хезмәт хакы түләүгә акча бүлеп бирелә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре аша эшкә урнашкан яшүсмерләргә эш бирүче түләгән хезмәт хакыннан тыш халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан матди ярдәм дә күрсәтелә. 2023 елда аның күләме бер ай эшләгән өчен 2 250 сум тәшкил итте.

2023 елда 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрле балигъ булмаган гражданнарны (12 980 яшүсмер) вакытлыча эшкә урнаштыруга 31,2 млн сум акча бүлеп бирелде, алар балигъ булмаган гражданнарга матди ярдәм түләүгә юнәлдерелде.

Балалар эшли торган төп эш төрләренә – мәктәпләрне, спорт мәйданчыкларын төзекләндерү, шәһәр һәм авылларны төзекләндерү һәм агач-үсемлекләр утырту буенча, экологик эшләр башкаруда (елга, күлләрнең яр буйларын, урманнарны, урман полосалары юл буйларын чүпләрдән чистарту) ярдәмче эшләр, авыл хуҗалыгында ярдәмче эшләр (авыл хуҗалыгы культураларын утырту, чүпләрен утау, үстерү һәм җыю), сәнәгать предприятиеләрендә, зоопаркта ярдәмче эшләр, һәйкәлләрне, мемориалларны тиешле тәртиптә тоту белән бәйле эшләр һәм башкалар керә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан 2024 елда балаларның сәламәтлеген ныгыту кампаниясе чорында төп 3 юнәлештә чаралар комплексы уздыру планлаштырыла:

сәламәтләндерү учреждениеләренә эшкә баручы персоналга профилактик медицина тикшеренүләре уздыруны оештыру;

Персоналга профилактик медицина тикшеренүләре уздыруның оештырылуына «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчерлык үзәге» мониторинг уздыра һәм әлеге эшне координацияли. Вакытлыча эшкә урнашкан балигъ булмаган балаларга профилактик медицина тикшеренүе Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтүгә дәүләт гарантияләре программасы нигезендә территориаль балалар поликлиникалары (консультацияләре) базасында бушлай уздырыла.

ял итү һәм сәламәтлекне ныгыту учреждениеләрендә балаларга медицина ярдәме күрсәтү;

Ял итү һәм сәламәтлекне ныгыту учреждениеләрендә балаларга медицина ярдәме күрсәтүне контрольдә тоту, санитария нормаларын үтәүгә кагылышлы мәгълүмат бирү максатларында республика медицина учреждениеләре, балалар поликлиникалары һәм үзәк район хастаханәләре белгечләре урыннарга барып, тикшерүләр уздыра.

2024 елда балаларның санаторияләрдә дәвалануын оештыру максатларында хроник авырулары булган 2 850 баланың, шулай ук хроник авырулары булган һәм авыр тормыш хәлендә калган 3 меңнән артык баланың санаторияләрдә дәвалануын оештыру планлаштырыла.

Бүгенге көндә «Россиядә эш» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре цифрлы платформасында «балигъ булмаганнар өчен эш» соратуы буенча 163 вакансия бирелгән.

**20. Мобилизацияләнгән гражданнар гаиләләренә ярдәм чараларын оештыру турында.**

Татарстан Республикасында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү эше оештырыла, түбәндәге бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр билгеләнде:

махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның 18 яшькәчә һәр баласына 20 мең сум күләмендә;

махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына 2,0 млн сум күләмендә;

Татарстан Республикасында махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына ярдәм итүнең түбәндәге чаралары каралган:

яңа туган балалары булган гаиләләрне, кеше башына уртача керемне исәпкә алмыйча, бала кирәк-яраклары өчен бүләк комплектлары белән тәэмин итү;

гаилә әгъзалары булып торучы пенсионерларга һәм 60 һәм 55 яше тулган гражданнарга (тиешенчә хатын-кызларга һәм ир-атларга) санаторий-курорт дәвалануы өчен беренче чиратта юлламалар бирү;

олы яшьтәге гражданнарга, I һәм II төркем инвалидларга өйдә бушлай социаль хезмәтләр күрсәтү;

олылар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда, психик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернат-йортларда, мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә өстенлекле хокук бирелү;

гаилә әгъзалары булып торучы инвалид балаларга мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә өстенлекле хокук бирелү;

тиешле эш табу максатында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләрендә теркәлеп, гариза калдырган гаилә әгъзасын, аңа туры килә торган эш табу мөмкин булмаган очракта, эшсез дип тану вакытын киметү (тиешле эш эзләүдә булышуны сорап дәүләт хезмәт күрсәтү турында гариза бирелгән көннән соң 3 көннән дә артык булмаган вакытта);

Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча көндезге уку бүлекләрендә укучы студентларга бер тапкыр кайнар ризык белән бушлай туклану мөмкинлеге бирелү;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының 1–11 сыйныф укучыларына көненә ике тапкыр бушлай кайнар ризык белән (иртәнге һәм көндезге аш) туклану мөмкинлеге бирелү;

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче 7 яшьтән алып 17 яшькә кадәрле балалары булган гаиләләргә ялга юлламалар алуга беренчел хокук бирелү;

18 яшькә кадәрле балаларга һәм әтисенә йә әнисенә (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләрендә уздырыла торган чараларга бушлай керү хокукы бирелү;

Түбәндәге өстәмә ярдәм чаралары расланды:

билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре тарафыннан аларның шәхси эш ачуга бизнес-планнарын беренчел чиратта карап тикшерү;

3 һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләргә, әгәр әтисе йә әнисе хәрби хезмәткәр булган очракта, гражданнарның Татарстан Республикасында 5 ел дәвамында даими яшәргә тиешлеге таләбен исәпкә алмыйча, җир кишәрлекләре бирү;

гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан бер йорт исәбеннән йортка газ уздыру һәм өй эченә куела торган газ җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга тотылган чыгымнар исәбеннән, ләкин 100 мең сумнан да артык булмаган күләмдә субсидия бирү;

Россия Федерациясе Президентының 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Указының 2 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән затларның һөнәри белем алуын һәм өстәмә һөнәри белем алуын оештыру.

Шулай ук адреслы ярдәм чаралары да, шул исәптән психологик, юридик һәм көнкүреш ярдәме күрсәтелә.

**21. Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында.**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып социаль ятимлекне кисәтү, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга ярдәм итү системасын булдыру, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча законнарның үтәлешен тәэмин итү тора.

2023 елда ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган 9 282 баланың 8 696 ы тәрбиягә алынды.

«Татарстан Республикасы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында аерым категория гражданнарга акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары нигезендә ел саен түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициенты билгеләнә. 2023 елда мәктәп укучыларына бирелә торган айлык акчалата түләү 11 907 сум, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалар өчен – 10 326 сум тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга өстәмә рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2017 елның 13 июлендәге 493 номерлы карары нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга 200 мең сум күләмендә акчалата түләү билгеләнде. 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга өстәмә рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү белән бәйле чыгымнарны каплауга 1,2 млн сум бүлеп бирелде, 2024 елга әлеге максатларга 2,0 млн сум каралган.

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның гомуми саныннан республикада ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү тиешле торак пункт шартларына яраклаштырып уңайлылыклар тудырылган әзер торак йортлар бирү юлы белән тормышка ашырыла.

2013 елдан 2023 елга кадәр балигъ булу яшенә җитеп, балалар йортларыннан һәм әти-әнине алмаштыручы гаиләләрдән киткән 4 728 бала торак белән тәэмин ителде, шул исәптән 2023 елда – 762 бала. Татарстан Республикасы бюджетында 2024 елга әлеге максатларга 147,9 млн сум каралган.

Республиканың социаль яклау системасында психик тайпылышлары булган балалар өчен 2 интернат-йорт эшләп килә:

«Дербышки психик тайпылышлары булган гражданнар өчен балалар интернат-йорты» дәүләт казна учреждениесе;

«Югары Утар психик тайпылышлары булган гражданнар өчен балалар интернат-йорты» дәүләт казна учреждениесе.

2024 елның 16 февраленә әлеге учреждениеләрдә 212 кеше тәрбияләнә, шул исәптән 140 балигъ булмаганнар һәм 72 балигълык яшенә җитүчеләр. Барлык тәрбияләнүчеләрең гомуми санынннан 34 кеше ятим, 137 кеше ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калучы булып тора, 41 кеше әти-әнисе гаризасы буенча кабул ителде.

Мәгариф өлкәсе законнары нигезендә интернатларда эшләүче барлык тәрбиячеләрнең психология-медицина-педагогия комиссияләре бәяләмәләре һәм (яисә) инвалид баланы тернәкләндерү буенча белем алу өчен махсус шартлар күрсәтелгән индивидуаль программа узу турында бәяләмәсе булырга тиеш.

Интернатта тәрбияләнүчеләргә белем бирүне Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт мәгариф оешмалары тормышка ашыра.

49 интернатта тәрбияләнүчеләргә өстәмә белем (өч юнәлештә: сәнгать, спорт, техник түгәрәкләр) бирелә.

Ике интернатта да тәрбияләнүчеләргә социаль-көнкүреш күнекмәләре бирү һәм аларны кеше тәрбиясендә яшәүгә әзерләү буенча барлык шартлар да тудырылган. «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе базасында өч ай дәвамында интернатта тәрбияләнүчеләр кеше тәрбиясендә яшәү күнекмәләре алды. «Дербышки психик тайпылышлары булган гражданнар өчен балалар интернат-йорты» дәүләт казна учреждениесен тәмамлаучылар (7 кеше), укуларын уңышлы тәмамлап, Казан шәһәрендә «ИгелекТелим» социаль җайлаштыру үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасында яшәүгә күчерелде.

Федераль һәм республика норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасында ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, шул исәптән уллыкка (кызлыкка), опекага, гаиләләргә тәрбия алынган балалар өчен диспансер тикшеренүе оештырылды. 2023 елда 1 042 ятим балалар һәм авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен стационар учреждениеләрдә тәрбияләнүче 1 042 бала диспансеризация узды (планның 10,2 %).

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, шул исәптән уллыкка (кызлыкка), опекага (попечительлеккә), гаиләләргә һәм тәрбия яки патронат гаиләгә алынган балалар диспансер тикшеренүен алар яшәү урыны буенча теркәлгән балалар поликлиникаларында уза. 2023 елда билгеле бер категория балаларга диспансеризация уздыруда 60 медицина учреждениесе катнашты. 4 836 бала тикшеренү узды, бу еллык планның 100,5 %ы.

Татарстан Республикасында барлык категория балаларның һәм яшьләрнең ялын нәтиҗәле оештыруга зур игътибар бирелә, шулай ук аларның физик, рухи һәм әхлакый үсеше өчен барлык шартлар да тудырылган.

2023 елда яшьләр үзәкләре, яшүсмерләр клублары, шулай ук муниципаль районнарның җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре тарафыннан 2 292 ятим бала һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала катнашында 246 чара оештырылды.

Җәйге каникуллар чорында балаларның сәламәтлеген ныгыту кампаниясендә 2023 елда 10 833 авыр тормыш хәлендә калган бала катнашты, шулардан:

1 151 ятим бала, мәктәп-интернатта тәрбияләүчеләр һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле бала;

гаиләгә тәрбиягә алынган 300 бала;

опекун гаиләләрендәге 1 мең бала.

«Раифаның ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениесе» федераль дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесендә (алга таба – Раифа ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениесе) тәрбияләүчеләргә һәръяклы ярдәм күрсәтелә. 2023 елда учреждениедә тәрбияләнүче балаларга Яңа ел бүләкләре тапшырылды. Раифа ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениесендә тәрбияләүчеләр 2023 елның 21 сентябреннән 26 сентябренә кадәр Чечня Республикасы территориясендә уздырылган «Россиянең куәте» дип аталган төрле төр профилактик исәптә торучы балигъ булмаган балалар өчен лагерь сменасында катнашты. Шулай ук яшүсмерләрнең хокук өлкәсендәге белемнәрен арттыру максатларында Раифа ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениесендә Балаларга хокукый ярдәм күрсәтү бөтенроссия көненә багышланган «Хокукый лабиринг» дигән квест-уен уздырылды.

Казан шәһәренең «Дуслык» девиант тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль-тернәкләндерү үзәге» базасында 123 бала тернәкләндерү программасы узды (ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен вакытлыча яшәү урыны белән тәэмин итеп, социаль хезмәтләр күрсәтү комплексы). Әлеге үзәктә булган вакытта 36 балигъ булмаган балага документларын рәсмиләштерү һәм торгызу буенча ярдәм күрсәтелде. Педагоглар составы тарафыннан балаларның тәртибендә һәм үзен-тотышында булган кимчелекләрне бетерү, төрле бәйлелекләрдән азат итү буенча зур эш алып барылды. 129 кешедән торган педагоглар, психологлар һәм социаль педагоглар коллективы тарафыннан консультацияләр, 718 тематик дәрес, 410 профилактик әңгәмә, 78 ял итү чарасы үткәрелде.

**22. Татарстан Республикасында аналар, балалар һәм хатын-кызлар хокуклары мәсьәләләренә бәйле эшчәнлек башкаручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт ярдәме турында.**

Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның (алга таба – СЮКБ оешма, КБ оешма) республика социаль-икътисадый үсешендә катнашуын стимуллау, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм этноконфессиональ татулыкны саклап калу, социаль сәясәтнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм халыкка күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту, дәүләт һәм җәмәгатьчелек мәнфәгатьләренең балансны булуы нигезендә җәмәгатьчелек килешүен тәэмин итү максатларында, 2023 елда «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм» төбәк проектын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 316,24 млн сум күләмендә акча җибәрелде. 2024 елда әлеге максатлар өчен 329,8 млн сум акча каралды.

2023 елда «Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм буенча республика ресурс үзәге» АКБ оешмасы (КБ оешмаларга грантлар бирү конкурсларын үткәрү буенча бердәм грант операторы) тарафыннан түбәндәге 2 конкурс уздырылды:

- Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга грантлар бирүгә (конкурс фонды – 35 млн сум);

- гражданлык җәмгыятен үстерү өчен Татарстан Республикасы грантларын бирүгә (конкурс фонды – 106,6 млн сум, шуларның 53,3 млн сумы – Президент грантлары фондыннан финанслашу).

«Гаиләгә, аналарга, аталарга һәм балачакка ярдәм» юнәлеше буенча конкурслар йомгаклары нигезендә 20 СЮКБ оешма 9,2 млн сум күләмендә грант алды.

Шулай ук СЮКБО оешмаларга грант ярдәме федераль дәрәҗәдә дә күрсәтелә. 2017 елдан башлап, конкурслар үткәрү һәм Россия Федерациясе Президенты грантларын бирү Президент грантлары фондына (гражданлык җәмгыятен үстерү буенча Президент грантлары операторына) тапшырылды.

2023 елда Президент грантлары фонды тарафыннан 2 конкурс үткәрелде, аларның йомгаклары буенча «Гаиләгә, аналарга, аталарга һәм балачакка ярдәм» юнәлеше буенча Татарстан Республикасының 13 СЮКБ оешмасы барлыгы 21,97 млн сум күләмендә грант алды.

«Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы нигезендә халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган секторны үстерү чаралары уздырыла. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрын һәм социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләр регистрын төзү һәм алып бару турында» 2014 елның 23 декабрендәге 1012 нче карары белән Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрын (алга таба – реестр) төзү һәм алып бару тәртибе расланды.

Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2016 елның 29 декабрендәге 1046 нчы карары белән расланды.

2024 елның 1 февраленә карата реестрга 29 дәүләтнеке булмаган оешма, шул исәптән өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга, тормышта авыр хәлдә калган, мөмкинлекләре чикләнгән балаларга һәм яшүсмерләргә тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүче 20 СЮКБ оешма кертелде.

2015 елдан социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, дәүләтнеке булмаган тәэмин итүчеләр саны 10 тапкырга диярлек (3 оешмадан 29 оешмага кадәр) артты. 2015 елдан социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең гомуми санында дәүләтнеке булмаган оешмалар өлеше 2,3 процենттан 20,6 процентка кадәр артты.

2023 елда 19 оешма, шул исәптән сайлап алуда җиңгән 15 СЮКБ оешма белән социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр төзелде.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021–2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 елның 13 февралендәге 77 нче карары нигезендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән «Содействие» социаль ярдәм үзәге» АКБО тарафыннан өлкән гражданнарга

(инвалидларга) «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирелде.

2023 ел нәтиҗәләре буенча дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан 10 693 кешегә, шул исәптән СЮКБ оешмалар тарафыннан 8 825 кешегә хезмәт күрсәтелде. Әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 323,1 млн сум, шул исәптән СЮКБ оешмаларга 276,5 млн сум акча бүлеп бирелде.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнгән вәкаләтләр кысаларында халыкның бик еш авырый торган төркемнәреннән социаль әһәмиятле чирләр белән интегүче затларга медицина-социаль ярдәм күрсәтүгә, халыкка мәгълүмат җиткерүгә һәм җәмәгатьчелек сәламәтлеген пропагандалауга юнәлдерелгән программаларны гамәлгә ашыру өлешендә СЮКБ оешмалар белән үзара хезмәттәшлек гамәлгә ашырыла.

СЮКБ оешмаларга ярдәм күрсәтү эшләре «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы кысаларында «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм» төбәк проекты кысаларында алып барыла.

Республикада ВИЧ/СПИД проблемасы буенча 7 СЮКБ оешма эшчәнлек алып бара: Татарстан Республикасының «Профилактика һәм инициатива» ТИО, Казан шәһәренең Наркотикларга бәйле затлар туганнарының «Вера» иҗтимагый оешмасы, «Яңа гасыр» автоном хәйрия коммерциячел булмаган оешмасы, «Халыкка гигиена буенча белем бирү үзәге» АКБО, «Светлана Изамбаева» коммерциячел булмаган хәйрия фонды, «Шаг навстречу» системалы чишелешләр үзәге» АКБО, «Бумеранг» тормышта авыр хәлдә калган затларга ярдәм үзәге» АКБО.

Шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Рак победим» иҗтимагый оешмасы белән актив хезмәттәшлек итә.

2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең төзәтү учреждениеләре базасында психоактив матдәләргә бәйле булуга эләккән хөкем ителгәннәрне реабилитацияләү буенча наркотикларга каршы өлкәдә проектларны гамәлгә ашыручы СЮКБ оешмаларга бирү өчен 3,54 млн сум акча бүлеп бирелде. Үткәрелгән конкурс йомгаклары буенча Наркотикларга бәйле затлар туганнарының «Вера» иҗтимагый оешмасы җиңү яулады.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль автоном һәм бюджет яшьләр сәясәте учреждениеләренә грантлар турында» 2022 елның 6 апрелендәге 316 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыру өчен яшьләр сәясәте буенча муниципаль учреждениеләргә грантлар бирү конкурсы уздырыла. 2024 елда конкурс кысаларында социаль әһәмиятле гаилә проектларын гамәлгә ашыруга 9,7 млн сум күләмендә акча бүлеп бирелде, шул исәптән:

Арча муниципаль районының «ФОРПОСТ» үзәге» базасында «#СәламәтАрча» проекты кысаларында гаилә туризмы чараларына;

Алабуга муниципаль районының «Барс» яшьләр үзәге базасында «Уң як яр. Яшь гаиләләр» форумына;

Тукай муниципаль районының «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» базасында «Гаилә бәхете формуласы» чаралары циклына;

Питрәч муниципаль районының «Яшьләр үзәге» базасында «Гаилә иле – Гаилә дөньясы» яшь гаиләләр фестиваленә һ.б.

Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын комплекслы тернәкләндерү проектлары уңышлы тормышка ашырыла. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, «Ватанны саклаучылар» фонды белән берлектә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның хатыннары өчен эмоциональ тигезлекне саклап калуга юнәлдерелгән арт-терапия элементлары белән ярдәм төркемнәре оештырылды. Әлмәт шәһәрендә махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче гражданнарның гаилә әгъзалары өчен «Ретрит-2023» проекты үткәрелде. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары, хатыннары һәм аналары төркем белән яисә индивидуаль рәвештә берничә төрле очрашуларда, интенсивларда, киеренкелекне бетерү һәм ял итү чараларында катнаштылар.

Республикада гаилә төзелеше өлкәсендә яшь буынга аң-белем бирүгә юнәлдерелгән күпсанлы программалар эшли. 2022 елдан «Әтиләр берлеге» Татарстан Республикасы төбәк иҗтимагый оешмасы ярдәме белән психологик-педагогик культураны формалаштыруга һәм ата-аналарның компетентлыгын арттыруга юнәлдерелгән «Аңлы ата-аналар мәктәбе» проекты гамәлгә ашырыла, бу балалар һәм ата-аналар мөнәсәбәтләренә һәм балаларның һәм яшүсмерләрнең психик сәламәтлеген саклауга уңай йогынты ясый. Программа тәҗрибәле психологлар һәм педагоглар тарафыннан эшләнде, аның кысаларында аналар һәм аталар гаилә һәм балалар психологиясе һәм педагогикасы өлкәсеннән «бертигез» форматында алдынгы белемнәрне алалар, чикләр булдырырга һәм проблемаларны конфликтсыз хәл итү кагыйдәләрен урнаштырырга өйрәнәләр, бала белән актив хезмәттәшлек итү һәм гармонияле мөнәсәбәтләр урнаштыру буенча конкрет алгоритмнар һәм алымнар үзләштерәләр.

«Татарстан Республикасының Аналар җәмгыяте» автоном коммерциячел булмаган оешмасы актив эш алып бара. Әлеге эшчәнлек кысаларында аз керемле яшь гаиләләр өчен 300дән артык хәйрия проекты гамәлгә ашырылды, декрет ялында булган 40 мең ана өчен онлайн укыту үткәрелде, алар барлыгы 520 мең тапкыр каралды, атна саен юристларның, психологларның, диетологларның бушлай консультацияләре оештырыла.

**23. Республиканың зур шәһәрләрендәге яңа микрорайоннар территорияләрендә яңа сәламәтлек саклау, мәдәният, мәгариф учреждениеләрен төзү (ачу) перспективалары турында.**

2024 елда Татарстан Республикасының зур шәһәрләре территориясендә түбәндәге социаль объектларны төзү планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла:

Мәдәният өлкәсендә.

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түбәндәгеләр төзелә:

Казан шәһәрендә «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры»ның яңа бинасы (программадан тыш объект);

Буа шәһәрендә Б.Урманче музее (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 28 октябрендәге 2384-б нче боерыгы).

Мәдәният учреждениеләрен төзү мәсьәләсе яңа микрорайоннар территорияләрендә актуаль булып тора. Мәсәлән, Казан шәһәренең «Азино-1», «Салават Күпере», «Светлая долина», «Весна» торак комплексларында яңа мәдәният учреждениеләрен төзүгә ихтыяҗ зур.

Шуңа бәйле рәвештә Казан шәһәрендә Казан шәһәренең Совет районындагы «Азино» торак массивы өчен күпфункцияле мәдәни үзәкнең проекты эшләнә. Аны төзү мәсьәләсе аларда яшәгән кешеләрнең депутатлар корпусы вәкилләре һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчелеге белән очрашуларында күтәрелде. Бертип проекты буенча 350 урынга исәпләнгән күпфункцияле мәдәният үзәге төзү өчен Җиңү проспекты буенча 172 нче йорт янында урнашкан 4 637 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеге резервланды. Төзелешнең якынча кыйммәте 406,2 млн сум тәшкил итә.

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе» ДАУ дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алганнан соң, «Мәдәният» илкүләм проектының «Мәдәният тармагының төбәк һәм муниципаль учреждениеләрен реновацияләү» чараларын гамәлгә ашыруда катнашу максаты белән Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгына тиешле заявка җибәреләчәк.

Хәзерге вакытта Яңа Савин районында, Казан шәһәренең Салмачи һәм Колсәет поселокларында мәдәният йортлары өчен җир бүлеп бирү мәсьәләсе җентекләп өйрәнелә.

Питрәч муниципаль районында, актив торак төзелүгә бәйле рәвештә, яңа мәдәният учреждениеләрен төзүгә ихтыяҗ бик зур. Богородский авылының хәзерге мәдәният йорты эшен кимету өчен Гильдеево авылында мәдәният йорты төзергә кирәк, бу мәсьәлә буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләре бар, шул ук вакытта Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан башлангыч проект документациясен эшләү алып барылмый. Шундый ук хәл Царево village яңа торак массивында күзәтелә, анда 13 мең кеше яши, клуб юк.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә.

2024 елда сәламәтлек саклау системасының беренчел звеносын модернизацияләү буенча федераль программаны гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәгеләр төзелә:

Казан шәһәренең «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ поликлиникасы филиалы (Казан шәһәре, «Салават Күпере» торак комплексы);

«Түбән Кама шәһәренең Перинаталь үзәге булган балалар район хастаханәсе» ДАССУнең 3 нче балалар поликлиникасы филиалы (Түбән Кама шәһәре, 35 нче микрорайон).

Түбәндәгеләрне төзү планлаштырылды:

Казан шәһәренең «7 нче балалар шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУнең гомуми практика табибы һәм участок педиатрлары офисы (Казан шәһәре, «Борисоглебское» торак комплексы);

«Социаль-иҗтимагый инфраструктура объектларын капиталь ремонтлау (2024 елда стационар сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау)» программасы кысаларында Казан шәһәренең «Профессор К.Ш. Зыятдинов исемендәге 18 нче үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУнең кабул итү һәм диагностика бүлеге (Казан шәһәре, Хөсәен Мәүлетов урамы, 3 нче йорт);

программадан тыш чаралар кысаларында 100 койкага исәпләнгән бала тудыру йорты (Бөгелмә шәһәре);

«Биектау үзәк район хастаханәсе» ДАССУ поликлиникасы филиалы.

Мәгариф өлкәсендә.

2024 елда республиканың зур шәһәрләрендәге яңа микрорайоннар территорияләрендә түбәндәге гомуми белем бирү оешмаларын төзү планлаштырыла:

7 621 урынга исәпләнгән 6 мәктәп (Лаеш муниципаль районының Сокуры авылында, җиһаз, җайланма һәм инвентарь сатып алып, 1 224 урынлык мәктәп; Биектау муниципаль районының Биектау авылында, территориясен төзекләндереп һәм җиһаз, җайланма һәм инвентарь сатып алып, 1 224 урынлык мәктәп; Казан шәһәрендә 1 224 урынлык мәктәп (Родин урамы); Казан шәһәренең Идел буе районындагы М-14 микрорайонында, территориясен төзекләндереп һәм җиһаз, җайланма һәм инвентарь сатып алып, 1 224 урынлык мәктәп; Казан шәһәренең «Весна» торак комплексында 1 224 урынлык мәктәп; Лаеш муниципаль районының Усад авылында 1 501 урынлык мәктәп);

«Алгоритм» технология лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә, җиһаз, җайланма һәм инвентарь сатып алып, 600 урынга исәпләнгән өстәмә корпус (Питрәч муниципаль районының Көек авылы);

1 640 урынга исәпләнгән 7 балалар бакчасы (Питрәч муниципаль районының Көек авылындагы «Яшьлек» микрорайонында 260 урынлык балалар бакчасы; Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Солнечная урамында 220 урынлык балалар бакчасы; Казан шәһәренең Бохара урамы буенча 260 урынлык балалар бакчасы; Казан шәһәренең Ягодинская урамында 80 урынлык балалар бакчасы; Питрәч муниципаль районының «Царево» торак комплексында, җиһаз, җайланма һәм инвентарь сатып алып, 340 урынлык балалар бакчасы; Лаеш муниципаль районының «Яңа Сокуры» коттедж поселогында, җиһаз, җайланма һәм инвентарь сатып алып, 220 урынлык балалар бакчасы; Казан шәһәренең «Салават күпере-2» торак комплексында, җиһаз, җайланма һәм инвентарь сатып алып, 220 урынлык балалар бакчасы).

2024 елда Татарстан Республикасы буенча, гомумән алганда, 9 183 урынга исәпләнгән 10 мәктәп (шул исәптән гамәлдәге мәктәпләргә 870 урынга исәпләнгән 2 өстәмә корпус) һәм 1 900 урынга исәпләнгән 8 балалар бакчасы төзү каралды. Шулай ук «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында 2024–2025 елларда мәктәпкә 375 урынга исәпләнгән өстәмә корпус һәм 80 урынга исәпләнгән балалар бакчасы төзү каралды.

## Сәламәтлек саклау

### 24. Татарстан Республикасында онкология авыруларын иртә ачыклау һәм профилактикалау, әлеге учреждениеләрнең матди-техник базасын арттыру һәм ныгыту буенча башкарыла торган эш турында.

Республикада «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектына керә торган «Онкология авыруларына каршы көрәш» төбәк проекты гамәлгә ашырыла. Аны гамәлгә ашыру кысаларында онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазлауга акча каралды. 2023 елда

әлеге максатлар өчен федераль бюджет акчасы исәбеннән 71,637 млн сум күләмендә финанс чаралары җибәрелде.

2024 елда Татарстан Республикасы бюджетында әлеге максатларга 97,448 млн сум акча, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән 78,933 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 18,515 млн сум күләмендә финанс чаралары каралды.

Моннан тыш, 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетында сәламәтлек саклау учреждениеләрен матди-техник тәэмин итү өчен 226,941 млн сум күләмендә акча каралды.

Диспансеризациянең иң мөһим компоненты – яман шеш авыруларын башлангыч стадияләрдә ачыклауга юнәлдерелгән онкоскрининг. 2013 елдан диспансеризация кысаларында онкоскрининг үткәргәндә эшләнгән махсус методик киңәшмәләр кулланыла, медицина учреждениеләрендә бердәм алымнар кертү оештырыла. 2017 елдан берничә махсуслаштырылган һәм күппрофильле клиника базасында лаборатория һәм инструменталь тикшеренүләрне үзәкләштерү моделе гамәлгә ашырыла.

Яман шеш авыруларын башлангыч (I – II) стадияләрдә ачыклау – яман шешләрне дәвалау нәтиҗәлелеген билгели торган факторларның берсе, ул дәвалануга яхшы шанслар бирә. Башлангыч стадияләрдәге яман шеш авыруы белән авырганда сәламәтләнү очрагы 85–95 % тәшкил итә. Шул ук вакытта авыру соңгы стадияләрдә булганда әлеге күрсәткеч 35–45 процентка кадәр кими.

2023 елда яман шеш авыруларын башлангыч стадияләрдә ачыклауны арттыру максатларында түбәндәге чаралар уздырылды:

акушер-гинекологларда һәм карау кабинетларының акушеркаларында (фельдшерларында) беренче тапкыр булу кысаларында 18 яшьлек һәм аннан олырак 512 040 хатын-кызга аналык муентыгы патологиясен ачыклауга цитологик скрининг тикшерүен 2 елга 1 тапкыр үткәрү;

50–69 яшьлек 13 467 хатын-кызга маммография скрининг тикшерүен үткәрү;

килеп чыгу куркынычы төркеменә керүче контингентның сулыш органнарында онкология авыруларын алдан ачыклау максатларында 1 000 пациентка скрининг үткәрү.

Өлкәннәрнең билгеле бер төркемнәренә профилактик медицина тикшерүләрен һәм диспансеризация үткәрү кысаларында 2023 елда яман шеш авырулары белән 2 602 авыру очрагы, шулардан башлангыч (I – II) стадияләрдә булган 1 925 авыру очрагы (74 %) билгеләнде.

Яман шеш авыруларын профилактикалау һәм гражданнарның үз сәламәтлеген саклауга җаваплы мөнәсәбәтләрен формалаштыру буенча мәгълүмат-коммуникация эше гамәлгә ашырыла.

Үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә 2023 елда Татарстан Республикасында 17 307 яман шеш белән авыру очрагы, шулардан 10 943 авыру очрагы башлангыч (I – II) стадияләрдә ачыкланды, бу 63,2 % (2022 елда – 62,5 %) тәшкил итә.

Моннан тыш, бу юнәлештә башкарыла торган эшләр кысаларында 2023 елның йомгаклары буенча онкология белән авыручыларны диспансер күзәтүе белән колачлау күләме 2022 елда ирешелгән 70,3 проценттан 75,1 процентка кадәр арттырылды (план – 75,0 %).

**25. Казан шәһәрендә 1 нче балалар күппрофильле хастаханәсенең яңа бинасын төзү перспективалары турында.**

Казан шәһәрендә «1 нче шәһәр балалар хастаханәсе» ДАССУ базасында балалар күппрофильле хастаханәсен төзү планлаштырыла. Проект-смета документациясен эшләү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 87,15 млн сум акча бирелде, объект төзү өчен 6,2 гектар мәйданлы җир кишәрлеге бүлеп бирелде.

Хәзерге вакытта «Татинвестгражданпроект» ДУП тарафыннан бүлеп бирелгән акча хисабыннан объектның проект-смета документациясе (куәте 450 койка, 8 кат) эшләнә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм Казан шәһәрендәге «1 нче шәһәр балалар хастаханәсе» ДАССУнең әйдәүче белгечләре белән берлектә, капиталь төзелеш объектының проектын ясау өчен медик-техник йөкләмә расланды.

Хәзерге вакытта «Татинвестгражданпроект» ДУП тарафыннан архитектура-планировка чишелешләренә төзәтмәләр кертелә.

**26. Халыкка диспансеризация үткәрү сыйфатын яхшырту чаралары турында.**

Республика халкына диспансеризация һәм медицина тикшерүен үткәрү Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

Халыкка профилактик медицина тикшерүләрен һәм диспансеризация үткәрүнең төп максаты – авыруларны алдан ачыклау, үз вакытында һәм нәтиҗәле дәвалау, аларның үсеш рискы факторларын билгеләү, һәм, аларның нәтиҗәсе буларак, халыкның үлем санын (шул исәптән шикәр диабеты, туберкулез, онкология һәм йөрәк-кан тамырлары авырулары кебек социаль әһәмиятле авырулардан) киметү.

2023 елда балигъ булмаганнарның профилактик медицина тикшерүләрен уздыруда 62 медицина оешмасы катнашты. 827 233 балигъ булмаган бала, яки еллык планның 100,8 проценты (2022 елда – 811 718 кеше) тикшерелде.

Олы яшьтәге халыкның билгеле бер төркемнәренә диспансеризация үткәрүдә 80 медицина оешмасы (2022 елда – 82 медицина оешмасы) катнашты.

Тирәнтен диспансеризация үткәрүгә 417 378 кеше, яки еллык планнан 110,1 процент (379 204 кеше), шуларның 84,3 проценты COVID-19 белән авырган затлар төркеменнән 351 910 кеше җәлеп ителде.

2023 елның мартыннан республикада Татарстан Республикасының дәүләт медицина оешмалары тарафыннан сәнәгать предприятиеләрендә олы яшьтәге халыкның билгеле бер төркемнәренә диспансеризация һәм хезмәткәрләргә профилактик медицина тикшерүләре оештыру һәм үткәрү буенча «Сәнәгать диспансеризациясе» проекты гамәлгә кертелде. Анда 61 медицина оешмасы катнашты.

«Сәнәгать диспансеризациясе» проекты кысаларында республиканың 681 оешмасының 113 008 хезмәткәре каралды. Уртача алганда, тикшерелгән хезмәткәрләрнең һәр унынчысы алга таба тикшереп бетерү өчен икенче этапка җибәрелде.

Өлкән яшьтәге халыкның билгеле бер төркемнәренә диспансеризация үткәрүнең һәм өлкән яшьтәге халыкка диспансер күзәтүе ясауның икенче этабы кысаларында авыл халкына квалификацияле медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлеген арттыру максатларында, «Мобиль поликлиника» проектын гамәлгә ашыру дәвам итте. Татарстан Республикасының 29 районына (148 торак пунктка) сәфәр кылынды. 31 982 кеше, шуларның 14 113 кеше диспансеризациянең икенче этабы барышында каралды.

2019 елның сентябреннән «Өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында төрле сәбәпләр белән медицина ярдәмен оештыру һәм күрсәтү (аз хәрәкәтләнүче гражданнарга хезмәт күрсәтү, профилактик тикшерүләр, диспансеризация, скрининг тикшерүе, диспансер күзәтүе, авыру белән бәйле мөрәҗәгать итү, медицина тикшерүе, тар юнәлештәге белгечләр консультация бирү, план буенча хастаханәгә яту) максатларында авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең транспорты белән медицина оешмаларына алып бару гамәлгә ашырыла

2023 елда үзәк район хастаханәләренә һәм табиб амбулаторияләренә 65 яшьтән өлкәнрәк 60 437 кеше, яки еллык планның 103,3 проценты (план – 58 498 кеше) алып барылды.

Татарстан Республикасы медицина оешмаларында хроник авырулардан интегүче затларга диспансер күзәтүен ясау нәтиҗәлелеген арттыру, диспансер күзәтү кысаларында, беренче чиратта, йөрәк-кан тамырлары авыруларының һәм онкология авыруларының төрле формалары белән халыкны җәлеп итүне һәм аларның актив килү санын арттыру чаралары комплексы гамәлгә ашырылды.

«Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының «Йөрәк һәм кан тамырлары авыруларына каршы көрәш» һәм «Онкология авыруларына каршы көрәш» төбәк проектлары, «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» төбәк проекты кысаларында республика халкын диспансер күзәтүе чараларын гамәлгә ашыру оештырылды.

2023 елда «Демография» илкүләм проекты кысаларында «Җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту» Татарстан Республикасы төбәк проектын гамәлгә ашыру дәвам иттерелде.

Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә халык арасында җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту буенча муниципаль программалар расланды.

Республика муниципаль берәмлекләренең, шул исәптән Казан, Чаллы шәһәрләренең, Түбән Кама, Зеленодольск, Мөслим, Актаныш, Яңа Чишмә муниципаль районнарының предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүчеләрнең сәламәтлеген ныгыту буенча корпоратив программаларын түбәндәге эшчәнлек өлкәләренә кертү буенча 73 килешү төзелде: сәламәтлек саклау (3), мәгариф (34), сәнәгать (7), транспорт (3), сәүдә (1), дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә (6), башкалар (19).

Республика халкы арасында аң-белем бирү эшен оештыру һәм үткәрү буенча җаваплылык үзәге итеп Казан, Әлмәт, Түбән Кама, Зеленодольск шәһәрләренең 4 җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге һәм Чаллы шәһәренең «Табиб-физкультура диспансеры» ДАССУ билгеләнде.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, наркомания, алкоголизм, тәмәке тартуны профилактикалау һәм аларга каршы тору буенча Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән хезмәттәшлек итү дәвам итте (матбугат конференцияләре, максатчан тематик тапшырулар, телесюжетлар, радиочыгышлар, матбугатта публикацияләр).

Ел саен республиканың медицина хезмәткәрләре 5 меңнән артык мәгълүмат материалы (телевизион тапшыру һәм әңгәмә, радиотапшыру һәм сюжетлар, интернет массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар) әзерләүдә катнаша. Тематик мәгълүмат бүлекләре шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең рәсми сайтларында һәм «Вконтакте», «Одноклассники» һәм «Telegram» социаль челтәрләре битләрендә урнаштырылды.

**27. Республиканың шифаханә-курорт учреждениеләрендә онкология авырулары белән интегүче гражданнарны дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыру турында.**

Шифаханә-курорт учреждениесе (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) шартларында стационар дәваланудан соң турыдан-туры дәвалап бетерелә (тернәкләндерелә) торган эшләүче гражданнарның авырулар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт учреждениесе (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыру турында» 2011 елның 28 мартындагы 233 нче карары белән расланды. Кискен миокард инфаркты булган, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына операция ясалган, тотрыксыз стенокардия белән авырган, баш мие кан әйләнеше кискен бозылганнан соң, умыртка сөяге үсешендә кимчелекләр һәм җитешсезлекләр булганда ортопедик, травматологик операция, буыннарга пластик операцияләр ясалганнан соң, эндопротезлау һәм реэндопротезлаудан соң, очлыклар реплантациясеннән соң авырулар, шикәр авыруы белән авыручылар, риск төркемендәге йөкле хатын-кызлар тернәкләндерүгә җибәреләләр.

2023 елда әлеге чараларны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 174,7 млн сум акча җибәрелде, 2024 елга 181,548 млн сум акча каралды, бу 5,602 эшләүче гражданны дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештырырга мөмкинлек бирәчәк.

Югарыда күрсәтелгән карар кысаларында онкология авырулары белән интегүче пациентларны тернәкләндерү (дәвалап бетерү) каралмаган.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Өлкәннәрнең медицина реабилитациясен оештыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 788н номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасында онкология авыруларыннан интегүче пациентлар «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» ДАССУнең, Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУнең, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» ДАССУнең, Казан шәһәренең «Профессор К.Ш. Зыятдинов

исемендәге 18 нче Үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУнең, Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» ДАССУнең, «Әлмәт районара күппрофильле хастаханәсе» ДАССУнең, «Медгард-Чаллы» ҖЧҖнең медицина реабилитациясенең стационар бүлекләре шартларында медицина реабилитациясе курсын үтүгә җибәрелергә мөмкин.

Әлеге категориядәге пациентларны медицина реабилитациясенә җибәрү өчен күрсәтмәләр дәвалаучы табиб тарафыннан билгеләнә.

Мәгариф, мәдәният

**28. Татарстан Республикасында китапханә системасын үстерү турында.**

2023 елда һәркем файдалана алырлык китапханәләрнең эшчәнлеге республика халкы өчен аларның социаль әһәмиятен арттыруга, республика халкының барлык категорияләренә китапханә хезмәтеннән файдалану өчен бертигез шартлар тәэмин итүгә, китапханәләрне республиканың мәгълүмат, мәгърифәт һәм мәдәни үзәкләре сыйфатында алга таба үстерүгә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасында мәдәният учреждениеләре челтәрендә 1 507, шул исәптән 4 республика һәм 1 503 муниципаль китапханә бар, шуларның 1 297се авыл җирлегендә урнашкан. Китапханәләрнең күпчелеге клуб учреждениеләре биналарында (95,2 %), 72 китапханә аерым торган биналарда урнашкан. Канәгатьләнерлек хәлдәге китапханәләрнең өлеше 89,3 % тәшкил итә, авария хәлендәге китапханәләр юк.

2022 ел белән чагыштырганда гомуми файдаланудагы китапханәләр саны 1 берәмлеккә кимеде – оптимальләштерү чаралары үткәрелүгә бәйле рәвештә, 2023 елда «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУнең 8 нче филиалы Ключище авыл китапханәсе ябылды.

2024 елның 1 гыйнварына барлыгы 1 507 китапханә «PRO.Культура.РФ» порталында теркәлгән. 2023 елда 85 571 чара (2022 ел белән чагыштырганда 39 871гә күбрәк) уздырылды, алар турында мәгълүмат порталга урнаштырылды.

Уздырылган чаралар саны буенча рейтинг лидерлары – Түбән Кама, Кукмара, Казан, Саба, Аксубай һәм Чүпрәле үзәкләштерелгән китапханә системалары.

2023 елда «PRO.Культура.РФ» порталына визитлар саны 752 106 тәшкил итте. Иң күп визитлар саны Казан, Баулы, Алексеевск, Биектау һәм Чирмешән үзәкләштерелгән китапханә системаларында булды.

2023 елда «PRO.Культура.РФ» порталында муниципаль китапханәләр катнашуларының гомуми рейтингында Татарстан Республикасы Россия Федерациясе буенча 2нче урында тора.

2023 елда Татарстан Республикасында һәркем файдалана алырлык китапханәләргә йөрүләр саны 12,1 процентка артты һәм 21,9 млн булу тәшкил итте.

Россия Федерациясендә 2019 елдан «Мәдәният» илкүләм проектының «Мәдәни мохит» федераль проекты кысаларында модельле китапханәләр булдыру проекты гамәлгә ашырыла. Ел саен республикадан конкурста һәркем файдалана алырлык 20 китапханә: 6 үзәк һәм 14 кече (авыл) китапханәләр катнаша.

2019 елдан 2023 елга кадәр барлыгы 14 китапханә – 5 үзәк һәм 9 кече (авыл) китапханә яңартылды һәм ачылды. 14 китапханәне яңарту өчен федераль бюджеттан

барлыгы 95 млн сум акча: 5 шәр млн сум кече китапханәләргә һәм 10 шар млн сум үзәк китапханәләргә бүлеп бирелде.

2023 елның октябрендә республикада федераль бюджет акчасы исәбеннән 3 яңартылган китапханә: Чаллы шәһәренең Үзәк балалар китапханәсе, Түбән Кама муниципаль районының Ширәмәт авылында һәм Тәтеш муниципаль районының Келәш авылында авыл китапханәләре ачылды.

2023 елда Казан шәһәренең муниципаль бюджеты акчасы исәбеннән өстәмә рәвештә «Казан шәһәренең Үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБМУнең 27 нче китапханә филиалы яңартылды.

2024 елда конкурста җиңгән кече китапханәләргә 8 млн сум, үзәк китапханәләргә 15 млн сум биреләчәк.

2023 елның октябрендә 2024 елда төбәктә модель китапханәләре булдыру буенча федераль конкурс нәтиҗәләре игълан ителде. Чүпрәле һәм Кукмара муниципаль районнарында, шулай ук Алабуга шәһәрендә федераль һәм республика бюджетлары акчасы исәбеннән барлыгы 39 млн сумга 4 гомумфайдаланудагы китапханәләр яңартылачак.

2021 елдан «Гений места» проекты старт алды, аның кураторы – Россия дәүләт китапханәсе. Проектны гамәлгә ашыра башлаганнан бирле талантларның концентрация нокталары Казан һәм Зеленодольск шәһәрләрендә, Кукмара, Спас һәм Арча муниципаль районнарында эшли. 2024 елда проектка «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең Г.Тукай исемендәге Үзәк балалар китапханәсе килеп кушылды.

«Пушкин картасы» проектын гамәлгә ашыру кысаларында китапханәләргә кызыксыну уятыла. Проектта актив катнашучылар – Әлмәт, Түбән Кама, Аксубай муниципаль районнары китапханәләре.

2023 елның 15 июнендә Мурманск шәһәрендә Бөтенроссия китапханә конгрессын ябу тантанасында Россия китапханә ассоциациясе тарафыннан Казан шәһәре 2024 елның Россия китапханә башкаласы итеп игълан ителде. Республика территориясендә Конгрессны оештыру һәм үткәрү төбәкнең китапханә тармагы эшчәнлегендә мөһим этап булачак.

2023 елда «Россиянең иң күп укый торган төбәге» дигән тугызынчы бөтенроссия конкурсында Татарстан «Россиянең әдәби флагманы» исеменә лаек булды. Республиканың «Роберт Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсе»нең «Күчмә китапханә» проекты җиңү яулады.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе тарафыннан:

2023 елда «Йорт» дип аталган төрки телле халыклар комикслары җыентыгын төзү һәм чыгару буенча махсус проект гамәлгә ашырылды;

2023 елның 6 августында «Россиянең китап маяклары» проекты кысаларында оештырылган «Россия төбәкләре буйлап китап экспедициясе» фестивале үткәрелде;

2023 елның 3 ноябрендә Халыклар бердәмлеге көненең эшлекле программасы һәм Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елының ябу тантанасы кысаларында «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә уздырылган республика китапханәләре белгечләре өчен белем бирү семинары оештырылды.

2023 елда мәдәният, сәнгать һәм креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе Президенты грантларын бирү конкурсында 5 китапханә җиңде:

«ZаПОБЕДУ» проекты белән Югары Ослан муниципаль районының үзәк китапханәсе;

«Шәһәр урамнарында сугыш турында китап. Хәрби-патриотик марафон» проекты белән Спас муниципаль районының үзәк китапханәсе;

яшүсмерләр арасында китап укуны популярлаштыру буенча «Книги на все времена» проекты белән Кукмара муниципаль районының үзәк китапханәсе;

«Фестиваль народной книги» проекты белән Лениногорск муниципаль районының үзәк китапханәсе;

«#Читать_Смотреть_Помнить» проекты белән Бөгелмә муниципаль районының үзәк китапханәсе.

Татарстан Республикасында китапханә эшен үстерүнең өстенлекле бурычларыннан берсе – «Татарстан Республикасының милли электрон китапханәсе» порталы белән эшләү, ул гражданнарның тулы текстлы электрон басмалардан ирекле файдалану мөмкинлеген тәэмин итә һәм гомумфайдаланудагы китапханәләрнең дәүләт һәм муниципаль китапханә фондлары турында мәгълүмат бирә. 2023 елда «Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе» порталында 487 мең кеше булу теркәлде.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә китапханә фондын цифрлаштыру буенча масштаблы эш алып барыла, проектны гамәлгә ашыра башлаганнан бирле 38 меңнән артык документ цифрлаштырылды.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе белгечләре тарафыннан китапханә фондларында китап ядкарьләре билгеләре булган басмаларны ачыклау, аларны өйрәнү, фәнни тасвирлау, Россия Федерациясенең китап ядкарьләре реестрында язулар булдыру буенча актив эш алып барыла. Реестрга барлыгы 133 язма мирас ядкаре тасвирламасы кертелде.

**29. Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру турында.**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 22 февралендәге 110 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында мәгарифне һәм фәнне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетында 2024 елга – 76 299,3 млн сум, 2025 елга – 89 781,9 млн сум, 2026 елга 105 643,4 млн сум күләмендә акча каралды.

Республика дәүләт программаларын («Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү», «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү», «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше») гамәлгә ашыру сыйфатлы белем алу өчен шартлар тудыруга, аның сыйфатын яхшырту, мәгариф оешмаларында өстәмә урыннар булдыру, милләтнең фәнни-техник, инновацион эшчәнлеген һәм интеллектуаль потенциалын үстерү, укыту методикаларын камилләштерү, туган телләрдә чаралар үткәрү, мультимедиа контентын эшләүгә ярдәм итте.

2023 елда «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында 112 мәгариф оешмасының матди-техник базасы яңартылды, 2 спорт залы ремонтланды, 9 329 урынга исәпләнгән 8 мәктәп һәм Казан шәһәре Идел буе районының «19 нчы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең 300 урынга исәпләнгән өстәмә корпусы төзелде.

«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» федераль проекты кысаларында 320 урынга исәпләнгән 2 мәктәп, шулай ук республика бюджеты акчасы исәбеннән 25 урынга исәпләнгән 1 мәктәп төзелде.

2023 елда «Демография» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәрендә 220шәр урынга исәпләнгән 2 балалар бакчасы, шулай ук Тукай муниципаль районында (220 урын) һәм Чаллы шәһәрендә (340 урын) республика бюджеты акчасы исәбеннән балалар бакчалары төзелде.

«Патриотик тәрбия бирү» федераль проекты кысаларында республиканың 734 мәктәбендә киңәшчеләр ставкалары кертелде, мәктәпләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт символлары белән җиһазландырылды.

«Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» ЮББ ФДБМУ базасында педагогик кванториум оештырылды.

Әгерҗе, Азнакай, Бөгелмә, Алабуга, Түбән Кама муниципаль районнарының, Казан һәм Чаллы шәһәрләренең 17 мәгариф оешмасы балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) психологик-педагогик, консультатив, методологик ярдәм күрсәтүгә грантлар алды.

«Социаль активлык» федераль проекты кысаларында Азнакай, Түбән Кама, Нурлат, Чистай муниципаль районнарының 4 мәктәбе «Изгелек каникулга китми» бөтенроссия конкурсында җиңде һәм мәктәпләрнең волонтерлар отрядлары проектларын гамәлгә ашыруга грантлар алды.

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында мәктәпләрнең 23,5 мең сыйныф җитәкчесе һәм һөнәри белем бирү оешмаларының 2,2 мең кураторы ай саен федераль бюджет акчасы исәбеннән 5 мең сум күләмендә түләүләр ала.

2023 елда дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны кайнар ризык белән бушлай ашатуны оештыруга 2,5 млрд сум, шулардан федераль бюджет акчасы исәбеннән – 1,5 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет акчасы исәбеннән – 1,0 млрд сум күләмендә акча җибәрелде.

Мәктәп мәгариф системаларын модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында республиканың 31 мәктәбенә капиталь ремонт ясалды. Бу максатлар өчен 4,0 млрд сум, шул исәптән федераль бюджеттан – 2,4 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 1,6 млрд сум акча бүлеп бирелде.

Россия Федерациясе субъектлары арасында сайлап алу конкурслары йомгаклары буенча Татарстан Республикасы 2023 елда «Профессионалитет» федераль проекты кысаларында 6 һөнәри белем бирү оешмасы базасында белем бирү-җитештерү үзәкләре булдыру хокукына ия булды. Федераль бюджеттан субсидия күләме – 510,0 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 87,6 млн сум тәшкил итте.

Инженерлар кадрларын әзерләү өлкәсендә югары белем бирү системасында 6 республика югары белем бирү оешмасы базасында алдынгы инженерлык мәктәпләре оештырылды.

2023 елда алдынгы инженерлык мәктәпләренә («Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮББ ФДАМУ, «Казан милли тикшеренү технология университеты» ЮББ ФДБМУ һәм «Иннополис университеты» ЮББ АКБО) ярдәм итү өчен федераль бюджеттан 1 млрд сум күләмендә акча бүлеп бирелде, әлеге акча, индустриаль партнерлар белән берлектә, яңа фәнни-технологик һәм эксперименталь лабораторияләр, тәҗрибә производстволары булдыруга, инженер кадрларын алга китеп әзерләү буенча яңа программалар эшләүгә юнәлдерелде.

«Фән һәм университетлар» илкүләм проектының грант чаралары кысаларында 2023 елда республиканың югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалары тарафыннан «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыруга; яшьләр лабораторияләре, уку-укыту һәм фәнни үзәкләр (шул исәптән дөньякүләм дәрәҗәдәге) булдыруга һәм аларның эшләвенә; агросәнәгать комплексында фәнни һәм мәгариф оешмаларының үз эшләнмәләре нигезендә заманча технологияләр булдыруга һәм гамәлгә кертүгә; фәннең приборлар базасын яңарту, реконструкцияләү һәм техник җиһазландыруга 2,0 млрд сум күләмендә акча җәлеп ителде.

Барлыгы 2019–2023 елларда республиканың 228 мәгариф оешмасы (163 мәктәп һәм 65 урта һөнәри белем бирү оешмасы), цифрлы мәгариф мохитен гамәлгә кертү максатларында, компьютер җиһазлары белән җиһазландырылды.

2023 елда Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында 40 гомуми белем бирү оешмасы мәгълүмат-коммуникация җиһазлары (ноутбуклар, күпфункцияле җайланмалар, телевизорлар, интерактив комплекслар, видеокамералар) белән җиһазландырылды.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның карары буенча 2022–2023 елларда мәктәп укытучылары өчен 36 мең ноутбук, шулардан 2023 елда 24 мең ноутбук сатып алынды.

Татарстан «Минем мәктәп» федераль дәүләт мәгълүмат системасын һәм «Сферум» мәгълүмат-коммуникация платформасын гамәлгә кертү һәм үзләштерү эшенә актив кушылды. 2023 ел нәтиҗәләре буенча әлеге ресурслардан 272 225 укучы һәм республиканың 36 187 педагогик хезмәткәре актив файдаланды.

2023 елда республиканың мәгариф системасын цифрлы нигездә идарә итүнең яңа моделенә күчү максатларында состав элементы сыйфатында Мәскәү электрон мәктәбе базасында электрон журналлар һәм көндәлекләрнең унификацияләнгән чишелешен кертү юлы белән «Татарстан Республикасы электрон мәгарифе» дәүләт мәгълүмат системасын модернизацияләү гамәлгә ашырылды. Республика мәктәпләре 2024 елның гыйнварыннан яңартылган системада эшли.

2022/2023 уку елында «Киләчәк коды» федераль проекты программалары буенча программалаштыруның заманча телен өйрәнү өчен 8 254 укучы, шул исәптән офлайн форматта белем алу өчен 3 720 укучы, 2023/2024 уку елында 13 139 укучы, шул исәптән офлайн форматта белем алу өчен 5 954 укучы укырга керде.

2023 елда 116 укучы «Яндекс.Лицей» мәгариф проекты кысаларында программалаштыруның заманча телләрен өйрәнү буенча ике еллык курсны

тәмамлады. Алты уку елы дәвамында Татарстаннан 2 292 мәктәп укучысы укырга керде. Проектны гамәлгә ашыру күрсәткечләре буенча республика Россия төбәкләренең беренче өчлегенә керә.

2018/19 уку елыннан башлап, республика мәгариф оешмалары уку елы дәвамында график буенча укучыларда цифрлы икътисад компетенцияләрен үстерүгә, шулай ук мәгълүмат технологияләре өлкәсендә аларга алдан һөнәри юнәлеш бирүгә юнәлдерелгән «Цифрлы дәрес» бөтенроссия белем бирү акциясендә катнаша.

Ел саен көз көне республика мәгариф оешмаларында Интернет челтәрендә киберкуркынычсызлык дәрәҗәсен арттыруга, ата-аналар белән педагоглар җәмәгатьчелегенең Интернет челтәрендә балалар иминлеге проблемаларына игътибарын җәлеп итүгә һәм мәктәп укучыларында цифрлы грамоталылыкны үстерүгә юнәлдерелгән Бердәм иминлек дәресе уздырыла.

Татарстанда балаларның һәм яшьләрнең әхлакый, физик, психологик һәм социаль сәламәтлеген тәэмин итү, саклап калу һәм ныгыту өчен имин мәгълүмат-белем бирү мохитен булдыруга юнәлдерелгән 2021–2027 елларга медиакиңлектә балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планы («юл картасы») гамәлгә ашырыла.

2023 елның 18 маенда Kazan Digital Week Халыкара форумы эгидасы астында «Мәгарифтә цифрлы технологияләр» дигән темага вебинар уздырылды, анда заманча һәм куркынычсыз цифрлы белем бирү мохитен булдыру һәм үстерү, укучыларның цифрлы компетенцияләрен үстерү, «Киләчәк коды» федераль проектын гамәлгә ашыру үзенчәлекләре, шулай ук Россия уку җиһазлары һәм укыту чаралары индустриясен үстерү векторлары каралды. Форум көннәрендә мәгарифкә багышланган 9 төрле форматтагы чара (секцияләр, «түгәрәк өстәлләр», мастер-класслар) үткәрелде. Докладлар белән 60тан артык Россия спикеры турыдан-туры да, онлайн форматта да чыгыш ясады.

2023 елның 20 сентябреннән 23 сентябренә кадәр «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәге базасында 30 мәгълүмат технологияләре компетенцияләре буенча DigitalSkills 2023 цифрлы технологияләр өлкәсендә V тармак чемпионаты уздырылды.

Республикада мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә 156 мәгариф оешмасыннан торган челтәр эшли, аңа 105 балалар сәнгать мәктәбе, мәдәният идарәсе органнары карамагындагы 2 балалар үзәге, мәгариф идарәсе органнары карамагындагы 38 балалар сәнгать мәктәбе, мәдәният һәм сәнгать өлкәсенә караган 9 һөнәри белем бирү оешмасы (көллият), 2 югары белем бирү мәгариф оешмасы керә.

Әлеге оешмаларда 43 345 кеше укый, шулардан 38 307 кеше – балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында, 2 389 кеше – һөнәри белем бирү оешмаларында (көллиятләрдә), 2 649 кеше – югары белем бирү мәгариф оешмаларында. Укытучылар составында 4 654 кеше исәпләнә, шулардан 3 687 кеше – өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары һәм концертмейстерлары, 638 кеше – һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары, 329 кеше – югары белем бирү мәгариф оешмаларының профессор-мөгаллимнәр составы.

2023 елда республикада «Балалар сәнгать мәктәбенең иң яхшы укытучысы» һәм «Иң яхшы балалар сәнгать мәктәбе» гомумроссия конкурсларының төбәк этаплары уздырылды.

Сәнгать өлкәсендә Бөтенроссия яшүсмерләр олимпиадасының «Россиянең яшь сәләтлеләре» бөтенроссия конкурсының төбәк этабында 13 кеше призга лаек булды.

«TAT·ARS·TAN» конкурс хәрәкәте кысаларында яшь талантларның республика конкурсы уздырылды, анда 253 кеше катнашты, олимпиадада 13 кеше призларга лаек булды.

Биектау муниципаль районының «Салих Сәйдәшев исемендәге Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе Идел буе федераль округында «Иң яхшы балалар сәнгать мәктәбе (авыл)» гомумроссия конкурсының II турда җиңү яулады.

2023 елның 28 октябрендә «Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» ДАҺББУ (техникум) базасында балалар сынлы сәнгать мәктәпләре һәм балалар сәнгать мәктәпләре укытучылары арасында һөнәри osталык буенча «МАЭСТРО» республика конкурсы уздырылды.

Креатив индустрияләр өлкәсендә белем алучыларның иҗади фикерләвен үстерүгә, һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләрен популярлаштыруга һәм үстерүгә ярдәм итә торган иң мөһим юнәлешләрнең берсе – креатив индустрияләр мәктәбен булдыру. Беренче шундый мәктәп Татарстан Республикасында 2022 елда «Н.И. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы» (техникум) ДАҺББУ базасында «Россиядә уйлап чыгарылган» федераль проекты кысаларында оештырылды. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбе» өстәмә һөнәри белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе һәм «С.Сәйдәшев исемендәге Түбән Кама музыка көллияте» ДАҺББУ базасында тагын 2 креатив индустрияләр мәктәбе ачылды.

**30. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру мәсьәләсен хәл итү перспективалары турында (шул исәптән иске төзелеш биналарында урнашкан шәһәр мәктәпләренең спорт залларын капиталь ремонтлау, спорт заллар төзү турында).**

2014 елдан авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру кысаларында ел саен республиканың авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының спорт залларына капиталь ремонт ясау гамәлгә ашырыла.

2023 елдан гомуми белем бирү оешмаларының спорт залларын капиталь ремонтлау мәгариф оешмаларында уку-укыту һәм тикшеренү, фәнни-гамәли, иҗади эшчәнлекне, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник базаны яңарту чаралары кысаларында гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта әлеге чаралар кысаларында спорт заллары төзү каралмаган.

Әлеге программа кысаларында 2024 елда Татарстан Республикасының 2 гомуми белем бирү оешмасының спорт залларын ремонтлау планлаштырыла (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Новый поселогының урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «3 нче Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ).

Шулай ук мәктәпләрнең спорт залларына капиталь ремонт ясау Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларын капиталь ремонтлау программасы һәм мәгарифнең мәктәп системаларын модернизацияләү чаралары (гомуми белем бирү оешмалары биналарын капиталь ремонтлау буенча федераль программа) кысаларында гамәлгә ашырыла. Объектларның исемлекләре, эш төрләре һәм күләмнәре Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан билгеләнә.

**31. Балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәпләренең тренер-укытучыларына ярдәм күрсәтү чараларының комплекслы системасын оештыру турында.**

Татарстан Республикасының әйдәүче спортчыларына югары спорт казанышлары өчен ай саен стипендияләр күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары казанышларга ирешкән өчен спортчыларга һәм тренер-укытучыларга дәүләт ярдәме турында» 2018 ел, 20 февраль, 98 нче карары белән расланды.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Татарстан Республикасының әйдәүче спортчыларына югары спорт казанышларына ирешкән өчен ай саен бирелә торган стипендияләр һәм аларның тренерларына ай саен бирелә торган өстәмә түләүләр билгеләү турында» 2023 елның 25 гыйнварына 38 номерлы боерыгы нигезендә 2023 елда 99 тренерга (2022 елда – 111 тренерга) ай саен өстәмә түләү бирелде. Тренерларга барлыгы 4,498 млн сум күләмендә түләүләр башкарылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 нчы карары белән спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә дәүләт ярдәме каралды, шул исәптән:

2 510 сум күләмендә ай саен бирелә торган акчалата өстәмә түләү;

хуҗалыкны төзекләндерү өчен 100 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү.

2023 елда дәүләт һәм муниципаль спорт мәктәпләрендә эшләүче 80 яшь белгеч ай саен стимул бирә торган өстәмә түләү, 35 яшь белгеч бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге буенча дәүләт үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 853 нче карары нигезендә спорт резервын әзерләү гамәлгә ашырыла торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче тренер-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләүләр билгеләнде. Спортның олимпия төрләре буенча әлеге түләүләр күләме, ярышлар дәрәҗәсенә һәм биләгән урынына карап, вазыйфаи окладның 20 процентыннан 500 процентына кадәр күләмдә билгеләнде. 2023 елда 489 тренер-укытучы түләүләр алды. Әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 99,05 млн сум күләмендә акча җибәрелде, 2024 елга 109,3 млн сум күләмендә акча каралды.

**32. Татарстан Республикасында яшь галимнәргә ярдәм күрсәтү буенча дәүләт чараларын оештыру турында.**

Татарстан Республикасында фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлекне популярлаштыруга һәм яшьләрнең тикшеренү һәм инновацион активлыгын стимуллауга юнәлдерелгән масштаблы эш алып барыла. Ул аларга адреслы стимуллар бирүнең һәм аларның фәнни эзләнүләрен бүләкләү һәм аларга ярдәм итү механизмнарының шактый санда булуында чагыла.

Яшь галимнәргә түбәндәге ярдәм чаралары гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе;

Татарстан Республикасы грантлары һәм премияләре;

«Мәгарифтә инновацияләр», «Перспектива», «У.М.Н.И.К.» (яшьләр инновация проекты) номинацияләрендә «Илле иң яхшы инновацион идея» республика конкурсы;

«Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе стипендиясе;

студентлар һәм аспирантлар арасында Казан шәһәре мэрының исемле стипендияләрен алуга конкурс.

Яшь тикшеренүчеләрнең фәнни эзләнүләрен бүләкләү механизмнарын һәм аларга яңа адреслы стимуллар бирүне арттыру максатларында, республиканың хокукый киңлегенә В.Е. Алемасов һәм М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премияләре кертелде.

2016 елдан башлап, республикада төрле фәнни юнәлешләргә һәм тормыш өлкәләренә багышланган белем бирү интенсивлары форматында уза торган «PROФән» проекты гамәлгә ашырыла.

«Фән һәм университетлар» илкүләм проекты кысаларында 3 әйдәүче оешма – «Циркуляр икътисад» дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни белем бирү үзәге – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» ФТҮ, «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮББ ФДАМУ, «Казан дәүләт энергетика университеты» ЮББ ФДБМУ базасында яшь перспективалы галимнәр җитәкчелегендә 7 фәнни-тикшеренү лабораториясе уңышлы эшли. «Казан дәүләт медицина университеты» ЮББ ФДБМУендә «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру барышында 3 яшьләр лабораториясе булдырылды. Шул ук вакытта Татарстанның фәнни-мәгариф комплексы оешмаларында эшләүче яшьләр лабораторияләренең гомуми саны хәзерге вакытта 20 берәмлектән артып китә.

«Университет технология эшкуарлыгы платформасы» федераль проекты кысаларында «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮББ ФДАМУ җитәкчелегендәге консорциум базасында 2022 елда университет стартап-студия оештырылды. Югары уку йортының партнерлары – «КАМАЗ» ГАҖ, Татарстан Республикасының Инвестиция венчур фонды» КБО, «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» ЮББ ФДБМУ, «Казан дәүләт энергетика университеты» ЮББ ФДБМУ, «Иннополис университеты» ЮББ АКБО һәм Инфраструктура һәм мәгариф проектлары фонды Мәскәү шәһәре).

Грант бирү шартлары нигезендә «КАМАЗ» ГАҖ, «Татарстан Республикасының Инвестиция венчур фонды» КБО һәм Инфраструктура һәм мәгариф проектлары фонды паритетлы башлангычларда ел саен 3 ел рәттән студия үсеше өчен һәр елны 100,0 млн сум күләмендә акча кертә. Шулай итеп, тулаем

финанслау елына 300,0 млн сум, ә проектны гамәлгә ашыруның барлык чоры өчен 900,0 млн сум тәшкил итә. Шул ук вакытта 300,0 млн сумы – Инфраструктура һәм мәгариф проектлары фонды бирә торган грант күләме, 600,0 млн сумы – «КАМАЗ» ГАЖ һәм «Татарстан Республикасының Инвестиция венчур фонды» КБО кертеме. Моннан тыш, «КАМАЗ» ГАЖ булачак стартапларны проектлар нигезендә эшләнә торган продуктларны беренчел сату базары белән тәэмин итү бурычын үз өстенә алды.

«Студентлар стартабы» конкурсы йомгаклары буенча федераль ярдәм күрсәтелү хокукына Татарстан Республикасының 442 вәкиле лаек булды (Россия Федерациясе буенча 1 урын).

**33. Казан шәһәрендә Абдулла Алиш исемендәге Балалар иҗат сараена капиталь ремонт ясау перспективалары турында.**

Казан шәһәренең Галактионов урамы 24 нче йорт адресы буенча урнашкан «А.Алиш исемендәге Шәһәр балалар иҗат сарае» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе бинасы «Пионерлар һәм мәктәп укучылары сарае» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты булып тора һәм Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2019 елның 9 декабрендәге 246-П номерлы боерыгы нигезендә дәүләт саклавына куелды.

«А.Алиш исемендәге Шәһәр балалар иҗат сарае» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең гамәлгә куючысы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге. Әлеге объект белән идарә итү өлкәсендә гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты һәм Мәгариф идарәсе башкара.

2020 елның мартында Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты хезмәткәрләре тарафыннан үткәрелгән әлеге объектны тикшерү нәтиҗәләре буенча бинаның гомуми техник торышы бәяләнде, акт төзелде һәм аны саклау буенча кирәкле эшләр төрләре һәм күләмнәре билгеләнде.

Ачыкланган җимерек урыннарны, җитешсезлекләрне бетерү максатларында 2020 елда объектка карата «Татарстан махсус фәнни-реставрация идарәсе» АҖ (лицензияләнгән проект оешмасы) тарафыннан аны саклау буенча эшләр башкаруга фәнни-проект документациясе эшләнде. Документация барлык кирәкле экспертизалар һәм килештерүләр аша узды, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе алынды. Проект карарларында бинаны реставрацияләү, киләчәктә аны заманча файдалануга җайлаштыру каралды.

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәяләр билгеләү идарәсе» ДАУ тарафыннан А.Алиш исемендәге Шәһәр балалар иҗат сараенда ремонт-реставрация эшләренең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә эшләр башкарыла.

## Иҗтимагый иминлек

**34. Татарстан Республикасында миграция сәясәте өлкәсендә күрелә торган чаралар турында.**

2023 елда Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны килү урыны буенча миграция исәбенә 396 736 (2022 елда –

324 901) кую факты теркәлде. Аларның күбесе Үзбәкстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Кыргызстан, Казахстан, Кытай, Азәрбайҗан һәм Төркиядән килде.

2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы территориясенә фактта 87 423 чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган затлар килде.

2023 елда 5 040 (2022 елда – 7 687) чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган зат Россия Федерациясе гражданлыгы алды.

Чит ил гражданнарының иң күп проценты Татарстан Республикасына хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру максаты белән килә.

Барлыгы 2023 елда оешмаларга һәм предприятиеләргә 723 чит ил хезмәткәрен җәлеп итүгә һәм алардан файдалануга 108 рөхсәт кәгазе рәсмиләштерелде.

2023 елда 3 448 предприятие, оешма һәм индивидуаль эшкуар чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итә, шул исәптән 60 (2020 елда – 44) эш бирүченең виза белән керелә торган илләрдән чит ил хезмәткәрен җәлеп итүгә рөхсәт кәгазе бар.

2023 елда чит ил гражданнарына эшләү өчен 915 (2022 елда – 1 578) рөхсәт кәгазе, шулай ук 52 932 (2022 елда – 41 300) патент рәсмиләштерелде.

Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның легаль булмаган миграциясенә һәм законсыз хезмәт эшчәнлеген башкаруга каршы тору максаты белән, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына караган Миграция мәсьәләләре идарәсенең структур бүлекчәләре хезмәткәрләре тарафыннан миграция законнарын бозу фактларын ачыклау буенча даими нигездә чаралар уздырыла.

Барлыгы 2023 елда 12 932 (2022 елда – 11 510) чара уздырылды, алар барышында миграция законнарын бозу буенча 19 791 (2022 елда – 17 980) административ хокук бозу ачыкланды.

2023 елда Россия Федерациясе территориясендә булу режимын һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә катнашу шартларын бозган өчен 3 061 чит ил гражданына карата Россия Федерациясе территориясеннән административ рәвештә куып чыгару турында (2022 елда – 1 459), депортация турында 225 (2022 елда – 214) суд карары кабул ителде. 4 400 чит ил гражданына Россия Федерациясенә керү тыелды.

Легаль булмаган миграциягә каршы торуның иң нәтиҗәле формаларыннан берсе – милли диаспоралар һәм автономияләр белән хезмәттәшлек итү. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы 40 милли автономиядән торган Татарстан халыклары ассамблеясе белән актив хезмәттәшлек итә. 2023 елда Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан Ассамблея мәйданчыгында милли диаспоралар белән 4 эшлекле очрашу уздырылды, алар барышында Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган миграция сәясәтенең актуаль мәсьәләләре тикшерелде, шулай ук миграция законнарына кертелгән үзгәрешләр һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының милли җәмгыятьләр вәкилләренә карата төп таләпләр турында мәгълүмат бирелде.

Чит ил гражданнары тарафыннан кылына торган җинаятьләрнең чагыштырма авырлыгы 2023 елда теркәлгән җинаятьләрнең гомуми саныннан 1 % (2022 елда – 1,2 %) тәшкил итте. 2023 елда 560 (2022 елда – 634) җинаять теркәлде, шул исәптән 160ы – наркотикларны законсыз әйләнештә йөртүгә бәйле җинаятьләр, 140ы – урлау, 62е – документларны ялганлап эшләү факты, 24е – алдашып акча алу, 20се – ришвәт

бирү факты, 8е – талау, җидешәрләр – аңлы рәвештә сәламәтлеккә авыр зыян салу һәм көчләү, 5се – кеше үтерү һәм 4се – юлбасарлык итү.

2023 елда чит ил гражданнарына карата 446 (2022 елда – 409) җинаять кылынды, шул исәптән 180е – урлау, 156сы – алдашып акча алу, 19ы – янап куркытып алу, 9ы – талау, 8е – аңлы рәвештә сәламәтлеккә авыр зыян салу, 5се – юл басарлык итү һәм 3се – үтерү.

**35. Татарстан Республикасында, аерым алганда Казан шәһәрендә гражданнарны, шулай ук аларның берләшмәләрен җәмәгать тәртибен саклауда катнашуга җәлеп итү буенча күрелә торган чаралар турында.**

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан, республика муниципаль берәмлекләренең ирекле халык дружиналары штаблары белән бергә, җәмәгать тәртибен саклауга һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүгә халыкның төрле катламнарын җәлеп итү буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

2024 елның 1 гыйнварына федераль һәм республика законнары таләпләре нигезендә республика реестрына барлыгы 20 369 кешедән торган 1 458 ирекле халык дружиналары кертелде һәм эшли:

предприятиеләрдә һәм оешмаларда – гомуми саны 2 928 кеше тәшкил иткән 194 отряд, шул исәптән 193 ирекле халык дружиналары һәм «Казаноргсинтез» гавами акционерлык җәмгыятендә хокук саклау юнәлешендәге 1 җәмәгать берләшмәсе (алга таба – ХСЮҖ берләшмәсе);

мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, спорт һ.б. учреждениеләрдә – гомуми саны 3 912 кеше тәшкил иткән 239 халык дружинасы;

гражданнарның яшәү урыны буенча – 1 025 халык дружинасы (13 529 кеше), шул исәптән 321 ишегалды дружинасы (1 610 кеше), авыл җирлекләрендә 674 дружина (5 440 кеше), район үзәкләрендә 30 дружина (6 479 кеше).

Казан шәһәрендә 269 халык дружинасы һәм 1 ХСЮҖ берләшмәсе («Казаноргсинтез» гавами акционерлык җәмгыятендә) бар, гомуми саны 1 690 кеше тәшкил итә, шулардан:

предприятиеләрдә һәм оешмаларда – 51 отряд, шулардан: 50 ирекле халык дружинасы һәм 1 ХСЮҖ берләшмәсе («Казаноргсинтез» гавами акционерлык җәмгыятендә), гомуми саны 636 кеше тәшкил итә;

мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, спорт һ.б. учреждениеләрдә – 31 халык дружинасы (481 кеше);

гражданнарның яшәү урыны буенча – 188 ишегалды дружинасы (573 кеше).

Халык дружиналары эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабы төзелде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 18 апрелендәге 702-б нче боерыгы).

Халык дружиналарының шундый ук штаблары Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә дә булдырылды, башлыклары итеп башкарма комитетның (башкарма комитет җитәкчесе урынбасары дәрәҗәсеннән ким булмаган) вазыйфаи затлары билгеләнде.

Халык дружиналары әгъзаларын җәлеп итү эше офицерлар патрульләре составындагы участок вәкаләтле полицияләре һәм тышкы хезмәтләр нарядлары белән бергә тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары базасында оештырылды.

Моннан тыш, халык дружиначылары гавами, иҗтимагый-сәяси, дини, мәдәни-тамаша һәм спорт чараларын үткәргәндә хокук тәртибен тәэмин итүдә катнаша.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары тарафыннан квартал саен дружиначыларның чыгу графиклары раслана, алар территориаль эчке эшләр органнары башлыклары белән килештерелә, дружиначыларның хокук тәртибен саклауга чыгуларын исәпкә алу буенча тиешле журналлар алып барыла, халык дружиначыларын әзерләү, шул исәптән физик көч куллануга бәйле шартларда гамәлләр кылуга әзерләү, шулай ук беренче ярдәм күрсәтү буенча инструктажлар оештырылды.

Атна саен башкарылган эшләр һәм җитешсезлекләр турында Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре башлыкларына хәбәр ителә.

«Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү буенча халык дружиналары эшен оештыруга, шул исәптән халык дружиналары эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүгә, дружиначыларны шәхси иминләштерүгә, аларны матди кызыксындыруга ел саен 8 млн сумнан артык акча карала.

Җәмәгатьчелек тәртибен саклау чараларында катнашу чорында ирекле халык дружиналарындагы барлык әгъзаларның тормышы һәм сәламәтлеге иминләштерелә (Татарстан Республикасында ирекле халык дружиналары отрядлары эшләгән чор дәвамында (2015 елдан башлап) иминият очраклары теркәлмәде).

Халык дружиначыларын шәхси иминләштерүне гамәлгә ашыру һәм мөлкәт сатып алуга шартнамәләр төзү, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дәүләт программасы буенча бүлеп бирелгән акчаны исәпкә алып, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе аша гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 августындагы 603 нче карары белән Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен республика премияләре турында нигезләмә расланды (3 категория каралды: 30 премия – 5ешәр мең сум, 10 премия – 20шәр мең сум, 3 премия – 50шәр мең сум).

Республика конкурсы белән охшаш өстәмә матди кызыксындыру чараларын кабул итү максатларында, республика муниципаль берәмлекләрендә җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен халык дружиначыларына премия бирү турында нигезләмәләр эшләнде, алар муниципаль берәмлекләр башлыклары карарлары белән расланды. Әлеге эшчәнлекне финанслау гамәлдәге профилактика программаларына кертелде.

2023 елда республика халык дружиналары әгъзалары катнашында 151 (2022 елда – 101) җинаять ачылды, 3 046 (2022 елда – 3 754) административ хокук бозу туктатылды.

**36. Татарстан Республикасында юл-транспорт һәлакәтләрен һәм юлларда үлүчеләр санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.**

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проектының «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасының «Юл хәрәкәте иминлеген арттыру» процесслы чаралар комплексын гамәлгә ашыру республика юлларында юл-транспорт һәлакәтләре (алга таба - юл-транспорт һәлакәтләре) санын киметүгә һәм аларның нәтиҗәләрен минимальләштерүгә уңай йогынты ясауны дәвам итә.

2023 елда Татарстан Республикасы юлларында 3 314 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән (2022 елда – 3 353), аларда 279 кеше һәлак булган (2022 елда – 306) һәм 3 987 кеше җәрәхәтләр алган (2022 елда – 4 145).

Авария дәрәҗәсенә, элеккеге кебек үк, транспорт чаралары йөртүчеләре аерым йогынты ясый, алар гаебе 90,1 % яки 2 987 юл-транспорт һәлакәте булган (2022 елда – 3 000), 2023 елда 238 кеше һәлак булган (2022 елда – 261 кеше) һәм 3 696 кеше җәрәхәтләр алган (2022 елда – 3 830 кеше).

Юл чатларында йөрү кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә 583 юл-транспорт һәлакәте (19,5 %) булды; билгеләнгән тизлек режимын бозу яки, юл һәм метеорология шартларын исәпкә алып, хәрәкәтнең куркынычсыз тизлеген дөрес сайламау – 480 юл-транспорт һәлакәте (16,1 %); җәяүлеләр кичүләрен узу кагыйдәләрен бозу – 397 юл-транспорт һәлакәте (13,3 %); каршы як хәрәкәт полосасы аша узу һәм чыгу кагыйдәләрен бозу – 270 юл-транспорт һәлакәте (9 %); исерек автотранспорт белән идарә иткән машина йөртүчеләр гаебе белән – 210 юл-транспорт һәлакәте (7 %); транспорт чарасы белән идарә итү хокукы булмаганнар – 127 юл-транспорт һәлакәте (4,3 %) .

2023 елда республика юлларында балалар катнашында 439 юл-транспорт һәлакәте булган (2022 елда – 416), нәтиҗәдә 17 бала һәлак булган (2022 елда – 11) һәм 466 - төрле дәрәҗәдәге авырлыктагы җәрәхәтләр алган (2022 елда – 443).

2023 елда Татарстан Республикасында юл хәрәкәте өлкәсендә гамәлдә булган 8 364 мең норма һәм кагыйдәне бозу ачыкланган (2022 елда – 7 177 мең), шуларның күпчелек өлеше (7 626,8 мең яисә 91,2 %) фото һәм видеофиксациянең автомат комплекслары белән теркәлгән, шул исәптән: 7 245 мең – тизлек режимын арттыру, 78 777 – юл билгеләре һәм тамгалары таләпләрен үтәмәү, 143 592 – иминлек каешын эләктермәү.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе хезмәткәрләре исереклек билгеләре булган машина йөртүчеләр тарафыннан транспорт чаралары белән идарә итүнең 12 995 фактын ачыкланган һәм бетергән (2022 елда – 13 819).

Автотранспорт белән идарә итүгә медицина каршылыгы булган затлар белән эшләү дәвам итте. Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Медицина-социаль экспертизасының Баш бюросы белән үзара хезмәттәшлектә психик тайпылышлары һәм нерв системасы авырулары булган затларда, шул исәптән алкоголь куллануга бәйле рәвештә, 1 502 йөртүче таныклыгы гамәлдән чыгарылды. Наркотикка бәйлелеге булган 352 кешегә карата транспорт белән идарә итү хокукын туктату турында карарлар чыгарылды.

«Паутина» махсус программа белән тәэмин итүнең төбәк сегментын кулланып, элек гамәлдән чыгарылган машина йөртү таныклыгы яисә транспорт чарасы белән идарә итүнең хокукы туктатылган машина йөртүчеләрне ачыклау һәм тоткарлау буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырыла. Әлеге система полиция хезмәткәрләренә оператив кызыксыну тудырган транспорт чараларын вакытында тоткарларга, күзәтеп торырга, ачыкланган хокук бозуларга җавап бирергә мөмкинлек бирә. 2023 елда «Паутина» махсус программа тәэмин ителешен кулланып, 2 534 транспорт чарасы тоткарланган (2022 елда – 574).

Юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә юлларны төзегәндә, ремонтлаганда, карап тотканда һәм юл эшләрен башкарганда, бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын файдаланганда мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында 1 010 кисәтү белдерелде. Системалы хокук бозулар фактлары буенча прокуратура органнарына 115 материал җибәрелгән (2022 елда – 111).

2023 елда юл хәрәкәтендә катнашучылар һәм халык белән профилактик эш кысаларында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе түбәндәге чаралар уздырды:

6 марттан 15 мартка кадәр, 30 июньнән 9 июльгә кадәр – «Каршы як полоса» профилактик чарасы (каршы як хәрәкәт полосасына чыгу белән бәйле юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү максатларында). Аны үткәрү вакытында каршы як хәрәкәт полосасына чыгуга бәйле 2 545 хокук бозу ачыкланган һәм бетерелгән; массакүләм мәгълүмат чараларында 531 материал чыгару оештырылган (басмаларда – 49, телевидениедә – 20, радиода – 65, интернет-басмаларда – 397);

2023 елның 20 мартыннан 29 мартына кадәр, 19 июненнән 28 июненә кадәр, 31 сентябреннән 9 ноябренә кадәр – «Җәяүле» профилактик чарасы (җәяүлеләр гаебе белән килеп чыга торган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү максатларында). Аны үткәрү вакытында җәяүлеләр тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуның 6 642 очрагы, транспорт чаралары йөртүчеләрнең җәяүлеләр хәрәкәтендә өстенлекләрне бирмәүнең 2 898 факты ачыкланган һәм бетерелгән; массакүләм мәгълүмат чараларында 786 материал (басмаларда – 75, телевидениедә – 53, радиода – 120, интернет-басмаларда – 538) чыгару оештырылган;

17 апрельдән 23 апрельгә кадәр, 17 июльдән 26 июлькә кадәр – «Иминлек каешы» профилактик чарасы. Аны үткәрү вакытында транспорт чаралары йөртүчеләр һәм пассажирлары тарафыннан иминлек каешын куллану кагыйдәләрен бозуның 10 494 очрагы ачыкланды һәм бетерелде, массакүләм мәгълүмат чараларында 253 материал чыгарылды (басмаларда – 14, телевидениедә – 11, радиода – 14, интернет-басмаларда – 214);

18 сентябрьдән 22 сентябрьгә кадәр – 24 меңгә якын кеше катнашкан юл хәрәкәте куркынычсызлыгы атнасына багышланган чаралар комплексы.

Балалар юл-транспорт травматизмын профилактикалау, балаларны тотып тору җайланмаларыннан башка йөртү фактларын кисәтү максатында үткәрелде:

2022 елның 26 декабреннән 2023 елның 8 гыйнварына кадәр – «Кышкы каникуллар» профилактик чарасы;

2023 елның 20 мартыннан 2 апреленә кадәр – «Язгы каникуллар» профилактик чарасы;

2023 елның 22 маеннан 4 июненә кадәр – «Игътибар – балалар!» профилактик чарасы;

2023 елның 25 октябреннән 6 ноябрьгә кадәр – «Көзге каникуллар» профилактик чарасы.

**37. Торак йортларда һәм гражданнар күпләп була торган урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.**

Республика территориясендә торак секторда янгыннарны кисәтү буенча эш оештырылган һәм системалы рәвештә алып барыла. Бу максат белән 984 профилактик төркем эше оештырылган, алар составына полиция хезмәткәрләре, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, «Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең янгын профилактикасы инструкторлары, «Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыяте» ҖЧҖ Татарстан төбәк бүлекчәсе хезмәткәрләре, муниципаль янгын сагы әгъзалары кергән.

75 209 тапкыр профилактик төркемнәр белән шәхси йорт биләмәләре, шул исәптән күп балалы гаиләләр яшәгән урыннар, өлкән яшьтәге гражданнарның, имин булмаган гражданнарның яшәү урыннары булган.

157 меңнән артык гражданга янгын куркынычсызлыгы чаралары турында (янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм көнкүрештә үз-үзләрен тоту турында листовкалар һәм белешмәләр тапшырып) мәгълүмат бирелде, халык белән 1 649 җыен уздырылды (60 меңнән артык кеше җәлеп ителде).

Радиода 449 чыгыш ясалды, телевидениедән 92 чыгыш ясалды, басма массакүләм мәгълүмат чараларында 191 профилактик мәкалә бастырылды.

2016–2024 елларда Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе тарафыннан башлану стадиясендә янгынны вакытында ачыклауны тәэмин итү, торак йортларда (фатирларда) яшәүчеләргә янгын чыгу турында хәбәр итү максатыннан социаль ярдәмгә мохтаҗ гражданнарның торак йортларына (фатирларына) автоном янгын хәбәр итү җайланмалары белән тәэмин итү эше башлап җибәрелде. 2016–2023 еллар чорында төрле финанс чыганаклары хисабына 421 309 автоном янгын сүндерү хәбәрчесе (алга таба – АДПИ) 142 284 йорт биләмәсендә урнаштырылган.

2024 елда АДПИ урнаштыру эше дәвам итте – ел башыннан республикада 740 йорт биләмәсендә 1 655 АДПИ куелды.

Урнаштырылган АДПИ нәтиҗәлелек күрсәтте: 2016–2023 елларда торак йортларда (фатирларда) булган 115 янгын очрагында янгын хәбәрчеләре реакциясе аркасында, йортта яшәүчеләргә янгын чыгу турында үз вакытында хәбәр иткәннәр, бу 285 кешенең (шул исәптән 86 бала) гомерен коткарган.

**38. Татарстан Республикасында мәгариф учреждениеләрендә балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозулар санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, республика муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф идарәсе органнары тарафыннан балачакны яклау, балаларның имгәнүләрен һәм мәгариф оешмаларында

тәрбияләнүчеләр белән бәхетсезлек очракларын кисәтү буенча чаралар комплексы уздырыла:

укытучылар, укучылар һәм аларның ата-аналары белән киңәшмәләр һәм инструктажлар уздыру;

укучылар (тәрбияләнүчеләр) арасында бәхетсезлек, җәрәхәтләнү очракларын булдырмау, балаларның тормыш эшчәнлеген һәм сәламәтлеген тәэмин итү буенча чаралар күрү;

массакүләм чаралар үткәрелгән урыннарга балаларны алып бару һәм алып кайту куркынычсызлыгын тәэмин итү, куркынычсызлык техникасын үтәү буенча өстәмә чаралар күрү;

янгын сүндерү һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлык таләпләрен үтәү;

спорт һәм хәрәкәтчән уеннар, спорт ярышлары буенча дәресләр уздырганда хезмәтне саклау буенча инструкцияләрнең үтәлешен тикшереп тору.

Читтән торып (Интернет аша) уздырыла торган ата-аналар җыелышлары һәм семинарлары кебек эш рәвеше үзен уңай яктан күрсәтте. Аларда балалар иминлеге, су объектларында балалар үлемен профилактикалау, аларның имгәнүенә юл куймау, балигъ булмаганнарның деструктив торышына каршы тору һәм балаларны интернет челтәрендә яклау мәсьәләләре карала. Онлайн-чараларда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Ата-аналар республика советы әгъзалары, мәктәптә ата-аналар комитетлары вәкилләре, мәгариф бүлекләре җитәкчеләренең тәрбия эшләре буенча урынбасарлары, гомуми белем бирү оешмаларының тәрбия эше буенча директор урынбасарлары катнаша.

2023 елның 31 мартында педагоглар, психологлар, ата-аналар комитетлары вәкилләрен җәлеп итеп, республика онлайн-ата-аналар җыелышы булды. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе, Татарстан Республикасында Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм башка оешмалар вәкилләренең җәйге каникуллар чорында куркынычсызлык мәсьәләләре буенча чыгышлары узды.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе белән берлектә, 2023 елның 22 маеннан 28 маена кадәр «Бала – төп пассажир» профилактик акциясен, 2023 елның 22 маеннан 4 июненә кадәр «Игътибар – балалар!» оператив-профилактик чарасын үткәрде.

Муниципаль берәмлекләргә, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе белгечләрен җәлеп итеп, юл хәрәкәте кагыйдәләренә багышланган чараларны барлык мәктәп яны лагерьлары планына кертергә тәкъдим ителде. «Куркынычсызлык атналыгы» дәвамында балалар шәһәр буйлап җәяү, самокатта, велосипедта, җәмәгать транспортында һәм автомобильдә йөргәндә юл хәрәкәте кагыйдәләре белән таныша.

Ата-аналарга юлларда, су объектларында балаларның тормышы, сәламәтлеге, иминлеге өчен зур җаваплылык йөкләнгән, шуңа күрә мәгариф оешмаларында балаларны караучысыз, бигрәк тә балаларның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы урыннарда калдыруны булдырмау буенча «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын бозган

өчен административ җаваплылык турында мәгълүмат бирү буенча ата-аналар (законлы вәкилләр) белән эшләүгә аерым игътибар бирелә.

Мәгариф оешмаларында педагог хезмәткәрләре белән мәгариф оешмаларында хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен үтәүне һәм башкаруны тәэмин итү, балаларның тормышы һәм сәламәтлеге өчен җаваплылыкны көчәйтү турында киңәшмәләр уздырыла.

Укучылар (тәрбияләнүчеләр) һәм хезмәткәрләр белән юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәү, транспортта, су объектларында, кешеләр күпләп җыела торган урыннарда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен, куркынычсызлык техникасын, янгын куркынычсызлыгын, көнкүреш электр җиһазларыннан имин файдалану, ут белән эш итү h.б.

2020–2024 елларга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында «Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре» укыту предметын укыту концепциясен гамәлгә ашыру өчен уку елы башында балаларның куркынычсызлыгын күтәрү максатыннан аларда мәктәп каникулларыннан соң юлларда, транспортта һәм көнкүрештә имин тәртип күнекмәләрен, шулай ук куркыныч һәм гадәттән тыш хәлләр янаганда һәм килеп чыкканда адекват гамәлләрне торгызу өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасында Баш идарәсе белән берлектә мәгариф оешмаларында балаларның куркынычсызлыгы айлыгы үткәрелә.

Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары мәгариф белән идарә итү органнары, гомуми белем бирү оешмалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы тарафыннан эшләнгән гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм күнегүләр әзерләү, халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау буенча методик тәкъдимнәргә таянып эш итәләр.

Бүген җәмгыять алдында торган актуаль һәм социаль әһәмияткә ия бурычларның берсе – балигъ булмаганнар арасында җинаятьләр һәм хокук бозуларның үсешен кимету һәм аларны профилактикалауның нәтиҗәлелеген арттыру юлларын эзләү.

Балалар һәм яшүсмерләрнең үз-үзләрен тотышында тайпылышларны вакытында ачыклау һәм дөрес оештырылган ярдәм хокук бозуларга һәм җинаятьләргә китерергә мөмкин булган хәлләрне булдырмауда мөһим роль уйнарга мөмкин.

Татарстан Республикасында барысы 498 516 балигъ булмаган бала белем ала. «Эчке контроль»дә торучы укучыларның гомуми саны – 50 288 кеше (шуларның: «яшел зона» – 40 700 кеше, «сары зона» – 7 686 кеше, «кызыл зона» – 1 902 кеше, шулардан 1 037 кеше балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәдә исәптә тора).

Балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау кысаларында «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасының процесслы чараларының түбәндәге комплекслары гамәлгә ашырыла: «Балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлек һәм

хокук бозуларны профилактикалау», «Халык арасында наркоманияне профилактикалау», «Терроризм һәм экстремизмны профилактикалау».

Бөтен уку елы дәвамында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, Гомуми һәм һөнәри белем бирү оешмаларында балигъ булмаганнарның аерым категорияләрен исәпкә алу турында нигезләмәләр кысаларында эшли, шул рәвешчә мәгариф оешмаларында эчке боерыклар нигезендә мәгариф оешмаларында белем алучыларны мониторинглау уздыру буенча җаваплы затлар билгеләнгән. Балигъ булмаганнарның хокукка каршы гамәлләр кылу очраклары турында мәгълүмат үз вакытында эчке эшләр органнарына тапшырыла.

«Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге һәм Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты сайтларында «Белем бирү мохитендә хокук бозуларны профилактикалау: тәртип бозуларны диагностикалау һәм коррекцияләү мәсьәләләре. Гомуми белем бирү оешмалары педагоглары һәм педагог-психологлары өчен практик җитәкчелек» педагог-психологлары өчен методик киңәшләр басылып чыкты.

26 муниципаль берәмлектә Психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм һәм хезмәт үзәкләре эшли.

Педагог-психологларның квалификациясен күтәрү өчен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге уздыра:

«Профилактик исәпкә алуның төрле төрләрендә торучы балигъ булмаганнарны психологик-педагогик озата баруны һәм тәрбия эшен камилләштерү» укыту семинарлары;

махсус игътибар зонасындагы мәгариф оешмаларының тәрбия эшләре буенча директорлар урынбасарлары, социаль педагоглары, педагог-психологлары белән түгәрәк өстәлләр;

«Мәгариф оешмаларының педагог-психологлары һәм педагогик хезмәткәрләре өчен Интернет челтәренә балигъ булмаганнарны деструктив берләшмәләргә җәлеп итүне профилактикалау» республика семинарлары;

сыйныф җитәкчеләре өчен «Укучылар арасында деструктив тәртипне профилактикалау» темасы буенча вебинар һәм башка чаралар.

Мәгариф оешмаларының иминлеген һәм террорчылыкка каршы якланганлыгын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының даими контролендә тора.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы яклануына таләпләрне һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) иминлек паспорты рәвешен раслау турында» 2019 елның 2 августындагы 1006 номерлы карары белән Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы объектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы яклануын тәэмин итү буенча оештыру, инженер-техник, хокукый һәм башка чараларны мәҗбүри үтәү өчен билгеләнгән.

Мәгариф объектларының террорчылыктан сакланышын тәэмин итү өчен җаваплылык объектларның хокук ияләре булган органнар (оешмалар)

җитәкчеләренә, шулай ук объектларда хезмәткәрләр эшчәнлегенә турыдан-туры җитәкчелек итүче вазыйфаи затларга йөкләнә.

Россия Эчке эшләр министрлыгының «Яңа уку елы башлануга багышланган чаралар уздырганда җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү турында» 2018 елның 01 августындагы 492 номерлы боерыгы таләпләрен үтәү йөзеннән, яңа уку елы башлануга багышланган чаралар әзерләү һәм уздыру чорында мәгариф өлкәсе объектларында җәмәгать тәртибен тәэмин итү, җинаятьләрне һәм хокук бозуларны булдырмау максатларында, республика шәһәрләрендә һәм районнарында ел саен мәгариф оешмаларын комплекслы тикшерүләр үткәрелә, аларда үз компетенциясе чикләрендә эчке эшләр органнары хезмәткәрләре дә катнаша. Тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне күрсәтеп, оешмаларга һәм ведомстволарга мәгълүмати хатлар җибәрелә.

Хокук бозуларны профилактикалау, шул исәптән мәгариф оешмаларында (гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри оешмаларда) укучы балигъ булмаганнар арасында, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Мәгариф оешмаларында балигъ булмаганнар белән профилактик эш уздыруда «Гаилә иминлеген һәм балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау» эшчәнлеге юнәлеше буенча муниципаль хезмәткәрләр актив катнаша.

Җитди сәбәпләрез дәрес калдыручы укучыларны, тәрбия эше буенча директор урынбасарлары, сыйныф җитәкчеләре, психологлар, медицина хезмәткәрләре белән әңгәмәләр үткәрү юлы белән балалар белән рәхимсез мөгамәлә кылу фактларын ачыклау эше оештырылды. 2023 елда алар катнашында профилактика советларының 1 937 утырышы уздырылган, анда укудан явызларчы читләшкән 580 яшүсмер билгеләнгән. Балигъ булмаганнарның үз-үзен деструктив тотышы турында 312 хәбәр ачыкланган һәм балигъ булмаганнарның эшләре буенча бүлекчә хезмәткәрләренә тапшырылган. 2 771 административ хокук бозу һәм 75 җинаять ачыклауда ярдәм күрсәтелгән.

2023 елда эчке эшләр органнары тарафыннан балигъ булмаганнар яисә алар катнашында кылынган 795 җинаять тикшерелгән (2022 елда – 736).

**39. Гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта халыкны яклауга юнәлдерелгән чаралар турында. Локаль хәбәр итү системаларын торгызуга юнәлдерелгән чаралар турында.**

Халыкка хәбәр итү системасын даими әзерлектә тоту максатларында Татарстан Республикасы буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән берлектә 2024 елга Татарстан Республикасына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасына эксплуатация-техник хезмәт күрсәтүгә дәүләт контрактын төзү эшен башкарды.

2023 елның 16 августында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов җитәкчелегендә киңәшмә үткәрелде, аның нәтиҗәләре буенча Татарстан

Республикасы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең яңа төбәк автоматлаштырылган системасын булдыру турында карар кабул ителде.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов күрсәтмәләре исемлеге нигезендә, 2023 елның 12 сентябрендәге ПР-192 номерлы киңәшмә нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы халкын үзәкләштерелгән хәбәр итүнең яңа төбәк автоматлаштырылган системасын төзү буенча проектны башкаручы итеп «Таттелеком» ГАҖ, заказчы итеп Татарстан Республикасы буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы билгеләнде. Проектны гамәлгә ашыру срогы – 2024–2028 еллар.

**40. Йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда иминлекне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелә торган чаралар турында.**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 14 маендагы 410 номерлы карары белән расланган Газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтелгәндә йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда иминлекне тәэмин итү өлешендә газдан файдалану кагыйдәләре нигезендә йорт эчендәге һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау эшләре Кагыйдәләрдә каралган тәртиптә заказчы һәм башкаручы арасында төзелгән йорт эчендәге һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау турындагы шартнамә нигезендә махсуслаштырылган оешма тарафыннан башкарыла. Йорт эчендәге һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау турындагы килешү буенча заказчы һәм башкаручы бер үк зат була алмый.

«Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтүне халык белән төзелгән йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү килешүләре нигезендә махсуслаштырылган оешма буларак башкара.

Йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итү мәсьәләсе квартал саен Татарстан Республикасында газлаштыру буенча төбәк штабы утырышында карала.

**41. Татарстан Республикасында азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен күрелә торган чаралар турында.**

«Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» 2017 елның 13 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы нигезендә республиканың азык-төлек иминлеге торышын бәяләү критерийлары булып 6 товар позициясе буенча тәэмин ителү тора (ашлык, шикәр, үсемлек мае, ит һәм ит продуктлары, сөт һәм сөт продуктлары, бәрәңге).

Республиканың агросәнәгать комплексы халыкны үз продукциясенең төп төрләре белән тулысынча тәэмин итә. Мәсәлән, ит һәм ашлык белән тәэмин ителеш 2023 елда 100 % тан артык, сөт буенча – 150% тан артык%, шикәр буенча – 200 % тан артык, үсемлек мае буенча тәэмин ителеш нормадан 7 тапкырдан да югарырак.

Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы культураларының тотрыклы уңышын тәэмин итү өчен мелиорация комплексын үстерү буенча федераль һәм республика программалары гамәлгә ашырыла. Федераль бюджет акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гидротехник корылмаларны һәм

мелиоратив системаларны реконструкцияләү һәм торгызу уздырыла. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне нәтиҗәле әйләнешкә кертү һәм Россия Федерациясе мелиорация комплексын үстерү дәүләт программасы турында» 2021 елның 14 маендагы 731 номерлы карары белән расланган дәүләт программасы буенча 2023 елда Мөслим һәм Азнакай сугару системаларын реконструкцияләү хисабына 1 020 гектар сугарулы җир файдалануга тапшырылган.

2019 елдан «Агросәнәгать комплексы продукциясе экспорты» федераль проекты буенча сугарулы кишәрлекләрне киңәйтү буенча системалы эш алып барыла. Сугару һәм киптерү системаларын төзү һәм реконструкцияләүне, шулай ук файдаланылмый торган җирләрне әйләнешкә кертүне субсидияләү башарыла (хуҗалыкларга федераль һәм республика бюджетларыннан уртак финанслау шартларында чыгымнарның 50 %ы кире кайтарыла). Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 7 290 гектар җир файдалануга тапшырылган, шул исәптән 5 082 гектар сугарулы җир, әйләнешкә 1 688 гектар җир кертелгән, шулай ук 520 гектар мәйданда сазлыклы кишәрлекләрне киптерү чаралары уздырылган.

2024 елга Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгында күрсәтелгән юнәлеш буенча 1 509 гектар мәйданда 6 проект сайлап алынды.

Шулай ук «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне әйләнешкә кертү һәм комплекслы мелиорацияләү» федераль проекты кысаларында 2024 елга Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 954 гектар сугарулы җирләрне кертү буенча 3 эре проект сайлап алынды. Объектларның гомуми смета бәясе 76,6 млн. сумнан артык.

Мелиорация буенча федераль программалардан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 5 юнәлеш гамәлгә ашырыла:

«Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне мелиорацияләүне үстерү» төбәк проекты кысаларында муниципаль һәм (яисә) дәүләт җирләрендә сугару һәм киптерү системаларын, шулай ук аерым урнашкан гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләре башкарыла. Финанслау тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән башкарыла. 2023 елда 2 561,4 гектар мәйданлы сугарулы кишәрлекләрне су белән тәэмин итү өчен 7 гидротехник корылмада эшләр башкарылган;

2023 елдан башлап, сугару һәм киптерү системаларын, шулай ук авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен аерым урнашкан гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның 95%ын финанс белән тәэмин итү рәвешендә (НДС исәпкә алмыйча) субсидия бирү буенча дәүләт ярдәме чарасы гамәлгә кертелде. Әлеге юнәлештә эшләр 826,4 гектар сугарулы җирләрдә 6 объектта башкарылган;

мелиорация техникасын сатып алуга бәйле чыгымнарның 70 %ын финанс белән тәэмин итү. Ел саен финанслау лимиты 100 млн. сум тәшкил итә. 2023 елда ярдәм чарасыннан 27 хуҗалык файдаланды;

үсемлекчелек һәм терлекчелек комплексларын су белән тәэмин итү. Скважиналарны бораулауга һәм су манараларын урнаштыруга 70% чыгымнар кире

кайтарыла. Барлыгы 20 артезиан скважинасы бораулангаң һәм 7 су җыю манарасы урнаштырылган;

авыл хуҗалыгы культураларын электр насослары белән сугару өчен күтәрелүнең ике баскычлы схемасында су бирү чыгымнары өлешен каплау. Дәүләт ярдәме, электр энергиясенә чыгымнарны исәпкә алып, җитештерелгән чыгымнарның 60%ы күләмендә бирелә.

Азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен агротехнологик чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

2023 елда уңышны формалаштыру өчен түбәндәге эш башкарылды:

сөрү катламын тирәнәйтү – 940 мең гектарда;

минераль ашламалар кертү – 82,1 кг гамәлдәге матдә/гектар (2022 елда – 74,4 кг гамәлдәге матдә/гектар). Нәтиҗәлелекне арттыру өчен, күбрәк сыек ашламалар кулланыла башлады;

чәчүлекләрне карау һәм яфрак аша туклandыру – 6,4 млн гектар, шул исәптән 1,8 млн гектар яфрак аша туклandырылды;

бөртекле культураларның 37 %ы оригиналь һәм элиталы орлыклар белән чәчелде;

чәчү кампаниясе кыскартылган оптималь агротехник срокларда югары сыйфатлы башкарылды.

Соңгы 5 елда авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларында сөт җитештерү 2018 ел белән чагыштырганда 29,3 %ка арткан, сугымга терлек һәм кош-корт тере үлчәмдә 6,2 %ка, йомырка җитештерү 17,2 %ка арткан.

2023 ел йомгаклары буенча Татарстан сөт җитештерү буенча Россия Федерациясендә ныклы 1 нче урынны (Россия Федерациясе гомуми күләменең 6,5 %), йомырка җитештерү буенча 6 нчы урынны (3,3 %), сугымга терлек һәм кош-корт җитештерү буенча 8 нче урынны (3,1 %) били.

Барлык төр хуҗалыкларда 2023 елда сөт – 2 190 мең тонна (2022 елга карата 107,5 %), сугымга тере үлчәмдә терлек һәм кош – 512,9 мең тонна (97,5 %); йомырка – 1 562,6 млн. данә (101,5 %) җитештерелде.

Терлекчелек фермаларын һәм комплексларын төзү, җитештерүне яхшырту өчен терлекләрне идентификацияләнең бердәм системасын кертү, терлекләр һәм ашату белән идарә итү программаларын гамәлгә кертү, рацион компонентларын сыйфатлы балanslау һәм катнаштыру өчен азык үзәкләрен урнаштыру буенча актив эш дәвам итә.

Соңгы 3 елда 43,2 мең баш куәтле 63 сөт комплексы һәм ферма файдалануга тапшырылган, шул исәптән 2023 елда – 10,6 мең башка исәпләнгән 19 сөтчелек комплексы, 54,9 мең баш нәселле тана сатып алынган, шул исәптән 2023 елда – 15,8 мең баш.

Заманча сөтчелек комплексларын төзү һәм гамәлгә кертү җитештерүне ел саен 2–3 % дәрәҗәсендә алга таба арттыру өчен база формалаштыра.

Терлек азыгы үзәкләрен оештыру өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора. 2023 елда 8 терлек азыгы үзәге файдалануга тапшырылган, 2024 елда 9 терлек азыгы үзәге төзү планлаштырыла.

**42. Балаларның һәм яшүсмерләрнең деструктив тәртибен профилактикалауны оештыру, Татарстан Республикасында балигъ булмаган хокук бозучыларны реабилитацияләү һәм социальләштерү турында.**

Мәгариф оешмалары укучылары катнашында һәм аларга карата хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча ведомствоара эш уздыру, хокук бозучы яшүсмерләр турында оператив мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашыру максатларында 2020 елның декабрендә «Электрон белем» дәүләт мәгълүмат системасы базасында девиант тәртипкә тартым балигъ булмаганнар турында Татарстан Республикасы мәгълүматларының бердәм банкын төзү турында карар кабул ителде.

Әлеге карарны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы арасында балигъ булмаганнарның хокук бозуларын һәм үз-үзләрен җәмгыятькә каршы тотышларын профилактикалау мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды.

Күрсәтелгән килешү кысаларында эш барышында белем бирү оешмасының эчке контроленә куелырга тиешле укучылар категорияләре исемлеген киңәйтү турында карар кабул ителде.

2022 елның июнендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Гомуми һәм һөнәри белем бирү оешмаларында балигъ булмаганнар категорияләрен исәпкә алу турында нигезләмә имзаланды, аңа 2022 елның декабрендә «Колумбайн» хәрәкәте тарафдарларын, буллинг белән шөгыльләнүче укучыларны, шулай ук буллингтан зыян күргән затларны алга таба тернәкләндерү эшләрен, шул исәптән психологлар катнашында да, алып бару өчен эчке контрольгә кую өлешендә өстәмәләр кертелде.

2024 елның 1 февраленә «Электрон белем» дәүләт мәгълүмат системасында 50 288 балигъ булмаган бала эчке контрольдә булу турында белешмәләр бар, шуларның югары куркыныч зонасында («кызыл зона») – 1 902, күтәренке куркыныч зонасында («сары зона») – 7 686, уртача куркыныч зонасында («яшел зона») – 40 700. Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре тарафыннан эчке контрольдә торучы затлар белән профилактик чаралар үткәрелә, деструктив тәртипкә китерә торган яшәү рәвеше, шартлар өйрәнелә.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында һәм эчке эшләр органнарының территориаль органнарында «Лидер» төркемнәре төзелде, аларның өстенлекле бурычлары –балигъ булмаганнарның асоциаль юнәлештәге деструктив төркемнәрен, шул исәптән Интернет челтәрендә, үз вакытында ачыклау, яшьләрне җинаятьчел эшчәнлеккә җәлеп итүгә юл куймау, хокукка каршы оештырылган яшьләр оешмаларын таркату.

2023 елда республика эчке эшләр территориаль органнарының «Лидер» төркеме хезмәткәрләре тарафыннан яшьләр тупланган урыннар буенча 1 807 рейд чарасы (2022 елда – 1 941), балигъ булмаганнар белән җәмгыятькә каршы юнәлештәге хокукка каршы яшьләр формированиеләрендә катнашуның ярамаганлыгы турында 9 809 профилактик әңгәмә уздырылган (2022 елда – 8 979).

2024 елның 1 гыйнварына эчке эшләр территориаль органнарында исемлек исәбендә барлыгы 398 кешедән торган (2022 елда – 361) балигъ булмаганнарның

113 деструктив төркеме тора (2022 елда – 102), республиканың уку йортларында эчке контрольдә – 46 166 укучы (2023 елның 1 гыйнварына – 24 123).

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ хезмәткәрләре тарафыннан даими нигездә потенциаль куркыныч мәгълүмати, шул исәптән яшьләр деструктив агымнары идеологиясен алга сөрә торган ресурслар эшчәнлегенә мониторинг уздырыла. 2023 елда эчке эшләр органнары хезмәткәрләре тарафыннан деструктив контенты булган интернет-сайтлар буенча 3 615 үтенечнамә (2022 елда – 2 275) әзерләнгән һәм компетентлы ведомстволарга юнәлтелгән, 1 566 блокка куелган (2022 елда – 845). Шул ук вакытта, кагыйдә буларак, хокук ияләре хокук бозуларны мөстәкыйль рәвештә бетерә, яки ачыкланган хокук бозулар «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясы белән расланган тыелган мәгълүмат исемлегенә эләкми.

Яшьләрне экстремистик эшчәнлеккә җәлеп итүгә юл куймау чаралары күрелә. Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлектә «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында яшүсмерләр арасында деструктив концепцияләр, криминаль субкультура таралуны, аларны законсыз гавами чаралар уздыруга җәлеп итүне булдырмау буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырыла. Гражданлык позициясен формалаштыру өчен, шулай ук радикаль агымнарның үсеп килүче буынның дөньяга карашына йогынты ясау мөмкинлеген булдырмау максатында республиканың барлык мәгариф учреждениеләрендә җаваплы педагоглар беркетелгән.

2023 елда экстремистик юнәлештәге административ хокук бозу кылган 8 балигъ булмаган һәм аларның 3 законлы вәкиле административ җаваплылыкка җәлеп ителгән. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре җыйган материалларга нигезләнеп, прокуратура органнары тарафыннан балигъ булмаганнарга һәм аларның законлы вәкилләренә экстремистлык эшчәнлекне гамәлгә ашырырга ярамау турында 5 кисәтү чыгарылды.

Балигъ булмаганнар катнашында башкарма хакимият органнары белән килештерелмәгән иҗтимагый акцияләр һәм башка хокукка каршы гамәлләр, балигъ булмаганнар катнашында җәмәгать тәртибен төркемле бозуларны да кертеп, үткәрүгә өндәүче затлар һәм оешмалар турында мәгълүматны җыю һәм системалаштыру максатында Интернет челтәрен һәм массакүләм мәгълүмат чараларын мониторинглау даими рәвештә оештырыла һәм үткәрелә.

Республиканың гомуми белем бирү, югары һәм урта-махсус уку йортлары укучылары арасында террорчылык һәм экстремистик идеология таралуга юл куймау максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән үзара хезмәттәшлек җайга салынды. Республика шәһәрләре һәм районнарының мәгариф учреждениеләрендә прокуратура органнары һәм мәгариф идарәләре (бүлекләре) белән үзара хезмәттәшлектә сыйныф сәгатьләре, рөхсәтсез җыелышларда, митингларда, демонстрацияләрдә, урам йөрешләрендә яисә пикетларда катнашуны профилактикалау дәресләре уздырыла.

«Колумбайн» («Скулшутинга») идеологиясе йогынтысына бәйле законсыз эшчәнлекне профилактикалау һәм чикләү чаралары дәвам итә. 2023 елда укучылар һәм педагоглар корбан булырга мөмкин булган җинаятьләрне әзерләү турында

8 хәбәр тикшерелде, аларның нәтиҗәләре буенча, җыелган материаллар нигезендә, Кукмара муниципаль районының балигъ булмаган яшәүчесенә карата ике һәм аннан күбрәк кешене үтерүгә һөҗүм итү факты буенча җинаять эше кузгатылды.

«Колумбайн» идеологиясе контенты урнаштырылган 36 ресурс ачыкланган һәм блокланган. Күрсәтелгән тематикадагы чатларда катнашучы 4 балигъ булмаган Татарстан Республикасы кешесе билгеләнде, аларга экстремистик эшчәнлек алып баруга юл куймау турында прокурор кисәтүләре чыгарылды. Тагын бер балигъ булмаганның ата-анасы Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 5.35 статьясы буенча административ җаваплылыкка тартылган.

«Колумбайн» идеологиясе нигезендә җинаятьләрне профилактикалауның нәтиҗәле коралы булып составына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенең, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм башка ведомстволарның җаваплы хезмәткәрләре кергән мәгариф оешмаларында массакүләм көч куллану куркынычын кисәтү буенча ведомствоара эш төркеме эшчәнлеге тора. Әлеге ведомствоара эш төркеменең төп бурычлары булып потенциаль җинаятьчеләрне ачыклау, аларның эшчәнлеген чикләү һәм алга таба профилактик озата бару тора. Шундый ук ведомствоара эш төркемнәре муниципаль дәрәҗәдә оештырылган.

Россия Федерациясе Кораллы көчләре тарафыннан махсус хәрби операция уздыру белән бәйле яңа чакырулар һәм янаулар фонында чит ил хезмәтләре тарафыннан Россия халкының төрле төркемнәренең Интернет челтәре мессенджерлары, бигрәк тә яшьләр һәм яшүсмерләр ярдәмендә җинаятьчел эшчәнлеккә җәлеп итүгә юнәлдерелгән актив омтылышлар ясала. Вәгъдә ителгән акча өчен алар чит ил кураторлары биргән транспорт инфраструктурасына зыян китерү, дәүләт хакимияте объектларының һәм хокук саклау органнарының эшен бозу турындагы йөкләмәләрен үтиләр. Дәүләт хакимияте органнары, критик һәм транспорт инфраструктурасы мөлкәтенә ут төртүне һәм башка төрле зарарланулар ясауны планлаштыручы затларны, шулай ук әлеге затларны вербовщикларны билгеләүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү нәтиҗәсендә Россия Федераль иминлек хезмәте идарәсенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән үзара хезмәттәшлектә әлеге җинаятьләрне кылуга катнашы булган 5 балигъ булмаган бала билгеләнгән.

## Экология

### 43. Туфракны саклау һәм җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге законнарны үтәүгә, шул исәптән эрозия процессларын киметүгә юнәлдерелгән чаралар турында.

Республиканың җир ресурсларын саклау Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының өстенлекле бурычларының берсе булып тора.

Авыл хуҗалыгы җирләренең сөрелү дәрәҗәсе югары булу (76 %) чәчүлек җирләре урман белән аз урап алынганда (4,7–7 % оптималь булганда 4 %) һәм

Татарстан Республикасы территориясенең урманчылыгы түбән булу күрсәткече (17,9 %) су һәм җил эрозиясенең актив процесслары үсешенең алшарты булып тора.

Республика туфрагын тотрыкландыру һәм аның торышын яхшырту, эрозия процессларын булдырмау һәм аларның үсешен туктату, сөрүлекләрнең ышанычлы саклануын һәм югары продуктив агроландшафт тәэмин итү өчен экологик каркас рәвешендә Татарстан Республикасында кимендә 190,0 мең гектар саклагыч урман үсентеләре булырга, республиканың табигый-климат үзенчәлекләрен һәм ландшафтлап районнарга бүленешен исәпкә алып, чәчүлекләрнең кимендә 4,7–7 % дәрәҗәсендә урманнар белән әйләндереп алу күрсәткеченә ирешү өчен өстәмә рәвештә 100 мең гектардан да ким булмаган эрозиягә каршы һәм кырларны яклау өчен урман утыртмалары булдырырга кирәк. Моннан тыш, агроландшафтның торышын оптимальләштерү һәм тулаем экологик вәзгыять өчен Татарстанда деградацияләнгән җирләрдә төзелә торган урманнар мәйданын арттырырга кирәк.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне мелиорацияләүне үстерү» төбәк проектын гамәлгә ашырганда эрозиягә каршы һәм кырларны саклау өчен урман утыртмалары булдыру кысаларында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан ел саен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән саклаучы урман утыртмаларын (эрозиягә каршы, чокыр-чакыр һәм кыр саклау) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге деградацияләнгән җирләрдә булдыру буенча эш алып барыла. Үткәрелгән эшләр йомгаклары буенча 2023 елда 1,5 мең гектар мәйданда катнаш токымнарның саклаучы урман үсентеләре булдырылган, дәүләт ярдәме 152,8 млн.сум тәшкил иткән.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 2023 елда 1,2 мең гектар мәйданда эрозиягә каршы саклагыч утыртмалар булдыру эшләре башкарылды. 500 гектар мәйданда парник газларын ташлауны компенсацияләү тәртибендә саклаучы урман үсентеләре утырту буенча эш алып барылды. Шулай ук урман утыртмаларын кискән яисә урман кишәрлегенең максатчан билгеләнешен үзгәртү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән урман кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан 172 гектар мәйданда урман торгызу һәм урман үрчетү буенча компенсация эшләре башкарылган.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) барышында гомумтаралган файдалы казылмаларны (карьераларны) рөхсәтсез чыгару, калдыклар (чүплекләр) белән эш итү кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә бозылган җирләрне ачыклау гамәлгә ашырыла. Табигатьтән файдаланучыларга карата административ йогынты чаралары күрелә, шул исәптән бозылган җирләрне рекультивацияләү өлешендә дә.

Һәр муниципаль берәмлектә муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан рекультивацияләнгән җир кишәрлекләрен кабул итүне (тапшыруны) оештыру, шулай ук хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек нәтиҗәсендә бозылган җирләрне торгызуга бәйле башка мәсьәләләрне карау өчен комиссия төзелде.

Еш кабатлана торган коры җилләрнең, атмосфера һәм туфрак корылыкларының тискәре йогынтысын минимальләштерү максатларында 2022 елдан башлап Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан игенчелекнең агроландшафт туфрак эшкәртү системасы кертелә, ул технологик процессларны системалаштыру белән беррәттән кыр саклагыч һәм эрозиягә каршы урман утыртмаларын булдыруны да күздә тота.

Агроландшафт игенчелеге югары һәм тотрыклы уңыш алуда, җирдән нәтиҗәле файдалануда һәм туфракның уңдырышлылыгын арттыруда, җитештерелә торган продукциянең экологик иминлеген үстерүдә үрнәк булып тора.

Бүгенге көндә республикада Татарстан Республикасы Тукай, Әлмәт, Биектау, Әтнә, Кукмара, Тәтеш, Нурлат, Аксубай, Арча, Спас, Балтач муниципаль районнары хуҗалыкларында игенчелекнең агроландшафт туфракны саклау системасы буенча 31 проект эшләнде. Эшләнгән проектлар буенча колачланган авыл хуҗалыгы җирләре 243,0 мең гектар тәшкил итә.

Җир эшкәртүдә агроландшафт туфракны саклау системасы буенча проектлар гамәлгә кертү авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен шактый җитди өстенлекләргә ия һәм түбәндәгеләргә мөмкинлек бирә:

авыл хуҗалыгы предприятиесенең экологик-географик һәм агроклимат шартларын анализларга;

авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең торышын һәм перспективаларын, сугаруны үстерүнең перспективаларын билгеләргә;

туфракны агроэкологик төркемләүне үткәрергә.

Моннан тыш, андый проектлар туфракны эрозиядән саклау, чәчү әйләнеше сиситемасын гамәлгә кертү, туфракны эшкәртү, орлыкчылык, туфракның уңдырышлыгын саклау һәм үстерү чараларын үз эченә ала.

Игенчелекнең агроландшафт туфракны саклаучы системасын гамәлгә ашыручы хуҗалыклар өчен дәүләт ярдәме чаралары каралган:

проектларны эшләүгә чыгымнарның 80%ын каплау. 2022–2023 еллар чорында хуҗалыкларга 17,7 млн. сум бирелгән;

минераль ашламалар сатып алу өчен ярдәм кысаларында игенчелекнең агроландшафт туфракны саклау системасы буенча проектка кертелгән 1 гектар чәчү мәйданына 450 сум өстәмә ставка каралган. 2023 елда күрсәтелгән юнәлеш буенча 87,2 млн.сум ярдәм күрсәтелгән.

**44. Атмосфера һавасының сыйфатын яхшыртуга һәм кеше сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны булдырмауга юнәлдерелгән чаралар турында.**

2023 елда Татарстанда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру дәвам итте.

2023 елда 822 автомобиль сатып алынган һәм газга күчерелгән, бу атмосферага чыгарылмаларны 1,4 мең тоннадан артыкка киметергә мөмкинлек биргән.

Программа башыннан барлыгы компримирланган табигый газга 13,9 мең автомобиль күчерелгән, бу атмосферага күчмә чыганаклардан зарарлы матдәләр чыгаруны 23,9 мең тоннадан артык киметүгә ирешергә мөмкинлек бирде.

Автотранспортның атмосфера һавасы торышына тискәре йогынтысын киметү өчен 2023 елның 1 июненнән 30 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафннан  Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе белән берлектә линиягә чыгарыла торган һәм кулланылышта булган автотранспорт чаралары ташлаган эшкәртелгән газларда пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларның билгеләнгән нормативларын үтәүне тикшереп тору буенча оператив-профилактик чаралар уздырылды («Чиста һава» операциясе). Операция кысаларында автомобиль юлларында 6 886 автомашина тикшерелде, шулардан 184 автомашина эшкәртелгән газларда пычраткыч матдәләр чыгаруларның таләп ителгән нормативларына туры килмәде.

Соңгы 5 елда эшкәртелгән газларда пычраткыч матдәләр күләме югары булган транспорт чаралары санының кимүе күзәтелә - 2019 елда 5,2 % тан 2023 елда 2,7 % ка кадәр. Кимү мотор ягулыгының сыйфатын яхшырту һәм чыгарып ташлаулар югары дәрәҗәдә булган автомобильләр паркын яңа, экологик булган, 4, 5, 6 экологик класс таләпләренә туры килә торган  автомобильләргә алыштыру белән дә аңлатыла.

2023 елда республика предприятиеләре үзләренең Табигатьне саклау чаралары программалары кысаларында производстволарны модернизацияләү һәм реконструкцияләүне, искергән җиһазларны алыштыруны, газ бирү системаларын оптимальләштерүне, тузан чистарту системаларын урнаштыруны, вентиляция системаларын һәм термоагрегатларны капиталь ремонтлауны һәм башка һава саклау чараларын гамәлгә ашырдылар, бу атмосферага чыгарып ташлауларны киметүгә ирешергә ярдәм итте.

**45. Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүнең торышы һәм аны үстерү перспективалары турында.**

2024 елның 1 гыйнварына республикада 7 авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе беренче (югары) дәрәҗәдәге органик җитештерүгә туры килә торган яшел сертификатлар алды һәм Россия Федерациясендә органик продукция җитештерүчеләрнең дәүләт реестрына кертелде:

«Андрюшкино» АСК ҖЧҖ (Мамадыш муниципаль районы, җиләк продукциясе);

ШЭ К(Ф)ХБ  Исхакова Р.Ш. (Лаеш муниципаль районы, бөртекле һәм азык культуралары);

К(Ф)ХБ Гафиуллин Р.Н. (Балтач муниципаль районы, җиләк продукциясе);

ШЭ Кыямов Ф.Ф. (Баулы муниципаль районы, азык культуралары);

ШЭ К(Ф)ХБ  Маслаков Д.Г. (Минзәлә муниципаль районы, бөртекле культуралар);

- ШЭ К(Ф)ХБ  Аксаков Р.Р. (Арча муниципаль районы, бөртекле һәм азык культуралары);

«Луч» ҖЧҖ (Чистай муниципаль районы, бөртекле, кузаклы һәм азык культуралары).

Конверсия процессында торалар һәм сары сертификатларга ия:

Мамадыш муниципаль районының «Андрюшкино» АСК ҖЧҖ (алмагачлар);

ШЭ Кыямов Ф.Ф. (Баулы муниципаль районы, ябык грунтта яшелчәләр (томатлар);

«Органик биосистемалар» ҖЧҖ (Лаеш муниципаль районы, бөртекле, кузаклы һәм ярма культуралары);

К(Ф)ХБ Хәсәнов М.Р. (Чистай муниципаль районы, бөртекле, майлы һәм җиләк культуралары);

К(Ф)ХБ Данилова Н.Х. (Арча муниципаль районы, ябык грунтта яшелчәләр (кыярлар);

«Луч» ҖЧҖ (Чистай муниципаль районы, эре мөгезле терлекләр үрчетү һәм чи сөт җитештерү);

ШЭ К(Ф)ХБ Исхакова Р.Ш. (Лаеш муниципаль районы, эре мөгезле терлекләр үрчетү һәм чи сөт җитештерү).

2024 елның 1 гыйнварына «Россия сыйфат системасы» АКБО органик продукцияне сертификацияләнгән җитештерүчеләр саны буенча Россия Федерациясе субъектларының рейтингы нигезендә Татарстан Республикасы 4 нче урынны алды.

Татарстан Республикасында «Татарстанның органик продукты» органик җитештерүне ихтыярый сертификацияләү системасы эшли. Сертификацияне «Тест-Татарстан» Республика сертификацион методик үзәге» АҖ гамәлгә ашыра.

«Татарстанның агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институты» өстәмә һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе каршындагы «Органика» укыту-методик үзәге төзелде һәм эшли.

Органик продукция җитештерүне үстерү максатларында «Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» 2021 елның 5 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, үсемлекчелек органик продукциясен җитештерүчеләрне субсидияләү тәртибе эшләнде.

2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан үсемлекчелек органик продукциясен җитештерүчеләргә ярдәм өчен 10 млн. сум акча бүлеп бирелде, 2022 елда - 20 млн. сум субсидия, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 17,8 млн. сум, 2023 елда - 20 млн. сум җиткерелде, 2024 елга шулай ук 20 млн. сум каралган.

Субсидия алучылар тарафыннан тәкъдим ителгән органик продукция җитештерүне үстерүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе турындагы хисапларга ярашлы рәвештә беренчел сертификат гамәлдә булган чорда күчеш чорында һәм (яисә) органик продукция җитештерүдә булган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә авыл хуҗалыгы культуралары җитештерү күләме 2023 елда 8 577,0 тонна тәшкил итте.

Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган 2030 елга кадәр Россия Федерациясендә органик продукция җитештерүне үстерү стратегиясе күрсәткечләре (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 4 июлендәге 1788-б номерлы боерыгы) һәм Аны гамәлгә ашыру чаралары планы нигезләмәләре нигезендә хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән берлектә 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында органик авыл хуҗалыгын үстерүнең дәүләт программасын эшләү алып барыла.

Органик продукция җитештерүне үстерү перспективалары:

органик продукция җитештерү күләмен 2024 елда 10 мең тоннага кадәр арттыру;

яңа авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен органик продукция җитештерүгә җәлеп итү;

республикада органик терлекчелекне алып баруның фәнни-нигезләнгән системаларын гамәлгә кертү.

Җирле үзидарә мәсьәләләре

**46. 2023 елда гражданнарның үзара салым программасын гамәлгә ашыру һәм 2024 елда инициативалы проектларны гамәлгә ашыру перспективалары турында.**

Республикада җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча гражданнарның инициативаларына дәүләт ярдәме гражданнарның үзара салым механизмын тормышка ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла. Гражданнар үзара салым кертү мәсьәләләре буенча референдумнарда шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә туры килә торган чаралар кысаларында акчаларны тоту юнәлешләрен үзләре билгеләде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әхәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау хакында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнарның үзара салымы кертелгән муниципаль берәмлекләр бюджетларына өстәмә акчалар бүленә.

2013 елдан 2023 елга кадәр үзара салым тәртибендә татарстанлылар үз территорияләрен үстерүгә барлыгы 2,36 млрд сум акча керткән. 2014 елдан 2023 елга кадәр Татарстан Республикасы бюджетыннан гомуми финанслау күләме 9,3 млрд сум тәшкил итте.

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетында күрсәтелгән максатларга ел саен 1,35 млрдн сум акча каралган.

Үзара салым акчасына торак пунктлар эчендәге юллар, күперләр төзелә һәм ремонтлана, су белән тәэмин итү, авыл торак пунктларын яктырту эшләре башкарыла, ял итү урыннарын, спорт һәм балалар мәйданчыкларын, чишмәләрне, табигый һәм ясалма сулыкларны төзекләндерү эшләре алып барыла, һәйкәлләр һәм обелисклар урнаштырыла һәм реконструкцияләнә.

Үзара салымда җирле үзидарә органнары һәм республика торак пунктларында яшәүчеләр кызыксына, алар җирле инициативаларны гамәлгә ашыру процессына җәлеп ителә. Практика күрсәткәнчә, үзара салым җирле үзидарә органнарының халык белән үзара хезмәттәшлегенең төп инструментларының берсе, халыктан капма-каршы элемтәнең көчле каналы булды. Гражданнар җыемнарының еллык үсеше җирле хакимиятнең абруе турында сөйли. Үзара салым программасын гамәлгә ашыру мәсьәләләре «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы» ассоциациясе съездларында, ассоциация президиумы утырышларында даими рәвештә тикшерелә.

2018 елга кадәр гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумнарда хәл ителде. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга  кертелгән үзгәрешләр гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсен аерым торак пунктлар

территорияләрендә үткәрелә торган гражданнар җыеннарында да хәл итәргә мөмкинлек бирде.

2019 елда законнарга гражданнар җыеннарын этаплап үткәрергә мөмкинлек бирә торган үзгәрешләр кертелде. Шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә һәм 2021 елның маенда тиешле Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, мегаполисларны да кертеп, эре торак пунктлар территориясендә (микрорайонда, кварталда, территориаль иҗтимагый үзидарәдә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын үткәрү мөмкинлеге каралган.

Югарыда бәян ителгән федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләр нигезендә муниципаль берәмлекләр уставларына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карарына тиешле үзгәрешләр кертелде.

Шәһәр һәм авыл халкы керемнәрендәге аерманы исәпкә алып, уртак финанслау күләме, җирлек категориясенә карап, җыелган үзара салым акчаларының һәр сумына 2 сумнан 4 сумга кадәр тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 декабрь, 909 нчы карары белән расланган Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2022 елның 23 декабрендәге 1397 нче карары нигезендә башка бюджетара трансфертларның акчалары җибәрелергә мөмкин булган эшләр төрләре билгеләнде, шулай ук гражданнарның үзара салым акчаларының норматив күләмен исәпкә ала торган башка бюджетара трансфертларны бүлү методикасы каралды. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында» 2024 елның 29 декабрендәге 1532 нче карары белән, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган торак пунктлардан тыш, 2024 елда Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлекләре составына керүче торак пунктлар өчен башка бюджетара трансфертлар бирелә дип каралган.

**47. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан**

**Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү турында.**

2024–2026 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары, тәкъдим ителгән федераль индекс-дефляторларны исәпкә алып, республиканың берләштерелгән бюджетын төзүнең бердәм сценар шартларыннан чыгып формалаштырылды.

Бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда 2024 елга җирле бюджетлар, 2023 ел дәрәҗәсенә караганда 4,1 млрд сумга (яки 9,5 %) үсеш белән 47,3 млрд сум күләмендә законда беркетелгән салым һәм салым булмаган керемнәр буенча фаразланган. Җирле бюджетларның чыгымнары сценария шартлары нигезендә 2023 елга карата 11,2 млрд сум үсеш белән 2024 елга үз вәкаләтләре буенча 94,3 млрд сум күләмендә билгеләнгән.

Шулай итеп, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларының чыгым вәкаләтләренең 2024 елга беркетелгән керемнәр белән тәэмин ителеше уртача 50,2 % тәшкил итте.

Бюджетара җайга салу нәтиҗәсендә физик затлар керемнәренә салым муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең бер өлешен алмаштыручы өстәмә нормативлар буенча җирле бюджетларга 20,6 млрд сум күләмендә күчерелергә тиеш.

Шулай ук җирле бюджетларның баланслылыгын тәэмин итү өчен 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетында җирле бюджетларга 26,1 млрд сум күләмендә дотацияләр һәм субсидияләр каралган. Моннан тыш, җирле бюджетларга 3,1 млрд сум күләмендә максатчан субсидияләр бирелә.

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү максатларында 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетында 42,0 млрд сум күләмендә субвенцияләр каралган.

Финанс ярдәмен исәпкә алып, республиканың җирле бюджетлары керемнәренең гомуми күләме 2024 елга 139,1 млрд сум тәшкил итте, «тискәре трансфертлар» түләү йөкләмәләрен исәпкә алып, чыгымнар күләме шулай ук 139,1 млрд сум.

Шул рәвешле, 2024 елга бюджетлар формалашуның сценарий шартларында җирле бюджетлар дефицитсыз булып тора.